ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

1.2007





**Минтимер ШӘЙМИЕВ**
*Татарстан Президенты*

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

**1**

**(1011)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Юллар текәрәк, еллар җаваплырак. 5

«Без бердәм булырга тиешбез...» (Татарстан Президенты М. ШӘЙМИЕВ тарафыннан төрле елларда әйтелгән кайбер фикерләр) 8

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гөлнур ЯКУПОВА. Күперләр. *Роман.* 17
ЗӨЛФӘТ. Борынгы яшен. *Шигырьләр.* 56
Фәнис ЯРУЛЛИН. Кыйбласызлар. *Повесть.* 62
Разил ВӘЛИЕВ. «Бер алманы бишкә бүләек». *(Төрле еллардан җырлар.)* 76
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Үзем хөкем итәм. *Роман.* 82
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Мәңгелек җирсу. *Шигырьләр.* 113
Камил КӘРИМОВ. Сунар вакыты. *Хикәя.* 116

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Рафис КОРБАН. Куян эз югалта... *Шигырьләр.* 124

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Алинә БИКМУЛЛИНА. Күзләр байлык белән томаланган... *Шигырьләр.* 126
Сиринә МӨХӘММӘТҖАНОВА. Мин — хыялый җир кызы. *Шигырьләр.* 127
Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА. Бәхет. *Шигырьләр.* 129

ПУБЛИЦИСТИКА

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. 131

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Нурфия ЮСУПОВА. Тылсымлы сүз остасы. 137
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Дулкын биеклеге. 143
Роберт МИҢНУЛЛИН. Дөрес яшисең, Рафис Корбан! 151

ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 157
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. 158

ХӘТЕР

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. Көндәлек сәхифәләре. 164
Әзһәр ШАКИРОВ. Язмыш һәм узмыш. *(Артист язмалары)* 172

ТАРИХ

Сәйдәш ГАРИФУЛЛИН. Төрки халыклар йолдызлыгы. 176

Бер сорауга — бер җавап. 180
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. 182
«Казан утлары» архивыннан. 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово гл. редактора»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Дороги все круче, года все ответственней».
«Мы должны быть сплочены». Мысли, высказанные Президентом Республики Татарстан М. ШАЙМИЕВЫМ в разные годы.
«Проза и поэзия»: романы Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Судить буду я!» (окончание), Г. ЯКУПОВОЙ «Мосты», повесть Ф. ЯРУЛЛИНА «Непутевые», рассказ К. КАРИМОВА «Охотничий сезон», стихи ЗУЛЬФАТА, Р. ВАЛЕЕВА, И. ГИЛЯЗОВА, Р. КУРБАН.
«Творчество молодых»: стихи А. БИКМУЛЛИНОЙ, С. МУХАМЕТЗЯНОВОЙ, Л. ФАТХУТДИНОВОЙ.
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа» (продолжение).
«Литературная критика»: статьи Н. ЮСУПОВОЙ о творчестве поэта Зульфата; Р. ЗАЙДУЛЛЫ о творчестве поэта Р. Валеева; Р. МИННУЛЛИНА о творчестве поэта Р. Курбан.
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации»: (продолжение); Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
«Память»: М. МАГДЕЕВ. «Страницы из дневника».
«К 100-летию татарского театра»: воспоминания А. ШАКИРОВА.
«История»: С. ГАРИФУЛЛИН. «Звезда тюркских народов».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимний пейзаж; поэтесса Илсияр ИКСАНОВА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Editor's words»: R. FAYZILLIN. «Roads steeper, years more responsible».
«We should be rallied». Ideas stated by President of Tatarstan Republic M. SHAYMIEV in different years.
«Prose and poetry»: novels by R. MIR-HAYDAROV «I'll judge!» (ending), G. YAKUPOVA «Bridges», story by F. YARULLIN «Bad lots», story by K. KARIMOV «Hunting season», verses by ZULFAT, R. VALEEV, I. GILAZOV, R. KURBAN.
«Youth's creativity»: verses by A. BIKMULLINA, S. MUHAMETZYANOVA, L. FATHUTDINOVA.
«Publicism»: R. HAKIM. «Metamorphoses of spirit» (continuation).
«Literary criticism»: articles: N. YUSUPOVA about creativity of poet Zulfat; R. ZAYDULLA about creativity of poet R. Valeev; R. MINNULLIN. about creativity of poet R. Kurban.
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation»: (continuation); F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
«Memory»: M. MAGDEEV. «Pages from diary».
«To 100th anniversary of Tatar theatre»: memoirs of A. SHAKIROV.
«History»: S. GARIFULLIN. «Star of Turkic peoples».
Pages from «Tatar encyclopedia».
From photo archive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Winter landscape; poetess Ilsiyar IKSANOVA.


* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.12.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3—1194 Тираж 6032.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2


© «Казан утлары», 2007 ел.

# ЮЛЛАР ТЕКӘРӘК, ЕЛЛАР ҖАВАПЛЫРАК

Вакыт дигәннәренең асылын аңлап бетерергә адәм баласының вакыты житми шикелле. Шулай да, талкып, изеп, киптереп дигәндәй, Вакытның үзе аша үтүен бөтен күзәнәкләре белән сизә, тоя, белә терек иясе! Әле кайчан гына милади исәп белән яңа гасырга чыгабыз дип мәш килеп йөргән идек. Кичә генә булган шикелле. Инде килеп алты елы үткән дә киткән! Жиденчесенә аяк басабыз. Уйландыра. Яшәгән саен һәр үткән елның мәгънәсе күпмедер үзгәрә бара. Еллары да тизрәк уза шикелле. Шулай да, ел кадәр ел эчендә, телибезме, юкмы, биниһая вакыйгаларның шаһитлары без. Гомумдөнья хәлләре турында һәркемнеке кебек минем дә кайбер уйлануларым бар барын, әмма алар турында зурдан кубып сөйләргә теләмим, мөгаен булдыра да алмам, шуңа күрә, үзебезнең Идел-йорттагы вазгыят турында уй-фикерләремнең беразы белән уртаклашып узмакчымын.

2006 ел — Казанның 1000 еллыгыннан соң үткән беренче ел булды. Казан юбилеен матур итеп уздырып, дөньяның байтак ил-дәүләтләренә «Бу Кояш астында без дә бар!» дигәнне яңа бер мәртәбә сизелерлек итеп белгертә алдык. Ярап куйды бу бәйрәм. Төбендә татар файдасына, безнең файдага булды. Казан — Татарстанныкы гына түгел, бөтен татарныкы да бит. «Булдырабыз!» дидек. Һәм чыннан да абруйлы билгеле бер биеклек алынды. Ә биеклектән төшәсе килми ул! Минемчә, үткән 2006 ел — биектә калу яки калырга тырышу елы булды. Ә югарыракка меңү яки меңәргә омтылыш булдымы соң, халык тормышы яхшырдымы, милли яңарыш көчәйдеме, диярләр. Бу катгый сорауларга төгәл кистереп әйтү кыен. Җаваптан бигрәк, күңелгә антоним мәгънәле уйлар килә. Җәмгыятьтә байлык арта, әхлак кими. Шәһәр үсә, авыл кечерәя. Татарстанның дәрәҗәсе үсә, дибез, ә Үзәк белән Шартнамә һаман яңартылмый («тарихи бу бергәлек» галәмәте). Мәчетләр төзелә тора, иманлылар бик артып тормый. Тел үсеше турында сүз сөйләү күбәя, чынлыкта татарча сөйләшүчеләр кими бара. Татарстан телевидениесенең техник мөмкинлекләре артты, ә радиобыз стуруктур яктан үзгәреп бетте, бай традицияләр җимерелде... Әйтелгәннәр гомумирәк яңгыраса да, үткән елга бик хас алар. Ярый, каршылыклы фикерләрне тәкърарлау житеп торыр. Ә биеклеккә килгәндә, үткән ел Казанның яңа үрләр яулау юнәлешендә тагын бер ыргымы булды әле! Башкалабыз тагын берничә елдан узачак Бөтендөнья яшьләре Универсиадасын үткәрү өчен реаль кандидат шәһәргә әверелде. Әгәр, барып чыкса, безнең халыкара дәрәҗә, һичшиксез, тагын да үсәчәк!

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Указы белән 2006 ел Республикада әдәбият һәм сәнгать елы шигаре астында үтте. Бу уңайдан, хәтерегездәдер, әдәбият һәм сәнгатькә бүгенге көндәге мөнәсәбәт, киләчәктә башкарылырга тиешле эшләр турында журналыбызда (2006 ел, 3 нче сан) Татарстан Президентының һәм баш мөхәррирнең тәфсилле әңгәмәсе басылып чыкты. Анда күтәрелгән мәсьәләләр, табигый ки, күпләрнең игътибарын җәлеп итте, уңай чишелешләргә ымсындырды. Әдәбият һәм сәнгать елының тарихына калырлык нинди сәхифәләрен атап китә алабыз соң? Иң әүвәл ике бөек шәхес — Г. Тукай һәм М. Җәлил юбилейлары күңелгә килә. Берсенең 120, икенчесенең 100 еллыклары. Татарстанда гына түгел, бөтенроссиядә һәм чит илләрдә дә югары дәрәҗәдә һәм масштаблы үтте ул

тантаналар. Элегрәк үткән юбилейлардан үзгә уңай гамәлләр булды. Әйтик, Петербургта Тукайга һәйкәл куелды, Уральскида музей ачылды, шагыйрьгә багышлап язылган яңа опера сәхнә күрде, рәссамнарыбыз хезмәтләреннән тупланган затлы альбом чыгарылды... Мәскәүдә М. Җәлилгә һәйкәл кую мәсьәләсе хәл ителеп килә. Татар халкының абруен күтәрүгә хезмәт итүче бу ике бөекнең варислары — бүгенге язучылар өчен аеруча горурлык: һәйкәлләрдә басып торучылар шагыйрь-әдипләр бит! Дәвамнары булырга тиешле бөек биеклекләр!

Музыка өлкәсенә күз салыйк. Мәшһүр композитор һәм җырчы С. Садыйкованың 100 еллыгы халыкчан көйләрнең онытылмас бәйрәме булып узды. Дөньякүләм билгеле икенче бер композиторыбыз С. Гобәйдуллинаның 75 яшьлеге уңаеннан аның исемендәге халыкара пианистлар конкурсы, А. Ключаревның 100 еллыгына багышланган концерт зур уңыш белән үтте. Р. Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале елдан-ел камилләшеп, үткән ел яңа биеклеккә күтәрелде. Сентябрь аенда «Алтын мөнбәр» дип аталган мөселман киносы халыкара фестиваленең янәдән Казанда зур күтәренкелек белән үтүе дә 2006 елның күркәм сәхифәсе саналырга лаек. Җөмләдән, үткән елда Камал театры коллективы Лондонга барып спектакльләр куеп кайтты. Әгәр Г. Камалга «бер гасырдан соң синең «Беренче театр»ың Бөекбритания башкаласында уйналачак» дигән булсалар, ул һич ышанмас иде. Татар театры оешуга 100 ел тулу уңаеннан, гомумән, бик күп эшләр башкарылды. Театр юбилее тантаналары быел да дәвам итәчәк әле. Рәссамнар дөньясында да җанлылык кимемәде, кызыклы-кызыклы истәлекләрчә күргәзмәләр оештырылды. Музейчыларыбызның үткән ел башкарган эшләре аеруча мактаулы. «Татар халкы һәм Татарстан дәүләтчелеге тарихы» музее ачылу гына да ни тора! Казан милли мәдәният үзәгенең 15 еллыгы билгеләп үтелде. Бу Үзәкнең әдәбият-сәнгать өчен никадәр әһәмиятле икәнлеге тагын бер мәртәбә тәгъдир ителде. Милли үзәнны үстерүгә хезмәт иткән йөзләгән кичәләр үтте анда. Китап басу, нәшрият өлкәсендә дә уңышларыбыз бар. Халыкара ярминкәләргә алып барырлык китаплар басыла (кайберләре призлы урыннар, халыкара дипломнар алалар), бүтән республика наширларын көнләштереп, классик әдипләребезнең күптомлыклары чыгу дәвам итә. Ата-бабаларыбыздан күркәм мирас булып калган Сабантуй 2006 елда тагын да киңрәк колач алып, дөнья иңләп бәйрәм ителде. Ул сабантуйлар һәркайда әдәбият-сәнгать вәкилләренең актив катнашында уздырыла. Мисал өчен генә әйтеп үтим: минем үземә дә, Татарстандагылардан тыш, Мәскәү, Истанбул сабантуйларында катнашырга туры килде.

Язучыларыбыз өчен әдәбият һәм сәнгать елының иң мәгънәле сәхифәсе — «Казан утлары»ның меңенче саны чыгу булгандыр. Үз әсәрләребез басыла торган төп журналыбыз бит. Язучылар өчен генә түгел, татар мәдәниятына бәйләнеше бар дип исәпләгән һәр зыялы кеше өчен чыннан да куанычлы вакыйга. Шунысын да искәртү кирәк: меңенче санга ирешкән бүтән әдәби журнал илдә юк. Журналның бу бәйрәме матбугат битләрендә, әдәбият көннәрендә, иҗат кичәләрендә һәм бүтән әдәби чараларда ел буе диярлек дәвам итте. 2007 елның башында «Казан утлары» бәйрәме Мәскәүдә дә узачак. Яңа елга аяк баскан көннәрдә журналыбыз елъязмасы саналырлык «Сүнмәс утлар балкышы» дигән зур күләмле хезмәт дөнья күрде. Бу китапта мең санлы хәзинәдән сайлап алынган әдәби әсәрләр, мәкаләләр, гыйльми язмалар, публицистик очерклар, истәлекләр, документлар тупланган. Күп көч сарыф ителеп, үзенчәлекле антология сыйфатында чыккан бу китапны тиздән укучыларыбызга да ирешер дип уйлыйм.

Әле саналган эш-вакыйгалар, (аларны казанышлар исемлеге дияргә дә ярыйдыр) турында кемнәрдер, «бу юбилейлар, гастрольләр, тантаналар әдәбият-сәнгать елы игълан ителмәсә дә барыбер үтәр иде бит» дип тә куяр, һәм өлешчә хаклы да булыр. Әйе, байтагы күнегелгәнчә үз агымы белән дә үтәр иде. Тик ничек һәм нинди дәрәҗәдә бит? Минемчә, бик күп әдәби-мәдәни чараларның әдәбият һәм сәнгать елы шигаре астында үтүе һәм бу эшләрнең байтагына Татарстан Президентының турыдан-туры катнашуы уңай нәтиҗәләр бирде. Әлбәттә, аерым бер елга «тамга салып» кына дәверләр буена җыелып килгән мәсьәләләрне хәл итү мөмкин түгел. Максатлар югарырак булган саен, барыр юллар текәрәк, еллар җаваплырак, таләпләр

кискенрәк. Шәхсән минем үземне (күпләрне дә дип уйлыйм) халкыбыз рухына кагылышлы мирасны саклау проблемалары борчый. Үткәндәге мирасын барлый, кадерле белмәгән халыкның киләчәге өметсез. Бу җәһәттән шөбһәле уйларга этәргән мисаллар байтак. Шул ук Казан мисалына әйләнеп кайтыйк. Мең еллык юбилейга әзерлек чорында (әлбәттә, ана кадәр дә) шәһәр үзәгендәге күпме тарихи биналар, корылмалар юк ителде. Өстәге түрәләрнең берсе «Казанны Явыз Иван бер җимергән булса, икенче тапкыр шәһәр мэры җимерде» дип тикмәгә генә әйтмәгәндер. Биналарның кайберләрен генә булса да реставрацияләп яңартырга кирәк булгандыр да бит! Әллә никадәр акча түксән дә, хәзер инде аларны кайтарып булмый... Казанда чагыштырмача болай да аз сакланган татар тарихы ядкарьләренә аеруча нык зыян килде. Болак арты һәм бистә якларын истә тотып әйтәм моны. Безнең өчен үтә дә кадерле, әлегә исән кайбер биналарның язмышы да ачык түгел. Әйтик, «Болгар» номерлары, Матбугат йорты... Икенчесенең язмышы аеруча борчый. Бу хакта язучыларыбыз матбугатта мөрәҗәгать белән дә чыгып карадылар. Соңгы 70-80 ел эчендә татарның (гомумән, республиканың) рухи учагы, әдәбият-сәнгать — тарихи-сәясәт тармакларын халык белән тоташтырган төп үзәк булып килде бит ул! Бу йорттан нәшриятларны, редакцияләрне, китапка бәйле булган бүтән оешмаларны чыгаргач, бина кемнәр кулына кала да, киләчәктә аңа кемнәр хуҗа булачак? Без белмибез. Белүчеләр бардыр, бәлки, әйтеп аңлатырлар? Әдәби мирас өлкәсендә дә хуҗасызлыкка, таркаулыкка мисаллар җитәрлек. Әйтик, татар теләндә иҗат иткән М. Гафури еллар уза-уза башкорт әдәбияты классигына әверелде. Аннан шактый дәвер элегрәк яшәгән Акмулланы элегрәк татар, башкорт, казакъ халыкларының уртак шагыйре санап йөри идек. Үзебезнең ваемсызлыгыбыз, бигрәк тә галимнәребезнең ваемсызлыгы, битарафлыгы аркасында ул да бездән ерагая бара... Без еш кына үзебезне мең еллык әдәби мирас вәкилләре дип һаваланырга яратабыз. Мираска, варислыкка хакың бар икән, аңа хуҗа булырга да кирәктер. Хуҗа була белгәннең генә абруе зур була.

Халыкта «чебешне көз көне санныйлар» дисәләр, без газет-журналларга бәйле кешеләр, үзебезнең «чебешләрне», ягъни әбүнәчеләр санын яңа ел алдыннан саныйбыз. Соңгы елларда, сер түгел, татар матбугаты тираж ягыннан гел үсү ягына бармый. Матбугат — телне, аның аша милли рухына саклаучы төп көчләрнең берсе. Икенчеләп әйтсәк, тиражлар күрсәткече — халыкның үзаңы үсеше (яки төшүе) күрсәткече ул. Укучы дигән сүз, Горький әйтмешли, горур яңгырый! Уку ул — ләззәт тә, хезмәт тә, хәтта иҗат та. Компьютерлашу (глобальләшүнең бер баскычы) — халыкның рухи үсешен тәэмин итүгә һич кенә дә гарантия түгел әле ул. Милли матбугатны таратуның мөһимлеген халык белән эшли һәм идарә итә торган җитәкчеләр тирән аңларга тиешләр дип уйлыйм мин.


Һәр язучының үткән ел турында үз уйлары, киләчәккә үз планнары бардыр. Язучылык хезмәте беркайчан да җиңел булмады, хәзерге заманда елдан-ел авырая гына бара ул. Язучылык эше — вөҗдан эше. Максатсыз һәм имансыз иҗат итүне күңел кабул итми. Минемчә, каләмдәшләребезнең күбесе моны яхшы аңлый. Кайчак уйлап куясың: әгәр язучыларыбыз булмаса, безнең милли халәт шактый түшенке, телебезнең көче күпкә ким булыр иде. Шөкер, дисталәгән менә дигән язучыбыз бар (аларның әсәрләре, һичшиксез, зуррак тираж белән чыгып, күбрәк сандагы укучылар игътибарына лаек). Булсынга дип эшли торган оешмабыз бар. Мөстәкыйльлек өчен көрәш елларының бер нәтиҗәсе буларак, хөр фикер йөртә торган яшь талантлар үсеп килә. Киләчәктә рухи мәйданыбыз киң булсын дисәк, туган телебезнең сау булуы шарт. Ә ул көрәшеп яклауга, саклауга мохтаҗ... Бу көрәштә безнең өлеш — кешеләргә кирәкле, аларга ышаныч бирерлек камил әсәрләр иҗат итү. Әгәр безнең әсәрләргә ихтыяҗ бетсә, язып торуның мәгънәсе юк. Шуна күрә дә начар язарга хакыбыз юк! Заманы шундый.

Яңа елда һәммәбезгә хәерле гамәлләр юлдаш булсын!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре*

# «БЕЗ БЕРДӘМ БУЛЫРГА ТИЕШБЕЗ...»

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ М. ШӘЙМИЕВ ТАРАФЫННАН ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДА ӘЙТЕЛГӘН КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР



*Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 70 яшь тулды. Ул 40 елдан артык хуҗалык һәм дәүләт эшләрендә җитәкче вазифалар башкарды, 1991 елдан алып—Татарстан Республикасы Президенты. Илбашы булып эшләү елларында М. Шәймиев халыкара масштабтагы абруйлы дәүләт эшлеклесенә әверелде. Татарстанның соңгы дәвердәге сәяси, икътисади, мәдәни тормышы турыдан-туры аның исеме белән бәйле. Үз тарихындагы иң зур мөстәкыйльлеккә дә республика нәкъ менә ул җитәкчелек иткән чорда иреште.*

*Гомере ил язмышыннан аерылгысыз Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевне юбилее белән котлыйбыз, исәнлек-саулык, ил-көн йөген иргетләрчә тартырлык көч вә дәрман телибез.*

● Үз заманының күренекле идеологы һәм сәясәтчесе буларак, Мөхәммәдьяр, әлбәттә, татар халкының мөстәкыйль дәүләт булып яшәвен теләгән. Ләкин ул чорда татар җәмгыяте бу мәсьәләдә бердәм фикердә тормый. Казан ханлыгының соңгы унъеллыклары дәвамында идарә даирәсе кешеләре ике төркемгә, шартлы итеп әйтсәк, ике партиягә бүленәләр һәм үзара берөзлексез көрәш алып баралар. Бер партия Казан ханлыгының тулы бәйсезлеген, алга таба да мөстәкыйль үсешен яклый. Икенче партия исә илнең киләчәген тышкы көчләргә ярашып—буйсынып яшәүдә күрә. Ахырда бу низаг-каршылыклар, бердәмлек булмау—Казан ханлыгының җимерелүенә, татар халкының дәүләтчелеге югалуга китерә.

Мөхәммәдьяр сарай шагыйре, сарай җырчысы булмаган. Ул үзен бәйсез тоткан, горур булган. Шул ук «Нуры содур» поэмасында, утопия жанрына хас сәнгати ысуллардан файдаланып, ул, хыялындагы гадел җәмгыятьне тасвирлау белән генә канәгатьләнмичә, үз заманына да, үзе яшәгән мохиткә дә тәнкыйть күзлеге аша карый. Хәтта поэманың Казан ханы, бәйсезлек яклы Сәхибгәрәй заказы белән язылуы да шагыйрьне бу адымнан туктатып кына калмый. Бу факт, бер яктан, Мөхәммәдьярның Казан тормышында дәүләткүләм дәрәҗәле, абруйлы шәхес булуын күрсәтә, икенче яктан, аның ил, халык гамен, ихтыяҗларын тирәнтен аңлый белгән, алар турында кайгыртуны шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куйган намуслы сәясәтче, дәүләт эшлеклесе булуы хакында да сөйли. «Нуры содур» поэмасында дин өчен, азатлык, гаделлек өчен алып барылган сугышны—газаватны мактау һич тә очраклы хәл түгел. Казан сугышында камалып калган милләттәшләребезнең батырларча көрәшүләрен искә төшерсәк, кем белә, бәлки, аларга нәкъ менә Мөхәммәдьярның ялкынлы шигъри юллары дәрт, көч биреп торгандыр?

*Мөхәммәдьярның 500 еллык юбилей кичәсендә ясаган чыгышыннан. 28 август, 1997 ел.*

● Татар халкы кебек буталчыклы тарихлы башка халык юктыр, мөгаен. Россиядә татарлар сан ягыннан икенче урында торса да, аларның меңьеллык бай тарихи мәдәниятен хәтта Россиядә дә белмиләр. Ә менә кайбер публицистлар һәм сәясәтчеләр вакыт-вакыт «татар-монголлар изүе», «татар яулары», «татар ясагы» дип татарларга карата тискәре караш уятып торалар. Тарих дәреслекләрендә татарларга цивилизацияле җәмгыятькә ят булган сыйфатлар тагыла, ә ул дәреслекләр буенча Россия балалары тарих фәне өйрәнәләр бит.

Россия тарихында татарлар уйнаган рольгә башка карашлар да бар, әлбәттә. Бөек галим һәм гражданин Лев Николаевич Гумилев «татар-монгол изүе» дигән нәрсәне халыкларның үзара мәнфәгати кызыксынуы, тартылуы нигезендә туган союз дип атый: русларга татар гаскәрләре көнбатыш чикләрне сакларга кирәк була. Ә русларның иминлеге өчен татарлар җыйган ясакны («десятина») һич тә зур дип әйтеп булмый. Ләкин Л. Н. Гумилев кебек үзгә, гадәти булмаган фикер әйтергә батырчылык иткән тарихчылар бик сирәк шул.

Тарихны бизәп күрсәтүнең бер кирәге юк. Теләсә кайсы чорда, теләсә кайсы халык тарихында күркәм сыйфатлар да, рәхимсезлек тә, күтәрелеш һәм түбәнгә тәгәрәү очраклары табарга мөмкин.

Бүген исә тарихта бүтән нәрсәләрне—гакыл казанышларын, сәүдә элемтәләрен, мәдәниятләрнең үзара баюын күрә белү мөһим.

*«Родина» журналында басылган, «Халыкның бүгенгесе һәм киләчәге аның тарихында» дигән мәкаләдән. N 3-4, февраль, 1997 ел.*

● Һәр халык, һәр милләтнең үсешендә күчеш-күтәрелеш чоры була. Андый чакта ул үзенең олы шәхесләренә, фикер ияләренә мөрәҗәгать итә, аларның мирасыннан акыллы киңәш эзли, кылган гамәлләрен, уй-фикерләрен чагыштыра, шуннан чыгып, ялгыш-хаталардан арына.

Без дә бүген шундый күчеш-күтәрелеш чорын кичерәбез. Гасыр башында—җәмгыятьнең кискен борылыш чорында—Тукайны борчыган сораулар бүген безне дә борчый, алар бүген дә актуаль. Менә ни өчен без бүген тагын Тукайга, аның үлемсез мирасына мөрәҗәгать итәбез. Тукай иҗатында—аның шигырьләрендә, проза әсәрләрендә бүгенге көннең күп сорауларына җавап табып була. Шуңа күрә Тукай безгә һәрчак бик якын.

Моны раслау өчен минем икенче бер олы шәхесебез Гаяз Исхакый фикеренә таянасым килә. Моннан 81 ел элек «Ил» газетасында аның «Тукай мәрхүм» дигән мәкаләсе басылып чыга. Ул бөек шагыйрьнең вафатына ике ел тулу уңаеннан язылган. Анда Исхакый Тукайның үлеме татар милләте өчен бик зур югалту икәнлеген, шагыйрьнең мирасы—халкыбызның мәдәни, милли тормышының нигезенә әйләнәчәген әйтә. «Көннән-көн... Тукай мәрхүмнең милли рухы бөтен татар яшьләренең җанын, рухын ашлый барган кебек, көн үткән саен аның кыйммәте дә күтәреләчәктер. Аның татар милләтенә хезмәте, әйтеп калдырган байлыгы меңнәр, йөзәр меңнәр мәртәбә артачактыр»,—дип яза Гаяз Исхакый.

Искиткеч алдан күрүчәнлек белән сугарылган бу сүзләрнең хаклыгына без бүген тагын бер кат инанабыз.

Бөек шагыйребез иҗатында—Ватанга, халыкка хезмәт итү—ирек, бәхет төшенчәләреннән аерылгысыз булды. Ул үзенең шәхси бәхетен дә шунда күрде. Тукайның:

*Бәхетлемен шушы халдән, бүтән бер хәл дә көтмимен,*
*Шушы юлдан ризамын, башка төрле юл да тотмыймын,*

—дигән сүзләре шагыйрь рухының тарихи оптимизмын һәр яңа буынга раслап тора.

Без бүген бирегә халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайны олыларга җыелдык. Әмма мин шунысын да әйтеп үтү урынлы булыр дип саныйм: бүген Тукайны олылау татар милләтен дөньяның башка халыклары арасында тигез хокуклы, жит-

леккән, дәрәҗәле һәм мәртәбәле милләт итеп таныту, раслату өчен кирәк. Чөнки һәр милләт турында барыннан да элек аның әнә шундый олы шәхесләрен истә тотып фикер йөртәләр. Без бүген теләсә нинди трибунадан: «Безнең Кол Галиебез, Мәрҗаниебез, Тукаебыз, Җәлилебез бар»,—дип горурланып әйтә алабыз, һәм бу шәхесләрнең исемнәре безгә дөньякүләм юл яру өчен хезмәт итә.

*Г. Тукайның тууына 110 ел тулуга багышланган тантаналы җыелышта ясаган чыгышыннан. 26 апрель, 1996 ел.*

● Базар икътисады массакүләм матбугат чараларын авыр хәлгә куйды. Газеталарның тиражы, табышлары кимеде. Газета-журналларны, китапларны илнең башка төбәкләренә тарату бик нык кыенлашты. Бу татарларга аеруча нык кагыла. Әлеге проблеманы хәл итүне үтенгән хатлар безгә бик күп килә. Җаваплылык монда республикабыз хөкүмәте өстенә дә, Россия хөкүмәте өстенә дә төшә. Шуның белән бергә мин татарлар тупланып яшәгән төбәкләргә газета-журналлар, китаплар, аудио-, видеопрограммалар илтеп тарату өчен коммерция оешмалары төзү дә максатка ярашлы хәл булыр иде дип уйлыйм.

Хәзер татарлар тупланып яшәгән күп кенә төбәкләрдә ана телендә эшләүче радиостанцияләр ачылды. Республикада да үз телебездә кыска дулкынлы станция эшли башлады. Шулай итеп, халкыбызның кыска дулкынлы радиостанциясен булдыру теләге бүген тормышка ашты. Сез кайтып кергәндә инде татар радиосы сөйләп торачак.

Әмма мәгълүмат чараларының иң үтемлесе—телевидение. Хәзерге техник яңалыклар ана телендә Җир иярченнәре аша махсус телевидение программасы оештыру мөмкинлеге бирә. Минем уемча, бу Татарстан хөкүмәтенең һәм татар эшмәкәрләренең уртак бурычына әверелергә тиеш.

Татарның рухи дөньясы һәрвакыт дин белән тыгыз бәйле булган. Соңгы елларда күп мәчетләр салына. Шунысы кызганыч: ислам әһелләре арасында бүгенгә бердәмлек юк, хәзер мөселман мәхәлләләре күп мөфтиятләргә берләшкән. Монда да проблемалар аз түгел һәм аларны уртак тырышлык белән хәл итәргә кирәк. Минем карашымча, Кремльдә салына торган Кол Шәриф мәчете мөселман руханилар һәм дин тотучыларның бердәмлек символына әверелергә тиеш.

*II Бөтендөнья татар конгрессында ясаган чыгыштан. 29 август, 1997 ел.*

● Республикабыз матбугатының дистәләрчә еллар буена тупланган матур традицияләре бар. Төрле-төрле модалы агымнарга кушылып, ул традицияләрне югалтмаска, саклап калырга кирәк. Соңгы елларда массакүләм матбугат чараларында фикер төрлелеге—плюрализм тамыр җәйде. Цензура бетте. Бу бик шәп нәрсә. Ләкин онытмыйк—шуның белән бергә журналист эшендә җаваплылык та, эчке цензура—шәхси позициянең объективлыгы да зарур таләпкә әйләнде бит. Дәүләт эшчәнлегенә, дәүләт эшлеклеләренә аеруча зур игътибарга без күнегеп киләбез инде, тик ул игътибар нигезендә бары тик җәмгыять мәнфәгате ятарга тиеш, башка берни түгел. Менә шунысы бик мөһим.

Матбугат бүгенге чорда күп нәрсә эшли ала. Тормышыбызны объектив яктырту—матбугатның төп бурычы.

Газета-журнал редакцияләре эзләнәләр, үз басмаларын кызыклырак итү өчен тырышалар. Белүемчә, «Татарстан» журналының да яңа концепциясе эшләнә. Димәк, киләчәктә ул күпмилләтле Татарстан халкы тормышын тагын да калкурак чагылдыра алыр, республиканы дөнья күләмендә югарырак баскычка күтәрергә ярдәм итәр.

*«Татарстан» журналына биргән интервьюдан. N 4, 1998 ел.*

● Әмирхан Еникигә карата мондый караш, мондый ихтирам, мондый зурлау ана 90 яшь тулган өчен генә түгел бит. Ана булган ихтирам, ул күпме яши, шуна бәрабәр рәвештә көннән-көн артып килә. Ни өчен шулай? Моның сәбәпләре, уйлавымча, берничәдер, юктан гына бар булмый торгандыр.

Мин аның соңгы әсәрләренең берсен укып чыккач, шундый фикергә килдем: ул бик ныклы нәселнең дәвамы. Аның токымы көчле: заманында татар язмышын кичергән күп кенә ныклы нәселләр кебек, аның нәселе дә Тамбов, Рязань, Пенза якларыннан, яшәргә чама калмагач, әле морзалар була торып та, Башкортстан далаларына күчеп киткән.



*Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәгә кул кую вакыты. Мәскәү, Кремль, 15 февраль, 1994 ел.*

Татар халкын үзе теләмәгәндә беркайчан да, беркая да күчереп булмый. Димәк, алар инде күчәргә мәҗбүр булган икән, тормыш чыгырыннан чыккан, түземлек чыгырыннан чыккан булгандыр дип саныйм. Шул вакыттан ныклы Еникиләр нәселе, шул ук Терегуловлар нәселе, Акчуриннар нәселе кебек, дөньяга таралып калган.

*Ә. Еникигә 90 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсендә ясаган чыгыштан. 5 март, 1999 ел.*

● Кеше—җәмгыятьтә хакимлек итүче иҗтимагый мөнәсәбәтләр җимеше. Телисеңме, юкмы, бу шулай. Кешене җәмгыять тәрбияли. Бүгенге җәмгыятьне ничек кенә каһәрләмә, ул яши. Димәк, тормыш дәвам итә. Ә сәнгать, әдәбият тормышны чагылдырырга тиеш. Нишләп соң безнең күп кенә язучыларыбыз аптырабрак калды әле? Хәзерге каршылыклы, көрәшле тормышны чагылдырган олы күләмле әсәрләр күп дип әйтеп булмый бит.

Бу уңайдан шунысын да әйтим: кайбер язучылар иҗатны тормыш кимчелекләрен кабат-кабат фаш итү белән алыштырды, шуның белән канәгатьләнә. Дөресен әйткәндә, олы күләмле, яшәешнең бик күп, катлы-катлы проблемаларын чагылдырган әсәрләр менә шушындый катлаулы чорларда туарга тиеш сыман тоела.

Шунысы кызганыч: бүгенге көндә миһербансызлык, эгоизм тәрбияләүче, тарихи, әхлакый тамырларыбызга балта чабучы, кеше мәнфәгатен, рухи халәтен шаблонга салучы арзан мәдәният киң тарала бара. Ә безнең әдипләребезнең күп кенә әсәрләренә мона каршы торырлык, нык фәлсәфи нигез җитешми.

Төптән уйлаганда, бүгенге чор—мона кадәр күрелмәгән гаҗәеп чор. Без әле мөстәкыйль үсешебезнең башлангыч этабында гына торабыз. Алда безне бик зур эшләр көтә. Зарланып торудан файда юк, без эшлисен башка эшләмәс. Шушы бөек омтылышны һәрьяклап уйлап, уртак уй, уртак теләк һәм уртак эш белән тормышка ашырырга тиешбез.

Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтим: идеологик басым беткәч, иҗат мөмкинлекләре киңәйде. Беркем сезне, ник тегесен тегеләй, монысын болай яздың, дип тинтерәтми. Ләкин моның негатив ягы да күренә шикелле. Бүгенге сәхнәдән,

экраннардан, концерт мәйданнарыннан яңгыраган җырларны гына тыңлап карагыз. Аларның күпчелегендә төче мәхәббәт, яисә сай хисләр, төшенкелек, язмыштан зар елау ярылып ята. Шуңа күрә алар йөрәккә сеңми, тиз онытыла, күңелдә канәгатьсезлек тудыра.

Җыр нигезендә көй белән шигырь ята. Нишләп соң безнең композиторларыбыз начар шигырь белән килешә? Нишләп без мона юл куябыз? Мин монда административ күрәш ачыйк димим. Эстетик күрәшне, зәвык күрәшен ник онытабыз? Сәнгатьнең олы бер функциясе матурны матур итеп күрсәтү, аңа соклану уяту, ә начарны бетерүгә өндәү ләбаса!

Мин бу күрәшне һәрвакыттагыча иҗат интеллигенциясен әйдәп баручы каләм осталары житәкләргә тиеш дип саныйм.

*Татарстан язучыларының XIII съездында ясаган чыгыштан. 28 май, 1996 ел.*

● Сүз иреге—шәхес ирегенең, тулаем кеше ирегенең состав өлешләреннән берсе ул. Җәмгыятьне демократик үзгәртеп корулар башланган еллардан бирле без сезнең белән бергә башка кешеләр булып әвереллдек. Әйтик, менә мине алып карыйк. Гомер буена хакимияттә булдым бугай, ләкин мин үземне күңелемнән элеккедән күпкә иркенрәк тоям. Сез дә шулай дип ышанам. Бездән менә шушы эчке ирек тоемын тартып алырга маташып карагыз әле. Берни дә барып чыкмас. Аны беркем дә болай гына бирмәс. Ләкин, әгәр хокукларны чикләү, сүз иркен чикләү башлана калса, һәркем хакимият белән капма-каршы тора башлаячак. Без инде башка кешеләр булып әверелдек. Һәм кешеләр татыган ирек дәрәҗәсен инде алардан тартып ала алмыйсың.

*«Журналист» журналына биргән интервьюдан. 20 июнь, 2000 ел.*

● Татар халкы үз дәүләтчелеген торгызу хакында күп гасырлар буена хыялланды. X гасырдан башлап үз дәүләтчелегенә ия булган халык үз дәүләте хакында хыялланмаска мөмкин дә түгел иде.

1918 ел безнең төбәк өчен ин фаҗигале чор булды, чөнки башында Садри Максуди, Гаяз Исхакый кебек бөек сәяси эшлеклеләр һәм башка күп кенә сәяси лидерлар торган Милли Мәҗлес автономияле «Идел-Урал» штатын игълан итәргә җыенды. Дәүләтчелекне «астан», ул гына да түгел, большевиклар белән бәйләнмәгән көчләр ярдәмендә оештыру үрнәге күрсәтеп, «Идел-Урал» штаты проектын гамәлгә ашыру Россиядәге хәлләрне тамырдан үзгәртә алган булыр иде. Ләкин Совет хөкүмәте хәлнең бу рәвешле үсүен теләмәде һәм аны тәзүгә юл куймас өчен көч куллану ысулларыннан файдаланды. Бер ук вакытта ашыгыч рәвештә Татар-Башкорт республикасы проекты әзерләнде.

Урындагы күп кенә җитәкчеләр большевикларның милләтләрнең үзбилгеләнүгә хокуклары турындагы лозунгларына, Россия халыклары хокуклары Декларациясенә ихлас күңелдән ышандылар һәм җиң сызганып күптән көткән Татар-Башкорт республикасын төзү эшенә керештеләр. Ләкин 1919 елда ук инде РКП(б) Үзәк Комитеты Татар-Башкорт республикасы турында нигезләмәне юкка чыгарды, һәм шул ук елны Башкортстан АССР барлыкка килде. Ә 1920 елның 27 маенда ТАССРны төзү хакында Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы декреты басылып чыкты.

Революциягә кадәрге чор белән чагыштырганда татар халкы шулай да үзенең үсеше, аерым алганда мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә кайбер яңа мөмкинлекләр алды.

Шул ук вакытта автономиянең статусы баштан ук союздаш республиканыкыннан аерылып тора иде. Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты әгъзасы булган чакта М. Солтангалиев автономияле республикаларның хокукын чикләү

сәясәтенә каршы торды. Советларның X Бөтенроссия съезды, РКП(б)ның XII съезды трибунасыннан чыгыш ясаганда, ул автономияләрнен Союзга тигез хокуклы субъектлар сыйфатында керүен таләп итте һәм моның өчен партия сафларыннан чыгарылды, барлык вазифаларыннан азат ителде һәм соңрак репрессияләнде.

Сүздә үзбилгеләнү нигезендә аларның мәдәниятен, телләрен, дәүләтчелеген үстерүгә вәгъдә итеп, ә чынлыкта боларның барысына да аяк чалып, большевиклар Россия халыклары белән мәкерле уен уйнадылар. Шулай да ТАССР җитәкчелеге 1936 елда, СССРның яңа Конституциясе проекты тикшерелгән вакытта, республиканың статусын күтәрү мәсьәләсен кабат куйды. Ләкин бу юлы да тәкъдим Сталин тарафыннан кире кагылды, юлбашчы моны республиканың тышкы чикләре булмау белән аңлатты.



*М. Шәймиев Лаешта Г. Державин һәйкәлен ачу тантанасында. Июль, 2003 ел.*

50—60 нчы елларда милли зыялыларның күп кенә вәкилләре татар халкының мәдәниятен, бигрәк тә куллану даирәсе кискен рәвештә тарайган татар телен торгызу өчен актив тырышлык күрсәтә башладылар. Партия җыелышларында, иҗади очрашуларда, мөрәҗәгатьләрдә, югары даирәләргә юлланган хатларда зыялылар һәм җәмәгатьчелек вәкилләре Татарстан автономияле республикасының статусы кысылуы хакында ачыктан-ачык сөйләделәр. Бу мәсьәлә 1964 елда һәм 1977 елда СССР Конституциясе проектларын тикшерү барышында аеруча кискен куелды.

Ләкин КПССның гомуми сәясәте милли мәдәниятләргә ярдәм итүне күздә тотмады, ә милләтләрне якынайтуга һәм кушуга юнәлдерелгән иде. Шуның аркасында без бик тә аяныч нәтиҗәләргә килдек, республиканың башкаласы Казанда бер генә татар мәктәбе дә калмады, татар телендәге барлык басмаларга чик билгеләнде, радио һәм телевидение тапшырулары фәкать сүз өчен генә калды. Татар телен саклау мәсьәләсен тикшерү милләтчелек дип бәяләнде, ә Алтын Урданы һәм Казан ханлыгын өйрәнү бөтенләй тыелды. Мең елдан артык тарихка ия булган татар мәдәниятенең әле беркайчан да мондый катлаулы хәлгә калганы юк иде...

● ...Соңгы елларда республикада мәдәнияткә һәм мәгарифкә ярдәм итү, рухи тормышыбызны баету җәһәтеннән күп эшләр эшләнде. Шуның нәтиҗәсендә бер генә театр да, бер генә югары уку йорты да, бер генә мәдәният сарае да ябылмады, киресенчә, аларның саны үсте. Ун ел дәвердә республикада Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры, 28 яңа музей экспозициясе, 7 тарихи-мәдәни һәм табигать тыюлыгы, 35 китапханә, 162 мәдәният сарае, 6 монументаль сәнгать һәйкәле, шул исәптән Казанда Федор Шаляпинга, Карл Фукска, Бакый Урманчега, Алабугада Иван Шишкинга һәйкәлләр ачылды.

Барлык югары уку йортларында да студентлар саны бик тиз үсә. Элек без шушындый кыска вакыт эчендә Европа дәрәҗәсендәге яңа концерт залын төзү, рес-

таврацияләнгән бинада хореография училищесы ачу, Болгар һәм Зөя тарих-архитектура тыюлыкларын салу хакында хыяллана да алмадык. Бүген Казан Кремлендә, Казанның үзәгендә киң колачлы реставрация эшләре алып барабыз. Башкалабыз гына түгел, ә республикабызның шәһәрләре һәм бистәләре дә көннән-көн үсә, яңара, матурлана.

*Дәүләт Советының Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация игълан итүнең 10 еллыгына багышланган пленар сессиясендә ясаган чыгыштан. 29 август, 2000 ел.*

● Әмма шул ук вакытта сай фикерле әсәрләр дә байтак. Яхшы әсәрләрне укучыларга җиткерүдә дә эшлисе эшләр бик күп. Без еш кына рухи хәзинәләребезне күрсәтеп бирә алмыйбыз. Моның өчен радиода, бигрәк тә телевидениедә соңгы вакытта туган зур мөмкинлекләр тулысынча файдаланылмый. Тәнкыйть тә ныклап җанланып китми әле.

Ел саен була торган Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү кампаниясен генә алыйк. Каләмдәшләрегезнең әсәрләрен бүләккә тәкъдим итәсез, ә ни өчен моны эшләвегезне матбугат чараларында ныклап аңлатмыйсыз. Югыйсә бу әдәбиятны пропагандалау өчен никадәр җайлы форсат бит. Сез премияләрне кемгә бирү мәсьәләсенә караган бәхәсләрне еш кына сәхнә артында куертасыз. Акыллы, төпле фикерләрегез белән халык алдына чыгарга кирәк ләбаса.

Халык шагыйре, халык язучысы дигән мактаулы исемнәр кыл иләктән үткәреп бирелә. Ә инде язучы бу бүләккә лаек булган икән, аңа иҗат мөмкинлекләре тагын да яхшыртылырга тиеш. Без күптән түгел бу хакта киңәш тоттык, мин бу мәсьәлә уңышлы чишелер дип уйлыйм.

Тагын бер мөһим мәсьәлә турында әйтергә кирәк. Ул да булса—мирасыбызны саклау проблемасы. Бездә вафат булган язучыларның әсәрләрен туплау үзагымына куелган. Бу эшне Язучылар берлеге, Г. Ибраһимов исемендәге институт һәм Дәүләт баш архив идарәсе килешеп, бергәләп алып барырга тиешләр. Татарстан Милли музее системасында әдәбият музее төзү турында да уйланырга кирәк. Без Г. Исхакый, Г. Тукай, Х. Туфан, П. Хузангай, М. Мәһдиев һәм башка әдипләр музейларын ачтык. Ш. Камал, М. Җәлил, Е. Боратынский, М. Горький музейлары да эшләп килә. Язучылар берлеге бу өлкәне дә күз алдыннан ычкындырмаска, алар эшендә актив катнашырга тиеш.

Әдәби журналларыбыз да әдәби тормыш сулышын ныграк тоеп, шул ук вакытта талымлырак эш итәргә тиешләр. Бу яктан «Казан утлары» үрнәк булып тора. Аның нигезләнүенә 80 ел тулды. Ул—әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең башка төрләрендә дә энциклопедия булырлык басма.

*Татарстан язучыларының XII съездында ясаган чыгыштан. 31 май, 2002 ел.*

● Яңа XXI гасыр илләргә һәм халыкларга карата кырыс һәм таләпчән. Без ул таләпләргә лаеклы җавап бирергә, үзебезнең башка милләтләр белән бер баскычта торып сөйләшә алуыбызны исбат итәргә тиешбез. Глобальләшү процессы дөньяның барлык илләрендә дә каршылыклы вәзгыять тудыра. Бер яктан, әлбәттә, монарчы күрелмәгән чиксез мөмкинлекләр дә ачыла. Спутник телевидениесе яки Интернетны гына телгә алу да җитә: алар ярдәме белән бөтен Евразия континентына таралган татарлар бер-берсе белән һич каршылыксыз аралаша ала. Әмма шул ук вакытта глобальләшү милли үзенчәлекләрнең югалуына, төссез масса культурасының тамыр җәюенә китерә. Дөнья ташкынына кушылып юкка чыкмас өчен, глобальләшүнең өстенлекле якларыннан—үз милли тамырларыбызны югалтмыйча файдаланырга кирәк. Без һәркайсыбыз—үз иленең гражданы һәм дөнья гражда-

ны, әмма барыбер татар булып калырга тиешбез.

Глобальләшү дәверендә, безгә, иң элек, үз республикабызны, үз дәүләтчелегебезне, үз Конституциябезне саклап калырга кирәк, чөнки тел һәм культура үсеше өчен тиешле структуралар бары тик Татарстанда гына бар. Дәүләтчелегебез булса—халкыбыз да исән калыр, телебез дә сакланыр. Шул чакта әдәбиятыбыз да, сәнгатебез дә, тарихыбыз да, мәдәниятебез дә алга китәр, гореф-гадәтләребез дә яшәр.

Гомуми проблемаларны хәл итү максатында безгә кардәш халыклар, иң элек, башкорт туганнар белән бергәләп эш итү кирәк.

*III Бөтендөнья татар конгрессында ясаган чыгыштан. 29 август, 2002 ел.*

● Бөтен дөньяны колачлап милли үзенчәлекләрне бетереп барган глобальләшү процессы дәвам иткәндә безнең алга үзебезне-үзебез саклау бурычы килеп басты. Милли мозаикасыз киләчәк тормыш аклы-каралы кинематограф кебек кенә булуы мөмкин бит. Хәзер дөнья икенче. Җәмгыять сәяси, икътисадый, рухи яктан кискен үзгәрде. Һәр җәмгыятькә хас булган кебек яна җәмгыятьнең дә унай, матур һәм тискәре яклары бар.

Хәзер ирек тантана итә. Ни телисең, шуны яза аласың. Цензура юк, кирәге дә юк. Шуна шатланырга кирәк—әдәбият-сәнгать язмышы хәзер иҗат әһелләренең үз кулында.

Тормыш нинди генә булмасын, ул әдәбият-сәнгатьнең үзәгендә торырга тиеш икәнен барыбыз да беләк. Әйе, бүгенге яшәеш болганчык, катлаулы. Ләкин без нинди тирән үзаны булган, гасырлар буена үз асылын, акылын, телен саклап калган халкыбыз киләчәктә дә якты өмет белән яшәсен дисәк, гавәм йөрәгенә юл салырлык, бигрәк тә яшьләргә үрнәк булырлык, оптимистик рух белән сугарылган яна герой образлары тудырырга тиешбез. Минемчә, безгә әлегә яна тормышны белү, аны тирәннән өйрәнү, унай геройны яшәештән таба белү җитми.

Тормышыбыз кайнап тора. Ә без әдәбият-сәнгатьнең төп вазифаларының берсе—тормышны чагылдыру дибез. Кайда соң ул әсәрләр?

Инде бу мәсьәләгә кагылганбыз икән, җәмгыять, тормышның үзгәрүенә мисал итеп Интернет, компьютерның авылга барып җитүен исегезгә төшерим. Шәһәрләр, авылларның эстетик йөзе үзгәрә. Соңгы 10—15 ел эчендә яна буын туды. Аның дөньяга карашы үзгә, идеал-тормышлары үзгә. Ә менә без аларга массакүләм культурадан, тозсыз юмордан башка нәрсә тәкъдим итә алабыз. Заман таләпләренә җавап бирерлек нинди әхлакый, рухи азык бирә алабыз? Бу сораулар безне һәрчак борчырга тиеш.

Соңгы вакытта тарихи әсәрләр байтак чыкты, тарихыбызга объектив караш урнашып бара. Бу бик яхшы. Ләкин безнең бүгенге көнебез дә иртәгә тарихка әйләнә. Димәк, киләчәгебез турында уйлыйбыз икән, без халкыбызга, бигрәк тә яшьләргә тормышның кара якларын гына түгел, яшәешнең бүгенге гүзәллеген таба белергә, аннан ләззәт таба белергә юл күрсәтергә тиеш. Сез үз хезмәтегезне «матур әдәбият» дип юкка гына әйтмисез ич.

*Татарстан Язучылар берлегенең 70 еллыгына багышланган кичәдә ясаган чыгыштан 26 октябрь, 2004 ел.*

● Иң элек шуны әйтеп китим: иҗат кешеләре, чыннан да, Аллаһ кешеләре. Аллаһ Тәгалә безне яхшы якка үзгәртер өчен, игелеклерәк, камилрәк итәр өчен аларны җибәрә. Бу дөньяда аларның үзләренә дә җиңел түгел һәм бүтәннәргә дә гел уңайлыклар гына тудырып тормыйлар. Төптәнрәк уйлап карасаң, халыкның вөҗданы инде алар. Ә вөҗданлыларга, бигрәк тә нечкә күңеллеләргә, беркайчан да

җинел булмаган. Тормышлары фаҗига белән тулы язмышлылар күпме! Шәрык тарихыннан да, гареп тарихыннан да мисаллар җитәрлек. Ерак китәсе юк, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр да каберстан сакчысы вазифасында иҗат иткән түгелме соң? Үткән гасыр әдәбиятыбыз классиклары—шул ук Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәримнәрне искә төшерик: хәтта 40 яшькә дә җитә алмаганнар. Кайсына—27, кайсына—30... «Үлемнәре белән үлемсезлек яулаган» талант иялəре. Гомумән, минемчә, һәрбер зур талантның язмышында үз фаҗигасе бар. Шул ук Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакыйларны алыйк... Ахыр килеп, иҗат итү өчен бар шартлар тудырылган сурәттә дә иҗат—ул үзе үк газап, авыр хезмәт түгелмени?

Инде талантның бәһаләнү-бәһаләнмәү мәсьәләсенә килсәк, шунда ук сорау туа: ә кем бәһаләргә тиеш соң? Минемчә, бу үзе бер аерым тема. Әлбәттә, төп бәһаләүче—халык үзе. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләре халык өчен иҗат ителә, халыкны кызыксындыра. Халыкка киң танылa алу бәһаләнүгә керәме? Әгәр керсә, бездә үзенең һәм рәсми, һәм гаммәви бәһасен алган иҗат кешеләре байтак...

...Милли язучыларга, ничек кенә талантлы булмасыннар, элек тә җиңел булмады, хәзерге заман да яна киртәләр барлыкка китерде. Милли әдәбият өчен нинди шартлар тудырырга? Бу аерым проблема һәм без аның турында сөйләшергә тиешбез. Мин болай фикер йөртәм: безнең яхшы шигырьләребез, проза әсәрләре халыкка ни рәвешле барып җитәләр соң? Әйе, китапларның тиражлары кими. Бу, әлбәттә, дөньяви процесс, глобаль проблема. Мин ел саен китапларның, газета-журналларның тиражларын карап барам. Тиражлар кимү мәгълүмат артуга бәйле дип саныйм, ул гына да түгел, мәгълүматның башка, заманча чаралары барлыкка килде. Бу бер милләткә генә кагыла дип әйтмәс идем. Төп чара—чын әсәрне, эстетик кыйммәте һәм тәрбияви әһәмияте булган талантлы әсәрне (әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең бүтән өлкәләрендәге әсәрләрне дә күздә тотам) халыкка җиткерүнең отышлы, үтемле ысулларын табу. Беләм, әйтергә генә җиңел, эшләве авыр.

*«Рухи галәмдә яшәргә». Президент М. Шәймиев белән шагыйрь Р. Фәйзуллин әңгәмәсеннән. «Казан утлары», N 3, 2006 ел.*

● Безнең ата-бабаларыбыз дәүләт тотканнар, дөнья халыклары арасында олы дәрәҗә казанып, һәркемнең хокукы сакланган иманлы тормышта яшәгәннәр.

Әмма 1552 елның октябрь ае җитә... Әлбәттә, акыл иясе, философ, шагыйрь, дипломат, дин эшлеклесе, үзенең бөтен гомерен, талантын белемен үз халкының бәхете өчен биргән шәхес—Казан ханлыгының баш имамы Колшәриф—халкы өстенә килгән әлеге афәтнең коточкыч зур булуын күңеле белән сизгәндер. Әйе, дөнья—кырыс. Бөек остаз да: «Угылны атадан аерып, кызын да анадан шулай ук, елатып бер-бер ишектә, зар иттергән дөнья бу»,—дип юкка язмагандыр.

Әйе, халкыма күп кыенлыклар кичерергә туры килде, әмма ул сыгылмады, бирешмәде. 1552 елгы фаҗигадән соң дистәләгән буыннар алышынды. Инде тел, дин, милләт бетәр сыман тоелды... Әмма Колшәриф кебек шәхесләргә ия булган татар халкы түзде, тырышты һәм үсеш-янарыш башланды.

Бүгенге көндә без бердәм булырга тиешбез. Бердәмлек—хәзерге вакытта милләтләр язмышында хәлиткеч фактор.

*«Колшәриф һәм аның заманы» дигән китапка кереш сүздән. Татарстан китап нәшрияты, 2005 ел.*

❋



Гөлнур
Якупова

# КҮПЕРЛӘР*

РОМАН

## I

Айсылу ялтырап торган яссы калай өстендә тыпырдатып бии, ә аны уратып алган ахирәтләре кечкенә генә жиз подносларга чиртә-чиртә өерелә: дзинь-дзинь, дин-дин, даң-доң, даңгыр-доңгыр... Шултиклем дә даңгырдатмасалар! Биегән унайга кызыкай әле бер якка, әле икенче якка чак аумый кала. Әллә төш күрәме? Кемнәрдер: "Та-та! Ра-ра! На-а!"—дип сөрән салгандай. Әндә дә сымак?

—Уян әле, балакай, уян!—Дәү әнисе Мәдинә шулай тарткалый икән дә, ә ул төш күреп ята. Бәй, теге тавышлар чын ласа, әллә...

—Дәү әни, әллә ахыр заман купканмы?

— Өчтатар урамы яна!

Өенендә ишеткән икән теге ижекләрне, "татар", "урам", "яна" дигән сүзләр шул рәвешле килеп кергән уяулы-йокылы колагына. Чаң кагалар, даңгыр-доңгыр итеп. Бар шул аларда Өчтатар урамы. Күпме укталганы булды дәү әнисеннән төпченергә, нигә андый исем кушканнар, дип. Инде дә сорашып белмәсәме?! Авылларының атамасы да Агайтуган—уйландыра Айсылуны, тикмәгә генә шулай атамаганнардыр, бер тарихы бардыр. Зирекле дә, Бишкаен да, Яктыкүл дә түгел, Агайтуган—кем "агай" да, кем "туган"?

Шул урында Айсылуның уе кырт өзелде.

—Тот әле монау сандыкның бер колагыннан,—дип каты гына боерды дәү әнисе,—арурак әйберләрне, ичмасам, Кырчынлыга якынрак, бакча очына төшереп куйыйк.

Авыр сандыкны тышка чак күтәреп чыгардылар. Татарлар ягында (шулай әйтергә күнегелгән) күккә ашып ялкын дәрли иде. Бермәлгә генә Айсылуга ул үрә баскан дәү диюне хәтерләтте. Дәү әнисенә шул хакта әйткән иде, анысы:

—Күргән кешедәй булып,—дип әрли башлады да, капыл йомшарып, җөпләп куйды:—Әйе шул, абау, балам, Ходай коткарсын ул диюдән.

Сандыкларын бакча артына алып барып житкергәндә, теге дию ярты

* Журнал варианты.

Гөлнур ЯКУПОВА—*шагыйрә һәм прозаик; башкорт телендә басылган дистәләгән китап авторы. Уфада яши.*

офыкны ялмап алган иде, гүя, "тоташ авылыгыз белән бер кабуда йотам!" дип үкерә иде.

—Жиле дә, игелексез. Шәрәтауга табан исми, ялан якка сыпыра, арышка сирпелмәсә ярар иде бу янгын, мәлгунь.—Дәү әнисе, шулай сөйләнә-сөйләнә, Айсылуга чиләк тоттырды, үзе көянтәләп алды:—Мә, тот, йөгерик, коткарышыйк бәлагә тарыганнарны.

Айсылу бер колагы белән дәү әнисен тыңласа, икенчесен үр ягыннан килгән авазларга тырпайтты:

—Өянке күленнән!..

—Арышка!..

—Буразна!..

Йөгергән уңайдан, дәү әнисе урык-сурык ишетелгән бу сүзләрне аңлатып килә:

—Өянке күле Өчтатарга терәлеп тора, суны шуннан алырга кирәк шул. Әй, күпмегә генә житә аның суы, уймак кына бит ул... Арышны аралап буразна ярдыртырга кемнең башы житте икән? Алдан ук сөреп куяр иде дә ул, берәү булса.

—Кулак дәү әтием булсамы?

Дәү әнисе ишетмәмешкә салышты. Агайтуганны кыл уртага бүлеп агып яткан Каранай елгасы аша аръяк белән бирьякны тоташтырган Олы күпергә килеп життеләр. Эреле-ваклы күперләр, таяулы һәм асмалы басмалар күп ул авылда, ә Олы күпер берәү генә—аннан ат белән дә, машина белән дә үтеп була.

—Дәү әни, шушы күпердән алып киткәннәрме дәү әтиемне?

Бу юлы да ишетмәде дәү әнисе Айсылуны. Ярый әле әрләп ташламады, урынсызга дәү әтиенең сөяген кузгатма, дип. Айсылу да хәбәренең ипсезлеген аңлады, белмәсә бер хәл. Ике мылтыклы кешенең Әхмәдулласын арбага утыртып алып китүләре, ә үзенең Олы күпернең бер бүрәнәсендә чукаеп торган орыга эләгеп егылып, аягын каймыктыруы, атлый алмагач, мәчет ягына тиклем үрмәләп баруы хакында дәү әнисе, мең булмаганда да, йөз сөйләде ләса ана. Дәү әтисе шул китүдән, суга баткандай, юк булган...

—Әниең бәләкәч иде әле ул чакта, шул баланы уйлапмыдыр, мине дә бергә Себергә сөрмәделәр...—Ишеткән икән дәү әнисе оныкасының әйткәннәрен, әнә, шул ук юньдә фараз кылып килә.

Айсылуның чигәсенә ут капкандай булды, чарасыздан аны учы белән каплады: ялкынның кайнар тыны өтеп алып бара, тирә-юньдә чыртлашып очкыннар сикерешә. Әллә яулыкларын чишмәдә чылатып ябынган иделәр, чәчен чытырдап янып китмәс, димә, югыйсә.

Дәү әнисе әллә юләрләнгән: шул эссе табадай кызган күпер уртасында туктапып иснәнеп тора бит.

—Ай, Аллам! Әллә?! Булмас ла... Койка исе чыга, шәйлисеңме, борының сизгер лә синең?

—Әти үгез башы өткәндәге сыман, көйгән мөгез исе килә.

—Әйе, әйе! Шулай гына була күрсен,—дип элеп алды дәү әнисе һәм, әллә чынлап та юләрләнгән, тиктомалдан өстәп куйды:—Их, Динислам!

Ул арада Айсылу Каранайга карап шаккатты. Елгага да ут капкан бит! Дулкыннар, берчә бурлат кызыл, берчә чи сары телен чыгарып азарына ләса. Анавы биегән ут шәүләсе шулай Каранайга ауган икән.

—Бахыркай, Зөлганифә тутакайны әйтәм, дер калтырап утырадыр инде, Өчтатар ана басма аша гына бит. Юл унае сугылып китик, дим, шуннан турырак та ул.

"Их, Динислам!" дигәннән соң, дәү әнисенең зурлап эндәшүе иде. Айсылу жиңел сулап куйды: юләрләнмәгән икән.

Зөлганифә тутакай—дәү әнисенең ахирәте. Кеше, гадәттә, үз яшьтәше белән ахирәтләшә, ә боларның яшь арасы ару гына. Тутакай җитмешкә җитеп барадыр инде. Япа-ялгызы гына көн күрә, кәҗәдән башка мал да асрамый.

Алар бәгъзеләрдән алдарак та килеп җиткәндер янгын сүндерешергә, әмма соң иде инде. Утның урты тулган иде, ул дию дүрт ихатаны, каралтысы-ние белән, ике кабып бер йоткан иде һәм әлеге мәлдә куркыныч кызыл күзләрен акайтып, ара-тирә авыз-борыныннан ялкын бөркеп, уфыллап ята иде. Янгын сүндерүче агай мичәүле арбасындагы олы мичкәле суны сиптереп бетергән. Илле чакрымда яткан район үзәгеннән янгын машинасы әле килеп җитмәгән.

Кешеләр диюнең күзенә һаман да чиләкләп су сибәләр, көрәкләп туфрак ыргыталар. Ниһаять, тегенең күзләре томаланды, сүнде. Дөнья капыл караңгыланып китте: әллә аң-зиһенгә чак барып җиткән кара кайгыдан, әллә тырым-тырагай таралышып яткан кара кисәүләрдән?.. Таң да чак кыелып килә икән әле, офык саргая гына башлаган. Менә-менә кояшның тәүге нурлары күк пәрдәсен ертыр, илаһи якты җисем дөньяга пәйда булыр. Бер генә мәлгә офык алсу канга манчылгандай итәр, бу—көн туу могҗизасына ишарәдер. Ә шуннан алда Агайтуганны, җиргә энә төшсә дә күренерлек итеп, янгын яктырткан икән...

Шулчак ниндидер хикмәт белән исән калган бер әтәч, бәрәнге бакчасыннан канатын чак сөйрәп килеп чыкты да, телсез калган халыкка да, вайран кыйралып яткан төягенә дә илтифат бирми, аншаеп утырган мич янында сөрәеп калган тимер караватның аркасына ничек тә очып менеп, "кикрикүк"не кычкырып җибәрде. Кычкырган көенә тәгәрәп тә төште, соңгы көчен салгандыр инде мәхлук үзенең дөньяви мөһим бурычын үтәүгә.

Таң атты! Мең тугыз йөз алтмышынчы елның җәйге бер таңы. Кешеләр капыл җанланып китте, колаклары ачылды, күзләре күрә башлады: авыл әтәчләре дәррәү сөрән сала икән тирә-якта да. Сыерлар мөгрәшә, сарык-кәҗә бакырыша, казлар каңгылдаша. Тормыш бетмәгән икән әле, әнә, күпме мәшәкатьләр кузгатып, яна көн килгән.

Малайлар кыекларден сикерешеп җиргә төште. Хатын-кыз көтү куарга дип ашыкты. Ир-ат колхоз эшенә унайлады. Өчтатар урамында әби-сәби, бабай-сабай, бала-чага гына торып калды. Алар ни, нишләсен, кичергән хәсрәтләреннән гаҗиз булудан ары китмәделәр.

Ә Айсылуның дәү әнисе, менә гаҗәп, шаулап торган күмер өстендә аркага арка терәп утырган Сонай әби белән Сонай бабайны үгетләп бер була: "Елагыз, еламасаң, кайгы бавырга таш булып төелә ул". Еласаң, күз яше белән эреп агып китә микән ул таш, дип үзенчә фикер төйнәде кызыкай.

Шушы картлар моннан әүвәлге бер янгында казага тарыган, ул чакта да әллә ничә йорт көлгә калган. Шунда чәчләренә ут кабып, колак яфраклары пешкән дә өзелеп төшкән. Халык ни аларга "Сонай", ягъни "китек колак", дип кушамат таккан. Ул янгын кайчанрак булды икән? Әй, бахыркайлар, шушы Өчтатарлар, нигә аларның башына шулай каныкты икән бу... (Ходай дип әйтмәкче иде дә, телен тыя салды, дәү әнисе кисәтеп куйган: белгән-белмәгән көенә, тигән-тимәгән урында Раббыга иддига кылма, дәгъва белдермә!) Шулай да, ни өчен соң әлеге урамның исеме "Өчтатар?" Булганмыни Агайтуганда татарлар? Очраклы кушылмагандыр бу атама, җирлеге юктан түгелдер... Әмма ләкин Айсылу "татар" дип бармак төртеп күрсәтерлек беркемне белми үз авылында. Ә менә урыслар бар: агроном Никитин, аның хатыны Мария апа, балалары. Аларны яшьли генә, укып чыккач, шунда эшкә җибәргәннәр. Хәзер инде башкортлашып беткәннәр, шартлатып агайтуганча сөйләшәләр. Күрше Бозаулыкта, әнә, бар типтәрләр, татарчалабрак сөйләшәләр. Авыллары бәләкәйлектән, мәктәпләре башлангыч кына булгач, арытабан Агайтуганда укыйлар. Аның сыйныфында—дүртәүләр. Рауза дигән кызыкай

белән ахирәтләшеп тә йөри Айсылу. "Син—татар!", "Син—башкорт!" сыман үчекләшүләр булгалый, шаяртышып кына инде. Рауза тәүдәрәк кенә телен башкортчага күндерә алмый азапланды, ә хәзер хәтта оста сөйләшә.

Аркадаш утырган картларның берсе торып басыйм дигәнче, икенчесе авып китте. Үз хәлләрен үзләре белеп терәлешкәннәрдер инде алар, бичаракайлар. Бер агай барып ярдәмләште. Сонайлар, олы сөякләрен чак кузгатып, атлап киттеләр. Әбие әйткән булды:

—Бурдан кала, уттан калмый шул.

Ул арада колхоз рәисе казага таручыларга ярдәмгә әзмәвердәй өч ирне тәгаенләп җибәргән иде, алар янган бүрәнәләрне—бер якка, ысланып кына котылган баз бурасын сүтеп, икенче якка өяргә тотынды. Абзар-кура тирәсендә булышканда, Олы күперне чыкканда борынга бәрелгән койка исе тагы янарды: мал-туарларын да коткара алмаганнар икән, таң алдыннан, иң татлы йокы сәгатендә купкач ни бу мәхшәр. Вак малның сөякләре үртәлеп вакланган, мөгез-тояклары, баш сөякләре күренә. Эре малның янаклары, теш ырҗайтып, капкынны хәтерләтеп ята. Әллә адәм башлары исән калган—шуна җинел сулап куйдылар авылда. Айсылуның колагына кереп калды: әүвәле бер кеше янып үлгән, әле армиядә йөргән Сынтимернең дәү әтисе Динислам шулай һәлак булган, ди, шикелле.

II

...Яз саен Каранай елгасы Өянке күле белән кушылып-кушылып ала. Аларны тоташтырган кадимге ерганакны агайтуганлылар "Үнәч" дип йөртә. Су-сүл кайткач та, шушы Үнәч байтак вакыт суүсемнәр басып, ләм җепшетеп ята әле. Бар кош-корт шунда ябырыла бу мәлдә. Инәләре бәбкә басып утырганда кангырып йөргән ата казлардан алып, җәйнен-җәе Мәтәес сазлыгын төяк иткән кыргый челәннәргә тиклем су тартылганда Үнәчтә торып калган һәм хәзер тыпырдашып яткан балыкларны, маймычларны, вак бакаларны чүплиләр. Челәннәр кешедән курыкмый, иркенләп йөри—әллә бу мизгелдә үзләрен ауламаячакларын беләләр микән? Очлы чукышлары белән әкәм-төкәмнәрне сөйрәп чыгаралар да, кабырчыкларын оста гына ачып, эчендәге йомшак җисемнәрен ашыйлар. Әмма шул озын аяклы мәзәк челәннәрдән дә алда Үнәчкә Динислам дигән малай "очып" килеп җитә. Хәер, аңа очасы да түгел, өйләре якын—Өянке күленә бакча артыгына—Өчтатар урамында.

Мәдинә былтыр тәүге яз шушы тирәдәге чирәмдә бәбкә көткән иде. Җиде яше белән бара ул, кул арасына кергән инде, өйдәгеләр әйтмешли. Быел да шушында китерәчәк бәбкәләрен, Дәү әнисе белән кичә генә каз йомыркаларын кояшка куеп карадылар—кабык эчендәге нарасыйларның муеннарын бөкләп, тәпиләрен йомарлап ятканы күренеп тора. Моннан алдарак беркөнне табакка җылымса су салып, йомыркаларны йөздереп караган иделәр, һәр оядан икешәр "атасыз"ы чыкты. Дәү әнисе ул юлы: "Ата казыбыз шәп иде, әллә картайды, әллә ашатмадык яхшылап, әбә-ә",—дип куйган иде...

Мәдинә ерактан ук күрде: теге Динислам Үнәчтә мәш килә, бер иелә, бер турая, нәрсәнедер кулына ала да озак итеп карап тора. Нәрсәне булсын, әкәм-төкәмне инде, шуларны җыя ласа ул! "Егерме тартмамда егерме төрле әкәм-төкәм бар",—дип мактанган иде былтыр җәй.

Малай, тубыктан баткак кичеп, кулын терсәгенә тиклем батырып, ләм бутап әкәм-төкәм эзли, элэктергәнен ярга бер тирәгә ыргыта бара.

—Әкәм-төкәмнәрен качып беткән!—Кызыкайның тавышына малайның исе китмәде, мөгаен, килгәнен алдан ук күргәндер.

—Әйдә, кабырчыкларны карыйк, менә, күр әле, өйдәге тегеләре арасында юк кебек мона охшаганы.

Динислам чалбар кесәсеннән жеп кәтүге сымаграк бер кабырчык китереп чыгарды.

—Ә монысы—мөгезле әкәм-төкәм, безнең бакча артындагы яссы таш тирәсенә жыела алар, нишләптер,—дип сүзне бик тиз ялгап китте Мәдинә.

—Жылынырга киләләр инде ташка, кояшта кызынырга, чишмәдән чыгалар да...

—Әйтәм, аларны безнең Чишмә урамындагы кызыкайлар гына таный, ибитә?

—Ибитә, мактанчык...—Мәдинәнең үпкәчеллеген узган жәйдә сынарга өлгергән Динислам тиз генә өстәп куйды:—Бу әкәм-төкәм үзе сине таныгандыр әле, йә көлмәгенә күзе кызгандыр, нинди тәти көлмәк, дип.

—Матур, ибитә, көлмәгем? Кичә генә тегеп кидерде әни, туган көнемә.

—Бүгенмени туган көнең?

—Юкчы...

—Ә кайчан?

—Жиләк пешкәндә...

—Әйдә, куш капкачлы кабырчыкларны Каранайга ыргытыйк,—дип сүзне икенчегә борды малай.

—Нигә?

—Алар суны тазарта.

—Ә лайлалы әкәм-төкәмнәр тазартмыймы?

—Әллә. Алар яшелчәгә, сарык-кәжәнең эченә ябыша, шуны беләм.

—Ябышса ни.

—Мал ябыга ласа.

—Нишләп?

—Әкәм-төкәм ябышып эч маенны имсә, белерсең.

—Абау, шушы Динислам!

Мәдинә былтыр бәбкәләрен тап шушында көткәненә сөенеп бетә алмый—менә нинди дуска юлыкты бит. Рәхмәт инде Ата казга, ул ияртеп китерде бит Ала инә белән Ак инәне шушында. Мәдинәгә дәү әнисе ныгытып жибәргән иде, Ата каз үзе белә ул оясын кайда әйдәргә, иркенә куй, тик күз яздырма гына, дип. Ә аларның Ата казы, чынлап та, хәтәр акыллы. Янгыр ява башласа, инәләрне тиз генә өянке астына куа, алары, бер нәрсә булса, каушый да китә, бәбкәләрен канат астына жыя алмый. Тилгән килгәнен дә сизми ул инәләр бәгъзе вакыт, исләре китеп үлән йолкып тик йөриләр. Бахыркайлар, оя басып, көн күрми утырып ни, әзрәк әллә диваналаналар? Бәхетләре, Ата каз сакта уяу тора, бәбкәләрен камап кына йөртә.

Динислам да бәбкә көтте былтыр. Зур булып кыланса да, күп дигәндә яшь-яшьярымга гына өлкәндер Мәдинәдән, юкса бүтән эшкә кушарлар иде. Ул бер унай биш-алты ояга, тоташ урам бәбкәләренә күз-колак булып йөри. "Бигрәк татулар инде шулар",—дип дәү әнисе белеп әйтә Өчтатар урамында яшәүчеләр хакында. Үзләре аерым утыралар, бәлки, шуна да күрше-күләнгә ярдәмчелләрдер?

...Тагы бер жәй үтеп китте. Бәбкәләре ныклабрак канат ныгыту белән, Ата каз аларны Кырчынлы буенда йөртә башлады. Мәдинәгә Динислам белән очрашырга форсат бетте. Шул ике жәй генә язган булып чыкты кызыкай белән малайга балаларча дус булырга, уйнарга, сер бүлешергә. Сер дигәннән, Динислам "нәсел комарткысы[1] булган бер нәрсәкәй" хакында сөйлим, дип ике кат укталды да тукталды. Бер авыз ачканында Мәдинәнең тынлыйсы килмәде: Өчтатар урамыннан, бизәкле зәңгәр көянтәләренә талдан үрелгән кәрзиннәр элеп, Динисламның ике апасы, унбиш-уналты яшьләрдәге кызлар,

---

[1] Комарткы—борынгыдан калган истәлекле нәрсә, мирас.

төшеп килгәнен күреп калды да алардан күзен дә ала алмады: алъяпкыч итәкләренә чигелгән күгәрченнәргә карап һушы китте. Күгәрченнәрнең чукышларында чәчкәләр, пешкән кура җиләкләре—андый гүзәл нәкышне күргәне дә юк иде кызыкайның. Апайлар купшы атлап үтеп киттеләр, кәрзиннәрендә—ап-ак челтәрләр, сөлге, тастымаллар.

Ә икенче юлы ничек булган иде әле? Әлеге шул апалар күршедәге җиңгәчәйләре (бу урамдагы җингиләр дә гади түгел, ә җиңгәчәй икән) белән Каранай тубыгына су керергә төштеләр. Бәрәңге күмгәннәр, битләрен туфрак чаңы баскан, маңгайларыннан агып төшкән тир юллары гына ап-ак булып беленеп тора. Ак йөзле шул Өчтатар урамы кызлары. Ак йөзле, коңгырт чәчлеләр. Ә Динислам чи сары—бите кояшта пешеп, тиресе сыдырыла да йөри, танавы шау сипкел. Чәче бит әле үзенең—салабаш юкәсе сыман аксыл сары.

—Әллә ишетмисең дә, мин сина, адәмгә санап, борынгы әманәт хакында сөйләп торам тагы.

—Битеңә каз мае сөрт, чи кабырчык!—диде дә Мәдинә кулмәге-ние белән апалар арасына суга сикерде. Шул мәлдә, җанын көйдереп, Динисламның: "Каракай, бар битенне ю, кул суы йомшак ул, бәлки, агарырсың",—дигәне исенә килеп төшкән иде. Моңынчы елганың кичүле ягында гына комга терсәкләнеп аяк чәпелдәткән булып "йөзгән" кызыкайның бу кыланышын күреп, малай югалып калды.

Әйе, ике җәй уйнап калдылар. Балалык белән хушлашулары да шул булгандыр. Арытабан Чишмә урамындагылар Кырчынлының тугайга чыккан җирендә буа буды, каз-үрдәкләрен шунда төшерде. Динисламны тегермәнче атасы үзе белән бергә эшкә йөртә башлады. Кабырчыклы тартмаларын да күрсәтә алмады Мәдинәгә, "нәсел комарткысы" да бер табышмак булып калды.

* * *

Биш елдан соң гына күзгә-күз тагы очраштылар. Инде үзләре генә түгел, тоташ дөнья үзгәргән иде—патша җәнаплары төшерелеп, алай гынамы, бөтен гаиләсе белән атып үтерелеп, илгә большевиклар хуҗа булган иде.

Көньяк Урал сыртларына сыенган төпкел башкорт төбәге Агайтуганга заман җиле килеп кагылган гына иде әле. Олы юллардан читтә, язлы-көзле таша торган ике зур елга—Каранай белән Агыйдел арьягында яткангамы, авылга бу инкыйлап нәсел-нәсәп өчен корбансыз, кансыз гына килеп керде. Буталышлар, кырылышлар алдарак иде әле...

—Мәдинә?!

—Әллә танымыйсыңмы?

—Таныймчы.

Икесе дә җайсызлык тойгысы кичерде, нишләптер.

—Апаларың кияүгә чыккан икән, ишеткән идем. Мөгаен, берәр алъяпкычлары калгандыр әле, чигү өлгеләрен күчермәкче идем, шуңа килгән идем,—диде Мәдинә. Чынында аны Өчтатар урамына Динисламны күрү теләге тартып китергән иде, моны үзе дә тоемлый гына, ә зиһененнән үткәреп аңламый иде. Күңеле шушы якка омтылды да торды, боекты да торды бу арада...

Бер-берсенә яшерен генә күз салыштылар. "Чәчләре әүвәлгечә юкә сүс сыман аксыл түгел, ә куе сары—арыш саламы төсенә кергән. Ә күзләре, йә Ходай!—шул арыш арасында үскән зәңгәр чәчкә кебек зәп-зәңгәр". Шулай уйлады Мәдинә егет булып җитмәсә дә, малайлыктан чыгып, буйчанланып киткән балалык дустын күзәтеп. Берчә үз итте, берчә ят итте аны.

Динислам таныды да, танымады да каршында торган кызыкайны: "Тынлаусыз бөдрә чәчләрен шомартып тарап үргән, маңгаендагы түгәрәкләр

генә, чәчүргечтән ычкынып, элекке Мәдинәне хәтерләтә. Ә битендәге чокырлары бармы икән? Елмайса, күрер идем...”

—Әйдә, мин сина күбәләкләремне күрсәтәм.

—Куй, йә кеше күреп калыр икәүләп өйгә кереп киткәнне.

—Күрсә ни?!

—Һаман да бала-чага кебек шул күбәләкләр белән булышасынмы?

—Кичә генә, тегермән шарлавыгыннан бәрде кармаклаганда, туп-туп булып очып йөргән сары чобар күбәләк тоттым.

Балалыгы әллә кая еракка китмәгән иде әле Мәдинәнен, кызыксынуын җинә алмады, егеткә (Динисламны хәзер малай дип әйтеп булмый да инде!) ияреп, җәйге алачыкка терәтеп салынган такта янкормага керде.

Монда—Динисламнын гына дөньясы икән. Киштәләрдә, эреле-ваклы тартмаларда—кабырчыклар, әгәр үз күзе белән күрмәсә, Мәдинә аларнын елга-күлләрендә шултиклем дә күптөрле әкәм-төкәм барлыгына һич ышанмас иде. Ә күбәләкләр! Ике зур тактага тезеп кадалган бу матур мәхлуккайларнын нинди генәсе юк икән лә! Бермәлгә кызыкайнын күзенә тәти каптырмалар, алкалар булып күренде ул күбәләкләр...

—Зәнгәр чикерткә очратканын бармы? Менә кара, былтыр печәнгә барганда тоттым.

—Әллә. Яшел чикерткәне генә беләм. Атаръянны, аю чикерткәсен әйтәм, күргәнем бар. Ә бу нинди бөҗәк ул, җиз төймә икән дип торам?

—Төймә түгел, җиз конгыз бит, алып кайтып күрсәткәч, әти дә аптырады, гомердә очратканым юк иде, ди.

—Әнә, өрлеккә тагылган кабык эчендә дә нидер бар.

—Күреп калгансын, ә...

Динислам утыргычка басып кабыкны төшерде дә эченнән киндер төргәк алып такта идәнгә җәйде.

Мәдинә башта берни анламады. Бер-беренә тоташтырылган сызмалар, язулар. Күпер сыман да, басма сыман да...

—Әллә күпер?

—Зирәк син, Мәдинә, шул зирәклеген өчен...—“яратам” дип әйтә язды, әлдә анлап калды, туктап өлгерде.—Бу—шәҗәрә, нәсел шәҗәрәсе, синенчә әйткәндә, күперләр инде, чынлап та. Буыннарны тоташтырган күперләр... Мин әле, синнән ишеткәч кенә төшендем мона үзем дә. Ин азакта кем тора, укы әле.

—Дин-ис-лам,—Мәдинә яратып, иҗекләп укыды. Әкренләп “күперләр” буйлап карашы ин өстәге язуга барып җитте дә кычкырып җибәрде:—Динислам!

—Әү. Сангырау юк ласа монда, шымрак сөйләш.

—Күпернен башында да синен исемен язылган бит, димәкче идем.

—Минеке түгел, ә борынгы бабам исеме, атаклы Динислам мулланыкы. Ул ияртеп китергән безнен нәселне Агайтуганга, шушы урамда нигез корган.

## III

...Аh!

Ачыргаланып, эчендәге тетрәнүләрен, хәтерен айкаган көчле дулкыннарны берьюлы тышка бәреп чыгаргангамы, янында кыр кәҗәсе кебек сикергәләгән оныкасы Айсылуны капыл исенә төшергәнгәме, үз авазы Мәдинәгә күк ишелгәндәй гөрселдәп ишетелде, чарасыздан ул тагы да, бу юлы сабыррак итеп, “аh” орды. “Табибә картәнием, тәнемне генә түгел, җанымны да имләгән олы җан, оҗмах түрләрендә утырасындыр, минем ниләр кичереп торуымны тоясындыр,—аh! Тату яшәгәндәй, бер-берсеннән тотам калмый дөнья куйган атам белән инәм, газиз җаннар—аh! Динислам... Аh, Динислам!” Шулай

сөрәнләде Мәдинәнең, иллене узган, иллә тәүге мәхәббәтен гомер бакый тәүге кайнарлыгында саклаган хатынның бар булмышы. Һәм ул капыл күкрәк читлегендә, йөрәк чаршавында кайчандыр кадалып калган энәнең чәнчүеннән чайкалып китте.

—Дәү әни, ни булды, дәү әникәем!—дип өзгәләнде кызыкай, әкренләп ава барып иненә килеп терәлгән өлкән гәүдәнең авырлыгыннан бөгелеп төшеп. Ахырда, хәле җинеләя төште, күрәсең, дәү әнисе турайды, түшен калкытып, башын, гадәтенчә, горур чөеп, боерык бирде: "Әйдә, атлыйк, кулынны ычкындырма, егылып хур булмыйк!" Шул чаклы чыдам шул аның дәү әнисе, уртында ут булса да, тышка бөркемәс, эчкә йотар.

Өчтатар урамындагы янгыннан сон Мәдинә карчыкка (кинәт төс ташлады ул, карчык кыяфәтенә керде дә куйды) йөрәк өянәге ябышты. Йорт-кура тирәсендә генә йөрештерде, фани дөньяга илтифаты югалды. Аның каравы, Айсылуга игътибары чамасыз артты, "ике каш арасында гына йөргән үлем"нең аяусыз тынын тоя иде ул һәр күзәнәге белән.

Арыш урагына төшәр көн дә җитеп килә. Айсылуның әтисе салабаш күленә салган кайрыларын әрчеп, юкәсен киптереп, сүсләп тарап бетергән дә, хәл белергә кайтып урады.

—Кияү, әллә генә сыерны ияртеп кайтмагансың, Айсылуга төшәр иде мәшәкате, мин хөртәеп киттем бит әле,—дип каршылады киявен Мәдинә карчык. Айсылу белә: дәү әнисе улы сыман күреп ярата аның әтисен. Үзенең улы булмагангадыр, бәлки. Булыр иде дә, Әхмәдулла дәү әтисен кулак итеп Себер сөрмәсәләр...

Шул вакыйганы яңартып яңадан сөйләде әле дәү әнисе Айсылуга. Ул гынамы, торганы бер тарихнамә бәян итте Мәдинә карчык оныкасына шушы араларда. Исләр китәрлек хикәятләр, мәхәббәт кыйссалары... Аннан алда, кояш сүрелгәч, көн җиләсләнгәч кенә, житәкләшеп, тора-тора Шәрәтауга менделәр, кичке шәфәкъ нурларында ниндидер илаһи бер төскә кергән Агайтуганга югарыдан карап тордылар. Шунда дәү әнисе бер чикерткәне күреп калды да мәзәк хәбәр салды: "Динисламнын зәңгәр чикерткәсе!" Айсылу күреп өлгермәде шул, сикереп торган бөҗәк бала үскәнне көтеп торамыни сина...

— Дәү әни! Кем ул, Динислам—авырганда телеңнән төшми?

—Динисламмы? Сөйләрмен, колынкаем, сиңа—сөйләрмен. Күңелем җәүһәрләрен тагы кемгә таратыйм да тагы кемгә мирас итеп бирим?!

* * *

...Печән өсте. Ирләр, бер-берсенең үкчәсенә басардай булып, тотам калышмый, колач каерып печән чаба. Аклан үләненең тыны тирә-юньгә тарала. Ак чәчкәләр, кыңгыраулар, мәтрүшкәләр, андыз, бөхтә, кымызлык үләннәре, чалгы чапкан унайга, исерткеч хуш ис бөркә, сут агыза. Мәдинә таганга чәйнүк элеп ут кабызды һәм, төтеннән качып, каен күләгәсенә барып утырды. Чабылмый калган озын үлән арасында алланып күренгән көртмәлегә үрелде. Шунда берәү шым гына арттан эндәште:

—Гөлмәдинә!

Динислам! Аннан башка кем аңа шулай эндәшсен, ди.

—Туган көнең белән Мәдинә-Гөлмәдинә. Менә бүләк китердем сиңа.

Егет аның каршысына килеп утырды, башына гөлләмә-таҗ кидерде.

—Ай!—Кыз мангаена килеп орынган җиләктән дертләп куйды.

—Җиләк тә кушып үргән идем шул, син бит җиләк пешкәндә тугансың. Ошыймы?—дине Динислам һәм Мәдинәгә карап, бер гаҗәп күргәндәй, телсез калды. Кыз, аптырап, итәк җинен тартып рәтләштерде, әллә берәр ябышкак үлән сарылганмы, дип, инбашларын сыпыргалады да түзми сорады:

—Ни булган, нигә алай карыйсың, исең китеп?
—Үзгәргәнсең син...
—Ямьсезләнгәнме?
—Киресенчә, синнән матур дөньяда юктыр...
—Әзләп кара.
—Билләһи, Гөлмәдинә, әллә шушы такыя шулай килешә, чибәрлеген—ятып үләрлек.
—Үлмә инде, зинһар, мә, такыяңны салам.
—Юк-юк, салма, сине ул түгел, ә син аны матурлыйсың.
—Теле шушының...

Динислам күп сөйләшеп тора алмады, бер-ике буйга гына чалгычылардан калып торган иде ул, бүләген бирер өчен генә. Иртәгәсенә кич тегермән шарлавыгында очрашырга сүз куештылар. Ашлык тарттыручы юк, тегермән ташлары бу чорда ял итә, шулай да, каралтыга күз-колак булырга кирәклектән, Динисламнар чиратлап сакта тора. Тегермәнчелек—аларның борынгы кәсебе. Сәвитләр дә әлегә шул кәсепләреннән аермады, халык та бик теш кайрамый. Әлек тә, хәлле генә яшәсәләр дә, артык бай исәптә йөрмәделәр, әҗергә ашлык алуын алалар иде, ләкин чама белеп, намус саклап—бәлки, шуңа аларга каты бәрелмәделәр. Аннан килеп, тегермәнчелек тә һәркемнең кулыннан килә торган эш түгел бит әле ул.

—Шәҗәрәне күргән идең бит, иң беренче торган исемне—тагын бер Динисламны—хәтерлисеңме,—дип башлады егет һушы китеп тыңлаган кызга,—ул ияртеп китергән безнең нәселне Агайтуганга. Башта Иван явыздан качучылар күмәк булганнар, килә-килә әзәйгәннәр, юл унае, кайсы төбәктә мөмкин, шунда торып кала барганнар. Шәҗәрә шулай сөйли... Өчәүләп, Динислам бабам, әнисе һәм хатыны, килеп шушында төпләнгәннәр. Урынны башкорт аксакаллары әлеге Каранай тубыгыннан биргән. Урталыкта, күз уңында булырлар, дип уйлаганнар микән? Шуннан киткән инде Өчтатар урамы, беләсең килсә.

—Әтү, Динислам, син—татармы?!
—Татарлык, Зөлганифә тутакай әйткәнчә, шәҗәрәдә генә саф көенчә калгандыр инде хәзер. Күп дәверләр яшәгән бит Динислам бабам нәселе монда, кара башкортлар арасында, кан катышып беткән, тел, гореф-гадәтләр агайтуганча, ә шулай да төп чыгышыбыз—әйе, татар, Казан татарлары.
—"Кара башкорт" дигәненне ничек аңларга? Көлүеңме?
—Чын башкорт диюем, исәркәй, Мәдинәкәй-Гөлкәй. Син тагы үзеңә алып торасыңмы, коңгырт йөзле, кара чәчле булгач, ә? Бер әйттем бит инде, дөньяда юктыр синдәй чибәр, дип.
—Казаннарда бардыр, бәлки?
—Гөлмәдинә, сиңа ышанып сөйлим боларны, сер тота беләсеңме әле?—Динислам сүзне икенчегә борып салды.
—Беләмче. Таптың тагы яшерер сүз, урамыгызның исеме үк кычкырып тора да аны.
—Шулай да сыман... әмма безнең өчен шәҗәрәбез изге сер—комарткы ул. Динислам бабам мулла булган, Корьән Кәримне яттан белгән. Диндарлыгы белән башкортлар арасында да хөрмәт казанган. Ватанын бик сагынган, зарыккан. "Токымымнан бер инсан кайчан да булса Казанга кире кайтса, туган туфракта тамыр җәйсә, мәңге бакый риза булыр идем", дигәнe васыять булып калган. Шул әманәтне үтәүне безнекеләр миңа аткарыр сыман тоям...
—Ә бабаң үзе нишләп кайтып китә алмаган икән?
—Шәҗәрә сөйләвенчә, аның өч кызы булган. Кыз балалар кузгаламыни, кияүләр хатыннары артыннан ияреме тагы?! Аннан инде нәсел үрчеп, жирегеп кителгәндер. Шулайдыр, дип фараз итәбез, хак дөресен кем әйтә алсын хәзер?

—Шәҗәрә шулай сөйли, дисең дә... Ничек, кем саклаган андый хәтерне?

—Һәр буында Шәҗәрә саклаучы булган, ана телдән сөйләнә торган тарих та мирас ителгән, шулай тапшырыла килгән буыннан буынга.

—Искиткеч...

—Ә беләсеңме, Гөлкәем-Мәдинәкәем, кем әлеге көндә Шәҗәрә саклаучы?

—Әллә син?

—Нәкъ шулай, Гөлкәем.

Шунда Мәдинәнең аңында күк капкасы ачылгандай тоелды: барыбер дә икенчерәк шул ул Өчтатар урамы кешеләре. Менә бит Динислам, тач башкорт булып беткән Динислам да, ничектер үзенчәлеклерәк, чак кына башкачарак. Кайсылый назлы эндәшә, аның телендә генә исеме Гөлмәдинә-Мәдинәгөл, Мәдинәкәй-Гөлкәй бит. Ә тутакай, җиңгәчәйләр—комарткы сүзләредер. Чигүле алъяпкычлары, калфак сымаграк итеп, купшылап яулык чөюләре, көянтәне сынар иңбашка гына салып суга йөрүләре Өчтатар кызларының? Игътибарлап баксаң, әллә күпме шәхсән аермалыклар табарга булыр ул... Бәгъзе рәвештасылларны буын-буын мирас итеп калдыра киләләрдер шул... Күпме еллар, гасырлар үткән, ә төсмерләре калган, хәтерләре оемаган.

—Динислам! Ә сиңа кәләшне татар авылыннан яки типтәрләрдән әйттереп куйсалар?

Бу уй кайдан килеп кергәндер башына, Мәдинә әйтте дә салды.

—Бар ул безнең Өчтатарда андый гадәт...

Динисламның тавышы ничектер ышанычлы чыкмады, Мәдинәнең күңеленә шом керде.

Авылларда туй үткәрер мәл, кыр эшләре очланган, сугым суелган. Кире уйларга бер генә сәбәп бар—күңеленнең, мәхәббәтеңнең башкада булуы. Ә кем һәм кайчан, татардамы, башкорттамы,—исәпләшкән соң ул хыялый тойгы белән?! Сөйгәннәр белән кавышу мөмкин түгеллектән, гашыйкларның өзгәләнгән йөрәкләреннән чыккан зар булып тугандыр ул мәхәббәт җырлары, мәхәббәт кыйссалары. Йосыф вә Зөләйха, Ләйлә вә Мәҗнүн... Динислам вә Мәдинә...

Динислам вә Мәдинәгәчә Агайтуганда Гыйндулла вә Зөлганифә булган әле, ә алардан да әүвәл—Асылгужа вә Сөмбел.

...Динислам мулланың өч кызының берсе Сөмбел башкорт егете Асылгужага гашыйк була. Егет хәйран оста курайчы ди. Кыз-кыркын Кызлар тавындагы акланга җыелып уен кора, ул курай тарта икән. Бер шулай, матур җәйге көндә, Сөмбел дә килгән. Биергә төшергәннәр, ә кыз көйгә салмак басмый, күбәләктәй җиңел хәрәкәтләнеп "оча" ди. Асылгужа, уйнаган җиреннән туктап, бөтенләй яңа, шул арада гына уйлап чыгарган җиңел көйне тарта башлаган. Күзе төшкән Сөмбелгә, гашыйк булган, әнә шул тылсымлы тойгы аннан көй чыгарткан да инде.

Берчак, җәйләүгә күчкәч, тагы очрашканнар. Асылгужа кызга курай хакында бер хикәят сөйләгән. Башкорт батыры баскынчыларга каршы яуга киткән, тирмә кашагасынаKураен элеп калдырган да әйткән ди: "Шәһит китсәм, курай очыннан кан тамар, чөнки ул—минем рухымдыр".

Үзе сөйли, үзе курай көпшәсе эзли икән егет. Сөмбел тажлы үләнне күреп калган да, шаяртып: "Асылгужа, әнә синең рухың",—дигән. Егет курайны кисеп алган, бармак баса торган уемнар уеп, озын көйне сыздырып җибәргән. Шулчак Сөмбелгә әллә ни булган, куркышыннан агарынып киткән дә: "Курай очыннан кан тама",—дип, һушын югалткан. Баксаң, көпшәне кисеп алганда үткер хәнҗәренең йөзе егетнең бармак битенә тиеп үткән дә, каны курай очыннан тамчылап сарка икән...

Асылгужа чарасыздан кызны күтәреп алган, Динислам муллаларның

тирмәләре ерак та булмаган, шунда илткән. Тирмәдәгеләрнең коты очкан: кызның ак күлмәгендә кан, егетнең кулында—аның һушсыз гәүдәсе!

Сөмбел исенә килгән. Көчле кичерештән, сөйгәне өчен хәвефләнүдән аның югалтуын белгәннәрдер дә, аңлаганнардыр да. Әмма барыбер Асылгужадан ваз кичәргә кушканнар. Аерганнар гашыйкларны, бер гаепсезгә мәхәббәттән мәхрүм иткәннәр саф күңелләрен.

Сөмбел, үтә дә нәзберек җан булгандыр шул ул кыз, кичерә алмаган аерылышу сагышын, саргаеп үлгән ди. Асылгужа башкорт далаларында, тирмәдән-тирмәгә курай уйнап йөреп йөргән басмакчы булган, ахырда бер яуда барымтачылар кулыннан һәлак булган...

...Ел да үтмәде, Өчтатар урамында кыз бала туды. Мәдинәнең күңеле сәер бер кинәнеч кичерде. Зөлганифә тутакай азак аңлатуынча, аны Динисламга алып бирмәүләренең төп сәбәбе ике нәселдә дә ир заты әз туу булган икән дә. Хактыр, Мәдинәләр токымында да хатын-кыз нисбәте күбрәк шул, ни хикмәттер. Ир нәсәбен үрчетмәкче, кан яңартмакчы булганнардыр да, мә сиңа—кыз бала...

Динислам, бәгъре сызланса да, хатынын какмады, гадәткә кергән уллык әдәбен саклап, канун ихтыярына буйсынып дөнья көтәргә күнде. Мәдинәне бер тапкыр да очратмады. Максат итмәсәң, бәгъзе кешене гомер бакый да күрмәскә була Агайтугандай олуг авылда.

Кыш бетте, җәй үтте, көз житте. Мең тугыз йөз егерме өченче елның көзе.

Әнә шул көзне булды да инде Өчтатар урамындагы беренче янгын. Ул чакта да уңлап йорт утыра иде тезелешеп. Каранай тубыгында олы урам ясап булмый шул, монда—Төп йорт, Динислам сөйләвенчә, шәҗәрә саклаучылар көн күрә, ә нәсел инде, тармакланып, бүтән урамнарга, хәтта башка авылларга да таралып беткән.

Халык арыш урагына төшкән иде. Мәдинәләр чүмәләләрен чүкәйтеп утыртып бетеп кенә барганда, кемдер әче тавыш белән кычкырып җибәрде: “Авыл яна!” Урта төштән күккә олгашып ялкын дөрләп күтәрелә иде. “Әллә Чишмә урамы, әллә безнең тирә?” Шулай сискәнде Мәдинә, чөнки йөрәге, үзенә генә төшәр казаны тойгандай, аяусыз дулый иде.

Уракчылар җан-фәрман авылга укталды. Кайтып житүләренә, янгын үзенең хәсислеген эшләп куйган иде.

Күзләре татарларның шәҗәрәле йортын, күркәм булып балкып утырган йортны, тапмагач, буыннары йомшарды Мәдинәнең. “Баһадир гәүдәле, чос Динислам йортны кабат салыр, тырыш бит ул, эшкә нык бит ул” дигән сымаграк уйлар чуалышты аның башында, ә йөрәге сизде, фаҗига салкыны калтыратты йөрәген.

Якынрак басуда эшләп йөргән Динислам, янгынны күреп калып, йөгереп кайткан, шартлап янып утырган йортына атылып кереп киткән, тотып калырга да өлгермәгәннәр. “Хөсне хат!” дип кычкырганын гына ишетеп калганнар...

Динислам янып үлде. Өрлек сынып, өстенә түшәм ишелгән.

Мәдинә дә янып көлгә калды ул янгында. Эчтән янды, эч-бавыры көйрәп, кара сөрем булды.

Ә дөнья куласасы барыбер әйләнде, таң саен кояш чыкты, кич саен баеды. Өчтатар урамында да тормыш дәвам итте. Авыл картлары, ташлагыз уңмаган нигезне, әнә Сәвит урамына күчегез, урын күп ләса, дип карасалар да, ташламадылар, шунда яңа бура күтәрделәр.

Мәдинәгә дә яучы килде. Тугынчылар нәселеннән Әхмәдулла исемле егет соратты. Белә иде кыз аны. Күрмәлекле егет, хәлле кешеләрнең баласы. Картәнисе дә өнәде. Аннан тагы, Зөлганифә тутакай сыман утырып каласы да килмәде кызның, үзе дә өй эчендә бердәнбер токым очтыгы, яшәеш ихтыярын үтәргә кирәктер ләса...

Әхмәдуллага карата йөрәгендә гыйшык очкыны кабынмады, әмма тәне дә чирканмады Мәдинәнең, тыңлаучан, ихлас җәмәгать булды ул. Ир белән хатын якынлыгын Динислам белән татып карамады, тик барыбер дә моның сөйгән яр куенында икенчерәк булуы ихтималын сиземли иде. Беркөнне, Әхмәдулла армансыз булып эштән кайтып, аягын да салырга иренеп, тупсада утыра. Көне буе тәгәрмәч тугыны ясап, дуга бөгеп арый ласа кеше, оста эше генә түгел, көч эше дә бит. Җәлләп китте ирен, таска су салып, аягын юарга итте. Җылымса сулы тасны китереп утыртты, ләкин уйлаганын аткармады. Хатын-кыз телендә "аягын юган суны да эчәр идем" дигән сүз бар,—бик-бик, өзелеп-өзелеп яраткан хатын сүзедер, дип уйлап куйды үзе.

Ярыйсы гына яшиләр иде. Кызлары туды, Камилә дип исем куштылар. Баласын кулына алгач, тәүге уе баланың әтисенә түгел, ә Динисламга барып тоташты: "Бәгърем, сина ул табар идем сыман". Уй бит ул, тотып йә тыеп буламыни аны, шулай көтмәгәндә килә дә уела...

Аннан инде вакыйгалар куерып китте авылда. Колхозлар төзелде. Кешеләрне кулакларга, ярлы крестьяннарга аердылар. Әхмәдуллаларның тугын сарайлары, кораллары булып, бөтен тирә-якка кәсеп итәләр иде. Әхмәдулланы кулак иттеләр, сарайларын тартып алып колхозга куштылар, үзен Себергә сөрделәр. Әй шул сәясәтне кылучыларның күрә караулыгы. Остасын һәлак иткәч, аның остаханәсеннән ни фәтвә соң?!

Агайтуганнар, исеменә күрә җисеме, дигәндәй, шулай да, бәгъзе бүтән авыллар белән чагыштырганда, бердәм яшәде. Күрәләтә әләкләшеп кеше башы ашап йөрүчеләр булмады сыман. Булса, им-томчы дип, Мәдинәне дә берәр хәлгә төшерерләр, татарларны да, тегермәннәре бар дип, урамнары белән олактырырлар иде. Әхмәдуллага тәкъдир каршы булды, үзе дә дистәләгән тәгәрмәчен сарай башына яшергән иде шул—тентү салдылар да таптылар.

Камиләсе биш кенә яшендә ятим калды шулай. Әхмәдулла кайтмады. Чит туфракта башын салгандыр, югыйсә, югалып калыр ир түгел иде.

...Ялгыз калгач, Мәдинә Зөлганифә тутакайга тартылды, аерып алгысыз ахирәт булышты алар. Белгәне белде, белмәгәне юк бу ике хатынны бертугандай итеп бәйләгән изге хәтер хакында. Камиләне икәүләп җил тидерми үстерделәр. Шөкер, ачлыкка да тарымадылар. Тормыш тора-бара бераз җинеләйде, колхоз ныгыды, кешеләрдә тамак кайгысы бетте. Балалар мәктәптә янача укый, яшьләр комсомол җырларын җырлый, дәртле басып йөри. Киләчәк ифрат матур булып күзаллана башлады.

Әгәр дә сугыш башланмаса, ул гүзәл киләчәк, чынлап та, озакламый алга килер дә иде.

Башта 1905—1918 елгыларга мобилизация игълан ителде. Мәдинәнең күршесе Нәкыйулла, Динисламның яшьлек дусты, тәүгеләр рәтендә фронтка китте. Кичтән кереп чыкты, озак кына сөйләшеп утырды. Ахырда култыгына кыстырып кергән, һаман да тубыгына салып тоткан ак төргәген таратты—китап икән. "Менә, күршем, яшьтәшем, дисәм дә була, шушы комарткыны синең кулыңа тапшырырга ниятләдем әле, тияр генә иясе дә син аның. Әйе... Мә, кабул ит",—дип Нәкыйулла борынгылыгы саргайган тышыннан ук билгеле китапны ана сузды. "Нөҗүмел Фөркан"—күзләре гарәп хәрефләрен таныды, ә күнеле—Динисламын. Анынчы Нәкыйулла да дөресләп куйды аның сиземен: "Дустымның төсе итеп саклаган идем, бик якын күргәндер мине, шушындый да һиммәтле бүләк күндермәс иде, югыйсә..."

Тора-бара яшьрәк ир-атка да чират килде. 1942 нен җәендә, июль урталарында, Нәкыйулланың улы Җәмил дә фронтка җыенды. Камилә, унтугызы белән барган кыз, аны бөтен авыл алдында озатып калды. Көзгә өйләнешмәкчеләр иде. Ә Динисламның кызы Гөлчибәр ул тапты—ниһаять,

ир бала. Житлекми туды сабый, жиде айлык булып. Иренә, Кара сатин Зарифуллага, сугышка повестка килгәч, нык көенеп киткәндер инде яшь хатын, тулгаклый башлаган да бәбәйләгән дә куйган. Ходайга шөкер—сабый исән, Зарифулла аны күреп, кулына алып, әманәт исем әйтеп киткән. Үзем сыман каракай бул, тимер сыман нык бул, дигән ди ата кеше, улын сөеп.

Кара сатин дигән сирәк кушаматны Зарифулла үзенә үзе ябыштырган, диләр. Динисламның кызын сората барганда, әлеге Зөлганифә тутакай сүз арасында әйтеп салган: "Бигрәк каракай да инде бу кияү егеткәе, ә безнең кызыбыз ап-ак кына, битләре ак сатиндай ялт итеп тора..." Зарифулла аптырап калмаган: "Ак сатиндай итеп кадерләп тотармын кызыгызны, ә үзем кара сатин сыман нык булып, әрсез, авыр эшләрне аткарырмын..."—дигән. Шулай итеп, Зарифулла Алсынбаев Өчтатар урамыннан үз өенә Кара сатинга әйләнеп кайткан.

Кияүләренең әманәтен үтәде татарлар: улга әтисе калдырган Сынтимер исемен куштылар.

1943 елның көзендә, ниһаять, фронтта борылыш булды. Нәкыйулланың соңгы хаты Воронеждан килгән иде, "Курск дугасы"на чыгабыз", дип язган. Шул дугада һәлак булды... Жәмилдән бер генә хәбәр алдылар, "Днестрны фашистлардан тазартабыз", дигән. Шуннан соң дүрт ай буе кош теледәй дә хат килмәде аннан. Әнисе түшәккә егылды. Сугышка тиклем үк жәфалаган ашказан чирен дә, Нәкыйулласының үлемен дә, инде килеп бөртек улының шулай югалуын да күтәрерлек көче юк иде шул. Жәмилнең "Камауда булдык, партизаннар белән бергә сугыштык, менә тагы хәрәкәт итүче армиягә кушылдык", дип язган хатын Мәдинә белән Камилә ачып укыды...

Ничек кенә авыр, озын-озак булмасын, Бөек Ватан сугышы дигән тинсез афәтнең дә ахыры житте, 1945 елның 9 май таңы атты.

Исәннәр әйләнеп кайтты. Авылдан ике йөз уналты ир-узаман китеп, шуларның кырык жидесенә генә туган якны күрү бәхете насыйп булды. Чиләбедәге хәрби заводка эшкә жибәрелгән кызларның да бер өлеше йә тәгаен эш дип, йә башка бер сәбәп белән Агайтуганга кире кайтмады. Какшады авыл, ятимләнде.

Камиләнең егете августта хәбәрсез генә кайтып төште. Кемгә хәбәр итсен инде, әтисе сугышта башын салды, Жәмил моны белеп киткән иде. Әнисе дә вафат. Бертуган апасы Зөбәржәт бар иде дә, ул корал заводында торып калды. Ленинградтан бронь белән килгән бер урыс егетенә ияләнгән, шуңа ияреп китмәкче икән, дип тә сөйләделәр аның хакында...

Жәмилнең, шулай да булса була икән, ике елдан артык ут эчендә йөреп, бер генә жәрәхәте дә юк иде. Жиләк кебек кызлар, япь-яшь тол хатыннар белән тубык тиңеннән тулып яткан авылга киштәдәй ныкчым гәүдәле, төскә-башка сөйкемле егет кайтып төште. Кем өлешенә? Барысы да белә: Камилә өлешенә. Ләкин, буйдак егетләр бармак белән генә санарлык булганда, нишләп әле Камиләгә генә тияргә тиеш бу бәхет?! Жәмилне үзенә каратырга тәвәккәлләп караучылар табылды, әлбәттә. Шулай да мәхәббәте тирән булган икән егетнең, урта матурлар рәтендә йөргән Камиләгә тугры калды. Озакка сузмый өйләнде. Кайнә йорты иркенрәк булгач, аларда яшәп алып киттеләр. Төрттерүчеләр табылды, янәсе, "саплы килен икән Жәмил", ләкин егет бу тәнгәлдә дә нык лык күрсәтте. Әнә шул нык лыгы белән Мәдинәнең ихтирамын яулады кияве, улы сыман итеп күрүе шуннан да килә.

Житкән кыз иде бит, көне белән буйга узган, ахрысы, тугыз ай дигәндә Камиләнең кызы туды. "Кыз таба торган нәселдән шул без" дип, бу юлы да Мәдинә уе белән Динисламының рухына хәбәр ташлады...

Кыз балага Айсылу дип исем куштылар. Төс бирер бу исем ана, тулган ай

нурына күмелгән июль төнендә дөньяга туды ул, йолдызнамә буенча ырыс китерер күк жисеме—Ай үзе.

Ә тегендә, Өчтатар урамындагы Төп йортта (Зарифулласы сугыштан кайтмагач, Гөлчибәр атасы нигезенә күченгән иде) үсеп яткан Сынтимер исемле малайга дүрт яшь тулып узган иде...

Откыр бала Айсылу. Мәктәптә яхшы укый, бер яклап та ал бирми. Дәү әнисе сыман ук чәмле түгел, салмак, уйчан булмакчы. Тирә-якка, кешегә шундый игътибарлы бага анын күзләре, әйтерсең, хәтеренә сендерә, күнеленә беркетә. Суга карап та һушы китеп тора, чәчкә күрсә, сокланып туя алмый, кош күрсә, артыннан күккә очып китәрдәй булып талпына. Табигатьнең һәр сулышыннан, һәр бизәгеннән хәйран калган оныкасын Мәдинә ирексездән балалык дусты, яшьлек мәхәббәте Динисламга охшатып та куя, әллә бер-бер кодрәт белән сары чәчле, зәңгәр күзле кабырчык патшасының асылы кучтеме икән Айсылуга?

Әмма, кызганычка каршы, нәсәбән һөнәре табиблыкны оныкасы үз итмәячәк, сизелеп тора. Откыр булгач, тиз ота ул шифалы үлән исемнәрен дә, "әнә, дәү әни, кияү үләне, күз үләне, сөял үләне, шеш үләне, әнә—кан үлән, тырнак үлән" дип, яланга чыксаң, алдан күреп тора. Нинди чиргә ни дәва икәнен дә анлап бара, ләкин барыбер ихласлыгы анын имчелектә түгел шул. Нишләмәк, хәзер инде заманы да бүтән, укыган табиблар бар, алар үзләренчә дәвалар...

Айсылу, мөгаен, мөгаллимә булыр? Үзе бер әйтеп ычкындырган иде, унынчыны бетергәч, техникумга китәм, дип. Салаватта укытучылар әзерлиләр икән. Харап ласа, шушы бала укып чыгып, Агайтуганда сабак биреп йөрсә?! Насыйп булса, күп тә калмаган...

Шулай шөкерана кылып, тормышка канәгать булып кына яшәп ятканда, таңгы йокыда, Агайтуган өстендә коточкыч дию пәйда булды—Өчтатар урамында янгын купты. Анын аяусыз ялкыны Мәдинә карчыкнын ят күздән, чит колактан куркып, жиде йозак белән бикләнгән хәтер дөньясын да ялмап алды. Сабырлыгы, зиһен яктылыгы белән яшәгән табибәнен йөрәгенә капкан утны сүндерер чара юк иде. Соңгы сәгатенәчә, жанындагы соңгы чырак янып сынгангача, Айсылу оныкасына әманәтләрен тапшырып өлгерәсе, вәгазь-нәзерләрен житкерәсе генә калган иде аңа...

## IV

Яз житте, кар бетәр-бетмәстән күгүлән чыкты. Төш житүгә, кояш көнне йомшартуга Айсылу укудан кайта да үзен көтеп кенә утырган дәү әнисен йорт алдындагы эскәмиягә житәкләп чыгарып утырта. Көннәрдән беркөнне дә шулай итте. Дәү әнисе, гадәтенчә, йөзен кыйблага куеп утырды. Тавышын шым гына чыгарып, көйләбрәк бер сүрә укый башлады. Айсылунын колагына ясин сүрәсенең сүзләре килеп керде. Әллә дәү әнисе үзенә үзе ясин чыга? Кызыкайнын күнеле сискәнеп куйды, әмма карчыкнын кыяфәте тыныч, хәтта сәламәт бер рәвештәгедәй күркәм күренгәч, борчылуы басылды.

Өйгә керде. Чәй эчеп алды. Колхоз эшеннән бушамаган әнисенең кулы житми калган вак-төяк эшне бетергәч, тышка чыкты. Дәү әнисен беләгенә ябыштырып әзрәк йөрештертеп алу иде уе, аяклары оеп киткәндер, югыйсә.

—Дәү әникәем?!

Кыз баланын йөрәк аянычы һавалардан каклыгып әйләнеп кайтты:

—Дәү әникәем!!! Дәү әни!! Дәү әникәем!!!

Агайтуганнын ак инәсе, табибәсе утырган килеш йоклап кына киткән иде гүя, шулай сабыр иде анын йөз сырлары.

...Айсылунын аны байтак вакыт карышты әле бу чынбарлыкны кабул

итмәскә. Ул, йола саклап, зират киртәсе тышында калган хатын-кыз арасында шым гына басып торды. Менә, ләхет ябылды булыр, туфрак төшерелә башлады. Беренче уч туфрак сибелде…

* * *

Рауза ахирәте тугызынчыга килмәде, ул Уфадагы полиграфия училищесына укырга кергән иде. "Хәреф җыючы булам, гәзит чыгарам ягъни", дип язган иде хатында. Айсылу шунда гына төшенде: үз авылында юк икән ләса анын җан дусты. Сыйныфташлары, күрше кызлар белән дә тату ул, әмма сердәш түгел. Бәләкәйдән дәү әнисе белән генә сер урталкашырга күнеккән иде, шуна күрә бүтәннәргә бик сыенып та бармады. Рауза исә аны үзенең алчаклыгы, ефәк теле белән әсир итте, шикелле.

Яңа ахирәт сайлап маташмады Айсылу. Ихтыяжы да булмады, вакыты да накыс иде—китап укуга салды ул әвәслеген.

Бер уй әзәрлекләде кызыкайны. Ул уй, әйләнә-әйләнә, тулгана-тулгана да "Сынтимер" дигән исемгә барып төртелә. Анавы Өчтатар урамыннан ул, әле хәрби хезмәттә. Янгыннан соң телеграмма биргәннәр икән, көттеләр, кайтмады. Солдат үзенә үзе хуҗа түгел, рөхсәт итмәгәннәрдер, күрәсен. Айсылунын кызыксынуы шултиклем көчле иде, дәү әнисенең хикәятләре дә нык кузгаткан иде анын иләс-миләс кенә яшь күңелен. Нигәдер хәтерләми шул Сынтимернен төс-башын. Ул үскәнне көтеп тормаган, армиягә китеп барган, имеш, берәү... Кызык, ул да теге кабырчык патшасы Динислам сыман сары чәчле микән?

Ниһаять, унынчыга да җителде. Ике ай укыган иделәр, көзге каникул башланды. Айсылунын күңеле җилкенә дә тора бит шушы чорда. Бәйрәм итәсе, тамаша күрәсе килеп тик тора. Клубка танцыга барсаң, берәр укытучы күреп кала да әрләп кинәнә. Мәктәптә өлкән сыйныфлар өчен танцылар була, әмма анда Айсылуга Хәйдәр дигән малай бәйләнеп йөдәтә. Тигәнәк белән бер, биергә чакырып тенкәсен корыта. Төшмәсән, җайсыз, төшсән, аерылырмын шуннан, димә, чат ябыша дә куя, башка берәү белән ни биеп, ни сөйләшеп булмый. Җитмәсә, озатып булыша, җитмәсә, кулыннан тотарга итә, култыкларга маташа, үзенең Айсылудан бер башка тәпәш икәнен әллә күрми?!

Бүген кич тотам да клубка барам, әләксәм әләгермен, дип, тәвәккәлләп кенә йөргәндә, йөгерә-атлап Рауза килеп кермәсенме!

—Сөенче лә кызына, Камилә апа, мин киләм!—дип сөрәнли, ә үзе, Айсылунын әнисеннән дә алда ишекне ачып, ахирәтенең кочагына ташлана. Җәйдән бирле күрешмәгән ләсә алар, бәй.

Әлеге Хәйдәрне озаклап сөйләп, көлешә-көлешә клубка юнәлделәр. Барсалар, ни күзләре белән күрсеннәр, авылга әллә ничә солдат кайткан бит берьюлы. "Кайсысы Сынтимер икән?" дип уйлап алды Айсылу.

Шул минутта читтәрәк, посыбрак торган ике ахирәт алдына шәмдәй төз гәүдәле егет килеп басмасынмы! Теге солдатларның берсе! Айсылу егетнең гимнастерка түшендәге значокларыннан күзен аера алмый торганда (йөзенә күтәрелеп карарга базмады), Рауза әйтә салды:

—Биергә чакырасынмы? Кемне, минеме?—Үзе тагы вальс көенә талпынып төшеп тә бара. Кыюлык—ярты бәхет, дип белеп әйтәләр, әнә, ахирәте егетнең ныкчым сынына сыенып алган да дөньясын онытып өерелә. Ә кое нинди матур, баганага тотынып та биеп китәрсен, әй.

—Айсылу, кемнән шүрләп яшеренеп торасын? Әйдә, көй беткәнче әйләнеп алыйк, бүген клубта укытучылар юк, хөррият,—дип, әлеге Хәйдәр шунда анын кулыннан эләктереп алды да уртага әйдәде.

Хәйдәр көйгә харап оста баса икән, әллә аяк очларында йөри, биегәндә биегрәк тә күренә үзе. Ләкин кызнын үе сыйныфташ малайда түгел, ә баягы

солдатта. Алар һаман да Рауза белән парны бозмаган икән, күптәнге танышлардай, сөйләшеп сүзләре дә бетмәгәнгә охшый. Күз кырые белән генә күзәтә Айсылу: кара чәчле, юка яңаклы, кырлач танаулы икән егет. Алар ягындагы ир-ат халкының гадәти кыяфәте инде...

Озак күңел ачарга форсат бирелмәде. Клуб мөдире агай үзенең башы дәүмәлле олы йозагын күтәреп килеп керде, "Көн дә бәйрәм, көн дә туй булмый ул",—дип сөйләнә-сөйләнә, яшьләрне куып дигәндәй чыгарды да ишекне шартлап бикләп кайтып китте. Яшьләр, тупсада әзрәк тапанып торганнан соң, таралыштты.

Кайтышлый Рауза яна танышы турында сөйләде. Хәйдәр дә иярәп алган иде, ул да кайсыбер мәгълүматлар бирде. Сынтимер икән!

—Яхшы беләм мин аны.—Шулай дип ычкындырды Айсылу. Янында килгән икәү гаҗәп итте:

—Яхшы беләсен?!—бер тавыштан кычкырып җибәрделәр хәтта.

—Бездән дүрт-биш яшькә өлкәндер ул,—дип фараз итте Рауза.—Хезмәтемне тутырып кайттым, ди. Өч ел йөргән икән. Чик буен саклаган—пограничник.

—Кырык икенче елгы ул, әтисе сугышка китәр көндә туган,—дип өстәде Айсылу.

—Әллә хат алыштың аның белән, миңа эндәшми генә?—Раузаның тавышында шикләнү белән бергә үпкәләү дә бар иде сыман.

Сорау һавада эленеп калды, аңа җавап булмады. Айсылуларның өй кырына килеп җиткән иделәр. Хәйдәр дә тигәнәкләнмәде, шымтаеп үз якларына унайлады.

Ике ахирәт, ләм-мим сүз катышмый, Камилә апа өстәлгә әзерләп, ак тастымал белән ябып куйган берәр чәшке сөтне эчтеләр, урын җәеп йокларга яттылар. Ята торгач, теге сорау эленеп торган җиреннән "шап" итеп урталарына килеп төште.

—Әллә хат алыштыңмы, дим, шул Сынтимер белән, сер яшерденме?

—Ул армиягә киткәндә мина чак ундүрт яшь булган ласа, бүген тәү күрдем әле төсен дә...

—Бер авылда яшәпме?

—Дәү әниемнең ахирәте Зөлганифә тутакайларда берничә очраткан идем ул агайны, бәләкәч чагымда.

—Әле "агай"ны таный салдың, ибитә, "бәләкәч"? Ошадымы соң?

—Нигә тота килеп бәйләнден, күзең төштеме әллә шул... Сынтимергә?

—Төште, ди, юкчы. Әллә сер яшерденме миннән, бөртек ахирәтеннән, дип җаным көеп китте.

Раузаның әйткәне ихлас тоелды Айсылуга. Укыган җирендә дуслашкан егете була торып, Сынтимергә күңел салып йөрмәс инде.

Ахирәтенең уен белгәндәй, Рауза үзе дә әйтеп куйды:

—Рауилым бар ла минем. Бер күрүдән гашыйк булдым аңа.

Шулай диде дә тынды. Йоклап китмәгәндер, ә Рауил хакындагы хыялларына чумгандыр, дип төшенде Айсылу, чөнки үзенең дә тамчы йокысы килми иде. Кырлач танаулы егет урлаган иде аның йокы фәрештәсен. Әллә, Рауза сыман, Айсылу да бер күрүдә гашыйк булдымы? Шул агайга?! Ә агай гимнастерка кигән ыспай егет кыяфәтендә күз алдына килә дә баса, килә дә баса иде...

Иртәгәсенә Рауза авылына кайтып китте. Айсылу үзенә урын тапмый аптырады. Әнисе дә сизде бугай, юаткандай итте:

—Куш кендекмени үзегез, ә? Калдырыр идең тагы берәр көнгә Раузаны, йә иярәп китәр идең Бозаулыкка, дим.

Юк, Бозаулыкка да юлланмады Айсылу, өй эчендә дә кәләп салмады, ә көтелмәгән бер шөгыль табып алды: башланмаган күн тышлы калын дәфтәре бар иде, саклап кына тота иде, шуны ачып, көндәлексыман әйбер язарга

тотынды. Тәүге битенә Мәдинә дәү әнисенен ин сагышлы чакларында көйләгән жырын теркәп куйды: "Карчыгадан качкан суна үрдәк толка тапмас жикән камышсыз..." Ни өчен нәкъ шушы жыр килде хәтеренә, ни өчен шушы, үзенә бер кагылышы да булмаган сыман сүзләр язылды дәфтәренә?..

Арытабан ул уналты яшьлек гомерендәге ин истәлекле вакыйгаларны тезеп чыгарга ниятләнде. Дәү әнисе сөйләгән тарихларны да түкми-чәчми тасвирламакчы булды. Һәр тарихка исем дә кушты үзенчә хәтта. Мәсәлән, "Ай мәзәге" үзе бер уймак кына хикәя сыман килеп чыкты.

"Безнен бер абзыйны Стәрле базарыннан базарлап кайтышлый, ике бүр таламак иткән. Ат менгән булган, артыннан төшкән теге юлбасарлар да сыбайлы ди. Әй куышалар, әй куышалар икән, безнеке шунда, жан-фәрман ат чаптырып барышлый, игътибар иткән: ун яктан аны зур утлы шарсыман әллә нәрсә тотам калмый бастыра ди! Юл урман аша булгач, теге нәрсә агач арасыннан елт-елт күренеп, сикереп-сикереп чаба, имеш. Шунын тәэсире нык булгандыр, безнеке бүрләрдән куркудан арынган, ничек тә ике хәвефтән берьюлы котылу хакында уйлый башлаган. Әһә! Атына артмаклаткан капчыкларнын берсендә вак тоз бар, түш кесәсендә тарттырылган борыч каплары—үчләп торып сипкән тегеләрнен күзенә тозын тозча, борычын борычча: тәмам куып житкән, ди, бит алары. "Мә, сезгә!"—атлары киткән дулап, үзләре киткән чәчрәп егылып—борыч, күзенә кереп алса, нишләтергә белә инде! Котылган бүрләрдән безнеке. Атын жайлата төшкән. Ә теге утлы шар барыбер торып калмаган, анын унаена, шәбәйсә шәбәеп, жайласа жайлап, килә биргән. Артында тояк тавышы ишетелмәгәч, ачыклыкка да килеп чыккач, безнеке бөтен рухын жыеп, атынын башын унга борган, туктап, туп-туры теге "әллә нәрсә"гә караган. Илаһикайлары—аны өзәрлекләгән хәтәр шар күктәге Ай үзе икән ләса! Якты жисем аны бастырмаган, әләйсән, ә иптәш булып, юлдаш булып кына ияргән, рәхмәт төшкере. Әллә япа-ялгыз күктә моная торгач, Ай бер шаярып алырга, мәзәк итәргә булган микән?.."

Айсылу хикәятләрне дәү әнисе ничек сөйләсә, шулай язды, кайсыбер төштә генә заманчарак сүзләр кыстыргалады, ә гамәлдә төп нөсхәдә калдырды. "Безнеке"—Өчтатар урамыннан берәү,—дигән иде карчык,—исеме әллә минем истә калмаган, әллә Динислам да (ул сөйләгән иде) әйтмәгән—бик борынгы тарих бит..."

Кызынын баш күтәрми язышып утыруына әнисе генә түгел, көне буе ферма эшендә йөреп өйгә сон гына кайта торган һәм шунлыктан Айсылунын ни рәвешле вакыт уздыруын бик белеп тә житмәгән әтисе Жәмил агай да игътибар итте: чәченнән генә сыйпап иркәлим дигәндә, дәфтәренә дә күз салды, кызыкай ике кулы белән язганын каплап өлгерде.

Каплар да шул. Тап өченче көн клубта күргән егет тәнгәленә килеп житкән иде көндәлекнен юллары. Эре генә хәрефләр белән "Сынтимер" дип язып утыра иде.

Шунда нокта куеп торды. Фикерләре әле тупланып өлгермәгән иде. Инде анын Раузага гына түгел, капылда гына көндәлек битенә дә ышанып күндермәслек сере бар иде—йөрәк сере. Күн тышлы калын дәфтәрен ябып, китаплары арасына яшерде.

• • •

Сөенечле уйлар белән мавыгып сизми дә калган, аяклары Айсылуны ни арададыр Зөлганифә тутакайнын капкасы төбенә китереп бастырган ласа. Бәй... Ярар, әйбәт булган да, бер унайда карчыкнын әз-мәз эш-көшен бетерешер.

Тутакай суган бакчасында әллә түтәл тырмап булыша? Бүгенме-иртәгәме кар явам дип торганда... Айсылуны күреп тә калды, сүзен дә тезеп жибәрде:

—Әһә, балакай, каникулында да килмәсәң, орышам үзенне, дип жилкенеп йөри идем, бер дә һич... Менә, Сынтимер оланыбыз бакчамны казып, түтәл ясап бирде әле, шуны тырмап йөрүем. Жир туңмас борын сарымсак утыртмакчы идем. Соңладым да инде... Ярар, көз үзе дә соңлады быел. Ничек кенә эшкә тотыныйм, дип торганда, килеп життең, рәхмәт төшкере, "ә" дигәнче төртеп чыгасың син аны, бер түтәл нәрсәне.

Әлбәттә, тиз үк утыртты сарымсакны Айсылу. Шуннан өйгә керде, Зөлганифә тутакайның самавыры кайнап та чыккан иде. Икәүләп чәй эчтеләр. Карчыкка кем беләндер чөкердәшеп ризык жыю үзе бер бәйрәмдер, күрәсең, куанычы эченә сыймады. Үзе туктаусыз тәтелди. Сүз уңаенда әллә ничә кат "Сынтимер оланыбызны" телгә алгалады, Айсылуга сәер генә (бәлки, шулай тоелгандыр) карашлар ташлагалады. Барыбер дә тутакай беркатлы ул, риясыз ул, дип уйларга да өлгермәде Айсылу, карчык эчендәген әйтеп тә ишеттерде, күттермәде:

—Бер хыял-ниятем бар әле минем, балакай. Ахирәткәем, Гөлмәдинәкәем, китеп барды шул, икәүләп аткарыр идек тә ул ниятне... Сынтимер оланыма яр ярәшергә дигән изге уем бар иде.

—Яр?!

Тутакай, Айсылуның көтелмәгән хәбәрдән аптырап калуына жавап иткәндәй, өстәп куйды:

—Гыйшык тотышырга гына димәгәндер безгә сезнең токым белән, кавышырга да язгандыр, иншалла.

Айсылуның күз алдына тезелешеп гашыйклар—Асылгужа вә Сөмбел, Гыйндулла вә Зөлганифә, Динислам вә Мәдинә килеп баскандай булды...

Яр ярәштерә, колак тешләтә торган заманнар үткән ләса. Әзрәк юләрләнеп тә барадыр тутакай, яше дә ыраган, кайгыны да күп кичергән. "Безгә сезнең токым белән" дигәнен ничек аңларга кирәк? Әллә... Сынтимер белән Айсылуга төбәвеме?!

Менә бер хәлдә—дәфтәр битендә язылган көенчә генә, бимазаламый гына онытылса булмыймы шул Сынтимергә!

Өенә кайткач, Айсылу тагы да әлеге көндәлеген, дөресрәге—күңел дәфтәрен, ачты. Акылы кулына баягы исемне сызып ташларга кушты, ә кулы бөтенләй икенчене эшләде, янә бертапкыр язып куйды: "Сынтимер".

Инде кызның күзләре тик шул чынлап торган күркәм исемнең иясен эзләде, колаклары бары аның хакында гына ишетергә теләде. Ары-бире күргәләде егетне йә урамда, йә тутакайларда. Сүз катышырлык танышлар да хәзер алар. Хәбәрләр дә булып торды: имеш, Сынтимер Мәжит дигән егет белән бергә читкә чыгып китәргә жыена. Мәжитне белә Айсылу, Тегермән урамыннан ул. Язга армиядән кайта шикелле, Сынтимергә нәселдәш, бугай.

Сынтимернең уе арытабан укырга керүдә булгач, китаплар караштырды, урыс теленең грамматикасын кабатлады. Бүтән фәннән курыкмый иде ул, ә урыс телен йомшаграк белә. Китаптан укып кына үзләштерү авыр бит чит телне, аралашу даирәсе булмагач. Казандагы университетка жибәрәм документларымны, дигәч, туган-ыруы икеләнеп тә калды: ай-һай?! Сынтимер аларны тиз тынычландырды, укырга керә алмасам, эшкә урнашырмын, башны хур итмәм, диде. Солдат хезмәте аңа өч ел буе ныклы гәүдә генә бирмәгән иде, ә дөнья тапкырында киң мәгълүматка ия итеп, иксез-чиксез Жир дигән планета офыкларын да ачып кайтарган иде. Ул үзендә тормыш давылларына каршы тора алырлык куәт, яшь кешегә хас йөрәк жилкенүе генә түгел, ә эчке бер рухи көч тә тоя иде.

Өмә итеп салынган йорт-каралтының бөртекләп эшлисе урыннары да әз түгел, Сынтимер шуларны жиренә житкерү белән дә мәшгуль булды. Клубка йөрештерде, кыз-кыркынга күз салды. Иртән, бригадирдан әмер көтешли,

кәнсәләр алдына жыелып гәп саткан авыл агайлары белән аралашудан да жан азыгы тапты. Ә бит ул армиядә йөргән әз генә бер арада авыл нык үзгәргән иде—"Хрущев заманы" дип атап куячаклар бу чорны киләчәктә. Бер карасаң, яхшыга да сыман әлеге үзгәреш: кешеләр иркенрәк тын алгандай. Кире яклары да бар: әлмисактан бирле арыш үскән басуларга кукуруз чәчү килешкән эш түгел, өлгерми дә ул, чи көенә урыла. Арышка, бодай-тарыга төс бирә Агайтуган басулары, их, Никита Сергеевич, шуны да белми икән, тап-такыр, йоп-йомры башы белән!

Әйе, югарыда утырганнарның да пәйгамбәр түгеллеген аңлаган, аларга тел тидерергә дә мөмкин, дип уйлаган буыннан иде Сынтимер. Һәрхәлдә, бу буынның аерым шәхесләре, киләчәк ярына өр-яңа күперләр салачак вәкилләре төсмерләнеп килә иде аның йөзендә...

Сынтимер клубка беренче баруында ук күреп калган иде, күзгә чалынмаска тырышыптыр, бер читтәрәк торган оялчан кызны. Оялчан дисәң, карашлары кыю үзенең, капыл гына, кырыйлатып кына күз атты егеткә, очкын сирпегәндәй итте, сискәндерде. Танцыга чакырырга иткән иде, ахирәте алдан йөгереп төште.

Тагы да Зөлганифә тутакайларда очраштылар. Баксаң, ул армиягә киткәнче үк белгән Айсылу икән ләса—Мәдинә әбинең оныкасы. Дәү әнисеннән тотам калмый йөри торган иде, тутакайга су ташып бирә иде. Шул кызыкай үсеп житкән, шаккатмалы үзгәргән. Тутакайларда иркенләп карады тегенә, буй-сынын, йөзен—күзе белән тоташ сөзеп чыкты: сылулыгы белән су буйлатыр бу! Авыл кызларына бик хас булмаганча, буйчан гәүдәле, аяклары болай базык, төз генә, юка күлмәгенең итәге аша үтә күренеп тора. Кыз шуны сизде булыр, бит очлары кызарып китте. Оялу килешә икән үзенә тагы. Карап туймады Сынтимер аңа. Куллары тутакай юнәтергә дип китереп тоттырган чәйнүкне тегеләй дә болай әйләндерде, ә күзләре Айсылу ягына карады да торды. Кызны тутакай гөбәдия пешерешергә үгетләгән иде, әле ул шуңа эчлек әзерли. Дөгене бөртекләп сайлап алды, бөртерергә суга салды, бер савытка яшь чогырт әзерләп куйды. Тотынышлары житез генә. Башын кырын салыбрак алган—харап ихлас кылана. Ә муены нинди купшы икән, аккош муены дисәң дә артык булмас... Шунда Сынтимернең кулыннан чәйнүк ычкынып, кәлтердәп тәгәрәп китте. Исенә килде, кызның сылу муенына, их, иренне тидереп кенә алырга, дип үе белән ымсынып кына торуы иде лә. Каушап калуыннан файдаланып, Айсылу да күзен егеткә йөгертте: чәчләре шырт та, бөдрә дә түгел икән, дулкынлы икән. Дулкын-дулкын кара чәчләре чыраена бигрәк килешә ләса. Кара чәч, кара каш, ә бите—каракай...

Зөлганифә тутакайның чал башына берләтә бер уй килде: боларның мәхәббәте кара-каршы булмакчы—"мәгашака" дияр иде борынгылар.

—Оланым, булмаса, мә, курай тартып алчы,—диде тутакай, Сынтимернең бүген барыбер чәйнүкне юнәтә алмавын күреп тора бит.

Гыйндулласыннан калган комартклы ул—курай. Сынтимергә, мәктәптә курай тартырга өйрәнгәндә, ялынып сораса да, бирми торган иде. "Сөйгән сөягемнән бердән-бер истәлек, үзем үлгәч, васыять—сина булыр",—дип кырт кисә иде. Ә өендә уйнарга рөхсәт, килеп комарткы курайны сыздыртып-сыздыртып китә торган иде Сынтимер. Зөлганифә тутакай, бөтен эшен ташлап, әле юньләп көй дә чыгара белмәгән малайны тыңлап утырыр иде. Шулай өйрәнде дә Сынтимер курай тартырга, нык кына остарды.

Әле килеп, Сынтимер тутакайга, "коткардың" дигән сыман, рәхмәтле карап куйды да курайны кулына алды. Ихтирам йөзеннән башта курай иясенең көен уйнап жибәрде, хәтерендә көйнең сүзләре янарды: "...Дөньяларны гизеп бер урадым, синең сыман асыл жир сирәк". Белми иде әле егет бу жырны киләчәктә ничек еш искә төшерәчәген, бәгырь ите береккән Агайтуганың

сагынып нинди күңел газаплары кичерәчәген.

Сынтимер туры басып, күкрәгән киереп, дулкын чәчләрен артка ташлап көй тарта, ә Айсылуның күзләре аның курай уемнары буйлап йөгергән бармакларына иярә. Һичкенә дә авыл тормышында, балта-көрәк тотып үскән кешенеке димәссең, сыгылмалы озын бармаклары егеткә, әйтерсең, курай уйнар өчен генә бирелгән. Аксөякләрдә генә буладыр ласа андый матур бармаклар... Һәм шулвакытта кызның булмышы моңынчы кичереп карамаган тойгылар кодрәтенә тарыды, әллә нинди татлы ләззәттә эреп талыкты. Егетнең матур бармаклары тотанаклы бер наз белән аның чәчләрен тарагандай итә, сизелер-сизелмәс кенә кагылып, битләрен, муенын иркәли. Өркетми бу бармаклар, ә сөя, әсәрләндерә, илаһи нурга коендыра...

Мәгашака яшь йөрәкләрдән ургылган хисләр дәрьясына мәхәббәт алиһәсенең канаты тиеп үткән сихри бу минутларга ирексездән шаһитлык кылып торды Зөлганифә карчык. Сынтимер белән Айсылуның язмышлары кушылырмы бу хис-дәрьяга? Әллә кара-каршы ике яр сыман, мәңге аерым һәм шул ук вакытта мәңге бергә калырлармы? Уртада аккан гомер елгасына, вакыт-вакыйгалар ташкынына, дәвер агышларына карап, очрашмас тәкъдирдә ерак та, югалтышмас тәкъдирдә якын да булып яшәү насыйптыр, бәлки, аларга?

* * *

Кыш тиз үтте, әллә юри шулай итте? Сынтимер балта осталары белән бура бурап акча эшләп кайтты. Аңынчы яз җитте. Колхоз чәчүгә төште. Көннәр, күчәреннән ычкынып түбәнгә җилдергән тәгәрмәчтәй, елдам тәгәрәде. Мәҗит кайтты. Мәктәптә имтиханнар башланды. Соңгы имтиханын тапшырып кайтуга Айсылуны өйдә хәбәр көтә иде: Сынтимер Казанга киткән. Берүзе киткән. Мәҗит карышып торып калган. Ярәшкән ярыннан, Нәфисәсеннән, аерылырга йөрәге җитмәгәндер егетнең.

Зөлганифә тутакайга йөгереп барган иде, анисы әллә нигә кырыс торды. "Укырга керер, керә алмаса, эшкә калыр",—дип коры гына әйтте дә: "Кайтмас",—дип кырт кисте. Айсылуның үзәгендә дә нидер өзелгәндәй булды, соңгы сүзне ишеткәч.

Уникe елдан соң, гомеренең соңгы көннәре җиткәндә, исенә төшерде шул кырыслыгын тутакай. Училищедан соң зур булмаган бер шәһәрдә башлангыч сыйныфларда укытып йөргән Айсылу карчыкның каты сырхаулавын ишетеп, авылга кайткан иде.

—Булмастайга өметләнмәсен, дигән идем сине, аһ, балакай! Гомереңне зая уздырма, тормышлан, ялгышмасам, яшең утызга җитеп киләдер ләса?—дип үзе башлады Зөлганифә тутакай.

—Ә ул... ул өйләнгәнме?

—Буйдак йөри һаман да. Мәҗитнең, әнә, ике баласы үсеп килә. Ә син Сынтимер дип барыбер дә җан атма, балакай. Язмагандыр... Хатларында ул синең хакта сораша сорашуын, онытмый. Әмма... Ир-ат илледә дә унҗиде яшьлек кызны карата ала, ә утырган кызның уты тиз сүрәнләнә. Минем сыман булма, ялгыз калма берүк!

Үзенчә шулай үгетләп алды да карчык, юк хәлен бар итеп, түрдә, чемәрле сандыгаяк өстендә утырган сандыгын ачты.

—Сиңа бер һәдиям бар, Гөлмәдинәм оныкасы, мә, кабул кыл, үз кулым белән тапшыруыма шөкерана кылам. Гыйндулламның кураен, Динисламд дәү әтисенең бөҗәкләрен Сынтимер оланыма васыять кылдым, кайтып өлгермәс шул үзе... Мә, төсем итеп күр, тәләф итмә.—Үзенә әнисеннән, бәлки, дәү әнисеннәндер дә, мирас булып калган матур калфакны тутакай аңа сузды. Айсылу бу затлы әйберне бәләкәй чагында күреп бер һушы киткән иде.

Кызыл мәрҗән басылган, ак энҗе белән бизәлгән калфак инде аның кулында—тик шатлыгы юк шул зәвыгын кинәнерлек бу бүләкнең. Калфак Айсылуныкы була да бит, кадерле кешесе, дәү әнисенең бер сынары Зөлганифә тутакай аны ташлап китә шул!

Хушлашып, бәхиллек алып, иртәгәсенә үк Айсылу кире юлланды. Укытучы кешегә сәгать калдырып йөрү килешми бит. Их, белсә икән ул юлда каршыга очраган автобуста Сынтимернең кайтып килүен—белмәде шул... Сынтимер дә белсә икән Айсылуның китеп баруын, туктатыр иде бит, кире борыр иде—бер генә көнгә, сәгатькә, ичмасам, минутка гына булса да. Ә, бәлки, язмышларын да башкача хәл итәр иде ул минут...

V

Авылдан әйләнеп килүенә, мәктәпне генә түгел, ә бар шәһәрне тетрәткән вакыйга хәсрәте чорнап алды Айсылуны. Ул укыткан өченче сыйныфтан бер бала асылынып үлгән. Тугызын гына тутырган сабый үзенә кул салган... Артур исемле малай, укуы уртача гына, әмма рәсем төшерергә сәләте бар иде. Арытабан да шулай мавыкса, рәссамлыкка укырга кирәк булыр ана, дип уйлап, төсле каләмнәр, буяулар алып бирергә ният итеп тә йөри иде ана шулвакыт Айсылу. Өлгермәде. Артур күрше малайның акварель буяуларын урлаган—бик күзе кызгандыр сабыйның.

Өлгермәде Айсылу. Өлгерсә, бала бу кылыкны кылмас иде, гөлдәй гомере өзелмәс иде. Күрше малайның әнисе, ичмасам, мәктәп директорына да түгел, туры милициягә йөгермәс иде, эчүдән айнып карамаган ата ишарәте улын су эчкесез итеп тукмап ташламас иде, "Артур бур" дигән хәбәр белән мәктәп тулмас иде. Иде, иде!..

Артур оялуын, куркуын җыйнә алмаган. Исерек ир белән житешсез тормышта хурланып яшәүдән мингерәүләнгән әнисенә аркалансынмы да, "Төрмәгә утыртам, җинаятьче!" дип тузынган күрше ападан мәрхәмәт көтсенме сабый? Укытучы апасы Айсылуга, мөгаен, ачыла, сыена алыр иде дә—ул да юлда булып калды.

Авыр минутларында гадәт иткәнчә, Айсылу уйларын көндәлегенә теркәде, үзенең үкенечләрен, кешеләрнең каты бәгырьлелеген ярсып-ярсып тасвир итте. Күн тышлы дәфтәре күптән тулган иде, яңаны ачты, шунда язды. Алай да күңеле басылмады. Юк, болай гына, үзенә бикләп-бастырып кына, дөреслекне табып булмыйдыр, башкалар да борчылсын, гыйбрәт алсын—шулчакта гына җәмгыятьне хаталардан йолып калырга мөмкиндер. Шулай зурдан уй йөртте дә язганнарын шәһәр гәзитенә алып барып тапшырды Айсылу.

Укытучының мәкаләсе халыкны, әйтерсең, йокысыннан уятты. Гәзиттә бер-бер артлы төрле фикерләр басылды, мәктәпләрдә җыелышлар үткәрелде, гүя ниндидер көчле саф агым тончыгып барган күлне кузгатты.

Әлеге мәкалә Айсылуның язмыш елгасын да яңа үзәнгә күчерде: аны гәзиткә эшкә чакырдылар. Ризалашты. Артур белән булган хәлдән соң ул үзендә мәктәптә арытабан эшләрлек көч таба алмый тора иде... Ана, тәрбияле кешеләргә хас булганча, югары исәптә намус тойгысы бирелгән иде. Гамәлдә гөнаһсыз бер сабыйның гомере кыелган—Айсылу гаепле; шуна сәбәпче булган кешеләр өчен—ана оят; җәмгыятьтә иман какшаса,—ул да шәхсән җаваплы.

Шушы сыйфатлары Айсылуның язганнарында да ярылып ятты. Үткер сүзгә, яңа карашка сусаган халык аны тиз үк үз итте, гәзитнең тиражы артты. Әмма халыкның сөюе югарыдагы хуҗаларның мөнәсәбәтенә капма-каршы иде. Чөнки Айсылу Җәмил кызы Нәдершина илдәге күп житешсезлекләрнең житәкчеләрнең пошмаслыгы, эшне белмәүләре, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртулары аркасында икәнлеген дә аңлый һәм укучыларына аңлата иде. Әлбәттә, бу

ошамады түрәләргә. Беркөнне гәзит редакторы партиянең шәһәр комитетыннан сөмсере коелып кайтты да Айсылуны бүлмәсенә чакыртып алды.

—Нәдершина,—дип башлады редактор (каты сүз әйтергә булса, гел шулай рәсмиләнә ул),—син читтән торып укыйсың бит әле?

—Әйе, укыйм,—дип аптырап калды Айсылу.

—Нинди факультетта әле?

—Тарих факультетында.

—Тарих укытучысы булачаксың, димәк.

—Димәк.

—Ә безгә журналистлар кирәк.

—Безнең университетта журналистика факультеты юк.

—Казанда бар.

—Ул бит Казанда...

—Кыскасы, Нәдершина...

Айсылу хуҗасын кыен хәлдән коткарды, тыңлап бетермәде, бүлмәдән чыгып китте. Редактор үзе ару кеше ул, җирле юктан гына шәп хәбәрчедән колак кагарга теләп тормыйдыр да—кушканнар, нишләсен.

"Казанда бар"—редакторның юк сәбәпне бар итәр өчен генә әйткән бу сүзе Айсылуның күңелендә тулышкан хис-хәтер буаларын ерып җибәрде. Тотып тыйгысыз уй дулкыннары күз ачып йомганчы ерак Татарстан тарафларында яшәгән Сынтимергә, йөзәр чакрымда яткан Агайтуганга тәгәрәп барып җитте. Хатларында сораша ди бит аның хакында сөйгәне, онытмаган ди...

Эшләгән өстәленнән әйбер-фәләнен алып, берчә аның киткәненә пошынып, берчә үз вазыйфалары өчен хафаланып калган хезмәттәшләре белән хушлашып чыккач, Айсылу почта бүлекчәсенә юнәлде. Әтисе белән әнисенә телеграмма сукты. Бер генә сүз язды ул: "Кайтам!"

Атна-ун көн дигәндә кайтып та төште. Атна-ун көн эчендә шушы араларда җан тынычлыгыннан яздырган бер мәсьәләне дә хәл итте. Артурның әнисе утыз ике генә яшендә вафат булып куйды, җиде яшьлек кызы, дүрт яшьлек малае калды. Айсылу элек тә аларга баргалап, ярдәм иткәләп йөри иде, әниләре үлгәч, ешлады. Ата ишарәте беркайда да эшләми, туктамый эчә. Житмәсә, өйдәге әйберләрен чыгарып аракыга алмаштыра башлады. Балаларга тәмам ятим төсе кереп бетте. Карамакка юаш кына күренсә дә, тегүче һөнәрендәге әниләре һаман да өсләрен бөтен, тамакларын тук йөртә иде әле. "Ата—җизнә, ана—казна" дигәннәре борынгыларның рас килә шул. Хәер, киресенчә булган очраклар да аз түгел, ике ел чамасы журналист булып эшләү чорында күп күрде Айсылу төрле хәлләрне. Һәм күбрәк күргән саен үзенең тормышны әз белүен ныграк аңлый барды...

Артурның туганнары өчен бигрәк өзгәләнде Айсылу. Ни дисәң дә, ниндидер аерым, ныклы җепләр буладыр ул кешеләрне бер-берсенә бәйли торган. Йә кайгыдан, йә шатлыктан тукылган җепләр. Айсылуны бу гаиләгә кайгы якынайтты. Иң элек ул балаларны эчкече атадан аеру хәстәрен күрде. Махсус комиссия шулай хәл итте: балаларны дәүләт карамагына бирергә, аталарын эчкечелектән дәвалау учреждениесенә озатырга.

Аңынчы Айсылу кызыкай белән малайны—Әнисә белән Шатморатны—үзенә кунакка алып кайтты. Кечкенә кунакларын телевизор карарга утыртты да йөгереп йөреп ашарга әзерләргә тотынды. Әллә нишләп дулкынланды үзе. Өч кешегә дип мул итеп ботка пешерде, өеп икмәк телде. Өстәлгә өч пар чынаяк тезде. Күз яшьләренә ирек бирде—дөньясы түгәрәкләнгән, өе нурланган кебек тоелды да, шул тәкъдирдән елады да куйды. Ә инде баштарак тартынып, шымып утырган Әнисә белән Шатморатның чәй эчкәндә чишелеп, иркенләп китүләре нинди куаныч иде Айсылу өчен—әйтеп тә аңлатырлык түгел. Моңынчы һич таныш булмаган тойгылар какты күңел ярларын һәм ул әлегәчә бикле булган ишекне чак кына ачып эчкә, ят бер дөньяга йөгерек кенә күз

ташлагандай итте. Ә инде кичен... кичен аны бөтенләй гаҗиз калдырган күренеш булды. Күренеш, дисән, дөрес үк тә булмас иде, кичереш, дип әйтергә кирәктер. Иң дөресе исә—кичерешләр.

—Апа, агай исереп кайтып сине тукмаса, безне урамга куып чыгарса?

Әнисәнең бу сүзенә Айсылу башта аптырап калды.

—Нинди агай?

—Ирен сон.

—Ирем? Ә, ирем юк минем.

—Үлдеме? Аерылыштыгызмы?

Менә сина, җиде яшьлек кызчык ничек төпченә.

—Ирем юк, дидем ләсә.

—Апа, бик акыллы эшләгәнсең әтү, иргә бармый. Мин дә бармаячакмын!

Айсылу бер сабый белән бу җәһәттә сүз озайтып тормады, шалтыр-шолтыр китереп савыт-саба юа башлаган булды.

Шатморатны ул диванга йокларга салды, ә Әнисәне, караваты берәү генә булгач, үзенең янына алды. Әнә шунда дучар булды да инде ул бу көндәге иң гаҗәеп кичерешкә. Кызыкай тиз генә йоклап китте. Ләкин йокысы тыныч түгел иде, дертләп-дертләп ала, теге юньсез атаның кычкырыну-сүгенүләреннән коты очып беткәндер, күрәсең. Шуны уйлап, Айсылуның йөрәге чеметеп алды, баланы үзенең түшенә елыштырды, юрганны аркасына ябып куйды. Бала, ана назын тойгандай, изрәп китте, иреннәрен чәпелдәтте. Инде Айсылу аның мендәргә сибелгән чәчләрен рәтләп, башын сыйпамый түзә алмады. Һәм күкрәк түрләрендә әллә нинди кайнар һәм миһербанлы, ләззәтле ташкын айкалганын сизде ул шунда. Чын итеп таныргa кыюлыгы җитмәсә дә, әйе, бу—аналык тойгысы уянуы иде.

Шул мәлдә башында тәвәккәл уй туды, балаларны үзенә тәрбиягә алырга дигән теләк уянды. Көн дими, төн дими язышырга, дежур итәргә туры килгән командировкалы гәзит эше дә хәзер киртә булып тормый, ниятен гамәлгә ашырырга юл ачык.

...Җәмил агай белән Камилә апа ике бала җитәкләп кайтып төшкән кызларына карап авызларын ачты да озак яба алмый торды.

—Саумысыз, әтәчегез кукәй салган, нигә чыгып алмыйсыз?

Айсылу гелән шулай җайлы гына әмәлен таба ул кешене уңайсыз халдән арындырырга, дип куанган әтисе беренче булып телгә килде:

—Саумы, кызым, саумы, әйдүк.

Әнисе һаман һушына килә алмый азаплана иде, ә күзләре—мөлдерәмә тулы аптырау, мөлдерәмә тулы сорау. Итагатьле ул Айсылуның әти-әнисе, Мәдинә табибә калдырган әдәп калыпларын бозмаслар, тота килеп сорау ала башламаслар. Әзрәк баш-күз алгач, чәй эчкәч, аңлашырлар.

• • •

Авылдашларына икеле-микеле уйлар йөртергә юл куймады Айсылу, барысын да ачыктан-ачык әйтеп бирде. Әлбәттә, халыкны җыеп хәбәр сөйләп тормады, моның кирәге дә юк иде, чөнки агайтуганлыларның Алмакай белән Хәлекәй атлы хәбәр ташучылары бар иде. Ирле-хатынлы бу ике мәзәк җан өйдән-өйгә юачалап йөриләр. Алардан берәү дә ялыкмый, чөнки дә Агайтуганны өй борынча йөреп чыкканчы әллә ничәмә тәүлекләр үтә ләсә. Ул арада Алмакай белән Хәлекәй байтак хәбәр җыеп өлгерә, үзләренчә бер катлы шуклык белән күпертеп, таратып та җибәрә. Аларны һәркем сыйлап, кием кидереп чыгарырга тырыша, чөнки дә мөселманда әүвәл-әүвәлдән мәзәк иярләренә якты йөз күрсәтү, хәер-хаклы булу мәртәбә саналган.

Алмакай-Алмабикә—шушы авылныкы. Акылга әзрәк зәгыйфьрәк булгач, кияү чыкмаган, шым гына өйдә утырган ул. Берзаман әллә кайсы яктан, аның өлешенә көмеш булып, Хәлекәй-Хәлиулла килеп төшкән. Бу сәер мосафир авыл әйләнеп йөрергә, шулай көн күрергә гадәт иткән, имеш. Ары китәр иде дә, Алмакайны очраткан шул—өйләнешкән дә куйганнар: чиләгенә күрә капкачы. Агайтуганлылар аларга ыспай гына өй салып биргән һәм менә, бихисап вакыт, яшәп яталар. Үзләренә күрә кәсепләре дә бар...

Әйе, авылның сөекле диваналары Айсылу кайткан көнне дә иртүк, эшкә баргандай, авыл буйлап төшеп киткән иде. Һәм аңа әнисе белән әтисенә бер кат, күрше-күләнгә икенче кат, таныш-тонышка өченче кат сөйләп торырга кирәкмәде хәл-әхвәлен, энә белән җеп сыман тагылышып килә салып кергән Алмакай белән Хәлекәй алдында бер генә таратты сүзен һәм, шиге юк, авылдагы бөтен колакка да, түкми-чәчми, яшен тизлеге белән барып та керер таратканы.

Чынлап та, диваналар, Айсылу аларга дип атап алып кайткан бүләкләр белән, Хәлекәй—бәрхет түбәтәе, Алмакай—ефәк яулыгы белән мактанып, Агайтуганны зыр әйләнеп чыкты. Һәм барысы да Мәдинә табибә оныкасының авыл күзеннән читтә узган язмышын белеп тә куйды. Шунсы гаҗәп: Алмакай белән Хәлекәй бер-ике кәлимә мәгълүматтан да тоташ бер хикәят ясый. Әмма уйдырма булмый өстәгәннәре, ә чын була—әллә күрәзәлекләре бар ул Ходай бәндәләренең? Менә Айсылу да гәзиттән ни өчен киткәнен әйтеп тормаган иде: белгәннәр—дөресен язганга сыйдырмаганнар, дип әйткәннәр. Бәлки, туры сүзлелекнең Айсылуга нәселдән күчә килгәнлеген тоемлаганнардыр, дивана дигәч тә, исәр түгел лә алар, ә беркатлы күңел хәятләре бәгъзе акыллыныкыннан нечкәрәктер дә әле... Зеркеннәргә "безнең Айсылуны берәү өч тапкыр сораткан, ул бармаган" дип сөйләп киткәннәр, үзләренчә тегеләрнең "ир чыкмаган" дигән сымаграк ләчтитенә киртә куйганнар, ахрысы. Ә бит хак, булды андый "берәү", озак өметләнеп йөрде...

Айсылу әйтеп бетергесез кинәнеч кичерде бу көннәрдә. Туган ягының бала чактан үз ителгән табигатеме, таныш һәм якын кешеләрнең якты чырайларымы, әллә каз бәбкәләредәй артыннан ияреп йөргән ике баламы—аның җанына тынычлык бирде, сулышын иркенәйтеп җибәрде. Арытабангы язмышы ун гына булырдай тоелды. Эшлим дисә, эш табылды: Шәяхмәт агай өч-дүрт ел инде пенсиядә, үзенә алмаш көтеп зарыккан икән, Айсылуга үзе үк үтенеп килде, урыныма кал, ди. Ә мәктәп директоры булып сабакташы Хәйдәр Латиповны куйганнар икән. Әйе, теге тигәнәк Хәйдәрне... Хәзер инде ул—Хәйдәр Хатипович. Армиядән сон туры институтка кереп киткән, дип ишеткән иде. Ул елларда егетләрне, аеруча хезмәт итеп кайтканнарын, конкурссыз алдылар. Хәйдәр дигәч тә, далансыз түгел икән үзе. Укуы да әллә ни хөрт түгел иде анын, ә ныкышлыгы—өчәүгә җитәрлек. Әнә бит, яна мәктәп салдырган, нидидер юлларын табып, күрше авылдан йөреп укучы балалар өчен интернат ачкан. Кулыннан килә, димәк, директорлык.

Хәйдәргә эш сорап баруны Айсылу сонгаракка калдырган иде: әле июль башы гына, вакыт бар. Анарчы директор үзе килеп керде Айсылуларга. Бәрәкәт, ничек буйга калкуланып киткән бит сабакташы!

—Мөхәммәт тауга бармаса, тау Мөхәммәткә үзе килә, диләрме әле? Саумы, Айсылу!

Хәйдәр шулай ишек төбеннән үк шаулап, шат тавыш белән сүз башлады. Анын бөтен кыяфәте ихлас сөенгәнен белдереп тора. Кулында чәчкә гөлләмәсен дә күреп, Айсылу сәерсенеп киткән иде, сабакташы әйтергә ашыкты:

—Туган көнең белән! Менә, үзебезнең мәктәп бакчасында үскән чәчкәләрне бүләк итәм.

Шулай диде дә гөлләмәне Айсылунын кочагына куйды. Чынлап та, учка гына түгел, кочакка сыярлык күркәм гөлләмә китергән иде Хәйдәр. Патша

бөдрәләре, тырнак гөле, яран гөле, тагы әллә ничәмә төрле чәчкәләрнең тажлары Айсылуның түшенә, битенә иркәләнде, хуш исләре өйгә таралды.

—Бәрәкәт, әйтмәм дигән идем: туган көнем шул бүген!—дип канатланды ул, кочагындагы гөлләмәгә куанганын яшерми.

Шул минутта Камилә апага ияреп килеп кергән балалар да, башкортча аңлаулары юк кимәлдә булса да, бәйрәм кәефен тоеп калдылар, икесе ике яктан барып Айсылу апаларына сыендылар. Хәйдәр аларны күреп һич тә аптырамады, "Әнисә", "Шатморат" дип, берәм-берәм башларыннан сыйпап алды. "Менә бит ул—авыл..." дип уйлап өлгерде Айсылу һәм Алмакай белән Хәлекәйне исләп көлемсерәп куйды: рәхмәт аларга, һәркайсысына бәйнә-бәйнә аңлатудан азат иттеләр. Ә агайтуганлылар белекле кавем, әлегә, бигайбә, шушы ишеткәннәре житеп тора, арытабан—күз күрер.

—Аһ, балам, күрче-күрче мин иссезбикәне, бөртек кенә кызымның туган көнен онытып йөрим, имеш,—дип өтәләнеп киткән әнисен тынычландырыр өчен, ахрысы, Айсылу әйтеп салды:

—Хафаланма, әни, ул тиклем... Әтием эштән кайткач утырып алырбыз.

Кичен, көтү кайткач, сыерны саугач, табын кордылар. Әтисе дә галәттәгедән иртәрәк кайтты, аңа хәбәр жил белән барып житкән иде, күрәсең. Үзе башлагач ни, кунакка Хәйдәрне дә, хатыны, бала-чагасы белән, чакырдылар. Шәяхмәт агайга әйттеләр, ут күршегә эндәштеләр—йоласы шундый. Ике өстәл куярга туры килде. Бер арада килешле генә итеп Алмакай белән Хәлекәй дә кереп чыкты: бу да агайтуганлыларның үз көнкүрешләренә үзләре беркетеп куйган бер йолаларына әйләнеп беткән. Сөекле диваналары да аларның итагатьсез түгел, өстәл артына үтеп, сүз адаштырып йөрмиләр, кучтәнәч алалар да, разый булып, сабыйдай шатланып кайтып китәләр. Сынаганнары бар: шул шатлануларының бер өлешен алар өй эчендә калдырып китә шикелле, табын тагын да мулрак, күңелләр көррәк тоела башлый.

Әле дә шушы сынамыш рас килде. Алмакай белән Хәлекәй кереп чыккач, Хәйдәрнең игезәкләр сыман тип-тиң үсеп килгән ике кызы Әнисә белән Шатморатны ияртеп Каранайны күрсәтергә алып китте. Балалар бер-берсенә тартылды—бу бит зур вакыйга. Дөньяда тиңдәш табу, бергә уйнар дус табу балачакта да бик мөһим ул.

Каранай буена чыгар алдыннан Әнисә белән Шатморат Айсылу апаларына жыр бүләк итте әле. Килештереп инглизчә жырладылар, мөгаен, балалар бакчасында өйрәткәннәрдер. Туган телләрен белмиләр, ә инглизчә жыр ятлаганнар.

Әллә кайчангыны искә төшереп, күңелләнеп алдылар. Әллә кайчан булмый—ике дистәгә якын ел үткән ләса ул чаклардан бирле. Әнә, Хәйдәрнең чигә чәчләре беленеп агара башлаган, мәктәп директоры дәрәжәсенә житкән, ике кызы үсеп килә, Әнисәдән чак кына өлкәнрәкләрдер әле. Айсылу гына, тугазак каз сыман, әллә кайда каңгырып йөргән. Ни укуын һаман очламаган, ни дөнья кормаган, ни бала тапмаган... Кешенең ике баласын житәкләп ата нигезенә килеп баш тергән дә... Әле елаганчы кинәнеп көлгән вакытта бөркелеп киткән күз яшьләре хәзер чигәсеннән елтырап чөберди башлады. Һәм ул үзен-үзе юатырга әмәл эзләде...

"Алай ук жилгә жиленләп, бозга бозаулап йөрмәдең. Шушы балаларны Ходай кулына китереп тапшырган икән, ул сиңа форсат бирә, димәк. Тормыш сынауларын үтмәдең дә түгел, үттең, арка үзәген нык, ышанам, фатыйхамны бирәм". Айсылу аерым-ачык ишетте сыман дәү әнисе Мәдинәнең тавышын шушы мәлдә. Әллә ул, олы жан, оныкасының янында гына өзгәләнеп йөриме?! Фатыйхамны бирәм, диде! Айсылу күз яшьләрен сөртте һәм елмаеп табындашларына карады. Иркенләп әңгәмә тотсыннар, дигәннәрдер, укытучыларны калдырып, күрше-күлән таралышкан иде. Авылда мөгаллимнәргә

элек-электән ихтирам көчле булган ул... Айсылу елмайды һәм бер күз сирпүдә барсын да күреп өлгерде: Шәяхмәт агай ана сынап, Хәйдәр сокланып, Аксылу сагаеп карый иде. Күнеленнән аларга җавап та бирде: "Сынатмам, Шәяхмәт агай! Рәхмәт, Хәйдәр, җылы хисләр саклавына, тиң күрмәде, башканы сөйде, дип, үч тотмавына! Сагай, Аксылу, сагай. Ирен, гаилә бәхетен хатыннар инә бөркет сыман уяу сакларга тиеш. Сагай, әмма миннән күрмәссең хыянәтне. Минем йөрәгемдә һаман да бер исем чыңлый—Сынтимер! "

Һәм, шушы исемнең илаһи чыныннандыр, Айсылуның теленә йомшак сүзләр килде:

—Аксылу, сеңлем, мин турысын әйтергә күнеккәнмен, әйдә, ачыклап куйыйк әле бернәрсәне, дим. Мәктәптә укыганда бер-ике озата килгән дип, шик тотып йөрмә Хәйдәр белән минем уңайда, яме. Балалар бергә уйнасын иде, рөхсәт итсәңче? Кызларынны бер күргәч тә яраттым, үзенә охшап тотанаклылар. Әнисә белән Шатморат әлегә монда ят сөяк, телне дә әлә-сәлә генә беләләр, үзең дә күрдең.

—Уйнасыннар, бәс, Айсылу апа, уйнасыннар бергә. Безнекеләр урысча өйрәнер. Синекеләр дә бәйдән ычкынган балалар түгел сыман...—Аксылу тагы нидер өстәргә әйткән иде шикелле, тыелды. Бик яхшы сүз булмагандыр тел очына килгәне, эчтән ояддымы, яшь хатынның коңгырт йөзенә куе кызыллык йөгерде. Исеме һич кенә дә төс бирмәгән шул, каракай ул үзе. Имеш, бәләкәй чагында аны әтисе Бозаулыкка ияртеп алып барган, шунда урам буйлап китеп барсалар, бер сабакташ малай кайдандыр йөгереп килеп чыккан да: "Аксылу, нишләп йөрисең безнең авылда?—дип сөрәнләгән. Моны шул тирәдә серләшеп басып торган ике апа ишетеп калган да малайның тотып колагын борган, нигә күрше авыл кызына, кунакның йөзен ертып, кушамат тага, янәсе. Кызыкайны күреп торалар бит инде—бите дә, кашы-күзе дә, чәче дә—дөм кара...

—Минекеләрнең аталары эчкече булса да, әниләре сабыр табигатьле иде, аңа тартканнар,—диде Айсылу һәм Аксылуның уен дөрес сиземләгәнен аңлады: тегесе җиңел сулап куюын яшерә алмады.

"Минекеләр" диде Айсылу. Тәүге тапкыр шулай әйтте.

Озакка сузмый, печәнгә төшкәнче, мәшәкать куерганчы, Айсылу балаларны җир-су күрсәтергә алып чыкты. Кайткалап торса да, күптән иркенләп ялан-кыр әйләнеп йөргәне юк иде үзенең дә. Тегермән арасыннан үткәндә Динислам мулла нәселенең төп йортына—Сынтимерләр йортына күз ташлады. Урам як тәрәзәләрдән аңа тамчыгөлнең алсу алкалары сәлам биреп чыңлап куйгандай тоелды. Ак яулык чөйгән бер апа да күренеп калды сыман тәрәзәдә, Сынтимернең әнисе микән? Улы аны үзе белән алып китәргә үгетләп кайтып киткән, диләр, ике-өч ел элек, ризалашмаган. Апаның нәсел тамырлары Агайтуганда шул, Сынтимернеке генә, әнә, кайларда—хәтта ки Казаннарда...

Уф! Белә иде Айсылу, сизә иде—авылда мәхәббәтенең шәүләсе эзәрлекләвен. Белә торып кайтты. Инде мона күнәргә, ничек тә эченә сыйдырып, бавырына урап йөртергә генә кала.

Әнисә белән Шатморат, шәһәрдән чыкмаган балалар ни, шундый канатландылар Агайтуган табигатен күреп, шундый әсәрләнделәр—Айсылу үзен дә бала чагына әйләнеп кайткандай тойды бераз. Шулай булмаса, ике сабый уңаена Шәрәтауның Каранай шарлавыгы сикергән сикәлтәләренә үрмәләп, лычма суга калып йөрмәс иде дә, элек су тегермәне утырган тирәдәге Ташлытүш яланында үсеп чыккан сандыкташларга исе китмәс иде. Ә бит чын—үскән ул ташлар! Элек, Айсылу бәләкәй чакта, алар да бәләкәй иде, билләһи. Хәзер килеп, дәүмәл-дәүмәл сөрәешеп торалар ласа. Заманында, ташын чүпләп ыргытып, монда иген дә чәчкәннәр, шуннан, ваз кичеп, ташлап куйганнар, ташлары әллә кайдан тагы чыгып тик торгач. Димәк, җир куенынннан үсеп чыга ул сандыкташлар—бу да агайтуганлылар өчен гадәтигә әйләнгән бер

могжиза.

Балаларны Шәрәтау түбәсенә дә житәкләп менде Айсылу. Бары тик аннан гына күренә тирә-як авыллар, бары тик тау башында гына кинәя офыклар. Ә күк барыбер якынаймый, һаман югарыда кала, хәтта тагы да биегәйгәнрәк тә күренә, гажәп... Шулай хозур уйлар уйлап торганда Айсылуның хәтер офыклары да кинәйде, һәм дәү әнисе Мәдинә сөйләгән бер хикәят, гүя, күз алдында пәйда булды.

...Гражданнар сугышы чорында Әхмәдулла, дәү әтисе нәселеннән, үзенең иң зур байлыгын, ике кызыл танасын, төпкелгә, Шәрәтау артындагы урманга яшергән ди. Шунда бер китеп барганында, мылтыклы урыслар килеп чыккан да: "Ты кто, белый или красный?"—дип сорау ала башлаган. Үзләренең киеменнән танырлык түгел ди,—акмы, кызылмы икәннәрен. Урысча аңлавы да чамалы, ди, агайның. Алай да әйткән булган: "Красныйга бара маянықы..." Теге зобаныйлар тәмам женләнеп киткәннәр. "Красный?!"—әй жилтерәтәләр икән мескен агайны. Шуннан аны Шәрәтауның текә кыясына алып барып атмакчы булганнар. Ахыр чиктә безнең агай аңгарып калган боларның ни төпченгәнен. Газиз малкайлары башыннан чыкмагач ни, баштук сүзнең аешына төшенмәгән шул. Хәзер килеп төшенгән дә, тик ничек жавапласын соң: ул кызыл да түгел, ак та түгел ләса!

—Кем, дисәгез, әйтәм: мөселман мин, хак мөселман!

Кычкырып торып әйткән агай, биектә торгангамы, тау асманы якынгамы, кайта-кайта яңгыраган ул аваз.

—Мөселман! Хак мөселман!

—Красный мусульманин?!—урыслар шулай диешкән дә мылтыкларын күтәргән.

Әллә нинди чая тәвәккәллек килгән шунда безнең агайга. Тоткан да үзенә үзе әмер биргән:

—Хак мөселман, сикер!

Һәм сикергән. Ә аста—кечкенә генә йомры аклан ди, анда күмәчтәй генә булып берничә кубә күренә ди.

Хак мөселман шул кубәләрнең берсенә барып төшкән, ә аның артыннан чәмләнеп сикергән акларның берсе (хәзер аларның кемлеге беленде сыман) как жиргә килеп төшкән. Үлгәндер, шәт. Тәңре үз жирендә тәпи баскан жан иясенә мәдәт күрсәтмичә, әллә кайдан килгән кемгәдер салам жәеп тормас ласа...

Туган яклары Айсылуның йөрәген кузгатып, жиде йозак белән бикләнгән хисләрен нindидер сихри әмәл белән ачып, азатлыкка чыгарып, сагыш газапларына дучар итте дә үзе үк имләп тә куйды. Шәрәтау түбәсендә аның күңел асманы да күтәрелде, иркенәйде кебек, зиһенендә яңа фикерләр, кан тамырларында көч-дәрман уянды. Авылдашларының балаларына тарих укытыр ул, илнең генә түгел, ә шул илнең аерылгысыз бер өлеше булган Агайтуганның да тарихын чын дәреслегендә аңнарына житкерер. Мин әдәбиятчы түгел, дип хисаплашып тормас, борынгы кыйссаларда яшәгән тарихны да житкерер, географ булмаса да, жир-су атамаларына бәйле риваятьләрне сөйләр—юкка гына дәү әниләре Кәримә белән Мәдинә ана мирас итмәгәндер аларны. Жанүлән хакында да, бәлки, сөйләр, ул да—тарих. Үскән урынын әмма күрсәтмәстер?..

Жанүләннәр, сөбханалла, ишәеп киткән ләса. Берәү, икәү, өчәү... жидәү! Инә Жанүлән жидәү булган. Ә кысыр жанүләннәр кайсылай күлбеп үсеп утыра, өйкем-өйкем булып. Көзен, яфрак-сабаклар сихәтле матдә белән тулышкач, килеп өзәр аларны, киптерер, төнәтмәләр, майлар әзерләр дә авылдашларына таратыр. Әллә генә, мәктәптә укыган чагында ук, бер дәфтәргә нәрсәне ничек, нинди микъдарда тотынырга кирәклеген язып куйган иде, табибә дәү әнисе әйтеп яздырган иде. Сихәтле матдә дигәнен дә, гамәлдә

чирне үтерә торган агу бит ул, микъдарын белмәсәң, зыян гына китерәчәк.

Шуларны күнелендә ныгытып, кайтырга чыкты. Аны юл буе әллә күпме җан ияләре озата барды: кайдадыр, төпкелдәрәк поши мышылдады, куян колакларын кайчылады, керпе теркелдәде, тычкан чиелдады; бик сирәк кешеләргә генә күренә торган канатлы тиен агачтан агачка очып күзен арбады; кош чутылдавы, яфраклар сөйләшүе, урманның саф сулышы һушын алды. Шундый илерткеч тәэссоратлар белән килеп чыкты Айсылу Агуй үрендәге аланга. Дәү әнисе өйрәткән ырым белән Җанүләнгә илткән юлны "бикләде" дә йомры сукмактан авыл ягына түбәнгә атлады. Агуй, ак уйлар юрап, кадимге урынында торып калды, ә тәэссоратлар аңа ияреп кайтты.

Кайтуына әнисе бик борчылып каршы алды. "Әтиеннең өянәге купты тагы, анавы Кәртечкәне әйтәм, бәйләнде бит әтиенә, аракы китереп эчергән...— дип сукранды.—Инде дә шулай кыланса, куып чыгарам мин ул Кәртечкәне!"

Асылда юаш кына әнисе шулай каты әйтеп куйгач, Айсылу эшнең тирәнгә китеп баруын аңлады. Әтисе алачыкта, җәйге челләләрдә чәй эчә торган киң сәкедә утыра иде. Алачыкның ике тәрәзәсе дә уймак кына, кояш нуры көлтәләп төшә, бөтен почмакларга барып та җитми. Бәләкәй чагында мәзәк күрә иде: кара-каршы ике тәрәзәдән агылган якты бер-берсе белән урталыкта чапырышлап кисешә, шул урынга бассаң, баштанаяк нурга күмеләсең сыман. Ә читтән карасаң, чапырыш юлларда тузан өерелгәнен күрәсең, әлбәттә, аны аяк астыннан күтәрелгән чаң дип түгел, ә күктән коелган алтын, кояш алтыны, дип уйлыйсың... Әтисе ишектән керүчегә игътибар да итмәде. Ул унсигез генә яшьлек чагында йөрәген тетрәткән, баш миендә уелып калган хәтәр сугыш эчендә иде. Куллары белән әллә нинди чатай-ботай хәрәкәтләр ясый, сәкегә бер чалкан барып төшә, бер ыргып килеп тора, үзе: "Плен не сдаюсь, не сдаюсь!"—дип кычкыра. Айсылуга бермәлгә генә теге чапырыш нурлар, кинода күрсәтелгәнчә, прожекторлар яктысы сыман күренде, ә әтисе—фашистлар кулына эләккән совет солдаты. Әнә ул ничек көрәшә! Ярдәмгә ташланырга, коткарырга кирәк аны!

—Әти! Бу мин—кызың. Тынычлан.

Айсылу әтисен барып кочаклады. Ә ул, әллә кызын танымады, ике кулын кемдер артка каерып бәйләгәндәй, әсир ителгәндәй, таш сыман катып тик утырды. Шул арада әнисе килеп керде. Картының янына мендәр куйды да: "Әйдә, Айсылу, әтиенне яткырыйк,—диде.—Көчем җитми берүземнен, карыша ул... Бер ятса, йоклап китә торган. Шушы өянәге хәлен алып бетә инде, алтмышы да тулмастан..."

Әтисен икәүләп, көч белән, мендәргә янтайттылар. Башы йомшакка тәрәлгәч, аның тәненең калтырануы басылгандай итте. Айсылу әтисенең артка каерылган кулларын ипләргә, бер-берсенә ишелгән бармакларын язарга иткән иде дә, әнисе туктатты: "Тимә, бу хәлендә ычкындырып булмый, үлемгә дип бәйләнгән аның куллары—әтиен, шулай икән, дип уйлай... Райондагы духтырга күренгән идек, әллә нәрсәләр сөйләде урысча, "бсих" дип тә бетерде, тәүбә-тәүбә."

Аңлады Айсылу. Әтисенең чире—психикага бәйле, нервылары тузгыган, күңел яралары газаплый аны. Сугыш шаңдавы эзәрлекли. Өстәвенә—гомер бакый малчылыктагы авыр эш, өстәвенә—аракы зәһәре, өстәвенә—бер бөртек кызының читтә олагып йөрүе... Шулай итеп, сәбәпне үзенә дә алып барып терәде Айсылу. Инде ул атасына инен куяр, коткарыр. Ә нәрсәдән тотып башларга? Башына килгән тәүге уй—Кәртечкә агай белән сөйләшү иде. Мансур агай ул, Айсылулардан бер тыкрык аша гына яши, Кәртечкә дигән кушаматны сылу булганга такканнар. Әле дә бетмәгән чибәрлеге: ак йөзенә кабарынкы коңгырт чәчләре шундый килешә, күзләре—яшькелт соры, карашы әллә шаян, әллә бәйсез. Айсылуны Кәртечкә агай әнә шул аңлаешсыз, бәлки, шунадыр да үзенә тартып торган карашлары белән каршы алды. Ферма мөдире булгач,

таң белән эшен оештырып килгән дә әле көпә-көндез өендә утыра иде.

Исәнлек-саулык сорашты да турысын ярып салды Айсылу:

—Мансур агай, үтенәм, әтиемне бүтән эчерәсе булма!

—А-һа-һай! Камила кызы түгел син, Мәдинә кызысың,—дип баш чайкады Кәртечкә, тигез эре тешләрен күрсәтеп кин елмайды. Ә яшькелт соры күзләре, тычкан аулаган ата песинеке сыман, берчә зураеп, берчә кечерәеп (аллә шулай тоелды гына), үзләренең сихри көчен сынамак булды: нindидер бер салмак наз белән Айсылуга бакты. Әйе ләса, картлык әлегә Каф тавы артында, дип, алдында үрә басып торган ир кәттәсе күз карашы белән генә аны капшый: гыйшык уенына аумакаймы, түгелме бу, дип чамалый.

—Жингә өйдә юкмыни?—дип сорады Айсылу, үзенең аумакай түгеллеген дәлилләп. Кәртечкә дә аңлады булыр, күзендәге мутлыгын басып, житди жаваплады:

—Чөгендердә ул.

—Әтиемне эчермә, агай. Шап-шактай иде, хәзер, әнә, эчсә, сугыш белән саташа. Аракы ярамый ана.

—Әй, шул бер эчкән, дип. Жәмил агай да булдымы аракычы. Илле яшь тулган иде менә бу кешегә, шуна агайны ризалатыйм дигән идем.

Кәртечкә "менә бу кешегә" дигәндә көчле кулы белән үзенең түшенә сугып алды. Киң күкрәк "гөп" итеп куйды, шул уңайга Айсылуның башына, колагына шаулап кан йөгергәндәй булды, менәгайыш...

—Ризалатасың килсә, агай, премия яз! Медаль бирсәгез дә яза китмәс, гомере буе колхоз малын карады. Әле, көтү жәйләүдә чакта, әзрәк ял итсә булмыйммы, ферма курасын ремонтлап азаплана. Олыгаеп бара бит инде әтием.

—Ярар, елап куйма, тик елама гына, хатын-кызның күз яшен күрсәм, жаным чыга. Бернәрсә булса, балавыз сыга башлыйлар, шулай итеп жинәләр.

Кәртечкә Мансурның теңкәсен аз корытмагандыр шул савучы хатыннар, әнә, ничек чыгынчылап китте.

—Сөйләштек, агай. Сөйләштекме?

—Ярар.

Шулай, сүзен ныгытып әйтеп кайтты Айсылу Кәртечкәгә. Ары-бире иткәнче, эңгер төште. Әнисә белән Шатморат көне буе Хәйдәрнең кызлары белән уйнап, "Дәү әни, парное молочко!" дип, кемузардан кайтып керде. "Сөт эчәм" диегез, "сөт эчәм",—дәү әнилегеннән ифрат канәгать Камилә апай, шулай ныгыта-ныгыта, балаларга яна гына сауган сөт коеп бирде.

Өйрәнеп килә сыман алар, "дәү әни"не жиңел генә әйтте дә куйдылар. "Әни" дип бирәр кайчан эндәшерме бу балалар Айсылуга? Эндәшмәсәләр дә риза, аңлый—үз әниләрен, тапкан, күкрәк сөтен имезгән әниләрен онытмаслар, ис белгәннәр бит. Шулай да, "баккан—әни" дигәне дә бар әле борынгыларның...

Олы өйгә кереп йокларга яткач та шушы уйлар тынгы бирмәде Айсылуга. Әтисе, барыбер кызының туган нигезгә әйләнеп кайтырын аллә белгән, искесенә янәш кенә яна йорт салган иде, шуны хәзер "олы өй" дип йөртәләр. Әтисе белән әнисе күчмәде: монда өйрәнгәнбез, яратканбыз, дип, кадимге бәләкәй өйдә яшәп калдылар.

Балалар икесе ике караватта мышнап йоклый. Уйнап армансыз булганнардыр. Жәйге хозурлыкта жәйләсеннәр әйдә, жәйрәп уйнасыннар. Әнисә озакламый беренчегә укырга төшәр. Ару гына башкортча сөйләшә башлаган, ахирәтләре уңаена тиз үк өйрәнеп килә. Туган теле ләса—ана теле—кан белән дә күчәдер ләса тел тоемы, сүз тоемы. Шуннан, шома гына итеп, уйлары бүген көндез күргән чибәр ир ягына шылышты. Илле яшь тулды, диме? Таза, яшь чырайлы ул Кәртечкә. Сугыш күрмәгән, авыр эшкә тарымаган... Айсылу аны, аннан бигрәк, анау халәтен—тәнендә дәрт кузгалып куюуын, яңадан исенә төшерде. Акылы бу тойгыны үзенчә аңлата: утызны яна узган чагы, жиләктәй пешкән

чагы, иркәләнәсе, сөеләсе килә! Жинәрме, тыя алырмы үз калбендәге бу дуамал дәгъваларны Айсылу, юкмы?

Балалар йоклый. Алар йолса йолыр Айсылуны языклардан. Үзенә аяусыз булыр ул, дәрт-дәрманын файдалы эшкә сарыф итәр. Яшькелт соры күзле кәртечкәләргә карап мәлжерәп төшергә башкача форсат бирмәс үзенә! Кем бит әле—Кәртечкә, әнә, стенаңа берәр артистның фоторәсемен элеп куй да карап кинән! Шулай үзен эчтән каты әрләп тынычланды да йокымсырый башлады. Йокы аралаш зиһененә бер уй килеп керде: Сынтимер булса икән әгәр ул Кәртечкә урынында... Сынтимер...

* * *

...Әнисә алтынчы сыйныфта укый, Шатморат—өченчедә. Кызыкай—дәү әнисенә, малай дәү әтисенә куш кендек кебек ябышкан—булсын, авылча бу, адәмчә. Шатморат бәхетенә әлдә әтием исән кайткан сугыштан, дип куана Айсылу, кем өйрәтер иде малайны сыбай йөрергә, югыйсә. Сыбай йөрү генәмени ирмен дигән ирләргә фарыз тасыллар? Әти кирәк малай кешегә, дәү әти кирәк—шунсыз аңа егет корына керү, "умырткалы" булу читен. Айсылу үзенең "солдатка" әниләр тәрбиясендә үскән яшьтәшләренә карап та аңлый моны: умырткалары сыеграк аларның. Аптырагач, дөнья йөгәнен хатын-кыз үз кулына алып бетеп бара ласа...

—Дәү әти, дәү әнием әйтә, абзар капкасының такталары таралып төшеп бара, шуны юнәтегез, ди.

—Ә, шулаймы, хәзер, әләйсәң. Бар, оланым, чоланнан оста яшниген эзләп ал.

—Дәү әти, кадакны үзем кагам, син карап кына тор, яме. Чүкечемне тартып алсаң...

—Тартып алмам, нишләп алыйм, ди. Мин өйрәткәнчә, кадакны келәшчә белән кысып тот, бармагыңны чүкеп куйма, яме.

Олы ир белән бәләкәч ир очтыгының шулай сөйләшүе Айсылуның колагына жыр булып ишетелә, гүя. Ә әнисе соң, әнисе: нинди шәп дәү әни булып чыкты. Әнисәне орчык кебек өерелтеп эшкә күндерә, мактап, күңелен үстереп торырга да онытмый.

Әтисе белән әнисе күп мәшәкатьләрдән арындыра Айсылуны, рәхмәт төшкерләре. Ул мәктәп эшеннән бушамый, гәзиткә дә язышa, музей хәстәрләре белән, экспонатлар эзләп районны айкый. Теләсәң, алдыңа куйсаң, эшләп була икән—Агайтуган мәктәбендәге кебек музей районда да юк!

Мең хәстәр эчендә яши Айсылу. Менә шушы көндә дә бер төркем укучыны Мәскәү күрсәтергә алып бару нияте белән янып йөри. Иртәгә—кышкы каникул, иртәгәдән сонга—юлга, башкалага. Билетлар алдан алынган, Уфага автобус сөйләшелгән. Аннан поездга утырасы да Мәскәүгә барып төшәсе. Балалар йөдәтеп бетерде инде, Мәскәүдә шуны күрсәтегез безгә, моны күрсәтегез, яме, дип. Айсылу апаларының да ул шәһәргә тәүләп баруы ласа. Үзе шүрләп тора әле, ничек исән-аман йөртеп алып кайтырга укучыларын.

Урамга күз салса, житәкләшеп Алмакай белән Хәлекәй килә яталар. Алмакай яңа шәл бөркәнгән, әллә кайдан күренә ул шәлнен ак жирлектәге кызыл чәчкәләре, купшы озын чуклары. Туры Айсылуларга йөз тотып атлыйлар, Ходай бәндәләре.

—Юлың унар, балам, әнә, кемнәр килә безгә. Юллыклы алар,—диде әнисе һәм күгәрченнәрне каршы алырга чыкты. Күгәрченнәр—татулыклары өчен, хат ташыган изгелекле кошлар сыман авылга тугры хезмәт күрсәтүләре өченме—күптән инде шулай дип йөртә сөекле диваналарын агайтуганлылар.

Алмакайның шәле өр-яңа икән шул, бүләк шәл икән. Сынтимер бүләге! Ул

Казаннан посылка салган, ике көннән үзе дә кайтып житәчәк икән...

Менә нинди хәбәр ташлап китте күгәрченнәр.

Ике көннән? Ике көннән! Ә ике көннән Айсылу, укучыларының чыр-чуына күмелеп, поездда Мәскәүгә китеп бара иде.

"Язмагандыр..." "Язмагандыр..." Поезд тәгәрмәчләре Зөлганифә тутакайның шушы сүзләрен кат-кат тукый сыман тоелды Айсылуга. Кавышырга түгел, хәтта күрешергә, күз карашлары белән генә булса да очрашырга—язмагандыр! Аларның юлларын тоташтырыр күперләр юктыр, күрәсең, бу дөньяларда...

Кайткан Сынтимер. Айсылуга әманәт калдырган—зур булмаган агач кумта, капкачында тәти генә тоткасы да бар.

—Үзе кереп хәл белешеп чыкты,—дип, шатлыгы эченә сыймый сөйләде әнисе, күчтәнәчкә цейлон чәе китергән, сина менә бүләк, мә.

Кумтаны ачыйм дисә, ачылмый. Әнисе шунда тагы чутырдап алды:

—Әй, ачкычы бар бит аның. Ачып та карамадым, тәүгеләп үзе күрсен, дидем.

Әнисе киштәдәге бер чынаяк эченнән әлеге ачкычны китереп учына салды. Бигрәк тә бәләкәч ачкычы—Айсылу учын йомды. Күзен дә йомды. Әллә нинди могжиза булыр кебек тоелды ана шушы минутта... Күзен ачты. Ипләп кенә кумтаны да ачты. Һәм үзен үзе белмәстән, дулкынланып өндәү салды:

—Динисламның зәңгәр чикерткәсе!

Янында торган әнисе хәвефләнеп, "ай, балам..." дип куйды.

Айсылу, кулымнан төшеп китмәсен дип аяп, кечкенә кумтаны күкрәгенә кысты. Күз алдыннан (инде ничәнче кат!) тезелешеп Асылгужа вә Сөмбел, Гыйндулла вә Зөлганифә, Динислам вә Мәдинә үтеп китте сыман тоелды...

—Карачы, нинди матур күбәләк! Әллә чикерткә? Безнең якта андыйлар юк. Чит илдән алып кайткандыр, зур кеше ләса хәзер Сынтимер, зур түрә.

—Әни, бу—музейга.

—Әһә, балам, үзенә аталган бүләкне ни?..

—Музейга!

Димәк, һаман онытмаган аны Сынтимер? Димәк, музей оештыруын да ишеткән. Башкортстанның Кызыл китабына кергән зәңгәр чикерткәне, дәү әтисеннән калган комарткыны, аның кулына ышанып тапшырган... Зур кеше булган үзе, зур түрә. Түрәлеген әйтә алмый Айсылу, ә Сынтимернең зур кеше булырына беркайчан да шик тотканы булмады. Алайса, юкка гына юнәлтмәгән туганнары аңа нәсәбән өметләрен, юкка гына тапшырмаган васыяти әманәтләрын. Ул да, Сынтимер дә, Айсылуның илсөярлегенә, халык мәнфәгатендә яшәвенә ышана икән. Исли икән. Ә яратамы һаман? Яратамы?!

Үз теле белән әйтмәсә дә, кулы белән язып жибәрмәсә дә, кумтадагы гаҗәеп чикерткәнең зәңгәр канатлары әйтте түгелме "ярата!", дип тапшырды түгелме мәхәббәт сәламен?!

Айсылуга көч бирде Сынтимернең сәламе, дәрман өстәде. Күптән яза башлаган "Агайтуган тарихы"н очлап куйды, бер журналда бастырып та чыгарды. Илнең төрле төбәкләренә таралган авылдашлары журналдан аның язганнарын укып, хат артыннан хат яудырды. "Агайтуган" дигән исемнең килеп чыгышы хакында гына да унлаган фараз тупланды ахырда. Берсен, Мәдинә дәү әнисенә карт әнисе Кәримәдән мирас булып калган бәянны, Айсылу ташка бастырган иде. Топонимик легенда ди андый әсәрләрне фольклорчы галимнәр. Әнә шул легенда буенча, дөньяда иң зур башкорт авылларының берсе Агайтуган шулай барлыкка килгән. Бертуган ике ир-узаман үзләренә асыл төяк эзләп сәфәр чыккан. Озак эзләгәннәр—тавы булса, елгасы юк ди, урманы булса, яланы юк ди, күргән жирләренең. Ниһаять, икесенең дә күнеленә хуш килгән якка

килеп юлыкканнар. Иркен кырлар калын урманга барып терәлә ди, дошманнан сакланырга текә тавы, мул сулы елгасы, балыклы күле—һәммәсе бар ди, монда. Нәсел-нәсәпләрен, мал-туарларын ияртеп китереп, шушында төпләнгәннәр. Берсе елганың уң ярында, икенчесе сул ярында тирмә корган. Тора-бара, бихисап сулар аккач, күп гасырлар үткәч, авыл рәвешенә кергәч, ана уртак бер исем таба алмыйлар икән. Аптырагач, теге ике бертуганның исемнәрен алмаш-тилмәш кушып карыйлар икән. Берсенекен кушсалар, елганың уң ягындагылар үпкәли, икенчесенекенә—сул яктагылар үпкәли, ди. Ахырда бер аксакал ике якны да яраштырган: "Агайтуган" атамасы бирик авылга, дип уртага тәкъдим салган. Килешмәслекмени бу исем—үзе колакка ягымлы, үзе тагы агай-туганны санлауга ишарә итеп тора!

* * *

...Егерменче гасырның туксанынчы еллары килеп тәгәрәде дөнья тупсасына. Тугыз гына түгел, туксан тугыз тулгаклы еллар...

Кояш болыт аша бер күренде, бер югалды. Җил купты, коен өерелде. Яшен уйнады. Кайдадыр ут чыкты, гөрселдәп таулар ишелде, башлар ауды... Коеп яңгыр яуды... Башкортстан күге, ниһаять, аяза башлады. Хыялдагы Салават күпере калыкты. Күнел офыкларын тоташтырган, балкыткан бу сәяси җәйгорның исеме—суверенитет булып телгә керде, тарихка теркәлде.

Җил-давыллы язгы көннәрнен берсендә Айсылу уку әсбаплары юллап Уфага килгән иде. Башкала кырмыска оясы кебек гүли, аны кемдер таяк тыгып кымҗыткан әллә? Яшьләр икән—хөкүмәт йорты алдында тирмәләр корып ачлык игълан итеп яталар—суверенитет даулыйлар. Аларга теләктәшлек белдереп, ут күрше Татарстаннан да егетләр килеп кушылган.

Айсылуның бу чая яшьләрне барып күрәсе, үзенең рухташлык мөнәсәбәтен белдерәсе килде. Һәм барды. Бер тирмә тирәсендә кеше аеруча күп иде, шунда юнәлде. Татар егетләрен уратып алган икән халык. Күршеләр бигрәк юка киенгән, көн болай булып китәр, суытып җибәрер, дип уйламаганнардыр инде. Бер хатын башындагы беретын салып өшеп беткән егеткә кидерде. Бәй, аның янында сикергәләп басып торганының аягында сандали, носкилары юка гына—тунгандыр тәмам, шуна сикергәләгән буладыр. Шатморатка дип калын гына берничә пар носки алган иде, кая, кисен шушы бала—аһ! Сумкасыннан алган носкиларын сузган көе катты да калды Айсылу: каршында Сынтимер тора иде.

—Сынтимер?!

—Сынтимерович, апа, Сынтимерович,—дип җөпләде сандалилы егет янындагы икенче берәү, дустыдыр, күрәсен.

—Сынтимер улымы? Алчынбаев?

—Тач үзе. И, рәхмәт, апа, аяклар тәмам тунган иде.—Сандалилы егет, носкиларны киеп алгач, сүз катты.

—Ярар, улым, игелеген күр,—диде дә Айсылу китеп барды. Автовокзалга барып өлгерәсе, авылга кайтасы әле ана.

Сынтимернен улын күрде бит ул. Үзен күргәндәй булды. Нигә тыелды, нигә кочаклап алмады, аркасыннан сөймәде шул баланың, дулкынлы кара чәчләреннән нигә сыйпамады?

Авылга Уфадан туры автобус йөрми, район үзәгенә барып кунарга туры килә. Рауза ахирәте шунда яши, бер сылтауда ана да сугылды Айсылу.

—Ай, Аллам, бу нихәл, сезләр безләргә килгән?—дип, шаяртып, шатланып каршылады Рауза аны. Йөгереп йөреп чәй куйды. Хәзер булган сый-сыргасын өстәлгә чыгарып та утыртачак. Ул гелән шулай итә. Башкортча укыса да, тик үзенчә, типтәрчә суктыра—туган тел бит, ул якын, ул онытылмый. Сынтимер

нинди телдә сөйләшә икән? Улы сыман татарчамы, әллә башкортчамы?

—Ахирәт, картым, Рауилым, төнге сменада, рәхәтләнеп серләшик, әйеме? Тоямын, тулышкансың...

Тулыланып киткән йомры гәүдәсе белән диванны селкетеп килеп утырган Рауза, бар гамен салып, ахирәтен тыңларга әзер иде.

—Сынтимер...—дип башлады Айсылу.

—Сынтимер?!

Рауза сискәнеп әйтте бу исемне, үзе хәтта диваннан килеп торды, аның унаена Айсылу да аякка басты. Бер-берсенә карадылар да бер сулыштан "Уф!" дип, ипләп кенә кире утырдылар. Инде алар тыныч кына сөйләшәчәк, эчбавырларында кер калдырмый сер уртаклашачак. Ә нинди сер соң? Сер юк та инде... Сынтимерме? Сынтимер—бар!

Аның барлыгын һәрчак йөрәге белән тойды Айсылу. Ниләр генә эшләсә дә, ниләр генә кичерсә дә, әллә кайлардагы, Иделләр аръягындагы сөйгәне күрәдер, беләдер сыман иде. Шушы хыялый инану ана дәрт бирде, зур уйлар уятты, зур эшләр аткарды.

* * *

Ишеттеме, белдеме икән Сынтимер авылда мәчет салынганын?

Ә Каранайның яңа күперен күрәсе килми микән? Нигә кайтмый?! Күпер салдырам дип, югары даирәләргә барып житкәнен белсә Айсылуның, аптырар идеме икән ул?..

Ишетә һәм белә иде Сынтимер Агайтуганның хәлләрен.

—Сынтимер Зарифуллович, синен туган авылыңнан хат килеп төште әле минем исемгә,—дип шылтыратты ана беркөнне Башкортстандагы дусты, югары Совет депутаты.—Күпер салдырырга ярдәм сорыйлар.

—Ә кем язган, хатның авторы бармы?

—Бар. Айсылу Нәдершина, укытучы.

—Айсылу?!—Сынтимер Зарифулловичның тавышындагы үзгәреш телефон чыбыгының теге очында да сизелде, күрәсен, дус кеше сорап куйды:

—Беләсеңме аны?

—Туган авыл бит...—дип читләтебрәк жаваплады Сынтимер Зарифуллович. Башта үзенә ятрак булган мохиткә берегеп китү кыенлыклары, житәкче һәм сәясмән язмышының четерекле яклары, адәми әдәп кагыйдәләре һәм башка дөньяви шартлылыклар аны сүз белән сак булырга өйрәткән иде. Чыгышының Башкортстаннан икәнен дә ул тиешле-тиешсез урында искә алып бармый—яшерми дә, игълан да итми. Әлеге дус кешесе дә, ныклы ир-узаман булып, елга үрендә су болгатып утыручылардан түгел, шуңа аралары сәламәт, ышанычлы кала килә.

—Ярдәм итик, туган.

—Әллә "зур абзый"га эндәшергәме?

—Авыл күпере дип аны борчыргамы, син дә әйттең сүз! Хәер, үзен кара... Минем дә ана шылтыратасым бар әле...

Депутат та мут кеше, оста гына кылын тартып карый Сынтимернең. Янәсе, "зур абзый" белән мөнәсәбәтләре рәсми дустанәме, әллә тагы да якынракмы?

...Агайтуганлылар, әгәр Сынтимерләренең төзелешкә катнашы барлыгын белсәләр, Каранай аша "ә" дигәнче күпер салынуына бу кадәрле дә аптырамас иделәр. Тиз үк кордылар күперне, төннәрен дә прожектор яктысында эшләделәр. Әллә нинди ят машиналар килеп тулды, чит телдә сөйләшкән эшчеләр дә бар иде. Көннәрдән беркөнне, иртәнчәк уянуларына, Каранай ярларын киң, машина өчен аерым, жәяүле өчен аерым юллары булган тимербетон күпер тоташтырган иде. Торганы—әкият! Ышанмас идең,—чын, берүзе

бер яры, бахыр гына булып иске күпер тора ласа. И, иске күпер, әллә сүтмәгәннәр әле аны капыл гына. Төнлә тар-мар итеп агызып җибәрсәләр, нинди үкенеч булыр иде. Күпер бит ул, күпер! Ике ярны гына тоташтырмаган ул, язмышларны да уртак иткән, буын-буын тарихлар шаһиты булган. Шушы күпердән кайчандыр Агайтуган башкортларына ислам динен күндергән пәйгамбәр илчеләре үткән, шушы күпердән ихтилаллар килгән, кемнәрнеңдер газиз башкайлары Себер киткән, шушы күпердә яудан кайта алмаган агайтуганлыларның эзләре уелып калган... Әйе, күпне күргән иске күпер: күз яшьләре генә түгел, кан да тамган аның тимердән дә чыдамрак булып пешеккән имән бүрәнәләренә. Һәм, әлбәттә, күпер гашыйкларны очраштыра торган илаһи урын да—нинди сере бардыр моның, әмма егет белән кыз җитәкләшеп Каранай аша үтмәсә, күпердә үбешмәсә, хисләре тулы түгел сыман, вәгъдәләре ялган сыман. Күпернең, ул тоташтырган ике ярның, шул ярлар кочагында алкынып аккан елганың күзләре күрә, колаклары ишетә, җисемнәре тоя, мәхәббәтле йөрәкләр боларның барысын да сизә шул...

Яңа күпер ырыслы булсын иде, хәерле булсын иде! Аның аша тик яхшылык илчеләре генә үтсен, бары иминлек хәбәрләре генә килсен. Айлы кичләрдә ул гашыйкларны каршыласын, якты таңнарда чуак йөзләрне күрсен—амин.

Әле яңа күпер бикле, ике яктан да тимерчыбык белән тарттырып куелган. Тагы бер атнадан ачалар икән, районнан гына түгел, Уфадан да кунаклар, югары хуҗалар килә ди.

Чын булды бу сүз. Авыл зык кубып бәйрәмгә әзерләнде. Бәйрәм булмыйча, Каранай күпере бит ике ярга сибелгән йортларга гына түгел, ике яктагы ялан-кырларга, күрше-күлән авылларга, олы шәһәрләргә дә юл ача, кыскасы—дөньяара бәйләнешнең, яшәүнең бер токтасы ул. Шушы күпер аша үтмичә, Уфага да, Мәскәүгә дә, Мәккәгә дә барып булмый!

Ниһаять, көткән сәгать сукты. Олылар эскәмияләргә олпатланып утырды, чәчкә тоткан укучы балалар юл читенә тезелде, вазыйфалы кешеләр биегрәк урынга төркемләнде.

Менә, күпергә чак кына җитмәстән, берничә машина туктады. Хөкүмәт машиналары—әллә кайдан билгеле. Аһа, ил башлыклары үзләре, олы башларын кече итеп, килеп төшкән ләбаса!

—Сынтимер?!

Айсылу кычкырып әйтте әллә, янында торган ике апа аның беләгенә килеп ябышты: "Сынтимер шул!" Шуннан апалар Айсылуны кунаклар ягынарак әйдәргә тотынды, тик ул кымшанмады да. Буйчан булмаса да, гәүдәле, аксыл костюм кигән ир уртасы аны үзенең үткер карашлары белән баскан урынында кадаклап куйган гүя. Әйе, Сынтимер дә Айсылуга төбәгән иде күзләрен.

Күпер тирәсенә җыелган халык капыл искән көчле җилдән тирбәлеп киткән иген басуыдай дулкынланып алды: Сынтимер кайткан ласа! Зур урында эшли, диләр иде, чын икән, әнә бит, түрәләр кырында йөри. Йөрсен, кемнеке—аларныкы.

Җил тына төште, басу шымды, ары-бире башаклар гына чайкалышты, шыбыр-шыбыр сөйләште...

Кызыл тасма киселде. Күпер ачылды. Тиешле сүзләр әйтелде. Тәгаенле кешеләргә чәчкәләр өләшелде. Шуларны аткарганда әдәп-тәртип саклап шаулашмый гына торган агайтуганлылар, ниһаять, Сынтимер янына укталды. Аның бүген авылда калачагын, иртәгә китәчәген белгәч, бер чама тынычланып, "ярар, күрешербез, әләйгәч" дип, сүрелделәр, ана ил хуҗалары белән бергәләп кунак сые әзерләнгән йортка китәргә ирек бирделәр. Ни дисәң дә, югары даирәнең үз кагыйдәләре дә бар ласа.

Ә төштән соң, зур кунаклар кайтып киткәч, Сынтимер әнисе, нәсел-нәсәбе белән очрашып, сөйләшеп алгач, агайтуганлылар аңа хөрмәт күрсәтте.

Һәркемнен дә аны үз өенә чакырасы, аягөсте басып сыйлыйсы килде дә,— мөмкин түгел. Шуна да Каранай күпере янында уртак табын оештырырга кинәш беркеттеләр, анда эскәмияләр дә, чәчкәләр куелган озын өстәлләр дә тора иде әле. Һәр йорттан ин затлы ризыклар килде монда: Гөлбостан әбинен тары коймагы, Мәҗит хатыны Нәфисәнен бавырсагы, чолыкчы Габделхак бабайнын кәрәзле балы, Айсылунын әнисе Камилә апанын саумал кымызы...

Анынчы Сынтимер мәктәпкә барып урарга, Айсылунын музеена кереп чыгарга да өлгерде. Шунда күреште алар. Күпмедер вакытка икәү генә дә калдылар, бәлки, авылдашлары махсус шундый форсат бирделер, ичмасам бер туйганчы сөйләшсеннәр, диделер?

Сүз байлыклары әллә кайда булган иде аларнын. Бер-берсеннән күзләрен ала алмадылар, телләре түгел, ә карашлары сөйләште.

«Айсылу, сагындым сине, жаным-тәнем белән зарыгып сагындым!»—диде Сынтимернен карашлары.

«Мин дә сине өзелеп сагындым. Көттем, гомер буе көттем, Сынтимер!»—дип җаваплады Айсылунын күзләре. Әйтерсен, бу хатын кырыктан узмаган, ә бу ир иллене кумый. Берсенә чак уналты тулган, икенчесе яна гына егерме аша атлаган. Һәм алар—мәгашака ике яр.

Ә телләре, ачылгач, икенчерәк сүзләр тирбәтте:

—Шәп музей туплагансын, Айсылу.

—Тырыштым үземчә.

—Халык та рәхмәт әйтәдер?

—"Айсылу музее" диләр дә куялар—шулдыр, дим, рәхмәтләре.

—Хәзер менә "Айсылу күпере" дә бар.

—Анысы—артык. Халык та чаманы яхшы белә: Каранай күпере булып калачак ул, бәгъзе бер киләчәктә алтыннан салсалар да, хәтта ки...

—Әйе.—Сынтимер килә торып Айсылуга сынаучыл сүз катканына унайсызланып куйды.

—Дәү әтиемнен чикерткәсен дә монда куйгансын икән? Анын гаҗәеп бөҗәкләре күп булган, берничәсен генә, ин кадерлеләрендер инде, Зөлганифә түтәкайнын сандыгына китереп куйган, ә калган коллекциясе янгында үртәлгән.

Шунда алар туктап калды. Нәрсәгә бөтенләй чит-ят адәмнәр кебек кыланалар? Сынтимер Айсылуга якын килде, кайнар тыннары бер-берсенә бөркелде. Эчтәге утлары тышка бәреп чыга башлады. Сынтимер каршысындагы хатынга әйтеп бетергесез наз белән бакты: әле ул бер дә чырай ташламаган, йөзендәге яшьлек яшьнәүләре җуелса да алар урынына базык матурлык язылган... Айсылу да, тартынуын җинеп, үзенә өзелеп караган ир уртасына хисләнеп күз салды. Сынтимер! Тау ягы башкортларына охшап кырлач танаулы, кара чәчле, коңгырт йөзле—тамчы да үзгәрмәгән сыман. Чәчләре сирәгәенкерәгән, маңгае ачылып, кинәя төшкән. Күпме акыл, сабырлык сыйгандыр бу якты маңгайга...

Ир кеше йөрәксенде, хатыннын иннәреннән алды, күкрәгенә сарылтырга теләде. Икесе дә сихри бер дулкын иркенә бирелде. Менә-менә ул дулкын бу икәүне тойгылар дингезенә алып китәр... Шул минутта кынгырау шылтырады. Ике гәүдә сискәнеп бер-берсеннән тайпылышты.

—Айсылу, иркәм!—Сынтимер хатыннын кулларын үзенен учларына кысты. Бармаклар кавышты. Йөрәкләрдән килгән кан тибешләре бер-берсен ишетте.

—Кайчандыр, "иркәм" дип тик сина гына әйтермен, дигән иден?—Айсылу булмышынын төпкел бер почмагында монынчы беркайчан да үзенен барлыгын белдерми яшеренеп яшәгән көнләшү көясенен бәгырь итен "кырт" итеп кисеп алуын шәйләде.

—Сина гына әйтәм бу сүзне, иркәм, сина гына. Ышан... Вәгъдәдер менә...—Сынтимер шунда ипле генә итеп Айсылунын бармагына яшел кашлы йөзек

кидерде.—Синең ташың, җәй кызларының бәхет ташы—зөбәрҗәт.

—Бу ни дигәнне аңлата?—Айсылу аптыраудан гаҗиз иде.—Бу ни?

—Балдак. Зинһар кабул ит, иркәм. Аңа карап мине искә төшерерсең.

—Болай да гел исемдә.

—Шулай да булгач... Салма бармагыңнан, яме. Никах балдагы кидерә алмадым...—Шуннан Сынтимер капылт сорап куйды:—Теге вакыт, Зөлганифә тутакай белән хушлашырга кайтканымда, очрашсак, китәр идеңме минем белән Казанга?

—Белмим... Сынтимер, мин шуңа куанам—мәхәббәтебез бушка гына фида булмады, зур максатлар белән яшисең, ата-бабаң васыятьләрен үтисең. Динислам мулланың изге рухы разыйдыр...

—Аңлыйсың икән минем өлешкә төшкән ир бурычын.

—Әйтәм ләса...

—Төп йортта: "Нәселебезнең борынгы ватаныбыз алдында бурычы бар",—диделәр. Миңа төште ул бурыч...

—Әйтәм ләса...

Айсылуның үз-үзенә ачуы килде. Әллә кайда гына булды ласа аның тел чаралары, улмы соң сүз тасвиры белмәгән хатын?! "Әйтәм ләса" ди дә тора... Сынтимерне аңлауларын, үпкә тотмавын, аның белән горурлануын һәм моңлы исемен вә газиз җисемен йөрәк түрләрендә генә йөртүен—шуларны әйтеп бетерерлек сүзләрне кайдан гына табарга?!

Тагы да кыңгырау тавышы ишетелде. Мәктәптәгеләргә җыелып халык янына, Каранай күперенә юлланырга ишарә иде бу.

Айсылуның урыны Сынтимернең каршысына туры килде. Күзләргә очрашырга, бары тик үзләре генә аңлаган телдә серләшергә тагы җае туды. Өнсез диалог дәвам итте:

«Шушы кәрәзле яшь бал сиңа ни ди?»

«Айсылу, иреннәреңнән кыргый бал тәме килә, ди.»

«Хәтерлисең...»

«Хәтерлим... Каранай күперендә...»

«Без бит бер генә тапкыр үбештек, ә тәмен гомер буе онытырлык түгел, иркәм.»

«Әйе, тик бер генә тапкыр...»

«Сирәк булса да кайткаладым, нигә бер дә очрамадың, әллә белә-күрә юл язлыктырдыңмы?»

«Язмагандыр...»

«Менә очраштык бит, иркәм?»

«Очраштык...»

Сынтимер кәрәздәге мөлдерәмә балны балкашык очына гына алып иреннәренә ягa. Чолыкчы Габделхәй бабай бу балны Агуй үрендә йөзьяшәр карагай куышындагы күчтән алган. Хуш исләре нинди—ничәмә ничә төрле чәчкәләрнең суты җыелган, чаер мае белән сыланган кәүсә кәре сеңгән, таңгы офык сафлыгы күчкән бу кыргый балга. Тәме соң аның, тәме—биздергеч ширбәт тә түгел, зәһәр әче дә түгел, ә гел тансык, гел тәмле—сөйгән ярың белән тәүге үбешү таты сыман...

Айсылуның тел очында, балкашыктан әнә тамам, менә тамам, дип тәкатьсезләнгән бал сыман, сүз гәрәбәләре тилмерде: "Мин башкага күңел сала алмадым... Ә син... Яратасыңдыр аны, сөймәгәнгә сөйкәлер ир түгелсең?"

Сынтимер бу гәрәбәләрне күрми, фикер җебенә тезми калмады. Ә ни дип юатыр иде соң ул бүген дә сылулыгы белән су буйлатыр бу хатынны? Мәхәббәтнең аның җиде төре була, диган галимнәр фаразы артына качар идеме? Бу фаразда дөреслек тә бардыр—хатының бит яратмый түгел... Тик тәүге сөю, бәгыренә яшьтән ярып ингән тылсымлы хис—ул берәү генә!

## VI

Төш сыман гына тоелса да, Сынтимер белән очрашулары өндә булган икән. Күпмедер айлар үткәч, Мәжитнен Нәфисәсе йөгереп килде, Айсылуга бәләкәч кенә дүрткел бернәрсә тоттырды—кәрәзле телефон, имеш. "Бүген сина Сынтимер кайнага шылтыратачак, кесәндә йөрт шуны",—диде. Айсылу башта бик дулкынланды, бер сәгать көтте, ике сәгать... Шуннан күнеле урынына утырды: нәрсәгә жилкенә дә китә шушы йөрәге, Сынтимер дисәләр?! Әнисәгә хат язып салсын әле, телефон шылтыраганын көтеп зар булып утырганчы. Кызы имтиханга әзерләнәдер, Талха нишләп йөри икән, дип өзгәләнәдер. Борчылмасын, егет эш белән мәшгуль әле, Тегермән урамында йорт сала. Кызлар тынгы бирми ана, су сөлегедәй егеткә, әле берсе, әле икенчесе баш әйләндермәкче булып карый—Талха бирешми, күрәсен, Әнисә нык "сихерләгән" аны. Чындыр ки, сихерләгән. Бер килке кызыкай тәмам тенкәсенә тиде бит Айсылунын: "Әни, син белми түгелсендер, Мәдинә дәү әни имче булган бит—әйдә, Талханы әмәллик, миннән башка кызенә беркем күренмәслек итик!"—диде дә бәйләнде. Айсылунын шунда үзенә хас бер шуклыгы уянды: "Әйдә, әмәллик!"—дип әйтте дә салды. Азак үкенде дә, әмма кире чигенмәде. Үзенчә юри генә бер сихер әтнәкәсен уйлап чыгарды. Анын кушканнарын Әнисә (менә беркатлы сабый!) жиренә житкереп үтәп торды: урман әйләнеп үр куяны тизәген эзләп тапты; кызыл рауза чәчкәсен өзеп киптерде; тангы сәгатьтә торып, үлән яфракларыннан бер чынаяк чык жыйды; Каранайнын балчыклы ярлавында оялаган ярканатны көндез йокыга талган чагында тотып, тырнагын кисеп алды; ахыр чиктә Талханын өч бөртек чәчен кулына төшерде һәм, шуларнын барсын бергә бутап болгап, пыяла шешәгә салып, жиде тәүлеккә баз нигезенә утыртты. Житмәсә, сәгать төнге уникедә шешәнен тыгынын ачып, бөтен ихласлыгын салып: "Талха, мин—синеке, син—минеке. Миннән бүтәнне күрмә, ишетмә, белмә!"—дип жиде кат пышылдарга кирәк иде әле Әнисәгә... Түземе житте бит шушы катмарлы мәшәкатьне аткарырга. Текә ярларга үрмәләп, әллә кайда, эчтә яшеренгән куркыныч ярканатны тотарга йөрәге житте бит. Мәхәббәте чатнатып таш ярырлык икән кызнын—Айсылу монга инанды һәм аны шундый сынауларга дучар иткәненә үзалдына берчә елый язды, берчә елмаеп куйды. Ләкин Әнисәгә серне ачмады әлегә, анын күнелен ныгытырга бер чара икән, зыян булмас ласа бу мәзәк сихердән. Жиде тәүлектән сон, шешәдәге матдәне тоныклатып сөзеп, унаен табып, Талханын битен-кулын юдырды ныкышмал кызыкай. Үзе тагы врач булырга йөри... Ярый, яшьлек дуамаллыгы басыла төшкәч, әниле-кызлы икәүләп исләрләр, тәгәрәп ятып көләрләр әле бу кызыктан.

Айсылу Әнисәгә бәйнә-бәйнә тезде өй хәлләрен. Талха тәнгаләндә тәфсилләп язды, анын эштән бушамавын, клубка да йөрергә вакыт тапмавын кызынын колагына тиште. Шатморатнын армиядән килгән хатын да мәгълүм итте, сәлам-әманәтен тапшырды.

Олы өйдә ялгыз калды хәзер Айсылу. Әти-әнисе иске өйдә дөнья көтә, күнмәгәч-күнмәделәр инде бер кыек астына күченергә. Әле ул тиклем карт түгелләр, үзләренә шулай унайлы булгач, Айсылу да артык ирексезләмәде аларны. Аерым дигәч тә, бер ихатада булгач, көнкүрешләре уртак инде ул. Аш-су күпчелек кече өйдә әзерләнә. "Башын эштән чыкмый, мин ни, гел мич тирәсендә уралам, бер ялгызына казан асып изаланма, балам",—дип, әнисе ныгытып ук әйтеп куйды. Ризыклары, шөкер, кин. Пенсиягә чыкканда, әтисенә колхоз байтал бүләк иткән иде, шул малкай жигемгә күндәм, көр бия булып китте. Ел да колын китерә үзе, саудырып тора. Әнисе бия сөтеннән кымыз куярга әвәсләнде. Агайтуганлылар, кунак-фәлән төшә калса, ана йөгереп килә бу һиммәтле эчемлекне сорап...

Өстәлдә яткан телефон мырылдап кына шылтырады, котны очырмый гына. Айсылу барыбер дертләде, сак кына аны колагына терәде:

—Әү?!

—Сау гынамы, Айсылу?

—Саумысыз...—диде дә Айсылу уңайсызланып калды һәм ашыгып өстәп куйды:—Сынтимер...

—Нишләп алай "сез"гә күчтең әле?

—Әлләче... Зур кешесең бит, каушадым...

—Каушама. Мин—һаман да шул ук Сынтимер, Каранай тугайларында тәгәрәп үскән бер малай.

—Малай?!

—Айсылу, синең белән киңәш тотасы бер мәсьәлә бар иде.—Сынтимер сүзне икенчегә борды, тавышы җитдиләнде.

—Тыңлыйм...—Чак әйтмәде Айсылу тагы да "сезне" дип.

—Җанүләннәр исәнме әле?

—Исән. Ә нигә сорыйсың ул хакта?

—Борчылма. Син ул серне миңа да чишмәгән идең... Зөлганифә тутакай аңгармастан бер әйтеп ычкындырган иде... Теләсәң, гомергә икебез арасында гына калыр, шикләнмә.

—Әйт, нәрсә дип киңәш тотмак идең?

—Бер талантлы галим белән таныштым. Химик та, биолог та үзе, гомумән, сирәк очрый торган гыйлем иясе. Ул табигатьтә булган дару үләннәрен өйрәнеп, химик матдәләрен ачыклап, ясалма игезәкләрен барлыкка китерә. Ягъни, Җанүләннең яфрак-сабагын, тамырын лаборатория шартларында тикшерсә, һичшиксез аның химик аналогын табачак. Аңлыйсыңмы?

—Әлбәттә.

—Бер-бер каза килеп, Җанүлән юкка чыкса, аның ишен, хәтта ясалмасын да, бар итеп булмаячак...

—Су бассамы?

—Янгын чыкса, боз яуса...

—Табигать бит ул, таш яуы да ихтимал...

—Димәк, ризасың?

—Җанүлән төяген Әнисәгә генә күрсәтергә ният иткәнмен. Миннән кала ул саклар әманәтне.

—Шулай ят итәсеңме мине, иркәм?

—Ят итмим, ант-иманнар шарты бар Җанүлән тарафында...

—Сине ничек аңлаганымны һәм тугрылыклы күңелең алдында баш игәнемне белсәң иде, Айсылу.

—Иелә торган баш синеке түгел.

—Ярар, йөрәгемдәге хисләрем аяк очларына ятсын, алайса, иркәм.

—Гаҗәп...

—Нәрсә гаҗәп?

—Югарыда йөргән кешенең шулай сөйләшүе гаҗәп.

—Мин дә—адәм баласы. Елатсалар—күз яшем чыга, киссәләр—каным...

—Шулайдыр да...

—Айсылу, Җанүләнне туфрагы-тамыры белән алып, савытка утыртып асрасаң яхшы булыр иде, барып алганчы...

—Әллә кайтасыңмы?!

—Юк... Иркәм?!

—Әү?

—Сагынам сине...

—...

—Бик күрәсем килә... Ә син? Дөньяда мин бармы синең өчен?

—Йөрәгемдә тамырлангансын, Сынтимер!

—Җанүлән сыман, мин дә синен яшерен серенме?

—Авылда сер була димени? Җанүлән барлыгын да беләләр, тик ул—изге катгыйлек багуында, ә тыелган кануни чикләрне безнең якта бозып бармыйлар, үзең беләсен...

—Беләм... Агайтуган нихәлдә? Туым-килем, үлем-китем бармы?

—Алмакай вафат булды, ай да үтмәде, Хәлекәй дә дөнья куйды. Кырык көн елады авыл...

—Олылар әйтмешли, туры оҗмахка очып кергәннәрдер күгәрченнәр. Алай икән...

Бу күнелсез хәбәрдән аны арындырырга теләпме, Айсылу урынлы-урынсыз сорап куйды:

—Сынтимер, син күпер салучылар хуҗасымы?

—Шулайрак... Озакламый Башкортстан белән Татарстанны тоташтырган бер зур күпер салынып бетәчәк.

—Сөн ашамы?

—Тап үзе. Әле шуннан шылтыратам.

Тагы да нәрсәләрдер хакында сөйләштеләр, Айсылу ачык кына хәтерләми. Сынтимердән сорыйсы килеп тә, беркайчан да сорамаячак сораулар бораулады анын зиһенен: "Яратасынмы?" "Башкага "иркәм" димисенме? Хәләл җефетенә дә әйтмә аны, мина дигәнне,—башка сүз тап!" "Мин сине тагы бер күрергә, күзләрендә сөю очкыннары кабызырга һәм... кочагында назларыннан һушымны җуярга телим. Ә син телисеңме? Телисенме кыргый бал тәмен янадан бер татырга?!"

Ә Сынтимер, ирлегенә барып, анын кылын тартып карамый булдыра алмады:

—Форсат тапсам, очрашырбызмы?

—Гыйндулла бабаемның кураенда уйныйсыңмы?—шулай диде дә салды Айсылу, җавап бирер урынга.

—Сирәкләп...—Сынтимернең тавышы капыл төшенкеләнде, хыялга артык бирелеп киткәненә кыенсынды, ахрысы.

Шулай, өметсез генә, тотнаклы хушлаштылар. Әмма бу өметсезлек йөрәкләрендә чәм кузгатты, сагыш утын дөрләтеп кенә җибәрде—ике ярдагы икәүнең мәхәббәте икеләтә көчәйдедер. Ярабби! Сөйгәннәр арасында очып йөрүче күзгә күренмәс фәрештәләр бардыр шул бу фани дөньяларда. Аларның берсе—Агайтуганнан Сөн буйларына, икенчесе—Сөн буйларыннан Агайтуганга очты һәм илаһи канатларында гашыйк ярларның, икесе ике ярда—аерылмаслык тәкъдирдә якын да, кавышмаслык тәкъдирдә ерак та—булган Сынтимер вә Айсылуның сүрелмәс хисләрен бер-берсенә китереп җиткерер...

Табылыр ласа бирәр форсаты, очрашыр ласа алар кайчан да бер?!



Зөлфәт

## БОРЫНГЫ ЯШЕН

* * *

**Чын дөресен әйтим сезгә, диеп,
Минә каләмгә мин тотындым—
Борынгыда—яшен булганмындыр,
Шул яшеннән калган ут булдым...**

**Суга языйм дисәм, яза алмыйм,
Хәрефләрем тоташ ут кына...
«Сөям!» диган гади бер сүзем дә
Яшьнәп ялтырарга омтыла.**

**Белмим инде, бу хорафат микән?
Әллә инде берәр тылсыммы?
Яшен икән, яшен! Язганнарым
Һаман яшен белән тулсынмы?**

**Тулсын, димен, чын дөресен сезгә
Әйтим диеп мин бит тотындым!
...Борынгы бер яшен булганмындыр,
Шул яшеннән калган ут булдым...**

### Мәхәббәтнең яралуы

**Туган туфрак диган ягың булсын
Һәм хәләлең булсын һәрвакыт.
Уятсыннар шулар синең уйны
Барлык былбылларын сайратып!**

**Туган якның сары сандугачы
Йкегезгә атап сайраса,
Асыл мәхәббәт дип әйтелгәннең
Яралуы шулдыр ләбаса!**

Зөлфәт (1947) — *шагыйрь; «Утлы бозлар», «Агыла болыт», «Йөрәгемне былбыл чакты» һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Сайрадымы качып бер сандугач
Өмет баглап сиңа һәм аңа?
Булмадымы? Сөйли генә күрмә,
Мин дә яшәдем дип дөньяда!

Сөеп яшәү—былбыл сайратудыр,
Сандугачның җанын кузгату,
Чын сөюне шул моң каршы алыр,
Хәтта ахырда да озатыр. . .

Сайрап торган сары сандугачлар
Тилерттеме сине һәм аны?—
Димәк, яралгансыз, мәхәббәтле
Итәр өчен бөек дөньяны...

## Дала түре

Гөлләрнең бер сөйләшәсе килә,
Казакъ даласының гөлләре. . .
Килде дә бу, абынгалап кына
Китеп бара инде, диләрме?

...Без Торсынтай белән дала кичтек.
Изге төшләр бар бит һәр җирдә!
Бардык
Кузы-Курпәч белән
Баян-Сылуларның эзләренә,
Каберләренә бер тезләнергә ...

Бардык көне буе... Дала кичтек!
Ә далада дөнья тар була...
Гашыйкларның эзен күргән чакта
Йолдызлы күк гүя ярыла!

## Дидер ул...

Боз ява, таулардан ай төшә,
Ташкыннар шашына, актара...
Тетрәнеп калабыз, бу иркә
Табигать котырган чакларда.

Табигать хәтерләп калганмы
Дөньяның яралган мәлләрен,
Адәмнәр белсен дип шул чакны
Һәм соңнан булачак хәлләрне?

Аз-азлап күрсәтә микән ул
Иң бөек дәһшәтнең гамәлен—
Дөньяның кайларга китәсен,
Дөньяның кайлардан килгәнен?

Яралу һәм үлем сулышын
Тойсыннар бәндәләр, дидер ул...
НӘРСӘдер түгел бит табигать,
Табигать һәрвакыт КЕМдер ул!

...Барыбер, Табигать, һичкайчан
Булмас ул мәңгегә таралыш!—
Табигать—һәрвакыт Яралыш,
Яралыш—һәрвакыт Яңарыш...

Бер үк ым бәндәгә—янартау
Тирәннән ут бөркеп атса да,
Тынса да тирә-юнь, сандугач
Үлепләр сайраган чакларда...

Димәк ки, нәкъ шулай, шул хәлдә
Булгандыр Яралыш... Күр, бәндә,
Үзеңә бирелгән елларда
Бу тере дөньяда йөргәндә!..

## Кое кибә...

Яши торгач күпне белсәм дә мин,
Шуны гына бары белмәдем—
Үзең түгел, авылың да хәтта
Инде күптән җиргә иңгәнен!

Икәү иелеп без сулар эчкән
Төбе айлы чиләк тирбәлә...
Инде яп-ялангач, җилле үрдә,
Безне танып белгән җирләрдә...

Чиләк—сусыз. Кое төбендә тик
Ни булды, дип, тетрәп Ай кала..
Безнең эзләр шыр бушлыкта инде...
Бушлыкта буш чиләк чайкала.
Кое кибә... Күктә Ай кала...

## Язгылык

Еллар күбәйде нигәдер, көннәр азайды...
«Яз!»—диде яз миңа... Яздым. Көннәр язайды!

Язарып кояш чыкты һәм офык язарды.
Язгандыр язмыш, күрәсең, шушы язларны!
Очты ул выжлап! Зыңгылдап җәя язылды.
Яшен булып язның сүзе күккә язылды...

Ымсындырды җанны гөнаһ—язык мәхәббәт!
Ташкын сыман узды тик бер язлык мәхәббәт...
«Яз!»—диде яз миңа. Яздым. Шул сүздән аздым,
Аз-аз гына яңарып мин язасын яздым!

Күңелемне бер күк итеп яз-болыт тулды—
Яздым... Һәм дә ялгызлыгым язгылык булды!..

## Илһамият

...Сулыштан шигырьгә кадәр,
Шигырьдән сулышкача.
Тылсымнар иңеп, күңелне
Гөл тажы итеп ача...

## Иске оя тынды...

Язгы тирәк... тибри кош оясы...
Өс ботакта ата саклап тора:
Әнкә кош күп бәбкә чыгармакчы.
Кузгалмый ул. Тынган. Гел утыра.

Күкрәп язгы яңгыр яуган чакта
Чыгар бәбкәләрне җылы котә.
Эре язгы яңгыр шыбырдашып,
Язгы җилләр һаман тибрәп үтә.

Көз тирәсе... тибри кош оясы...
Пыскый көзге яңгыр. Кошлар киткән...
Буш ояга суык оялаган!
...Һәммәсе дә вакытлыча икән...

Кышкы җилдә калды кош оясы...
Анда—бушлык, җил һәм кыш салкыны.
...Кеше җаны язмышы бу ласа!
Әле генә сайрап торган оя
Буп-буш калды... Сүнде... Тәмам тынды.

Мәңгелекнең тирәк ботагында
Иске оя тынган... Тибрәнми дә...
...Шулай булыр... Әмма әлегә гел
Язгы тирәк шаулый күкрәгемдә!

## Мине һаман су тарта!..

Төбе микән, дулкыннары микән?—
Дәшә дә гел дәшә күңелне!
Су тарта гел, һаман су тарта гел!
Чиксез сулар дәшә гел мине...

Гел сихерли мине сәер шул көч!—
Шомланам мин аның алдында...
Дулкыннары, бәлки, айкап йөртер,
Йә чоңгылы убар тын гына...
Диңгезчене шашындырган шаукым
Бармы әллә минем канымда?

Нәкъ шул шаукым каргый мәллә мине,
Ялгышларга баттың, бәндәм, дип,
Су төбе йә текә дулкын гына
Йолыр сине мондый хәлдән, дип?

Мин аңлата алмыйм бу халәтне...
Зур су шаулый ерак-еракта!—
Мине—аулак кара урман улын—
Ни хикмәттер?—һаман су тарта!..

## Җен җыры

Иблис кушкан сүзне өскә язып куйдым,
Үзем уйлыйм өзеп чылбырны:
—Кем белә бит, Иблис гимны бардыр,
Бардыр, бәлки, Җеннең дә җыры?

Мин җен җыры җырламадым микән
Үзем шыр фәрештә чагымда.
Җеннәр миңа кычкырмады микән?
«Тагын! Тагын! Тагын да!»

«Тагын!» икән «Тагын!» Бу мин—җен җыры.
Мин җен буламмыни, бозмагач?!
Караңгы тал арасыннан килеп,
Ут-кисәүдән скрипка сызмагач?!

Уйлап карасаң бит, бу шагыйрең
Аллаһ белән Иблис зынҗыры.
Рәнҗеп шагыйрь кулы бер сүз язса—
Шигырь түгел... Ул бит—җен җыры.

## Чоңгыл

Ник үлемнән куркасың син, Кеше?
Качып калырмын дип белдеңме?—
Ходай сиңа яшәр гомер биргән
Һәм бирмичә калмас үлемне.

Ә шулай да миңа килгән үлем
Ул чын үлем булмас шикелле..
Бөтерер дә убар бу дөньяның
Бөтерчекле чоңгыл-төпкеле.

Чоңгыл бөтерчеге эзе булып,
Вакыт елгасының өстендә
Су алкасы гүя бөтерелер,
Туктый, тына белмәс һич кенә...

Һәм, ниһаять ул да тынып калыр.
Вакыт тонар. Дулкын сүрелер...
Вакыт елгасының көзгесендә
Ходай Тәгаләнең мең дәһшәтле,
Мең дәһшәтле килеш шәфәгатьле
Күз карашы гына күренер...

...Яшәр гомер биргән икән Ходай,
Юк, онытмас, бирер үлемне...
Табигатьтән без убылган идек...
Табигатькә кабат убылуны,
Йә, син үлем дияр идеңме?..

## «Ни күрәсең анда?..»

*А. С. Пушкин җан биргәндә янында торган Жуковский бу мәлләр хакында кыска гына тетрәнгеч шигырь яза. Дустының йөзен сурәтләгәннән соң болай ди: «Һәм сорыйсым килде аңардан: «Йә, ни күрәсең син анда?»*

Әйләндерә Галәм йолдызларын
Һәм дәверләр иңә томанга!
Авыр сорау һәм дустанә сорау:
«Йә, ни күрәсең син анда?»

Ә җавапка сорау кабатланса?
Һәм ул кабатлана, минемчә...
Кайсы якта кем кала да, кайсы
Якка кайсың—тагын кем кичә?

«Йә, ни күрдең син анда?»—
Дус эндәшә дуска, аръякка.
Ул аптырап, йөдәп эндәшә бит!
Ничек өмет итсен җавапка?

Хәер: «Сорыйсылар килде...»—ди ул.
Һәм сорамый. Җавап кирәкми.
Әмма шушы теләк, терелткәндәй,
Тоташтырган ике йөрәкне.

Бөекләрнең сәерлегеме бу?
Йә, дустыннан дусты ни көтә?—
Кызгану да, ялвару да түгел,
Бу—ышану үлемсезлеккә...

## Җан җылысы

Була мәлләр, пошаманга төшеп,
Котсыз уйлар тула күңелләргә...
Җан җылысы, дибез... Була микән
Җан суыгы бездә—тереләрдә?..

Җан җылысы белән җылытырга
Телибез бит якын, газизләрне...
Җан суыгы белән өшетергә
Телисездер, бәлки, сез? Кемнәрне?

Җан җылысы төшкәч, сөю шыта,
Шул җылыда тып-тын чәчәк ата.
Чәчәк булгач, кырау суту бар бит,
Җан азыгы! Бу сүз—синең хакта!

Тегеннән дә кошчык булып кайтып,
Җылы җаным тәрәзәңә килер...
Тәрәзәңдә булса җан суыгы—
Җан җылысы җиңәр, суык эрер...

Дөнья бизәкләрең уңып бетсен
Күңлең җылы төстән бушаганда...
Бу хәл—дөрес түгел! Син ышанма!
Җан җылымны көт син... Пошаланма!.



Фәнис
Яруллин

# КЫЙБЛАСЫЗЛАР

ПОВЕСТЬ

Фатыйма юлга бик ныклап әзерләнде. Чәчтарашка барып чәчләрен матурлатты, тырнакларын буятты. Өстенә яңа спорт костюмы киде. Бу костюмны ире Илсур күптән түгел генә Чехиядән алып кайткан иде. Фатыйма аны бик яратты, чөнки аның дус хатыннары арасында мондый костюм киюче юк иде. Фатыйма яраткан костюмын киеп, гаражда һәрвакыт үзен көтеп ачкычын бер боругa кабынып китәргә әзер торган кара «Форд»ы янына килде. «Нихәл, дускай?»—дип машинасына кагылып, чәнчә бармагы белән аның өстен сыпырып алды. Бармак тигән урында эз күргәч, зәңгәрле-яшелле тавыш белән кычкырып җибәрде: «Сабина! Сабина, дим, чык әле монда!»

Ике катлы йортның коймасы артында посып утырган кечкенә өйдән ашыга-ашыга аксак хатын килеп чыкты. Фатыйма аны күрүгә: «Нигә машинаның тузанын сөртмәдең?»—дип ачулы тавыш белән дәште. Юкса аның бер ачуы да юк, күңеле күтәренке иде. Тик үзенең хуҗа, ә Сабинаның хезмәтче икәненә басым ясамаса, күтәренке күңелнең төшүе мөмкин. Ә Фатыймага бүген көн буена җитәрлек кәеф кирәк. Ул бик мөһим юлга чыгарга җыена. Ә мондый чакларда хезмәтчеңне кимсетүдән дә рәхәт ни бар?!

Сабина, телсез кеше кебек, тузанны үзенә җыя һәм буяуны тырнамый торган чүпрәк белән «эһ» дигәнче машинаны сөртеп алды. Фатыйма аңа рәхмәт әйтеп тормады, машинасын кабызды. «Форд», көтмәгәндә сыртына тимер чуклы каеш камчы төшкән айгырдай, кинәт кузгалып китте. Гараж эчендә әчкелтем төтенгә күмелеп хезмәтче хатын Сабина гына калды. Әллә машина төтененнән, әллә язмышына рәнҗүдән аның күзләре яшьләнде. «Йөриләр шунда әлләкем булып!»—дип сукрана-сукрана гараждан чыгып капкасын бикләп куйды.

Фатыйма шәһәрнең иң бай кибетенә юнәлде. Ире Илсурны үзе моннан алты ел элек ташлап киткән малаен алып кайтырга ризалата алуына, улын алып кайткан очракта байлыкка күмеләчәгенә ышану аның күңелен күтәргән иде.

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938)—*Татарстанның халык шагыйре; Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Күпсанлы шигырь, проза, драма әсәрләре һәм балалар өчен китаплар, шул исәптән биш томлык "Сайланма әсәрләр" авторы. Казанда яши.*

Фатыйма башта ук улын яратмады. Авырга узуын белгәннән бирле ул ана үзенен иреген чикләүче, матурлыгын урлаучы итеп карады. Фатыйманың күргәне бар: күп кенә сылу кызлар, бала табуга, солы капчыгына әверелә, күкрәкләре асылынып төшә, билләре юаная. Ә Фатыйманың үз байлыгын югалтасы килмәде. Ярый инде, вакытында «мунча пәрие» очрап куйды. Бөтенләй чит кешене «әти» дип йөри башлагач, улына карата тагын да нәфрәте арта төште. Шуна күрә ул, Илсурга чыккач, малае турында искә төшермәскә тырышты. Ә менә бүген улы кинәт кенә бик кирәк булды.

—Ай-һай, хәзер аны әтисе сина бирер микән? Мин булсам—бирмәс идем,—диде Илсур Мансурович.

—Бирмәскә анын хакы юк.

—Балага атанын да, ананын да хокукы тигез. Ярар, кайтып карарсын. Дөресен әйткәндә, мин үз улыбыз булуын теләгән идем. Булмады бит.—Илсур Мансурович үкенүле тавыш белән әйтте бу сүзләрне. Фатыйма аны юатырга теләгәндәй: «Син яратачаксын аны, Илсур»,—диде.

—Ярар, ярар, күрербез. Ләкин алдан кисәтеп куям: улын килергә теләмәсә—көчләмә.

—Ничек теләмәсен! Күрү белән кочагыма ташланачак,—диде Фатыйма һәм ирен үбеп алды.—Бөтенесе әйбәт булыр.

—Тик кара аны: улыннын берәр кыек эшен сизсәм, икегезне дә куып чыгарачакмын.

Фатыйма бу сүзләрне ишетмәде дә кебек. Анын уйлары күптән инде үзе укыган, шунда яшьлегенен ин татлы җимешләрен койган Н. шәһәрендә иде.

Кара «Форд» кибет янына килеп туктады. Кибеттә җанын ни тели—шул бар, әмма Фатыйма гомерендә беренче мәртәбә үзенә ни кирәген белми аптырап калды. Анын бу халәтен сизгер сатучылар бик тиз күрде.

—Чибәр ханымга ни кирәк икән?—диде берсе һәм:—Әйдәгез, кызлар, сайлашыйк чибәр ханымга кирәк әйберләрен,—дип кызларга дәште.

—Үзегезгәме, әллә улыгыз яки кызыгызгамы?—дип сорады арадан берсе. Кибет хезмәткәрләренен артык кызыксынуы Фатыйманын ачуын чыгарды. Хәер, монда ачу килерлек нәрсә юклыгын Фатыйма анлый, әмма бай кеше сәбәпсез дә кызып китәргә, теләсә кемне кимсетергә хаклы, дип саный иде ул. Кешедә яшеренеп яткан әрсезлек, әдәпсезлек байлык арткан саен өскәрәк калка һәм кешенен холкын үзгәртә. Кайчандыр сукыр тычкан кебек тавышсыз-тынсыз гына йөргән Фатыйма хәзер сүзләрен бөердән чыгарып әйтә башлады. Кешеләрне кимсетү күнеленә рәхәтлек бирде. Менә әле дә кибетчеләрнен: «Чибәр ханым, нәрсә алырга телисез?»—дип бөтерелеп йөрүләре җанын назлап торды. Башка вакыт булса, бәлки ул кибетчеләрне үз тирәсендә бераз биеткәннән сон: «Бу хәерчеләр кибете икән, монда мина ошардай әйбер юк»,—дип берни алмый чыгып киткән булыр иде. Кулында калын кашилүгенне сикертә-сикертә сатучыларны тәмам ымсындырып бетергәч, аларнын әйберләрен хурлап чыгып китүдән дә рәхәт ни бар сон? Бу гамәлен сине алар алдында әллә ничә баскычка күтәрә. Алар бит синен ике катлы, зиннәтле җиһазлар тутырылган өйдә кая барып бәрелергә белмичә, көннәр буе япа-ялгыз саргаеп ятучы гап-гади бер хатын икәненне белмиләр. Хәер, гап-гади хатынмы сон ул? Кесәгә акча күбрәк керә барган саен күнелдәге гадилек кими бара түгелме? Хәзер ул үзен нинлидер биеклектә сизә. Ә биеккә чыпчыклар түгел, бөркетләр генә оялый. Әнә шулай, Фатыйма биеклек белән түбәнлекне бутый башлады.

—Ярый!—диде Фатыйма күнелендәге уйларын куарга теләп.—Унбер яшьлек малай өчен киемнәр сайлагыз.

—Үзен күрмәгән кешегә кием сайлау авыр инде. Мөмкин булса, әйтегез әле: малаегызнын буе нинлиерәк? Ябыкмы, тазамы?

Сатучыларның бу сораулары Фатыйманың саруын кайнатты. Шулай да, ул ярсып китмәде: чынлап та анның Заһиты нindirәк икән хәзер? Анның бит инде улын күрмәгәненә күпме! Атасына ошаса...

Фатыйманың күз алдына ире Гыймай килеп басты. «Фу!»—дип куып җибәргәндәй селтәнгәләп алды Фатыйма. Анның селтәнүеннән курыккандай Гыймай юкка чыкты һәм анның урынына биш ел бергә укыган классташы Заһит пәйдә булды. Ул астыртын елмаеп Фатыймага карап тора башлады. «Малайның миннән икәнен онытма!»—дип әйтә иде кебек ул.

Заһит - озын буйлы чибәр егет. Фатыйманы кайда гына ялгыз очратса да, кызның төрле җирләрен чеметкәли, кайвакыт алар әүмәкләшеп тә китәләр. Андый чакта Фатыйма да кимен куймый: Заһитның кайсы җиреннән эләктерсә—шуннан умырып ала. Көче җитмәгәндә тешләшергә үк тотына. Аларның шаярганын карап торган кеше: кыргый җәнлекләр сугыша, дип уйлар иде. Бер-берләрен яратудан түгел, ә шушылай котырып үртәшү күпвакыт әдәп чикләреннән чыгып, азгынлык юлына алып кереп китә. Яшь кан тиз генә сүрелми. Тыелган сызыкны үтеп чыгу аларның йөрәгенә җину хисе булып тоела. Шаулап аккан елганың агымына кызыгып һаман эчкәрәк кергәненне сизми калган кебек ике кайнар йөрәк торган саен тирәнгәрәк керергә омтылды. Хәлен барында дулкыннар сине назлый, ә инде көчен кими барган саен алар усаллана, ярсый, ачулана һәм авырттырып-авырттырып кыйный. Суның агымы шаярып кына көтмәгәндә сине бөтереп ала да төпкә суыра. Ан томалана, акыл сизгерлеген югалта.

Фатыйма белән Заһит күп мәртәбә шундый хәлдә калдылар. Калкып чыгуга тагын төпкә чумасылары килде. Төпкәрәк төшкән саен асылташлар күбрәк табылыр төсле тоелды. Әмма көннәрдән бер көнне кыз үзенең «ятьмәсенә» чуртан кереп оялаганын аңлады. Билгеле, бу ана шатлык китермәде. Кыз бу хакта Заһитка әйткәч, чумышлы уйнаганда батыр егеттән җилләр исте.

...Фатыймага кыска буйлы, олы башлы Гыймай күптән кызыгып йөри иде. Кайвакыт кызны туктатып нидер әйтергә тели, әмма Фатыйма өчен Гыймай дигән егет әллә бар, әллә юк. Гыймайның үзен күзәтүе анның ачуын гына китерә.

—Мине сагалап йөрмә, карт пәри,—ди ана кыз һәм «карт пәри»нен башына кулында ни бар шуның белән берне менеп төшә. Гыймайның мона ачуы килми. Чынлап та ул Фатыймадан берничә яшькә өлкән һәм кыяфәте белән дә мактанырлыгы юк. Бәлки пәри Гыймай төсле буладыр?.. Кыска авыр гәүдә, кәрәктәй куллар.

Ятьмәдәге «балык» үзен сиздергәли башлагач, Фатыйманың ачуы чыкты. Ничә ел буе Заһит белән шул елгада коенып мондый хәлгә юлыкканы булмаганлыктан, ул инде Заһит белән коенган күлдә «балык» юктыр дип йөри иде. Менә сина мә! Бу «балык» чәбәләнә башлаганчы котылырга кирәк моннан!

Фатыйма врачка китте. Врач картаеп килгән, өрсәң җаны чыгарга торган сөйкемсез бер ханым иде. Ул Фатыйманы караганнан соң:

—Сина һичшиксез табарга кирәк. Котылу турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

—Мина кирәкми ул. Аны табып сездә калдырып чыгыйммы?

—Үзегез карап үстерерсез.

—Кирәкми! Үгетләмәгез мине.

—Мин үгетләмим. Менә мина карагыз әле.

Фатыйма врачка текәлебрәк карады. Һәм анын тәне буйлап салкын елан шуышып үткәндәй булды. Табибәнең йөзендә нур юк, күзләре хәрәкәтсез диярлек. Табибә үзенең кыяфәте кызга ничек тәэсир иткәнен күрде.

—Менә сезнең кебек чагымда мин дә «артык йөгем»нән котылырга килдем.

Мине үгетләп тормадылар, «йөгем»не, ә «йөгем» белән бергә күзләремнең нурын, йөземнең яктылыгын да суырып алдылар. Күп котыласын—бер тотыласын.

—Бөтен кызлар сезнең кебек булмый бит,—диде Фатыйма.—Бушанучылар дөнья тулы, өр-янадан тугандай йөриләр.

—Ямьсезләрнен—матурлыгын, тинтәкләрнең акылын суырып алып булмый. Сез чибәр һәм юләр дә түгеллер дип уйлыйм. Сезнең күнел түрегездә яна жан яралып ята. Жан кыюнын зур гөнаһ икәнен әйтеп тормыйм. Ул гөнаһ йөзгә бәреп чыгачак. Төшләрегезгә кереп йокыгыздан уятачак...

—Житте, сөйләмәгез,—диде Фатыйма һәм бу убырлы карчык яныннан тизрәк чыгып качу ягын карады. Табибәнең сүзләренә ышанмаса да эченә шом йөгерде.

Ә ятьмәдәге балык үзенә куркыныч янавын сизгән кебек, күпмедер вакытка тынып калды.

Фатыйма тизрәк тормышка чыгарга кирәк дигән максат куйды. Шунда ул Гыймайны исенә төшерде. Юри генә Гыймайның юлында очраган булды, юри генә: «Нихәл, мунча пәрие?»—дип чытлыкланып алды. «Мунча пәрие» кызнын үзенә мөнәсәбәте үзгәрә баруын сизеп, күнеленнән зур өметләр баглап йөри башлады.

Гыймай гадәттә урынга барып яту белән йоклап китә иде. Әйтерсен киселгән агач—кайсы ягы белән ятса—шул ягы белән тора. Тау күкрәгеннән һәркөн саен ташлар актарып ала-ала аның хәле калмый. Ләкин хөкүмәт таш кисүчеләргә караганда юкны бушка әйләндереп йөрүчеләргә күбрәк түли. Дәүләт өчен чиновниклар кадерлерәк. Алар машинада гына йөри. Эшкә килүгә «каядыр чыккан» була.

Артык арып кайтмаган көннәрдә Гыймай дөньядагы гаделсезлек турында уйланып ята. Менә бүген дә борынын мендәргә төртү белән йоклап китмәде, уйланып ятты. Ә уйлары матур иде аның: Фатыймага өйләнеп үз тормышынны корып жибәрү. Фатыйма ана «мунча пәрие» дигән кушамат таккач, кызны тагын да якынрак күрә башлады. «Яратканга әйтә, яратканга! Яраткан кешеләрне генә шулай үртиләр. Димәк, мин әле кызлар яратырлык егет!»

Гыймай шундый якты, өметле уйлар белән йокыга китте. Әмма йокысы бик тынычсыз булды. Имеш ул якты алан буйлап, андагы чәчәкләргә сокланып бара. Хозурланып йөрү озакка сузылмый. Ниндидер бер болыт күкнең зәңгәр дингезеннән агып килә дә Гыймайның баш очында эленеп кала. Кояш сүнә. Гыймайның бөтен тәне буйлап салкын агым агып үтә. Карга өерен кугандай Гыймай «Көш! Көш!»—дип болытны куарга тели: куллары белән селтәнә, аланда аунап яткан агач ботакларын ыргыта. Болыт кузгалмый, әйтерсең аны күккә кадаклаганнар. Гыймай кояшлы аланга чыкмакчы була, тик аяклары бик авыр кузгала. Хәле бетеп кояшлы аланга чыгып житкәндә генә теге болыт тагын да куера төшеп егетнең түбәсенә эленә. Курку белмәгән Гыймайның йөрәгенә шом йөгерә. Ул калтырана башлый.

—Кит әле, болыт, кит моннан! Нигә мине эзәрлеклисен болай? Каплама кояшны, миңа яктылык, жылылык кирәк,—дип кычкыра Гыймай болытка. Гыймайның тавыш дулкыннары болытка килеп бәрелә һәм болыт төрле рәвешкә кереп таркала, ә берсе—иң тыгызы, иң авыры егетнең жилкәсенә менеп атлана. Күпме генә көчәнмәсен, егет болытны иннәреннән алып ташлый алмый.

Гыймай шабыртма тиргә батып уянып китә. Төшен нәрсәгә юрарга да белми, аптырап, миңгерәүләнеп йөри. Бөтенесе әйбәт бара бит югыйсә. Гомергә янына якын жибәрмәгән Фатыйма ана егет кеше итеп карый башлады. Тынычланырга гына да бит. Эштә вакытларда бераз онытылып торса да, өйгә кайтып ял итәргә яттымы уйлар болытына урала. Ниһаять уйлар

тоткынлыгыннан арынгандай була егет. Ләкин тынычлыгы озакка бармый, берничә көннән соң икенче бер төш кереп аны аптырашка сала. Бу юлы ул үзенең таудан таш чыгарганын күрә. Ташлар шундый ап-аклар.

—Бу ташлардан өй салып куйсаң, бөтен урамны балкытып торыр иде,— дип уйлый Гыймай һәм беркемгә әйтмичә, бу ташларны аерым җыя. Кеше күрмәсен, дип өстен үләннәр белән каплый. Берничә көн җыйган ташларны үзләренә машина белән алып кайтыйм дисә, ни күрә—таш өеме өстендә пычрак итекле кемдер йөри. Ул кешенең итеге тигән ташлар пычранып кына калмый, уала. Тагын шунысы бик гаҗәп: уалгач, алар үзләренең аклыгын югалталар. Димәк, эче кара булган.

Уянгач та, Гыймай: «Бусы нәрсә икән инде тагын?—дип уйлана һәм шундый нәтиҗәгә килә:—Тизрәк өйләнергә кирәк! Тәндәге көч саташтыра мине. Таш кисү ничек авыр булмасын, тәндәге икенче көч үзенекен итә: котырына, куркыта, шомландыра. Шушы котырган көчне чыгармыйча торып, тынычлана алмастыр ул, мөгаен».

* * *

Фатыйма кибеттә малаена кием сайлаганда озынча буйлы, ябык гәүдәле Заһитны күз алдында тотты. Нинди киемнәр алырга икән дип торганда, кибеткә туптай атылып бер малай килеп керде. Ул нидер алырга кергән идеме икән, ләкин малай авызын ачканчы сатучыларның берсе: «Үскәнем, сина ничә яшь әле?»—диде.

—Унбер яшь. Исемем Тимур.

—Әйбәт, әйбәт!—диде сатучы кызлар һәм Фатыймага карадылар. Фатыйма: «Минем Заһитым нәкъ шушы Тимур кадәр булырга тиеш»,—дип уйлады.

—Менә шушы малайга яраклык киемнәр сайлагыз,—диде ул сатучы кызларга.

—Кышкы киемнәрме, җәйгелектә кияргәме?

—Кышкы да, җәйге дә, яз һәм көзге дә,—диде Фатыйма.

Сатучылар төрлесе төрле якка таралышты. Берсе спорт костюмы, икенчесе ботинкалар, өченчесе пальто белән бүрек алып Фатыймага төреп тоттырды. Шунда сатучы кызларның берсе Тимурдан сорап куйды: «Тимур, синең кебек малайларга иң кирәкле әйбер ни була?»

—Туп!—диде малай.

—Туп? Нинди туп?

—Футбол тубы инде,—диде Тимур шуны да белмисез, дигән сыман.

Фатыйма кызларга ымлады: ике туп!

Сатучылар Фатыймага ике туп китереп тоттырдылар. Фатыйма бер тубын Тимурга бирде. «Мә, рәхәтләнеп уйнагыз!»

Малай рәхмәт әйтергә дә онытып чыгып китте. Алган әйберләрен Фатыйманың машинасына төяп җибәрделәр. Фатыйма олы юлга чыгып китте.

* * *

Фатыйма үзенә сөйкемлерәк карый башлауга, Гыймай кыюланып китте. Бер көнне ул Фатыймага: «Чибәркәй, чык миңа кияүгә, кулларымда гына күтәреп йөрттермен»,—диде. Фатыйма уйга калды. Аның бу бер катлы «мунча пәрие»н алдыйсы килми иде. Егетнең күзенә карап торганнан соң:

—Кулларында күтәреп йөртергә көчең җитәрме соң?—диде.—Без бит...

—Җитәр!—диде Гыймай кызның сүзен әйттереп бетермичә.—Мин ташчы егет.

—Таштан да авыррак нәрсәләр була.

—Таштан авыррагын да күтәрербез.

—Алайса бел: мин үзем генә түгел...

Гыймай берни анламады.

—Минем йөгем бар.

—Нинди йөк?—Гыймай һаман берни төшенмәде.

—Хатын-кызда нинди йөк булырга мөмкин соң?

Шуннан соң гына егетнең башына барып житте. Ул, маңгаена кусәк белән тондыргандай, ангыраеп калды. Фатыйма инде китеп барырга уйлаган иде, Гыймай анына килеп өлгерде.

—Туктале, Фатыйма,—диде ул.—Китмә! Мин сине «йөгең» белән күтәрәм.—Һәм Гыймай кызны кулларына күтәреп өенә таба атлады.

• • •

Фатыйманың күзләре юлда, уе—Үткәннәрдә. Ә үткәннәр әле Заһитка, әле Гыймайга килеп тоташа. Заһит Фатыйманың Гыймайга кияүгә чыкканын ишетү белән качкан жиреннән кире кайтты. Ул Фатыйманы очратырга теләп, бәбкә сагалаган тилгәндәй, Гыймайлар өе тирәсендә әйләнде. Беркөнне Гыймайның эшкә киткәнен күреп ялт кына ишегалдына сикерде. Фатыйма болдырга нинди дер савыт күтәреп чыга иде. Чит кешенең ишегалдына керүен күреп чылбырга бәйләнгән Сарбай өрергә тотынды.

—Сарбай, нишләп тавыш куптарасың? Менә бит үзеңә ашарга алып чыктым,—диде Фатыйма, ләкин эт бер генә секундка туктап торды да тагын өрергә тотынды. Фатыйма тыкрык ягына күз салды. Аннан әрекмәннәр арасыннан аксый-аксый Заһит килеп чыкты.

—Заһит?—Фатыйманың күзләре шар булды.

—Аягымны сындырдым ахры,—диде Заһит мескен тавыш белән.

—Нишләп йөрисең соң син монда?

—Менә үтеп бара идем, кинәт бер чокырга бастым... Шунда шартлап аяк сынды.

—Сынган аяк белән ничек безнең ишегалдына керә алдың соң син?

—Әй, күп сорашма әле.—Заһит жиргә утырды. Эт тә өрүдән туктады. Фатыйма алып чыккан ашын аның алдына куйды.

—Әйдә, өйгә кер. Аягыңны бәйләргә кирәктер бит,—диде Фатыйма.

Бу сүзләр Заһитның йөрәгенә ефәк булып уралды. Ул аксаклый-аксаклый болдыр баскычыннан менеп өйгә керде. Һәм Фатыйма аны-моны уйлап өлгергәнче хатынны күтәреп тә алды.

—Ә аяк?—диде Фатыйма.

—Аякка берни булмаган ана. Сине сагынып кайттым мин, Фатыймам.

Фатыйма Заһитка үпкәле иде. Күңеленнән аны мәңге кичермәскә антлар итте. Ләкин Заһитның куллары үзенең биленә уралуга антлар онытылды, үпкә рәшә булып таралды. Заһит аны караватка күтәреп салды да шашынып үбәргә тотынды. Куллар-аяклар үрелеште. Өй эче мышнаган, чинаган һәм тагын нинди дер ят өннәр белән тулды. Караваттан мендәрләр тәгәрәде. Юрганнар бозау чәйнәгән чүпрәк хәленә керде.

Бераз сөйләшерлек хәлгә килгәч Фатыйма:

—Нигә теге вакыт качтың син?—диде.

—Качмадым. Срочно военкоматка чакырдылар.

—Сине армиягә алдылармыни?

—Юк. Әтиләр акча түләп ансын жайлады.

—Алайса син хәзер иреклe?

—Ничек ирекле?

—Соң, армиягә китәсең юк.—Фатыйма бераз сүзсез торды.—Мин бит Гыймайга бала ятим тумасын дип кенә чыктым.

—Дура!—диде Заһит.—Анардан котылу—бер тапкыр бәдрәфкә барып килү кебек кенә бит. Котылырга кирәк иде.

—Син бит мине яратасың, Заһит. Әйдә, хәзер үк үзегезгә алып кит мине.

—Ярату ул—язучылар уйлап чыгарган әкият. Шул әкияткә кешеләр үзләрен ышандырырга тели.

—Алайса ни пычагыма минем яныма килеп йөрисен?

—Синең жиңең тарта мине. Шул «жен»гә ияләштем.

—Син әйткән «жен» бәлки минем мәхәббәтемдер.

—Бәлки. Минем мондый сорауларга җавап эзләп утырасым килми.

—Яратасың, яратасың. Миннән башка тора алмаганга киләсең син,—дип Фатыймаа сүзне шаяруга күчерергә тырышты. Заһитның да бу мәсьәләдә тирәнгә керәсе килми иде. Ул Фатыйманы күтәреп алды.

—Фатыймакай, мин сине беркайчан да ташламаячакмын. Тормышым бераз көйләнү белән үземә алып китәрмен. Ә хәзергә...—Заһит китәргә җыена башлады, Фатыйма аңа ябышып:

—Тормышны бергә җайларбыз. Алып кит мине моннан. Минем мунча пәрие белән яшисем килми.

—Ни бит...—Заһит ни әйтергә белми торды.—Ни бит, Фатыймакай. Мин сине бу йортта бер көн тотмас идем. Армиядән мин бит качып йөрим.

—Әниләр акча түләп алып калдылар, дигән идең түгелме?

—Бу алып калулар вакытлыча гына булды. Теләсә кайсы көнне муеныма камыт кидерергә мөмкиннәр минем. Бер-беребезне төрле сораулар белән интектермик әле, Фатыймакай-гөлкәй.—Заһит Фатыйманы өр-яңадан үзенең назларына күмеп ташлады. Заһит кочагында Фатыйма тәмам эреде.

—Һәрвакыт ирекле булып калыйк. Ир белән тору—иркенне авызлыклау түгел. Сусаган саен су эчерергә Гыймаең кирәк сиңа. Артык сусатып интектермиме соң мунча пәриең?

Фатыйма Заһитның колагына нидер әйтте. Алар икесе дә көләргә тотындылар. Көлүдән туктагач Заһит:

—Алайса, ул яктан уңгансың икән,—диде.

—Әйе. Мунчага барсам бөтен кеше миңа карый, дип ул шәһәр мунчасына да йөрми. Әтиләренең мунчасына йөрибез.

Заһит әкрен-әкрен Фатыйманың күңел серләрен суырды. Китәр алдыннан ул бик кыенсынган рәвешкә кереп:

—Фатыймакай-гөлкәй, әгәр синнән бер әйбер сорасам, арабызга күләгә төшмәс микән?

—Нәрсә сорамакчы буласың?

—Аны әйтергә дә кыен инде.—Заһит оятлы эш эшләгәндәй түбән карап, аягының баш бармагы белән идәнне «чокып» торды, аннары Фатыйманың күзләренә карап:—Бик кыен хәлдә калдым бит әле мин, Фатыймакай,—диде.

—Нинди кыен хәл?

—Акча кирәгие.

—Бик күп кирәкмени?

—Кемгә күп, кемгә әз.

—Шулай да?..

—Ун мең!

—Әстәгыфирулла! Нишлисең ул кадәр акча белән?

—Әтиләр мине армиядән коткарыр өчен бик күп әҗәт җыйганнар. Хәзер акча биреп торучылар шуларны тыкырдаталар. Җитмәсә процент белән. Тиз арада табып бирмәсәң, берәр караңгы почмакта тончыктырабыз, диләр. Әле бу түлисе акчаның уннан бере генә.

Фатыйма уйга калды. Ире аның эштән соң кешеләргә рамнар ясап шактый акча таба. Ләкин аны аңардан ничек сорарга?! Хәер, Фатыймага бит ул: «Үз кирәгеңә тотарсың»,—дип ай саен шактый акча биреп бара. Туктале... Фатыйма урындыкка басып шкаф өстенә куелган бер тартма алып төште. Анда биш

менләп акча бар икән. Ике уйлап тормастан шуларны Заһитка тоттырды. Заһит бик тиз генә акчаларны йомарлап кесәсенә тыкты, ә үзенең күзләре тартмадагы алтын муенсага төште.

—Бик кыен инде мина синең алда, Фатыймам минем. Әмма ләкин бу биш мең генә безнең этине үлемнән коткармас шул...—Заһит Фатыйманың алтын чылбырын кулына алды.

—Нинди матур. Бик кыйбаттыр инде бу?

—Кыйбат! Аны туй бүләге итеп мина Гыймай алып бирде. Менә балдак белән.—Фатыйма Заһитка кулындагы алтын балдагын күрсәтте.

—Кием карыйм әле шул балдагыңны, мөмкин булса,—диде Заһит.—Юкса минем андый кыйбатлы әйберләрне тотып караган юк.

Фатыйма балдагын Заһитның учына салды. Заһит әле алтын чылбырга, әле балдакка карап сокланып торды. Хәер, бу соклану түгел, корбанына караган ерткыч карашы иде.

—Боларын да мина биреп тормассыңмы, дисәм оятсызлыкка китәр инде.

—Синең өчен берни жәл түгел, Заһиткаем. Тик Гыймай теге алтын әйберләренне нигә кимисең, дип сораса?

—Юк, алмыйм!—диде Заһит,—акчаларыңны да кире кайтарам.—Ул хатын-кызның психологиясен шактый нык белә иде. Шуна күрә кесәсендәге акчаларын Фатыймага кайтарып бирде. Заһит бу гамәле белән Фатыйманың «мин-мин»легенә тиячәген аңлый иде. Һәм ул Фатыймага тагын да ныграк басым ясарга теләп, чыгып китәргә ашыккан кеше кебек, нәрсәдер эзләде, кабаланды. Аннары кырт кына:

—Йә, хуш!—диде.

—Туктале,—диде Фатыйма.—Этиләрең жәл түгелмени?

—Жәл конечно. Ну син, Фатыймакай, минем өчен бөтен кешедән дә кадерле. Минем аркада Гыймаең белән арагыз бозылып китсә...

—Гыймай бичара бер бозау ул. Мә, ал акчаларны, алтын әйберләрне.

—Юк, юк,—дип каршы төшкән булды Заһит. Ә үзенең йөрәге дон-дон тибә, күзләре яна иде. Әмма Фатыйманың күңелен тагын бер айкап алуны кирәк тапты.

—Жанымнан артык күргән кешедән ничек шул кадәр байлык алыйм? Ничек оялмыйча синнән сорый алдым икән дип шаккатып утырам әле. Ахмак мин. Синең исеңнән исереп башын жуйган ахмак.

Әле генә мәхәббәт юк ул дип бәхәсләшеп утырганын онытып, Заһит бөтенләй башкача сайрый башлады. Бер мизгел эчендә ул үзенең үткән тормышын, Фатыйма белән танышуларын хәтер сукмагы аша уздырып алды. Этисе авариягә эләгеп үлгәннән соң, кырыгын уздыруга ук әнисе килмешәк бер үзбәккә кияүгә чыкты. Малай тәртипсезләнде. Үги этисенең ботинкаларына яки куртка кесәләренә бака салып куя иде. Үзбәк Заһитның ыштанын төшереп каеш белән каезлый. Әнисе үзбәктән әллә курка, әллә улын яратып бетерми—иренә каршы төшми. Ә бер елдан үз балалары тугач, Заһитка өйдә урын калмады. Аны балалар йортына тапшырдылар. Балалар йортында Заһит бөтенләй азды: урлашу дисеңме, үзеннән кечеләрне кыйнау дисеңме—берсе дә калмады. Тәрбиячеләр улыңны моннан ал, дип әнисенә әйтеп-әйтеп карадылар. Ләкин ана үзбәк сүзеннән чыга алмады. Өч елдан соң Заһитны этисенең энесе Сәгыйть үзләренә алдырып, интернат-мәктәпкә урнаштырды. Бу интернатта укучыларның күпчелеге авыл балалары булганлыктан басынкылар, йомшаклар иде. Заһит беренче мәртәбә Фатыйманы шунда очратты. Кыз, башкалар кебек авылдан килсә дә үзен шактый иркенле тота иде.

—Һәй, сары чыпчык, исемең ничек синең?

—Синеке кебек Заһит-маһит түгел инде,—диде кыз һәм классына йөгереп кереп китте.

—Кара син аны, минем исемне белә!—дип горурланды Заһит.

Фатыйманың да йөрәге аша үткәннәрнең кайнар агымы узды ахры. Ул һич икеләнмичә әйберләрен Заһитка сузды.

—Мә, ал, йә кире уйлый башлармын.

Фатыйма акчаларын һәм алтын әйберләрен бер кульяулыкка төреп Заһитның кесәсенә салды.

—Мин аларны бик тиз кайтарачакмын сина. Себердә безнең әтинең энесе нефть эшендә эшли. Анардан берәр атна эчендә йөз мең сум акча килеп төшәргә тиеш. Шул килеп житү белән...

Заһит чыгып китәргә торганда гына эт өрергә тотынды. Икесе дә сагаеп калды. Фатыйма әллә Гыймай кайттымы, дип пошаманга төште, чөнки Сарбай Гыймайны шулай шатланып каршы ала иде. Фатыйма сак кына ишекне ачып тышка чыкты. Гыймайның әтисе үтеп бара, эт шуңа өргән икән. Эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, һәр икесе жиңел сулап куйды. Аласын алган Заһит тиз арада чыгып китү ягын карады.

Шул китүдән Заһит айдан артык күренмәде. Менә ул бер көнне тагын Фатыймалар өе тирәсендә әйләнеп йөри башлады. Өйдә Гыймай юкмы—шуны тикшерүе иде аның. Койма ярыгына авызын куеп әкрен генә Сарбайга дәште: «Сарбай жанаш, өйдә кемнәр барын әйтмәссеңме?»

Заһитның тавышына эт өрергә тотынды. Өйдән Фатыйма чыкты.

—Фатыймакай, мин, синең Заһитың. Өйдә үзең генәме?

—Әйе.

Шул сүзне ишетүгә Заһит койма аша ишегалдына сикерде. Ул колачын жәеп Фатыймага таба килә башлаган иде, Фатыйма артка чигенде. Заһитның өс-башы пычрак, күз төпләре күгәргән, битендә ниндидер яра эзе.

—Курыктыңмы, кадерлем? Әйе, минем кыяфәттән куркырлык шул.

—Нәрсә булды, Заһит?

—Әй, сорама, Фатыймакай.

—Шулай да?..

—Сина теге акчаларны китергәндә ниндидер шайка юлыма каршы төште дә тартырга сорады. Тартмыйм, дигәч икесе килеп кулларымны тотты, берсе битемә пычак очы терәп торды, калганнары кесәләремне актарырга тотынды. Кесәмдә синең алтын әйберләрең белән бергә теге Себердә эшләүче абзый жибәргән йөз мең акчаның илле меңе бар иде.

—Нишләп кесәнә шулкадәр акча салып йөрисең? Безнең шәһәр шпаналар шәһәре икәнен белмисеңмени?

—Беләм, жаным, беләм. Син мина шулкадәр яхшылык эшләгәч, минем дә бурычлы булып каласым килмәде. Мин яхшылыкны бише белән кайтара торган кеше.

—И жүләрем минем! Нигә мина шулкадәр акча? Әтиләреннең әжәтен түләргә идең.

Фатыйма Заһитның әтисе күптән вафат булганлыгын, әнисенең ниндидер билгесез эш белән шөгыльләнүче үзбәккә чыгуын, Заһитның күпмедер вакыт балалар йортында тәрбияләнүен белми иде. Заһит үзенең эчке дөньясын иң якын дусларына да ачмады. Сәгыйть абзыйсы интернат-мәктәпкә урнаштыргач та, әти-әниләре турында сораштыручы булса: «Алар Америкага акча эшләргә киттеләр»,—ди иде. Күпләр моңа ышана, чөнки ял көннәрендә бик шәп импортный джип Заһитны абыйларына алып кайта иде. Егетнең: «Армиядән коткарып калырга әти-әниләр йөз мең акча түләделәр»,—диюе Фатыйманың күңелен йомшартып акча алу һәм шуның белән уен автоматларында оттырган бурычын түләү иде. Теге вакыт Фатыйма акчалары аны афәттән коткарып калган иде, ләкин янадан зур сумма оттырып түләми йөри башлагач, беренче юлга кисәтү йөзеннән, бик каты тәпәләп ташладылар.

Заһитның канлы күлмәкләре белән Фатыймаларга килүе үзенең «дуслары»ннан качуы иде.

Фатыйма Заһитны өенә чакырды.

—Урман—колак, кыр—күз, ишегалдының да күзе булырга мөмкин,—диде ул.

Фатыйма Заһитка булган хисләрен аңлатып та бирә алмый. Заһит югында ул аны онытып тора: әйтерсең Заһит конфет, ә Фатыйма кечкенә бала. Бала бит конфет булмаганда аны уйлап та карамый, ә инде матур кәгазьгә төрелгән конфет күрсә, тәкатьсезләнеп әти-әнисеннән шул «мәми»не сорый.

Фатыйма өчен Заһит—матур кәгазьгә төрелгән конфет. Ләкин ул ялтыравыклы кәгазь эчендә нәрсә икәнлеген һич белә алмый, чөнки Заһит һәр килүендә башка «кәгазьгә төрелгән» була. Егет артык оялчанмы, куркакмы—һич аңларлык түгел. Өйгә керергә чакыргач та ул шактый ялындырды.

—Мондый пычрак өс-башым белән ничек синең кершәндәй ак идәненә басыйм?

—Әйдә, әйдә, идән пычранса, тагын юармын.

—Юк инде, Фатыйма, мин китим генә.

—Шушы килеш урамга чыгасыңмы?

—Минннән шакшылар да йөри әле.

—Минем сине чип-чиста йөртәсем килә. Син бит минем туачак улымның атасы.—Фатыйма шактый тулыланып килгән корсагын ышкып куйды.

—Йә, ярар алайса, керәм.

Заһитның бала турында ишетәсе килми иде, ул сүзне икенчегә борырга ашыкты.

—Өегез бигрәк нурлы сезнең, Фатыйма. Синең йөзең төсле.

Егетнең мактавы Фатыйма күңеленә сары май булып ятты.

Өйгә кергәч, ул Заһитны анадан тума чишендерде.

—Мин хәзер синең бу шакшы киемнәреңне тиз генә машинага салып алам.

—О-о!—диде Заһит ризасызлык күрсәтеп.—Синең ул машинаң минем әйберләрне ике-өч сәгать болгатачак. Мин сездә ике-өч сәгать ыштансыз утырырмынмы?

—Ә нигә? Утырырсың, утырасың килмәсә ятып торырсың.

—Ирең кайтып керсә?

—Әй куркак та инде үзең.

—Мин синең өчен куркам, җүләр. Минем аркада арагыз бозылмасын, дим.

—Бозылмас!—диде Фатыйма каттый итеп һәм Заһитның киемнәрен кер юу машинасына чумдырды.

—Бер сәгатьтән киемнәрең юылган һәм кипкән булыр. Ә син өстеңә менә бу халатны киеп тор, күрше-күлән керүе мөмкин.

Заһит Фатыйма биргән халатны киеп куйды. Ул хатын-кыз халаты булып чыкты. Өстәвенә берничә төймәсе дә юк икән. Заһит көзге каршына килеп басты да үзеннән-үзе көләргә тотынды

—Нәрсә бар?—диде Фатыйма.

—Кил әле, кил. Ни барын үзең күрерсең.

Фатыйма Заһит янына килде һәм ул да көләргә тотынды. Анда көзгедә, халатның төймәсез урыныннан мәче башлы ябалак карап тора иде.

—Каян кергән ул анда, әллә урманда йөрденме?—дигән булды Фатыйма.

—Урман аша үткән идем шул,—диде Заһит шаяруга каршы шаяру белән.

—Гадәттә ябалаклар төнлә генә оча торган иде. Яктыда бит алар күрмиләр.

—Ә без хәзер төн ясыйбыз.—Заһит калын пәрдәләрне төшерде. Өй караңгыланып китте.—Менә караңгы төште, ябалак очар вакыт житте.

—Кара син нинди тылсымчы икәнсен. Бу һөнәреңне белми идем әле.

Шулай шаярыша-шаярыша караватка аудылар.

Тагын мендәрләр ишелеп төште, тагын бөтен нәрсә йомарланып бетте. Фатыйма башта саграк кыланырга маташкан иде, ләкин, кызып киткәч, кабара башлаган корсак онытылды.

Вакыт бик аз үткән кебек тоелган иде, тик кер юу машинасы үзенең эше беткәнен белгертеп сызгырып куйды. Фатыйма сикереп торып машинадан керләрне алды. Алар юылган, кипкән иде. Фатыйма аларны үтүкли башлады. Заһитның карыны бик ачкан иде, кухняга кереп суыткычта актарына башлады. Суыткыч бай булып чыкты. Заһит гомергә ризык күрмәгән кешедәй, бер кулына казылык, икенче кулына кыйммәтле сыр эләктерде. Ризыкларның әле берсен, әле икенчесен авызына дөмбәсләп маташканда аның күзе бер шешәгә төште. Шешәне ачып башта иснәде (уксус-мазар түгелме). Юк, түгел икән—спирт исе килә. Заһит голт-голт итеп эчемлекне йотты. Шешәдә аракы түгел, чын спирт булып чыкты. Заһит исерә башлаганын сизде, ә аңа исерергә ярамый, юкса кармакка кабуы бар.

Ул, бераз капкалагач, Фатыйманың халатын салып ташлап әрле-бирле йөренә башлады. Киемнәрен үтүкләп маташкан Фатыйма янына чыкты.

—Мә, чалбарыңны кия тор.

Чалбар артыннан башкалары әзер булды.

—Бигрәк уңган хатын син. Әгәр мөмкинлегем булса, сине беркемгә бирмәс идем. Наз белән күмеп тотар идем үзеңне. Кочагымнан чыгармас идем.

—Тел бар инде үзеңдә.

—Тел генә түгел бит, Фатыймам.—Заһит Фатыйманың корсагын сыйпап:—Менә моны бит тел белән кабартып булмый.

—Житте инде, мактанма. Ул ишәктә дә бар.

Заһит ашыга иде, сүз куертып маташмады. Ашыгуына карамастан, ул һаман ишек төбендә таптанды. Нәрсәдер сорыйсы килгәнлеге әллә каян күренеп тора иде.

—Фатыймакай-жанкай,—диде хатынга сырпаланып.—Бу дөньяда синнән шәп кеше юктыр, валлаһи. Матурлыгыңны әйтмим, ансы болай да күренеп тора. Хәзерге хатын-кызларда сирәк очрый торган йомшаклык, шәфкатьлелек, юмартлык бар синдә. Художник булсам, мин синең портретыңны ясар һәм аны «Гүзәллек» дип атар идем.

Фатыйма Заһитны бераз аңлый башлаган иде инде: бу мактау артында нәрсә яшеренгәнен көтте. Заһит озак көттермәде, Фатыйманы кочаклап алып мышный башлады. Хатын аның чәчләреннән сыйпап:

—Нәрсә булды?—диде.

—Соң әйттем бит: сиңа акча китергәндә бандитлар таладылар, дип. Менә хәзер бер тиенсез калдым. Автобуска түләргә дә акчам юк. Ә күпме әҗәт түлисебез бар.

—Әҗәтле үлми,—диде Фатыйма.—Озаграк яшәрсең.

—Фатыймакай-жанкай, беләсең килсә, минем дөньяда яшисем килми. Әгәр син булмасаң, әллә кайчан үземне-үзем буып үтерә идем инде.—Заһит рольгә кергәннән-керә барып, ике кулы белән бугазын буа башлады. Егетнең күзләре акайды. Фатыйма куркып Заһитның кулларына килеп ябышты.

—Жүләрләнмә, Заһитым. Менә бит синең яраткан Фатыймаң янында. Әҗәт дип инде. Табарбыз. Түләрбез.

Акча бит ул—мунчала,
Юынабыз, сөртенәбез

Акча белән мунчала,—дип жырлый иде безнең авылда бер карт. Шул мунчала сөртенә торган мунчала өчен үлеп торалармы?! Күпме кирәк?

—Күп түгел, бер-ике мең генә.

Кичә генә Гыймайга кемнендер бакчасында парник ясаган өчен шактый акча китергәннәр иде. Гыймай ул акчаларны Фатыймага биргәндә:

—Тиздән малай туар вакыт житә. Бишекле арбалар караштырып йөри башладым инде, ә син вак-төякләр алгалый башла,—дигән иде. Фатыйма ике уйлап тормастан шул акчаларны Заһитка китереп тоттырды: «Мә, саграк йөр!»

—Рәхмәт, кадерлем. Мин синен алдында гомерем белән бурычлы.—Ул пафоска бирелеп Фатыйма алдында тезләнде дә, хатынның аякларын үбәргә тотынды. Фатыйма кыенсынып: «Кирәкми, Заһит, алай түбәнсенмә»,—дип аякларын кыймшата башлаган иде, Заһит аларны тагын да катырак кысып, тубыктан—тезгә, тездән тагын да өскәрәк менә башлады: «Син фәрештә бит, Фатыймакай. Фәрештәнең кай жирен үпсән дә савап кына».

Бөтен тәне һәрвакыт наз сорап торган хатынга житә калды. Ул бөтенләй эреп төште. Хәтта өстендәге күлмәген кайчан салып ташлаганын да хәтерләмәде. Үзе дә ниндидер хайвани комсызлык белән Заһитны үбә башлады. Заһит Фатыймадан бу кадәрлесен үк көтмәгән иде: гажәпләнү катыш рәхәтлек тоеп басып торды.

—Син минем мәңгелек мәхәббәтем, Фатыймакай,—диде чыгып киткәндә Заһит.—Озаграк килә алмый торсам, онытты дип уйлама. Син онытыла торган кеше түгел.

—Мине дә ал үзең белән. Ни күрсәк тә бергә күрербез, Заһит,—диде Фатыйма.

—Юк, кадерлем. Сине төрле куркыныч астына куйсам—мин кем булам. Хәзер бит безнең малаебыз туарга тора. Ә минем сине апкайтырлык шалашым да юк. Йә, хуш, жаныем. Дөньям рәтләнгәч, барыбер эзләп табачакмын, ансына шикләнмә!

Заһит шулай дип чыгып китте һәм шул китүдән юк булды.

Фатыйма гел Заһитны көтте. Заһит турында төрле хәбәрләр йөрде. Имеш, ул фатирлар басып йөргәндә тотылган һәм хәзер төрмәдә утыра. Икенче берәүләр аны урамда хатын-кызларның кыйммәтле алка, йөзек, муенса ише бәяле әйберләрен талаганда күргән. Фатыйма боларның берсенә дә ышанмады. Заһит хатын-кызга илаһилаштырып караучы зат. Әгәр аның турында берәр хатын-кызны артык иркәләп интектергән дисәләр ышаныр иде. Теге көнне Фатыйманың аяк бармакларыннан алып, борын очына кадәр үбеп чыкты бит.

* * *

Гыймай хатыны үзенә хыянәт итәдер, дип башына да китермәде. Авырлы килеш алгач Фатыйма рәхмәт укыйдыр, дип йөрде. Үзе һичбервакыт бу турыда сүз кузгатмады. Хәтта карашы белән дә хатынын рәнжетмәде. Бүген кайтып кергәндә хатынының эчтән генә жырлап йөрүен ишетеп:

—Минем хатынкайның күнеле күтәренке. Әллә берәр шатлыклы хәбәр бармы?

—Бар,—диде Фатыйма.

—Бәлки мина да әйтерсең, икәүләп шатланырбыз.

—Әйтәм, нигә әйтмәскә!—Фатыйма корсагын уып алды.—Улым тыпырчына башлады.

—Улыбыз диген.

—Улыбыз алайса.

—Кая әле, кая, мин дә тыңлап карыйм.—Гыймай хатынының эченә башын куйды. Тик бернинди тыпырчыну тоймады.—Халатың кыштырдый, кая, чишик әле төймәләрен.

—Көпә-көндез! Мин оялам.

—Нигә оялырга? Без бит ир белән хатын.

—Юк, юк, салмыйм. Төнлә тыңларсың.—Фатыйма Заһит котырып үпкән

урыннарда эз калгандыр дип курыкканлыктан халатына чат ябышты. Әмма Гыймай үҗәт булып чыкты. Ул ярым көчләп, ярым үгетләп Фатыйманың халат төймәләрен ычкындырды, тезләнеп Фатыйманың корсагына колагын куйды. Озак кына тыңлаганнан соң: «Ишетелә!»—диде һәм хатынын күтәреп алды. Шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, барлык төймәләр ычкынып китте. Гыймай хатынының тәненә текәлеп карарга ояла иде, ләкин бүген аның карашы хатынының бөтен тәне буйлап йөгереп үтте.

—Бу ни?—диде Фатыйманың чуарланып беткән тәненә карап.

—Үзем дә белмим,—диде хатыны,—аллергия ахрысы.

—Нәрсә ашаган идең соң?

—Хәтерләмим дә инде. Бакчада кишерләр бик матур үсеп килә икән. Шуларны ашаган идем. Көндез лимонлы чәй эчтем. Көне буе нәрсә ашаганыңны хәтерләп бетереп буламыни?

—Бөтен тәнеңне баскан бит бу,—диде беркатлы Гыймай.

—Бетәр әле, кайгырма!—Фатыйма халат төймәләрен каптырмакчы иде, ләкин бик борчылган ир хатынының бөтен җирен тикшереп чыкмыйча туктамады.

—Ими башларына кадәр кызарган бит, бәлки экземадыр бу.

Фатыйманың ачуы килде. Ул Гыймайны читкәрәк этте.

—Житте, тикшеренмә, йөкле хатында нинди үзгәрешләр булмас.

—Мин шуның өчен әйтәм бит: врачка барырга кирәк.

—Ярар, барырмын.

—Иртәгә үк бар.

Сүз бу хакта яңадан кузгатылмады. Гыймай үзенең мастерскоена чыгып китте. Бетерәсе эшләре бар иде. Ләкин ничек кенә тырышмасын, бүген аның эше бармады. Кулыннан әле бер, әле икенче коралы төшеп китте. Күз алдыннан һаман Фатыйманың чуарланган тәне китмәде. Өйләнгәнче аның хатын-кыз тәне күргәне булмады. Хәер, бер мәртәбә үзләре белән бергә эшли торган дусты аны үзенең туган көненә чакырган иде. Аракы өстәл тулы. Хатын-кызлар да рюмкаларын каплап кына куялар. Шунда берсе: «Уф мин кыздым. Чишенәм әле»,—дип түшендәге төймәләрен ычкындыра башлады. Ана икенче бүлмәгә кереп чишенергә куштылар. Ул кереп китте, ләкин бераздан аның кычкырганы ишетелде: «Берәрегез керегез әле, юбкамның молниясе ватылган. Ни өстән салып булмый, ни астан».

Мәҗлестә бөтенесе парлашып беткәннәр иде, Гыймайны кертеп җибәрделәр. Гыймай кергәндә хатын ярым чишенгән, бары тик шул каһәр төшкән юбкасын гына сала алмый иде. Гыймай кызның ачык күкрәгенә күз салмаска тырышты. Итәкнең замогы чынлап та ватылган. Ни өскә, ни аска төшми. Мондый эшләрдә Гыймайның маһирлыгы юк иде. Ул тегеләй матошты, болай азапланды—булдыра алмады. Исерүе житкән кыз Гыймайны этеп, итәк молниясен аерып җибәрде. Һәм үзе әллә башы әйләнеп, әллә исереп идәнгә егылды. Гыймай аны караватка күтәреп салмакчы булган иде, кыз аның муеныннан эләктереп алды. Хатын-кыз тәне кагылгач, Гыймайда егетлек хисләре калкып куйды, тик ул үзенең нәфесен тыя алды.

—Пешмәгән нәрсә!—дип калды аның артыннан кыз. Шуннан башка Гыймайга хатын-кыз тәне күрергә туры килмәде. Тик бер генә күрүгә карамастан, күп мәртәбә егетнең күз алдына килеп йөдәтте ул.

Ул мәҗлестә тәне экземалы бер егет бар иде. Өй бөркүләнгәч, ул да күлмәген салып атты. Аның экземасы ничектер болай кызармаган, ә Фатыйманыкы бит... Тфү, тфү, әстәгъфирулла, әллә нинди гөнаһлы уйлар килә башка. Әйе, Фатыйманың тәне суырып үпкәнгә охшый. Алай дисәң, нигә ул кызыл эзләр ботларда бар? Ботны үпмиләр бит инде. Юк, юк. Фатыйма әйбәт хатын. Тегендә-монда чыгып йөрми, гел өйдә. Житмәсә

болдырда эт ята. Сарбай бик усал. Фатыйма турында начар уйлап гөнаһлы булырсың, валлаһи!

Вакыт үзенекен итте. Гөнаһ эзләре, сабынлап юган пычрактай, юкка чыкты. Озакламый ул малай тапты. Ана Заһит дип исем куштылар. Малайны Гыймай да, аның әти-әниләре дә бик яратты. Заһит бик тере малай булып үсте. Урамга чыгып йөри башлауга берәрсе белән сугышып кайтты.

—Кемгә охшаган бу малай?—дип аптырашты әби-бабасы.

—Үземә охшаган,—диде Гыймай сүзне озакка сузмас өчен.

Улының сүзен әтисе эләктереп алды.

—Әле беркөнне телевизордан күрсәттеләр,—диде ул,—сап-сары урыс белән маржадан кап-кара негр малае туган.

—Ахырзаман галәмәте,—дип кушылды картына Әдибә карчык.

Заһит турында сүзләр шактый куерырга мөмкин иде, ләкин Гыймай бу әңгәмәгә нокта куйды.

—Малайга күз тидерәсез, житте!—диде ул кискен итеп.—Янадан бу турыда сүз кузгатмагыз.

Малайның үзенеке булмавы вакыт-вакыт Гыймайның йөрәген чеметеп ала иде. Ләкин жанындагы рәнжүне һичбервакыт тышка чыгармады. Фатыймасын артык ярата иде шул.

Хәтергә Фатыймага кызыгып, сокланып йөргән чаклар төшә. Фатыйма кибеттә эшли. Гыймай эштән кайтышлый һәркөнне шул кибеткә кереп, ипидер, сөттер ише ризыклар ала. Дөрес, бу кибет аның кайта торган юл өстендә түгел, ләкин анда Фатыйма эшли. Гыймай читтән генә Фатыйманың житез хәрәкәтләрен карап торырга ярата. Әйберне ул һәрвакыт Фатыймадан ала. Кайвакыт Гыймайга ипи яки сөт сузганда сатучы кызның ап-ак куллары аңа тиеп китә. Ул көнне Гыймай бәхетле. Күңеленә генә сыймаган бәхет, сөенеч һәм жыр булып тышка бәреп чыга.

Ал да булырбыз әле,
Гөл дә булырбыз әле;
Алла бәхеткәйләр булса
Бергә булырбыз әле.

Гыймайны барлык сатучылар танып бетерде. Товарны гел Фатыймадан алганга, кибеттә Гыймайның пәке белән кырылган олы башы күренүгә: «Фатыйма, синең кавалерың килгән, йөгереп чыгып хезмәт күрсәт үзенә»,—дип кызны үртиләр. Фатыйма иптәшләренә:

—Нинди кавалер? Мунча пәрие бит ул. Андый кавалерың булудан Аллам сакласын,—ди. Ләкин кибеткә кергән кешене елмаеп каршы алмый хәлең юк.

Тора-бара кушаматы «мунча пәрие» икәнен Гыймай үзе дә белеп алды. Ләкин мондый кушамат тагуларына һич үпкәләмәде. «Ә нигә?—дип уйлады ул.—Мунча пәрие булу начармыни? Мунча—чистарыну урыны. Кешеләр юынганнан соң мунча пәриләре үзләре хужа булып кала. Юыналардыр, чистарыналардыр. Ә инде кыяфәткә килгәндә, берни эшләп булмый. Ходай шулай яраткан. Матурлык төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый бит. Гыймай гарип-гораба түгел. Тазалыгы Аллага шөкер. Бервакыт авылдан кайтканда дустының машинасы баткан иде. Буксовать иттерә-иттерә тәгәрмәч асларыннан төтеннәр чыга башлады. Шунда Гыймай сүзсез-нисез генә төште дә, машинаның арт ягыннан күтәрде. Баткан жиреннән машина выжлап чыгып китте.

*Ахыры киләсе санда*



Разил
Вәлиев

## «БЕР АЛМАНЫ БИШКӘ БҮЛӘЕК»

ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН ҖЫРЛАР

### Бәхетем башкаласы

*Илгиз Закиров музыкасы*

Кайчакларда килә минем
Иңнәреңә баш саласым.
И Казаным, син бит минем
Сагышым башкаласы.

Кушымта:
Яктырак яна Казан утлары,
Чакыра безне үзенә һаман.
Кайтабыз сиңа, кайтабыз, Казан,
Учак янына җыелган сыман.

Сөенечем, шатлыгымны
Сәгатьләрең гел санасын.
И Казаным, син бит минем
Хыялым башкаласы.

Кушымта.

Йөрәкләргә утлар салып,
Без китәбез, син каласың.
И Казаным, син бит минем
Бәхетем башкаласы.

Кушымта:
Яктырак яна Казан утлары,
Чакыра безне үзенә һаман.
Кайтабыз сиңа, кайтабыз, Казан,
Учак янына җыелган сыман.

---

Разил ВӘЛИЕВ (1947) — *шагыйрь, прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар, шул исәптән 4 томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Муса Җәлил исемендәге республика яшьләр премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Ватаным

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

Кушымта:
—Сез кайсы халыктан?—дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Кушымта.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибә Ватаным.

Кушымта:
—Сез кайсы халыктан?—дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

## Таң җыры

*Татар халык көе*

Уңда юллар, сулда юллар...
Юлларга кемнәр чыгар.
Таңда егет җырлап узса,
Кыз күңеле ничек чыдар.

Егет китәр еракларга,
Эзләрен яңгыр юар.
Кыз, көн саен чиләк асып,
Авыл башына чыгар.

—Көтмә,—дип үртәр кызлары—
Аның күңеле чуар.
Яңгыр түгел, күз яшьләре
Кызның иренен юар.

Уңда юллар, сулда юллар...
Кайтмыйча ничек чыдар?
Таңда егет җырлап кайтыр,
Кыз йөгереп каршы чыгар.

## Бер алманы бишкә бүләек

*Татар халык көе*

Бакчалардан былбыл качса,
Күзләр тисә алмагачка,
Кайгы төшсә безнең башка,—
Бер кайгыны бишкә, әй, бүләек.

Кыш аклыгы гөлгә күчсә,
Алмагачлар кояш эчсә,
Күңелләргә шатлык күчсә,—
Бер шатлыкны бишкә, әй, бүләек.

Шатлык килде, кайгы төште...
Бәхетләр соң кем өлеше..!
Бәхет булып алма пеште,—
Бер алманы бишкә, әй, бүләек.

## Дулкын

*Татар халык көе*

Чем-кара карлыгачлары,
Гөнаһсыз иде яры.
Ник шунда гына калмады,
Ник дулкын китте ары?

Тарсынып язмыш ярларын,
Ул диңгезгә юл алды.
Тау дулкыннар арасына
Кереп күздән югалды.

Күз яшьле акчарлаклары...
Күренми инде яры...
Зәңгәр күк һәм зәңгәр диңгез,
Йолдызлар монда бары.

Бар иде гөлләр, таллары...
Ник китте икән ары?
Елга ярын сагынып елый
Диңгезнең дулкыннары.

## Ядкарь

*Фасил Әхмәт музыкасы*

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсез бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш—
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Уртак иде хисләр, айлы кичләр,—
Без кертмәдек анда ятларны.
Күңелләрдә йөргән дуслык хисе—
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Бергә откан өмет тулы җырны
Йөрәк инде мен кат ятлады.
Үткәннәрдән бары шул җыр калды,
Ул җыр безгә яшьлек ядкаре.

## Сагынам

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Су буенда үскән өянкеләр
Синең кебек ак шәл ябынган.
Синең чәчең төсле ак җил тузгый,—
Мин кышларда сине сагынам.

Карашыңдай җылы, аяз көннәр,
Җилләр исә синең ягыңнан.
Гөрләвекләр булып кайтыр идем...
Мин язларда сине сагынам.

Бөтен дөнья бүген шау чәчәктә,
Арынган җир хәсрәт-кайгыдан.
Шатлык төяп кайтып килер идем...
Мин җәйләрдә сине сагынам.

Синең сагыш әллә күчкән инде?—
Урманнарга сары кабынган.
Күзләремдә яшьме, яңгырмы ул?—
Мин көзләрдә сине сагынам.

Офыкларга карап, һәр көн саен
Сине уйлыйм, сиңа табынам.
Бөтенләйгә тиздән кайтырмын күк,—
Сине, әнкәй, сине сагынам.

## Төсле җыр

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Нигә күк һәрвакыт зәп-зәңгәр, гел зәңгәр?
Сагышлы зәңгәрлек сибелә күзләрдән.

Сөйсәң син әгәр дә,—
Сагыш бар зәңгәрдә.
Зәңгәр күк, зәңгәр күз, зәңгәр моң...
Мәхәббәт сагыштан тора ул.

Нигә таң көн саен алсу гел, гел алсу?
Таңнарда нигә соң һәрвакыт ямансу?

Сөйсәң син әгәр дә,—
Таң—алтын мәгарә.
Алсу күк, алсу йөз, алсу моң...
Мәхәббәт шатлыктан тора ул.

Зәңгәр күк, алсу таң, якты көн, кара төн...
Син мине, ахрысы, мәңгегә караттың.

Төсләрне тараттың...
Мин сине яраттым.
Сөюем—бәхеткә илткән юл...
Сагышлы шатлыктан тора ул.

## Урман чишмәсе

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Урман юлында чыктың каршыма,
Такыя үреп кидең башыңа.
Кара урманда көндез адаштым,
Калды урманда моңлы карашым.

Кушымта:
Челтер-челтер ага урман чишмәсе.
Челтер-челтер суга ятлар төшмәсен.
Челтер-челтер килә синең сүзләрең лә...
Челтер-челтер көлә гүзәлем, гүзәлем, гүзәлем лә.

Зифа каендай синең буйларың.
Карадым сиңа, карап туймадым.
Чишмә суыдай акты чәчләрең,
Чишмә суыдай җанга чәчрәдең.

Кушымта.

Урман яктырды, безне күргәч.
Чакырдың мине урман түренә.
Урман чишмәсе, сиңа мең рәхмәт!
Чишмәдәй чиста безнең мәхәббәт.

Кушымта:
Челтер-челтер ага урман чишмәсе.
Челтер-челтер суга ятлар төшмәсен.
Челтер-челтер килә синең сүзләрең лә...
Челтер-челтер көлә гүзәлем, гүзәлем, гүзәлем лә.

## Ак пароход

*Сәгыйт Абдуллин музыкасы*

Идел буйлап ак пароход килә.
Иркәм, миңа ак бәхетләр телә.
Ак пароход ялгызларны табыштыра,
Ак пароход йөрәкләрне кавыштыра.

Шатлык төяп ак пароход килә.
Бөтен дөнья бүген уйный-көлә.
Ак пароход сагышларны тараттыра,
Ак пароход мәңгелеккә яраттыра.

Талгын гына ак пароход килә.
Акчарлаклар җырлый безнең көйгә.
Ак пароход дәшә ерак ил гизәргә.
Ак пароход алып бара диңгезләргә.

Дулкын ярып ак пароход килә.
Серләреңне дулкыннарга сөйлә.
Ак пароход ак хыяллар бүләк итә,
Ак пароход ак бәхеткә алып китә.

## Сөембикә

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Казаныма төннәр иңсә,
Сине эзләп карыйм күккә.
Зәңгәр күктә Ай моңлана,
Моңлана күк Сөембикә.

Кушымта:
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.

Сине уйлап үтә язлар,
Сине уйлап күзләр җитә.
Яңгыр булып күз еламый,
Син елыйсың, Сөембикә.

Кушымта:
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.

Сагышларны сүтә-сүтә
Айлар үтә, еллар үтә.
Безнең язмыш синең белән
Мәңге бергә, Сөембикә.

Кушымта:
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә!

Рауль
Мирхәйдәров

# ҮЗЕМ ХӨКЕМ ИТӘМ

РОМАН

## XXV

Сенатор банктан үртәлеп һәм ачулы чыкты. Ул шикләнгән иң начар хәлләр тормышка ашкан икән: Шубарин аның Лас-Вегаста чакта прокурор Азларханов документларының күчермәләрен алганлыгын сизенгән. Ул бары тик бер нәрсәгә куана—Шубаринны билгесезлектә калдырып, очрашуның азагын тизрәк тәмамларга тырышты, шул рәвешле үзенә бик кирәкле ун көн вакытны отты, ә Японец, мөгаен, бүген үк үзен борчыган сорауларга җавап алырга теләгәндер. Шушы вакыт эчендә үз хәлен ачыклар, аннары Миршаб белән бергә килеп, гафу үтенер, гаепләрен таныр, яки инде үпкәләгән кыяфәттә Японецтан читләшер дә, аның дошманнары белән килешергә тырышыр. Иң әүвәл банкирның юлына аркылы төшәргә кыюсынган Талиб Солтанов дигән бәндә белән якынлык табарга кирәк булыр. Әгәр дә Тулкун Назарович тәфсилләп Шубаринга Сухробның ничек итеп Ак йортка үрләгәнен сөйләп бирмәгән булса, һаман да шикләнүләре белән банкир аны түбәнсеткән-үпкәләткән кеше булып кыланырга мөмкин булыр иде, ә хәзер берни дә эшләп булмый, азуы житкән сәясәтчене өркетердәй мәгълүматларның урланган кейстан алынуы ачык.

Ун көн... ун көн... Ни өчендер башында гел шул сан кабатланып торды. Ниһаять, аңа барып житте: ун көннән аны һәр яктан камап алачаклар! Сенатор аларны берәм-берәм күз алдына китерде. Күбесе әле бүген дә югары урыннарда утыра, вакытлы рәвештә хакимияттә булмаганнары да бик зур йогынтылы, дәрәжәле кешеләр. Алар арасында жинаятьчеләр дә бар, болары үзләренен кылган гамәлләре турында язма раслауларны бигрәк тә яратмыйлар, алар әле телдән сөйләгән шаһитлардан да котылу жаен карыйлар, ә инде алар өстеннән махсус мәгълүматлар жыючыга ... гафу юк та юк, котылу да юк. Тулкун Назарович үзе дә Шубариннан, туганы Үткурдан тыш, үзе өстеннән дә Сенатор кулында дөнья мәгълүматлар барлыгын белгәч, шатланмастыр шул. Бу хәлләр теләсә кемне төшенкелеккә салыр иде, ләкин Сенаторны түгел, ул, әлбәттә, үзен нинди тупыйкка куып кертүкәннәрен аңлый. Әле бит Шубарин белән Тулкун Назаровичтан башка да үзен ауларга йөрүче прокурор Камалов бар, аның эләктергәнен ычкындырмас кеше икәнен Сенатор яхшы белә, шуна күрә әлегә ирекТә калуына бик куанмый да. Бу ун көн эчендә аның бердәнбер дошманы Камалов кына булачак, Шубарин тәртипле кеше, ун көн үтмичә, бер хәл дә кылмаячак, бу көннәрне бик акыллы, нәтижәле итеп файдаланырга кирәк. Японецның Сухроб Әхмәтович белгән күп кенә

*Ахыры. Башы журналның 2006 елгы 10–12 саннарында.*

көчле яклары бүген йомшаклык булып чыга, элекке кулдашының шул йомшак якларын файдаланып та булыр әле.

Шулай фикер йөртә-йөртә, Сенатор машинасы белән иске шәһәрдәге чәйханәгә килеп чыкты, ул әле анда күптән түгел генә Сабир-бобо кешесе алтын тешле Исмат белән чәйләп утырган иде. Төш вакыты житкән чак, ул өенә дә, Миршабка барырга да ашыкмады, машинасын бүдәнәле читлекләр эленгән йөзъяшәр чинар агачы күләгәсенә китереп туктатты. Аның ялгызы гына калып, үз нәтиҗәләре һәм карарларының кире һәм унай якларын уйлап-исәпләп утырасы килә иде.

Ялгызы ашап утырса да, ваклап туралган сарык кабыргаларыннан пешерелгән шашлык һәм бик тә йомшак бавырдан ул канәгать калды, ризык тәмлелектән генә түгел, ул инде үзенең бөтен ихтыярын бер йодрыкка туплаган, алга таба кемнәр белән атлаячагын билгеләгән иде. Гүя күнелендә нindидер сәгать йөри, аның вакыты—ун көн. Шул арада ул Шубаринны йә сафтан чыгару, йә юк итү юлларын табарга тиеш! Бу очракта да, нәкъ Камалов белән булган шикелле, үз язмышы шуна корылган, килешү мөмкин дә түгел, чөнки ул үзенең мәгънәсез рәвештә өметсез яшәве белән һич килешмәячәк. Ул иң беренче эш итеп, кичке самолет Мәскәүгә очканчы, Миршаб белән көрешергә тиеш, ана үзләренең элекке яклаучысы һәм кулдашы булган Шубариннан үлем куркынычы янаганын төшендерергә кирәк.

Сенатор Шубаринның нинди куркыныч кеше икәненә никадәр күп кешене ышандырса, аның белән көрәшү дә шул кадәр җинел булачагын аңлый иде. Ә Миршаб әле рәсми урында да эшләп утыра—аны гадәттә шәхси дошманнары белән көрәшү өчен файдаланалар. Миршаб белән икесенә төрмәдән чыккан хан Акмал белән Шубаринның араларын тиз генә бозарга кирәк. Ул эченнән генә Сабир-бобога рәхмәтен укыды. Карт әнә ничек итеп ханны коткару артыннан йөри, моны төрмә сәкеләренең катылыгын татыганнар гына белә ала, ә инде кемнең дә булса битарафлыгын сизсәләр, шундый кешеләрне күрәлми башлыйлар.

Чәйханәдән, вакыт никадәр ашыктырса да, чыгып китәсе килмәде аның, үзенең мәктәптән бирле аерылмас дусты, тугрылыклы кулдашы Миршаб янына ни өчен барасы килмәгәнен дә аңлады. Әлбәттә, «сиам игезәкләре» дип атап йөртүләре дә күңелгә ятышлы, аларның дуслыгын, Миршабның ана бирелгәнлеген дә шик астына алучылар юк. Ләкин, банкта Шубарин белән сөйләшеп чыкканнан соң, аның күңелендә нindидер бер Америка фильмындагы сүзләр янарды: «Бәладән ялгыз чыгалар», яки «Һәркем үзен-үзе коткара», яки О. Генриның шуларга охшаш җөмләсе: «Боливар икебезне дә күтәрә алмас». Айвандагы мәхәллә чәйханәсендә башына килгән уйларның бары тик берсе—үз-үзен коткару нияте генә калды, үзенең имин тормышын, иркенлек һәм дәрәҗәсен саклап калу гына әйбәт буласы иде, Сухроб моны үз-үзенә яшермичә әйтте. Хәер, ул прокурор Камаловның аны Миршаб белән бергә каптырырга җыенганын белә иде. Прокурор Артем Парсегянны үтерүне күреп торган төп шаһитларны да белә иде, шуна күрә ул анардан ун көннән соң Миршаб белән бергә тиешле документларны алып килүен таләп тә итте. Алар, тәүбәгә килеп, аңа тезләнергә тиешләр иде. Сенатор белән очрашырга җыенганда, ул тегенең үз тормышын саклап калу һәм сәяси карьера өчен һәрнәрсәгә барырга әзер, әгәр кирәк булса, дусты Миршабны да корбан итүгә барачак икәнен белә, төрмәгә янадан утырасы килмәс Сенаторның—боларны да Шубарин чамалый иде.

Миршабны күңеленнән инде саткач, Сенаторның хыяллары уйнаклап китте, әйтерсең лә, икенче сулышы ачылды, аны-зиһене яктырды. Ул инде болай да әхлакый тыюларны белми иде. Ул Канзафарның Шубарин турындагы мәгълүматларын үзе Аксайга—Сабир-бобо янына унышлы сәфәреннән кайткач

алды. Ул хәзер, әгәр дә Шубарин белән прокурор Камалов арасында ниндидер элементләр барлыгы беленсә, америкаң Гвидо Лежаваны Японецтан урлап кайткан кешене аңа каршы котыртачак та котыртачак. Бүген исә, Шубарин белән күзгә-күз күнелсез сөйләшүдән соң, вакыт һәм вакыйгалар аларны баррикаданың ике ягына бастырды, Шубаринның Камалов белән элемтәсен тикшереп торасы калмады: димәк, Сенатор Талиб Солтановны, яки аның өстеннән торучыларны Шубаринга өстерергә тиеш.

«Ә, бәлки, Талибны прокурор Камаловка каршы да котыртырга кирәктер?— дигән тәвәккәл фикер дә калкып чыкты.—Шул бит Шубаринга Гвидо Лежаваны кем урлаганын әйткән, әйтеп кенә калмаган, аны кайда яшереп тотканнарын да хәбәр иткән. Талиб кулы белән бу дошманнарның барысын да юк итсән, иллә мәгәр дә шәп булыр иде!»—дип үз уйларын үстерә төште Сенатор. Аннары, Талиб белән бер сүздә була алмаса да, аңа да эш табылачагын уйлап, фикерен йомгаклады.

## XXVI

Прокурор белән сөйләшкәннән соң, Шубарин генерал Саматов белән очрашырга туры киләчәген аңлады. Алар башлаган эш дәүләт дәрәҗәсендә генә түгел, ә халыкара дәрәҗәдә мөһим иде. Әгәр дә җинаятьчел дөнья акчаларын кулга төшерүдә хокук саклау оешмаларының күпмедер тәҗрибәләре булса да, хәер, анысы да әле фаразларда гына, әмма анда һәрвакыт Интерполдан киңәш-уңаш алырга була иде. «Мәскәүле» дә үз вакытында шунда эшләп торган. Ә бу очракта, партия акчаларын кайтару эше беренче башкарыла, сукыр килеш кенә, аерым мәсьәләләрне эш барышында чишә-чишә генә. Әлбәттә, прокурор Камалов хаклы: элеккеге КГБ хезмәткәрләре арасыннан тәҗрибәле белгечләрне тартып, бер көчле үзәк оештырырга кирәк. Яклаучысыз гына берьюлы ике төрле көрәш алып бару—чип-чиста авантюра, башсызлык. Менә шуның өчен дә ул Камалов белән очрашырга теләвен төпле итеп белдерде. Чит илләрдә тупланган җинаятьчел акчаларны кайтарып, «юып» чыгаручылар белән көрәшүче белгечләргә таяну, әлбәттә, акыллы фикер. Моны «мәскәүле» тәкъдим итте, мондый таяныч булыр дип башына да китермәгән иде ул. Бу ыгы-зыгы беткәнче, гаиләсен Европаның кайсыдыр илендә яшереп тотуны да Саматов ярдәменнән башка оештыру җиңел булмастыр. Шуңа күрә мөрәҗәгать хаты бик тәфсилле, планнар-чыгармалар белән язылган иде. Вакытны югалтмыйча, белгечләрне шунда ук бу эшкә тарту кирәк булачак. Миланга очып китү көне дә борын төбендә генә иде бит инде.

Ике хат салынган конверт республика прокуратурасының ишек төбендәге почта тартмасыннан эш башланыр алдыннан ук алынды. Камалов алдан кисәтеп куйганлыктан, Татьяна Шилова ул конвертны иртәнге киңәшмә үтүгә үк аңа кертеп бирде. Конвертны алгач, прокурор кызыксынып сорады:

—Канзафар белән мөнәсәбәтләрегез ни хәлдә?

Җавапны ишетеп, ул кисәтте дә:

—Мөгаен, якын көннәрдә аңа кайбер мөһим хәбәрләр бирергә туры килер, әзер булып торыгыз...—Бераз тынып торгач, Камалов өстәп әйтте.—Бу мәгълүмат миңа рухи якын булган бер кешенең гомере белән бәйле. Аның белән үзегезгә дә танышырга җай чыгар әле дип уйлыйм...

Татьяна киткәч, Камалов конвертны ачты да үзенә адресланган хатны алып укыды: кичә очрашканда сөйләгәнгә караганда, бик тәфсилле, акыллы итеп язылган иде ул хат. Камалов алда торган эшнең бик катлаулы һәм куркыныч булачагын, уңышсызлык очрагында Шубарин үз гомере белән генә түләячәген аңлап алды. Прокурор телефон трубкасын күтәрде дә, генерал

Саматовка шылтыратасы урынга, полковник Жураев номерын җыйды. Юкса, әле бер минут кына элек мондый нияте һич юк иде. Республиканың угрозыск начальнигы урынында иде, дусты белән җылы гына исәнләште. Соңгы көннәрдә алар күрешмәгән иделәр. Жураев, әлбәттә, прокурорның көтмәгәндә генә банкир белән очрашуын да белми иде әле.

—Ә сез хаклы булып чыктыгыз,—дип, прокурор туп-туры эш турында сөйләшүгә күчте.—«Шәрекъ» банкының ачылуын тәкъдир итү унаеннан җыелган халык арасында ул симез калҗага кызыгучылар күп булыр, дигән идегез. Шулай булды да.

—Әллә Японецның тагын берәр кешесен урлаганнармы?—дип, кискен генә сорады полковник.

—Юк, әлегә һәммәсе дә үз урынында. Урлау-нитү булмасын өчен, мин сезнең якындагы ике-өч көндә каттә генә акыллы дүрт егетегезне әзерләп куюыгызны үтенер идем. Икесе кычкыртып талау, рэкет җинаятьчеләрен яхшы белүчеләр булсын, ә калган икесе һәртөрле алдакчы мошенникларны, аферистларны, кәрт сугучыларны һәм башка шундыйларны белсеннәр. Мин яшерен рәсми хат җибәрермен, без ул егетләрне ярты ел «Шәрекъ»тә эшләп торырга күндерербез, ә Шубарин белән сөйләшеп куярмын, ул аларны үзенә эшкә алган саналыр. Егетләр алмаш-тилмәш икешәр кеше кизү торырлар. Аларның әүвәлге бурычлары билгеле, ә инде андый-мондый хәл туа калса—максатларны бергәләп ачыкларбыз. Бүгенгә әле мин анык кына бер нәрсә дә әйтә алмыйм, генерал Саматов белән алдагы бер-ике көндә күрешкәч, күп нәрсәләр ачыкланыр...

—Гади генә банк Бәхтияр Саматов оешмасын да кызыксындырамы?—дип гаҗәпләнде полковник.

—Гади банкмы? Алай әйтмәс идем. Аның хуҗасы кем икәнен онытасыз. Мина аның финанс даһие булганлыгын, гаҗәп талантлы икәнлеген сез үзегез сөйләгән идегез түгелме соң? Бер сүз белән әйткәндә, галәмәт зур хәлләр...

—Японецка авыр минутларында ярдәм итеп, дөрес эшләдек, дисезме?—дип сорады полковник.

—Әйе, әлбәттә. Шуңа күрә яңа үтенечебез бит: иң яхшыларның да яхшылары кирәк егетләрнең. Банк эше—нечкә эш...

Бу трубкасын куюга, ул икенчесен—хөкүмәт телефонынныкын күтәрде дә, турыдан-туры генерал Саматов белән сөйләшә башлады.

—Хәерле иртә, Бахтияр Саматович! Әгәр сез урыныгызда булсагыз, бер ярты сәгатьтән бик мөһим документлар белән кеше җибәрер идем. Документлар бәяләп бетергесез һәм үтә яшерен, шуңа күрә аны сезнең ышанычлы кешегез аша кулдан-кулга тапшыруны кирәк табам. Сезнең кырыслыгыгызны беләм, әмма үзегез кабул итеп алсагыз иде.

—Мин аңа расписка бирергә тиеш түгелдер бит?—дип шаяртты генерал. Кәефе яхшы иде, күрәсең. Аннары җитди генә сүзен дәвам итте:—Әйе, мин әле тагын берәр сәгать урынымда булам, килсен егетегез. Үтенечегез буенча биргән егетләремнән ризамы сез?

—Ризамын. Рәхмәт сезгә. Алар үз эшләрен яхшы беләләр, гаделләр. Мин аларга тулысынча ышанам. Ә безнең эштә бер-береңә ышану—ярты уңыш ул. Мин җибәргән хәбәргә битараф калмассыздыр. Әгәр ачыклыйсы мәсьәләләр булса, хәзер үк очрашырга әзермен. Эш бик ашыгыч бит...

—Ә без шундый эшләр белән генә шөгыльләнәбез,—дип янә шаяртып алды генерал.—Димәк, болай. Кичке дүртләргә килегез, сезнең вак-төяк белән борчымаганыгызны беләм, ә безнең эштә сораулар һәрвакыт туып тора, шул сораулар белән генә яшибез дә.—Куркынычсызлык хезмәте шефы үзенең остазы белән җылы гына саубуллашты, ул аны һәрвакыт хөрмәт итә иде.

Прокурор үз исеменә килгән хатны яңадан кулына алды, генерал Саматов янына Шубарин билгеләгән план буенча әзер тәкъдимнәр белән барасы килә иде аның. Ул кинәт кенә кичә хан Акмал адвокатлары артыннан Сенаторның да Мәскәүгә очуын исенә төшерде. Димәк, шәхсән үзе кулга алган Аксай ханы тиздән ирекә чыгачак дигән сүз. Димәк, Сенатор Арипов белән якынаерга тырыша, аның акчасын һәм элемтәләрен файдаланырга өметләнә. Асылда, хан Акмал тикшерүчеләргә беркемне дә сатмады, ирекә чыккач, ул байтак кешеләрнең исәп-хисап тотуларын таләп итәргә, үзенең дәгъваларын да белдерергә мөмкин. Хан Акмал белән Сенатор үзләренең прокурор күзе алдында җинаятьче саналганнарын белә. Димәк, прокурор үз вазыйфасын үтәгәндә, аларга республикада югары урыннарга үрләү авыр булачак, төгәлрәге—бөтенләй мөмкин булмаячак. Ә моның белән ни беренчесе, ни икенчесе килешә алмаячак. Димәк, чираттагы дүртенче һөҗүм итүне көтәргә дә күп калмагандыр. «Бәлки, шул аңлашылмас тойгы аркасында мин Шубаринга ярдәм итәргә ашыгамдыр да»,—дип уйлап куйды прокурор. Дүртенче һөҗүмнән ничек котылып калу мәсьәләсе Камаловның үз эше, ул үз борчуларын башкалар җилкәсенә салырга күнекмәгән. Ахыр чиктә бүген-иртәгә Канзафар өстеннән дәлилләр җыелып бетәчәк, аны кулга алгач, Сенаторның да җыры җырланачак—Карден теккән ефәк костюм киеп озак йөри алмас. Бу юлы прокурор эшне судка илтеп җиткерәчәк. Канзафар Рөстәмов үз яклаучысын тоттырган Парсегяннан да каты чикләвек түгелдер әле. Үз тиресен саклап калу өчен Канзафар «сиам игезәкләре»н сатудан тайчанмаячак. Тегеләрнең, кайчандыр үзен аулап, аны зур оттырышка дучар иткәннәрен, шул рәвешле прокуратура бүлмәләрендә казынырга, төрле серләрне иснәнергә туры килгәнен белеп алса—бигрәк тә. Ә Сенатор белән Миршаб махсус яллап, Миршаб өендә озак айлар буе кәрт сугу осталыгына өйрәнгән, аннары Канзафарны «чишендереп» ташлаган кеше хәзер төрмәдә утыра, кирәк булса, очраштыргач, барысын да түкми-чәчми сөйләп бирергә әзер иде. Ул көтелмәгән шаһитны җинаятьчеләр дөньясын яхшы белгән полковник Жураев табып биргән иде.

Хәзер Камалов өчен Канзафар үзәк фигурага әйләнде, аннардан башка Сенаторга да, Миршабка да юл ябык.

Прокурор аның тормышы өчен дә ирексездән борчыла башлады: ике якка да уйнаганда, теге әллә нинди бәлаләргә дә тарырга мөмкин ич. Шуңа Камалов үзенең бер урынбасарына якын көннәрдә Канзафар Рөстәмовны колония яки төрмәләрдәге гадәттән тыш хәлләрне тикшерергә җибәрмәскә кушты,—көтелмәгән бәла килеп чыкмасын тагын. Урынбасарының: «Ни өчен?»—дигән соравына ул Мәскәүдә элекке союздаш республикалар прокуратуралары хезмәткәрләренең киңәшмәсе булачагын, Канзафарны да шунда җибәрәчәген әйтте. Камалов бу хәбәрнең Канзафарга барып ирешәчәгенә шикләнмәде, димәк, егет, кулга алыныры алдыннан сизгерлеген дә югалта төшәчәк. Камалов моның белән генә тынычланып калмады, полковникка шылтыратты, башта аның генерал Саматов белән очрашуын сорашты, аннары Канзафарны кулга алу турындагы ордерга кул кую өчен тагын ничә көн кирәк булачагын белеште. Полковник: «Бер ун көн»,—дигәч, ул: «Нишләп шулай озак?»—дип сорады. Кузгатылган эшне тулыландыру өчен Рөстәмовның атаклы җинаятьчеләр, кәрт уены ялганчылары һәм Миршаб белән төшкән кайбер фоторәсемнәр җитми икән. Камалов, андый рәсемнәр һәм видеоязмалар булса, Канзафарның озаклап чишелми утыруына юл калмаячагын аңлый иде. Ә егетнең сөйләгән дәлилләре исә «сиам игезәкләрен» кулга алу көнен якынайтачак. Әмма Канзафар тормышы өчен борчылу хисе прокурорның күңеленнән чыкмады: Парсегянны саклап кала алмаганнан соң, шундый ук хәл Почтальон белән дә кабатланырга мөмкин. Әгәр Сенатор Рөстәмовның

прокуратура күзәтүе астында икәнен сизсә—бик мөмкин хәл бу. Шуңа күрә Камалов янадан беренче катка—Шиловага шылтыратты.

Кыз бүген аның янына Шубариннан пакет кертеп чыгарга кергән иде инде.

—Татьяна, сез егет белән кайчан очрашкан идегез?—дип сорады прокурор.

—Бер өч көн элек,—дип җавап бирде Шилова. Ул Камаловның Канзафар фамилиясен махсус атамавын да төшенде.

—Аның кәефе ничегрәк, алга таба планнары бармы? Безнең күп кенә хезмәткәрләребез, шул исәптән ул да, әбәт ашарга кайсы кая таралып бетә. Хәзер Ташкентта тәмле ашап чыгардай урыннар күп бит. Егетебез еш кына Чорсу уйгырлары янына лагман ашарга йөри, бер үзенә ияреп барып кайт әле син дә.

—Ярар, Хөршид Азизович, искә төшерүегез өчен рәхмәт, үзем дә күптәннән лагман белән сыйланырга теләп йөри идем әле,—дип шаяртկандай итте дә, Шилова трубканы куйды.

Шулай да, Канзафар өчен борчылу хисе кимемәде, хәзер үк аны кулга алу турында ордер язып бирә алмавына үкенде прокурор, бары тик шул чагында гына тегенең тормышы өчен борчылмас иде ул.

Камалов республиканың куркынычсызлык хезмәте шефына шылтыратты.

—Сез җибәргән кәгазьләр белән танышып чыктым,—диде генерал.—Алар, чынлап та, кичекмәстән хәл ителүне сорыйлар. Әгәр вакытыгыз булса, хәзер үк килегез, күзгә-күз генә сөйләшеп алырбыз. Сәгать дүрткә мин тәҗрибәле ике белгеч белән бер халыкара хокуклар кешесен дә чакырдым. Мөгаен, алар белән киңәшү кирәк булырдыр сезгә.

—Шунсыз булмастыр шул,—дип ризалашты прокурор. Үзенең тәвәккәл уй-ниятен генералның да яклавы сөендерде аны.—Бер ун минуттан барып җитәрмен.

## XXVII

Мәскәүдә Сенатор башкала адвокатларының юкка гына президентныкына тиң гонорар алып утырмаганнарына ышанды—хан Акмалны ирекка чыгару бик дәрәҗәле кешеләр аша, бик зур акчалар түгеп кенә мөмкин булды. Бигрәк тә соңгы мәртәбә бирелгән доллларлар ярдәм итте. Дөрес сайлап алган ысуллар да үз эшен эшләде, һәммәсе да рәсми рәвештә югары даирәләр тарафыннан хәл ителде. Үзбәкстанның Югары судыннан һәм Югары Советы исеменнән оештырылган чын һәм ялган үтенү-юллау хатлары да бик булышты, алардан башка гына бернинди ришвәт-фәләннәр дә ярдәм итмәс иде. Ә болай исә барысы да законлы рәвештә хәл ителгәндәй булып чыкты. Шулай да төрле рәсмилекләр хан Акмалның төрмәдән чыгу көнен кичектереп торды. Көтмәгәндә Үзбәкстан Югары судыннан кеше килүе кирәк булды. Ул гаепләү буенча җыелган алты йөз томны рәсми рәвештә алырга тиеш икән, шуның өстенә әле аларны шәрехләүче-озатучы дөнья кадәр башка кәгазьләрне Мәскәүнең төрле почмакларындагы төрле оешмалардан да җыярга туры килде. Боларның барысын да төяп алып китәр өчен төяүчеләр бригадасы, зур контейнер белән йөк машинасы ялладылар. Юкса һәркем белеп тора иде: ул тау-тау томнарның беркемгә дә кирәге юк, аларны чыгарып ыргытачаклар гына. Сенатор бу мәрәкәне бер атна түгел, ун көндә дә ерып чыга алмасын аңлады.

Шубарин аңа ун көн вакыт биргән иде, әгәр Сенатор шул арада эшләрен бетермәсә, банкир аңа каршы күп кешеләрне котыртачак. Сенатор җавап тотуны ничек булса да чигереп торырга тырышты—Миршабны кисәтеп куйды: әгәр Артур Александрович шылтыратса, Сенатор белән хан Акмалның

Мәскәүдән кайтуын көтик, алар кайткач, сөйләшербез, дияргә кирәк. Янәсе, гадел дә, үтенечлерәк тә янгырар. «... хан Акмал кайткач...» дигәнендә янау да бар шикелле. Янәсе, хан Акмал да алар яклы, Сенаторны рәнҗеттермәс, чын хуҗа үзе икәнен сиздерер. Кыскасы, ничек хыяллансаң-уйлансаң да була бу очракта.

Мәскәүдә Сенаторның никадәр генә җене котырмасын, ул ни Камаловка, ни Шубаринга, берничек тә яный алмый иде. Ә бит Ташкенттагы Миршаб белән Канзафар да кул кушырып кына утырмыйлар. Ләкин Сенатор үзенең Мәскәүдә тикмәгә генә йөрмәгәнен белә: хан Акмал, иреккә чыккач, аның борчуларын да хәл итә алыр иде, ул, мөгаен, үзен төрмә сәкесенә кем утыртканын онытмагандыр—прокурор Камалов аның да тамагына сөяк булып калалды бит. Әмма, аксакал хаҗи Сабир-бобо өйрәткәнчә, түзәргә һәм көтәргә кирәк иде.

## XXVIII

Икенче көнне төшкә табарак җитди генә бер яшь егет, ишек төбендә җирле газет хәбәрчесе таныклыгын күрсәтеп, Шубаринга пакет китереп китте. Шубарин нәкъ аны көтеп банкта утыра иде.

Сораулар аз булып чыкмады—егерме өч. Шубарин тиешле оешмаларның бу эшкә җитди алынганлыкларын, үзенә ышанычлы яклау да булачагын аңлады. Кайбер сораулардан ул, андый-мондый хәл килеп чыга калса, гаиләсе белән китәрдәй чит илне әзерләп куюларын да төшенде. Сораулар арасында аның кулдашы Әнвәр Абидович турындагысы да бар иде—Ленинград урамында аның мамык Наполеонына тимәүне сораячагын беләләр иде шикелле. Күпчелек сораулар исә аның сугыштан соң Көнбатышка киткән беренче-икенче дулкын дусларына кагылышлы иде, күрәсең, кирәге чыкса, шулар янына барырга, алардан ярдәм көтәргә булыр дип искәртүләредер.

Кайбер сорауларга җавапны хәтер төпкеленнән эзләп табарга кирәк, ә кайберләре архивларда казынып вакыт үткәрүне сорый иде. Кыскасы, бер өч көн үтеп китәрдер, хәер, аңа «фәлән вакытка» дигән анык көн билгеләмәгән иделәр. Ул җавап әзерләгән көннәрдә телефон аша ике җитди сөйләшү булды. Беренчесе Әнвәр Абидович белән иде: ул Италиягә барып төшү көнен ачыкларга тели икән. Аның кәефе күтәренке иде, димәк, эш әйбәт, уйланганча бара. Икенче шылтыратучы шәһәрдән, бик соң гына булды, Шубарин йоклый иде инде. Шылтыратучы «Шәрекъ» банкы ачылыр алдыннан аңа янаган кеше булып чыкты. Бу юлы аның тавышы ягымлы иде, сөйләшү дә ачыктан-ачык барды.

—Төн уртасында бимазалавым өчен гафу итегез,—дип башлады ул сүзен.—Ләкин мин сезнең соңгы сүзегезне ишетергә тиеш. Бер сәгатьтән миңа янадан Һамбургтан шылтыратачаклар, мин Талибка ялгыз гына кайтсынмы, әллә сез эш йөртәчәк немец беләнме икәнен әйтергә тиеш.

Димәк, әле Шубаринга ышаналар иде.

—Талибның тәкъдиме кызыктырырлык. Әле бу суверенитет дигәннәре белән ыгы-зыгы тиз генә бетмәстер, без бер-ике ел хәвеф-хәтәрсез генә эшли алырбыз,—диде Шубарин.—Ләкин без Талиб белән бер мәсьәлә турында да аерым сөйләшмәдек. Сөйләшү алып барырга вәкаләтле кешеләр килсен, уртак тел табарбыз дип уйлыйм.

—Анык кына без кайчан очраша алабыз?

—Әгәр дә Германия кешесе хәзер Ташкентта булса, иртәгә үк очрашыр идек. Ләкин ул бирегә түгел, ә мин биш-алты көннән Италиягә—Миланга очам. Анда бик абруйлы бер банкның юбилеенә гаиләм белән чакырулымын. Хәзер китәр өчен документлар юллап йөрүем. Димәк, шуннан кайткач, бер

ун-унике көннән булыр инде. Шул вакытка үз кешеләрегезне Ташкентка чакыртып алыгыз.

Телефон бераз тынып торды, аннары шатланып:

—Италиягәме?.. Бик шәп!.. Әгәр очрашуны Миланда оештырсак, каршы килмәссезме?—диде сөйләшүче.—Талиб сезне танып беләдер бит?—күрәсең, бу кеше Талибны да үз кулында тота, барлык мәсьәләләрне дә үзе хәл итә иде.

—Юк, Италиядә булмастыр. Гаиләм белән барам дип әйттем бит. Аларны куркыныч астына куярга теләмим, сезнең кешеләрегез артыннан койрык булырга мөмкин. Берәр атнага түзегез, кунагыгыз өчен Ташкент та Миланнан начар күренмәс. Ә биредә без аңа иминлекне тәэмин итәрбез, барысы да үзебезнең кулда.

—Сез хаклы, Ходай «саклаганны саклармын» дигәнме әле?—дип ризалашты сөйләшүче.—Италиядә көннәрегезне матур үткәрүегезне, Европа банкирлары арасына лаеклы керүегезне телим...

Сөйләшеп бетергәч, Шубарин маңгаена бәреп чыккан салкын тирне сөртеп алды—Миланда очрашырга тәкъдим итүләре бер дә ошамаган иде. Радиотелефонын куйгач, ул икенче бүлмәдәге телефон янына чыкты. Анысы кемнең кайдан сөйләшкәнен язып ала торганы иде. Әмма бу юлы экранда бернинди язу да юк, бары тик сызыклар гына күренде. Алар чит шәһәрләр белән сөйләшкәндә генә була иде юкса, ә бу үзебездән шылтыраткан иде.

Соңыннан Шубарин, күзгә-күз очрашып, бу хакта Саматовка сөйләгәч, генерал аңа:

—Без сезнең сөйләшүләрегезне үзегезгә әйтмичә генә язып бардык. Монысы сезнең иминлегегез өчен һәм башлаган эшебезнең уңышлы булуы өчен кирәк иде,—диде.—Ә теге икенче шылтыратучыдан шикләнүегез урынлы. Безнең белгечләр аны белергә тырышып карадылар, ул йорт телефоны да, телефон-автомат та түгел икән. Күрәсең, шәһәрдә телефоннар ыгы-зыгысы вакытында махсус буташтырылган телефон-автомат номерыдыр, хәзер исә ул кемнеңдер өендә тора, ул тирәдә нигездә шәхси йортлар гына. Безнең егетләр ул квадратны теркәп куйдылар, яңадан шылтыратканда кайдан икәнен төгәл беләчәкләр, йортның кемнеке икәнлеге дә билгеле булыр. Иртәмесонмы безгә анда сугылып чыгарга туры килер, кесәдә адресы булу комачауламас. Без аны Камаловка да, Жураевка да бирербез, бәлки, анда аларга электән таныш кешеләр яшидер. Ташкент Мехико да, Токио да түгел ич. Барып чыкса, ул сөйләшүчене сез әйләнеп кайтканчы ук белербез. Хәер, сез кайчан китеп, кайчан кайтасыгызны әйткәч, ул яшерен телефоннан яңадан шылтыратып тормас. Чит шәһәрдән шылтыратулары да кызык. Бер түрәнең дачасыннан—Мәскәүдән Тилләхуҗаев шылтыраткан икән. Ә без төрмәдән сораштыргач, аның шунда икәнен, әле юарга керләр илтергә киткәнен әйттеләр.

Ташкентта күзгә ташланмый гына торган бер кунакханә номерында очрашу иде бу. Генерал Саматов Шубаринны Италиягә үз кешеләре озата барачагын раслады, әмма әлегә аның кем буласын ачыкламаганнар икән.

Бер өч көннән Шубарин, чит илгә чыгу өчен паспорт һәм башка документлар алырга баргач, үзен кем озатып йөриячәген очраклы рәвештә генә белеп тә кайтты.

Визалар бирү бинасында ремонт эшләре озакка сузылганлыктан, документларны бер кысан гына бүлмәдә биреп азаплана иделәр. Аның тәрәзәсе янында һәрвакыттагыча су буе тулы чират—нигездә Израильгә, Грециягә, Германиягә, Америкага бөтенләйгә китәргә теләүчеләр тора иде—шау-шулы, пырдымсыз халык. Боларны чират дип әйтерлек тә булмагач, Шубарин басып торырга уйламады да. «Кемгә шылтыратып, ярдәм сорарга икән?»—дип

уйлана-уйлана, ул ишегалдына чыкты. Тәмәкесен тартып та бетерә алмады, ана әле генә килеп туктаган милиция машинасыннан чыккан полковник эндәште. Шубарин аның белән кул биреп күреште, үзбәкчә сәламләшсәләр дә, ул аның кем икәнлеген исенә төшерә алмады. Ул, әлбәттә, байтак кына милиция кешеләрен белә, полковникның да аны абруй-дәрәҗәле халык белән берәр кабул итүдә йә туй-мазарда күргәне булуы ихтимал. Шәрекъта һәр сөйләшү «берәр ярдәм кирәкмиме?» дигәнрәк сүзләр белән тәмамлана. Шубарин да үзенең гозерен сөйләп бирде. Полковник бинага кереп китеп, берничә минутка гына югалып торды, аннары Артур Александровичны паспортлар-документлар бирә торган кысан бүлмәгә арткы ишектән генә алып керде.

Паспортларны тормыш әчесен күп күргән кырык яшьләрдәге бер ханым тутырып бирә икән. Ул Шубаринга илтифатсыз гына карап алды да, үз өстәле янындагы урындыкка утырырга тәкъдим итте. Бүлмә кысан булгач, янәшә үк дигәндәй утырырга туры килде. Полковник чыгып киткән иде инде. Ханым тарта икән, өстәлдә яткан арзанлы сигарет кабына үрелде, Шубарин аны кул хәрәкәте белән ишарәләп туктатты да, «Мальборо» тәкъдим итеп, кабызгычын чыртлатып кабызды. Ханымның йөзе яктырып китте, түшәмгә таба алка-алка төтен өреп, уйнак кына сорап куйды:

—Димәк, Миланга барасыз. Кайда әле безнең Италия дәфтәре?

Ул алдында өелеп яткан дәфтәр-папкалар арасыннан эзләп, бер юкарагын алып ачты да, шуннан Шубарин белән хатынына тутырылган документларны алды. Аннары ачык дәфтәрне Шубарин каршысына ук ташлап, үзе калын-калын амбар кенәгәләренә нәрсәләрдер язарга тотынды. Шубаринга ачык яткан дәфтәрдәге «Стрельцов Сергей Юрьевич» дигән язулы анкетага күз салу берни тормый иде. Анкетага утыз яшьләрдәге ягымлы гына подполковник фоторәсеме ябыштырылган иде. Иминлек хезмәте подполковнигы да Италиягә—Миланга бара икән, бару вакыты да Шубаринныкына туры килә. Димәк, төс-кыяфәте белән журналистка охшаган шушы егет аны чит шәһәрдә саклап йөриячәк дигән сүз.

Шубарин үзенең Сенаторга ун көн вакыт билгеләгәнен исенә төшерде. Шул вакыт эчендә Сенатор аның прокуратурадагы кейсыннан урланган документларының барлык күчермәләрен дә кайтарып бирергә тиеш. Билгеләнгән вакыт үтеп барганлыктан, Артур Александрович анын өенә шылтыратты. Мәскәүдән кайтмаганмы икән дип кызыксынуы иде. Сенаторның хатыны гына сөйләште, ире әле һаман да кайтмаган икән, көн дә шылтыратып тора, ди. Төгәл генә кайчан кайтасы билгесез, Акмал Ариповны азат итү нигездә хәл ителгән. Артур Александрович анын хатыны белән тәгаен генә бернәрсә дә сөйләшмәде. Сәлам әйтергә кушты, кайтуына үзенә шылтыратуын сорады. Ул Миршабка да шылтыратып тормады, соңгы сүзне һәрвакыт Сенатор әйтә бит, димәк, аның кайтканын көтәргә кала. Бүген Шубаринның төп мәшәкате Миланга барып кайту, ә кайткач, Талиб белән очрашу иде.

## XXIX

Миланга ул иртән килеп төште. Аэропортта аларны бер яшь егет белән Әнвәр Абидович каршы алды, егетне банк хезмәткәре дип таныштырды.

Мамык Наполеоны үзе гаҗәеп матур ак костюмнан, хәзер Италиядә бик данлыклы саналган юка ефәк күлмәктән иде. Ләкин, бик фырт киенүенә карамастан, игътибарлы кеше аның төрмәдә агарып киткән йөзен, күптән инде яхшы азык ашамаганлыктан ябыгып калган гәүдәсен күрми калмас иде. Әмма Әнвәр Абидовичның кәефе күтәренке, елмаеп кына тора, үзен

бик лаеклы тота, беркем дә аның әле берничә көн элек кенә төрмә киеменнән йөргәнлеген күз алдына да китерә алмас иде. Шубаринның хатынын күргәч, ул бигрәк тә нык шатланды, бу ханымны ул бит әле Бохарадан ук белә, биредә—Италиядә очратырмын дип һич тә көтмәгән иде. Сонрак, бергәләп төн уртасына кадәр шәһәрне манзара кылып йөргәндә дә, Әнвәр Абидович гел генә Шубарин хатыны янында булырга тырышты. Күрәсең, барлык газет мәгълүматларына һәм Артур Александровичның кыска-коры җавапларына караганда, шушы ханымның иректәге тормыш турында сөйләгән сүзләре аның талчыккан йөрәгенә күбрәк май булып яткандыр.

Юбилейга килгән барлык кунакларны да исемен әле бирегә килгәнче үк Шубарин белгән бер кунакханәгә урнаштырдылар. Кунакханә биш катлы борынгы йорт иде. Ул, мөгаен, кат-кат янартылгандыр, үзенә төрле чорларның төрле стильләрен җыйган, «П» хәрефенә охшаш бинаның зур ишегалды испанчарак «патко» дип йөртелә икән. Эсселектән саклану өчен үзбәкчә йөзем куаклары һәм чәй розалары үрелгән коймалар артында кунакханә түгел, ә хөкүмәт йорты торадыр шикелле иде. Шәһәрнең ин абруйлы районы, ыгы-зыгысыз урам, шәһәр кварталларына хас булмаган тынлык, һәр машинаны ишек төбендә каршы алып торучы яхшы өйрәтелгән хезмәтчеләр—һәммәсе кабул итүнең ин югары дәрәҗәдә оештырылуы турында сөйли иде.

Шубарин беренчеләрдән булып килгән иде, банк җитәкчеләре аны ишек төбеннән үк сәламләп каршы алдылар. Үзенә билгеләнгән бүлмәнең ачкычларын алганда, аның күзе буфет бары янында муенына фотоаппаратлар аскан егеткә төште. Егетнең чәче таныш шикелле тоелды. Бераз борыла төшүгә, аны танып та алды: ул—Стрельцов иде. Кичә Гамбург аэропортында күздән яздырган иде, менә хәзер тагын аның тирәсендә генә икән, кирәк була-нитә калса, ана мөрәҗәгать итәргә мөмкин. «Кайда тукталды икән ул? Биредәме, әллә якындарак башка бер җирдәме?»—дип уйлап алды Артур Александрович. Ни өчендер Сенаторны исенә төшерде ул. Ташкент аэропортында Гамбургка очасы пассажирларны таможня залына чакыргач, шунда очрашкан иделәр. Сенатор Ташкентка халыкара Мәскәү-Дәһли рейсында хан Акмал белән бергә килгән булып чыкты, самолет Үзбәкстан башкаласында да туктап ала икән.

Акмал Ариповны бер зур төркем туган-тумачалары, дуслары, якташлары каршы алды. Халыкара аэропортта кагыйдәләр кырыс булуына карамастан, бу төркем самолет ишеге янына кадәр үк бәреп керде, хәтта шунда каракучкар сарык тәкәсен дә өстерәп китергәннәр икән. Аны, хан Акмалның кайтуы хөрмәтенә дип, шунда ук чалып та ташладылар. Шубарин очрашуны алдан ук шулай уйлап оештырганнарын аңлап алды. Артур Александровичның гаиләсе белән Италиягә ниндидер тантанага барырга җыенуын белгәч, Сенатор, хан Акмалны каршы алучылары белән ялгыз калдырган да, Шубаринга хәерле юл теләр өчен килеп тә җиткән, имеш. Барысы да бик тәртипле, урынлы, Шәрекъта нәкъ шулай эшләнә дә.

Сенатор банкирның чит илгә озаккамы барасын белергә тели иде. Бер атна аның өчен азрак иде, әлбәттә, ләкин юк ише дә түгел, җавап бирергә билгеләнгән вакыт иртәгә үк түгел ич. Сенаторның бәхете басты. Шубариннарның чемоданнарын таможня контроле залына кадәр күтәреп илтешкәч, алар белән хушлашып, ул беренче катка—хан Акмалны шаулашып каршы алучылар янына ашыкты. Шунда көтеп тору залындагы бер егеткә күзе төште. Егет аңа таныш иде шикелле.

Ашыгып үтеп барганда, ул егетне җентекләбрәк күрергә теләгән иде дә, егет моны сизенеп, тәрәзәгә таба борылып та куйды. Шуннан соң Сенаторны көтмәгәндә аның кем икәнен беләсе килү теләге биләп алды. Ул, беренче катка төшеп, зал аша аркылы үткәч, икенче баскычтан янадан өскә күтәрелә

башлады. Әле баскычның яртысын да менеп җитә алмады, теге кеше, тиз генә урыныннан торып, таможня тикшерүе ягына юнәлде.

Сенаторның икеләнүләре юкка чыкты: ул бу егетне белә, хәтта фамилиясен дә хәтерли иде: Стрельцов, Стрельцов Сергей Юрьевич. Үзе КГБ белән бәйләнештә чакта алар Ленинградта очраштыргалый иделәр, егетне бик сәләтле офицер дип сөйлиләр, аңа ин җаваплы һәм четрекле эшләрне тапшыралар иде. Чит илләрдә бик җаваплы эшләр өчен Мәскәү аны файдалана, чөнки ул әле башкалада читләр өчен дә, үзебезнекеләр өчен дә аз билгеле иде.

Әлбәттә, Стрельцов аның кочагына ташланырга җыенмады, әмма качарга да сәбәбе юк иде. Ә Сенатор, Шубарин белән аның хатынын озата барганда, егетнең үзен игътибар белән күзәткәнен сизде. Димәк, Стрельцов та Шубаринның кем белән сөйләшеп торганын белергә тели иде. Хәер, Стрельцов турыдан-туры алар белән кызыксынса, Гамбургка бүген үк очып китәргә дә җыенмас иде.

«Тынычрак бул, тынычрак,—дип үзенең куанычын басарга тырышты Сухроб Әхмәтович һәм аска—халыкара аэропорт холлына төшеп китәргә ашыкты. Анда инде бай табын әзер, килүче-китүче, каршы алучыларга бертуктаусыз затлы «Үзбәкстан» коньягы тәкъдим итеп торалар, кай арададыр җыелып өлгергән журналистлар чарт та чорт фоторәсемгә төшерәләр иде. Бу мизгелне һич тә ычкындырырга ярамый иде, шуна күрә Сенатор хан Акмалны уратып алган кешеләрне аралап, аның янәшәсенә барып басты. Болай купшы каршы алуларыннан битәр бер тулы бокал коньяк та эчеп куйган Арипов аны дустанә кочып алды, үзләрен рәсемгә төшерүчеләр алдында Сенатор белән бергә әле тегеләй, әле болай боргалана башлады. Каршы алу тантанасы сәгатьтән артык дәвам итте, машиналар кортеже шуннан соң гына шәһәр үзәгенә—«Үзбәкстан» кунакханәсенә юл алачак. Анда хан Акмал белән аның туганнарына кунакханәнең тулы бер катын алып куйганнар икән инде.

Сенатор Миршабны бер читкәрәк алып китте дә:

—Әйдәле, очып китүчеләр залына күтәрелик, эш бар,—диде.

Аста шау-шу тынып тормауга карамастан, Сенатор дикторның: «Самолет Гамбургка юл алды»,—дигән хәбәрен ишетте. Китүчеләрне теркәү залында Миршаб кизү торучы кызга таныклыгын күрсәтте, ә Сенатор сорап куйды:

—Гафу итегез, без сонга калдык. Дустыбыз Стрельцов Сергей Юрьевич Гамбургка очып китә алдымы икән?

—Хәзер, бер генә минут көтегез,—диде элегрәк депутатлар бүлмәсендә эшләгән һәм бу ир-атларны танып белгән кыз.—Әйе, борчылмагыз, очып китте. Әмма ул Гамбургта икенче самолетка күчеп утырачак, ә Миланга очучы самолетка без инде урынны аңа алдан ук әзерләп куйган идек,—диде.

—Димәк, дөрес сиземләгәнмен. Унган егет лә мин!—диде.

—Юньләп аңлат әле, нәрсә булды соң?—Хан Акмалны калдырып киттең дә, хәзер нииндидер Стрельцов «очтымы-юкмы» дип төпченәсең,—дип үртәлеп сорады Миршаб.

Сенатор дулкынланудан кызарынган йөзе белән аңа таба борылды. Дустының ризасызлыгын сизмәстән:

—Әгәр ялгышмасам, безгә ничек фарт килгәнен син әле чамаламыйсың да,—диде.—Хәтерлисеңме, Канзафар безгә Камаловның Шубаринга америкалы кунагын коткарырга ярдәм иткәнен җиткергән иде. Без әле шул чагында ук Японецның «мәскәүле» белән бер җырны җырларга җыенуын чамалаган идек. Димәк, шулай булса, ул КГБ белән дә бер юнәлештә эшли, ә Камаловның республикадагы хәзерге иминлек хезмәткәрләренә йогынтысы барын һәркем белә. Шулай түгелме?

—Шулай,—диде, әле һаман да аңлап җитмәстән Миршаб.

—Аларның шулай тиз генә дуслашып китүләренен сәбәбен белмим. Әмма Шубаринның һәрвакыт закон бозмыйча, гадел-тәртипле яшәргә теләгәнен беләм. Ул бу хакта үзе миңа да берничә мәртәбә әйткән иде. Ә бүген Шубарин ни өчендер Италиягә—ниндидер банкның юбилеена очып китте, әйтерсең, аның биредә эшләре беткән. Сизенәм: аның китүе дә ни-нәрсә беләндер бәйле. Европага сәяхәте Талибка бәйле булмагае. Шулай булса, без җинаятьчеләр аша, гадәттәгечә, байтак мәсьәләләрне хәл итә алырбыздыр,—диде Сенатор.

—Аңламыйм. Ничек итеп?—дип гаҗәпләнде Миршаб.

—Эш шунда, дустым, әле без белешкән Стрельцов Сергей Юрьевич элек КГБда хезмәт итә иде, мин дә аны яхшы беләм. Аны вак-төяк эш белән генә берәр җиргә җибәрмиләр. Ә бүген алар бергәләп Гамбургка очтылар, аннары Шубарин Миланга китәчәк, Стрельцов та. Мөгаен, ул банкирны ниндидер эш буенча карап-күзәтеп торырга тиештер.

Әгәр дә Шубаринның генерал Саматов кешеләре белән бер уен уйнаганнарын белсәләр, бу—аларга үлем дигән сүз.

—Аңлый башладым шикелле. Сүзләреңдә усал һәм мәрхәмәтсез хаклык бар. Тик шуны гына аңламыйм—җинаятьчеләргә Шубарин банкы нәрсәгә кирәк?

—Мәрхәмәтсезлек, дисеңме? Без бит Японецка бернәрсә дә бирмәскә, бернәрсә дә сөйләмәскә дип бергә хәл иткән идек. Ул, кайткач, ярты Ташкентны безгә каршы котыртачак. Бер Тулкун Назаровичны искә төшергәндә дә каз тәннәре чыга. Димәк, яки ул безне, яки без аны... Башка юл юк... Ә җинаятьчеләргә килгәндә... Банкир аларга ни өчен кирәк булды икән? Бу хакта мин Мәскәүдә ике атна баш ваттым, җавабын... газеталардан таптым. Ялган чечен авизолары турында укыган идеңме? Анда йөзләрчә миллиард сумнар йөри. Ә бит шул рәвешле валюталарны да әйләндерергә була. Көнбатышның әле моңа башы җитмәгән. Әгәр Европа илләренең берничәсендә бер үк вакытта шундый операция үткәрсәң, йөз миллионнарча сумны гына түгел, ә долларларны эләктерергә була. Йә, ничек?

—Ышандырдың, сиңа «Интерпол»да эшләргә иде,—дип, Миршаб аның салпы ягына салам кыстырган булды. Сәгатенә карап:—Хәзер «Үзбәкстан» ресторанына ашыгыйк, анда хан Акмал тулы бер зал алган, үзенең кайтуын бик зурлап билгеләп үтәргә җыена икән. Үзен каршы алырга килүчеләрнең һәммәсен дә шунда мәҗлескә чакырган,—дип өстәде.

Әмма Сенатор бу тәкъдимне кире какты, үртәлеп:

—Син пычагымны да аңламагансың,—диде.—Безнең вакытыбыз санаулы. Без бит Шубаринның Италиядә күпме торасын төгәл белмибез. Ташкенттамы, Германиядәме—кайда булуына карамастан, хәзер үк Талиб белән сөйләшергә кирәк. Ул үзенең чит илдәге әшнәләренә Миланда Шубарин белән Стрельцовны күзәтеп торырга кушсын. Алар өчен дә бу бик мөһим. Ә хәзер Канзафарны эзләп табыйк. Җир астыннан булса да—табыйк. Шуннан, вакыт калса, «Үзбәкстан»га да сугылырбыз: анда мәҗлес иртәнгә кадәр сузылачак әле. Мин хан Акмалның гадәтләрен беләм.

## XXX

Канзафар өйдә юк иде. Аны таныш катраннардан эзли башладылар, ләкин Почтальон аларның берсендә дә күренмәде, Сенатор борчыла ук башлаган иде, әмма соңгы катран адресын әйттеләр. Анда Ташкентның бизнес вәкилләре җыела икән. Канзафар Рөстәмов та шунда булып чыкты. Күрәмсең, Канзафарның уены әйбәт иде, аның һич кенә дә ташлап китәсе килмәде. Ләкин Сенатор, кинәт кенә иелеп, аның колагына усал гына пышылдап

нәрсәдер әйтте, егет китәргә ашыга башлады. Машинага чыгып утыргач, Сенатор карышып тормаслык итеп әйтте:

—Хәзер мине бүлдермичә генә тынла. Безнең кушу буенча син янында бөтерелгән Талиб Шубарин белән бергәләп ниндидер зур финанс операциясе әзерли шикелле. Без нечкәлекләрен белмибез. Бу шикле эш, безнеңчә, Европадан кайтасы акчалар яки банклар белән бәйләнгән. Талиб юкка гына Германиягә ике мәртәбә барып кайтмагандыр, бер сәгать элек кенә Шубарин да Германия аша Италиягә очты. Аның банкы валюта операцияләре үткәрергә хөкүмәт рөхсәте алган Үзбәкстандагы берләнбер банк. Без банкир республика прокуратурасы һәм КГБ белән бергә эш йөртәдер дип уйлыйбыз. Кайда гына булса да, бу турыда Талибка хәбәр итәргә кирәк.

—Соң, сез Шубарин белән иске дуслар бит!—дип, сүзләрен курка-курка гына сыгып чыгарды югалып калган Канзафар.

Озак дәшми утырган Миршаб тыныч кына:

—Дөньялар үзгәреп тора,—диде.

—Безгә әйтми-нитми генә КГБ белән хезмәттәшлек иткән кеше белән аралаша алмыйбыз без,—диде Сенатор кырыс кына. Аннары:—Кая барырга кирәк?—дип сорады.

«Эшчеләр шәһәрчегенә. Радиальная, 12, зәңгәр капкалы йорт,—дип ачыклады Рөстәмов.—Ләкин банкир Гамбургтан кайтып җиттеме икән әле. Шушы көннәрдә ул аралаша торган кайбер кешеләр белән очрашкан идем, аны бүген-иртәгә кайтыр дип көтәләр икән,—диде ул. Тавышы төшенкерәк чыкты, үзенең тагын ниндидер бер куркынычка тарганын аңлый. Японец белән дә дошманлашырга туры киләчәк бит. «Әгәр бу агылый белән тагылый икәүләп гадәтләренчә шыттырсалар, Талибка каршы берәр этлек эшләргә жыенсалар?»—дигән уй Рөстәмовның миен яндырып узды. Бөтен тәне калтыранып куйды, үзе дә сизмәстән:

—Эчәргә берәр нәрсәгез юкмы?—дип сорады.

Сенатор Миршаб машинасының «бардачогын» ача төшеп, андагы фляжканы капшап алды. Алар икесе дә машинада һәрвакыт эчемлек йөртергә гадәтләнгән иделәр.

—Әгәр Талиб кайтмаган булса, эш катлаулана. Ә син барыбер аның әшнәләрен табарга тиеш. Без аларга кирәкле хәбәрне җиткерербез, алар Германия белән кичекмәстән бәйләнешкә керсеннәр,—диде Сенатор, Канзафарга коньяклы фляжканы суза-суза, үзе дә бер-ике йотым уртлап куярга онытмады.

Эшчеләр шәһәрчегенә караңгы капкач кына килеп керделәр. Урамнар, һәр җирдәгечә, караңгы, бары тик Талиб йорты янындагы фонарь баганалары гына балкып утыра иде. Тимер белән тышланган биек капка тирәсендә тәртипсез генә тезелешкән дистәләгән затлы машиналар тора, төсләре—«юеш асфальт», «шампан күбеге», «сирень», нигездә соңгы мода «тугызлыклар», алар арасына күзгә ташланмый гына ике «мерседес» та кереп кунаклаган. Кайбер машиналарның тәрәзәләре ачыла төшкән, ни кабиналарында, ни яннарында беркем дә күренми үзе. Монысы инде каракларның кәпрәюе кебегрәк—янәсе, миннән урлап алып китәргә кыюлыклары җитмәс. Хәер, Талиб йорты янында мондый хәлнең булуы да мөмкин түгел.

Машина килеп туктагач, Сенатор Канзафар белән бергә чыгарга теләгән иде, егет аны мыскыллабрак туктатты:

—Үзәк Комитетка килмәдек, көтеп торырга туры килер. Юлдан кайткан унаена кабул итәргә риза булса ярый ла!—диде.

Ул биек койманың ян капкасына юнәлде, капка эчтән шундук ачылып китте, көтеп кенә торганнар кебек. Рөстәмов кереп китүгә капканы шалтыр-шолтыр бикләп тә куйдылар. «Төрмәдәге кебек»,—дип уйлап алды Сенатор.

Бер сәгатьтән артык көтеп утырсалар да, йорт янына килеп туктаучы булмады, эчтән чыгучы да юк иде. Ачулары кабарган Сенатор белән Миршаб калган коньякны эчеп бетерделәр. Сенатор китәргә талпынып та карады, әмма Миршаб аны тыеп калды:

—Шундый хәбәр алганнан соң сиңа тыныч кына йокларга бирер иделәр, дип уйлыйсыңмы?

—Азынды шпаналар, азынды,—дип кабынып китте Сенатор.—Бәхетсез карак, үзен кем дип уйлый икән ул?!

Рульдә утырган Миршаб магнитофоннан агылган музыка тавышына башын селкеп утыра—ул бию көйләрен үлеп ярата иде.

Бераздан, инде гадәттә тыныч Миршаб та чыгырыннан чыга башлагач, ниһаять, йорт ишеге шыгырдап ачылды да, аннан күңелсез генә Канзафар күренде, ул атлый-йөгерә машина янына килде.

—Нишләп шулай озакладың?—дип сорады Сенатор.

—Мин бит әйттем: бу Үзәк Комитет түгел, дидем. Үзем дә абруйлы карак түгел, бер дә ихтирам-хөрмәтләп каршы алмадылар. Байларның үз хикмәтләре булган шикелле, каракларның да үз гореф-гадәтләре, бигрәк тә ментлар өчен,—дип Сенаторның сүзен тыйды Канзафар, үзе арган кыяфәттә «Волга» утыргычына сөялде.

—Ул нәрсә әйтте, ничек кабул итте сүзләреңне?—дип сорады Миршаб.

—Берничек тә түгел. Мин сезнең эшләрегезне белмим, белергә дә теләмим. Мин бары тик сезнең кем икәнегезне генә әйттем. Ана ашыгыч мөһим йомышыгыз бар, дидем. Мин сезнең эшегезгә кысылырга теләмим. Әгәр Шубарин үзен сез сатканны белсә, нәрсә буласын күз алдына китерә аласызмы? Әгәр сез ялгышсагыз?.. Юк инде, минсез генә... Мин бер сәгать эчендә дә бер ун килограмм югалтканмындыр.

—Аңарда кунакта кемнәр?—дип түземсезләнеп сорады Әкрәмхуҗаев.

—Керегез дә сорагыз. Мине залга чакырып тормадылар,—дип төксе генә әйтеп куйды Рөстәмов.

Куркуыннан, егет тагын да кызып китәргә мөмкин иде.

Сенатор, галстугын рәтләде дә, түземсез генә үзен көтүче ниндидер егет басып торган шар ачык ян капкага атлады. Егет тән сакчысы, ахры, аны ишегалдына алып кереп китте.

Сенаторны кайчандыр Гвидо Лежаваны яшереп тоткан бер катлы йортта кабул иттеләр. Сухроб Әхмәтовичны келәм түшәлгән тәрәзәсез бүлмәгә кертүгә, спорт костюмы кигән Талиб, дивар буендагы курпач өстеннән күтәрелеп, исәнләште дә:

—Биш-алты минут вакытыгыз бар. Кунакларым көтә, мин бүген генә читтән кайтып төштем. Сүзегезне кыскарак тотыгыз, тыңлыйм,—диде.

Очрашуны сәгатьтән артык көтеп торган Сенатор сөйләшү шулай кыска һәм коры булыр дип уйламаган иде. Аңа хәтта утырырга да тәкъдим итмәделәр, кара-каршы баскан килеш кенә сөйләшүне дәвам иттеләр. Болай каршы алу Сенаторны суыта төште, аның өметләре киселде, ул инде Талибка таяну ниятен кызгана да башлады, әмма чигенергә соң иде инде. Аннары, ник килгәнен ничек аңлатыр иде ул? Әгәр дә Канзафар бөтенесен дә сөйләп биргән булса? Ул ашыга-ашыга, әмма җентекләп Шубарин турында да, Стрельцов турында да сөйләде.

Талиб, пөхтә мыегын сыпыргалап, бүлдермичә генә игътибар белән тыңлады. Кунакның сүзе бетүгә, иң әүвәл:

—Ничек болай килеп чыга соң әле?—дип сорады.—Белгәнемчә, Миршаб белән сезгә югары урыннарга, республикада дәрәҗәле урыннар биләргә Японец булышкан. Ә хәзер сез аны пычак астына куярга җыенасыз.

—Анысы башка тарих. Аңлатырга да бер сәгать кенә җитмәс. Ләкин сез

безнең максатыбызны дөрес анламыйсыз,—диде Сенатор, ул үзләшә төшкән иде инде.

—Ә сез ярдәм сорап кемгә килгәнегезне ачык күзаллыйсызмы соң? Әгәр дә сез минем кулдашыма яла яккан булсагыз, безнең кануннар буенча үзегезгә нәрсә буласын чамалыйсызмы?—дип бераз шыттырып җибәрде Талиб.

—Безнең кануннарыбыз да сезнеке белән тигезләнде инде. Сезнең кануннарыгызның үтәлешен тикшереп торалар, мөрәҗәгать итәргә суд та бар, анда, кемнең кем булуына карамастан, эшне кызу тоталар,—дигән булды Сенатор, хуҗаның күзенә карамыйча гына.

—Сез хаклы һәм сез шундый хөкем чыгара торган йортка килгәнсез. Сез җиткергән мәгълүмат игътибарга лаек, сез үз иркегез белән тормышыгызны куркыныч астына да куясыз. Ләкин, әгәр сез ялгышкан булсагыз, мин сезне Японец кулына бирәчәкмен, ә ул үз дуслары белән ничек тели, шулай хәл итәр. Ул безнең ихласлыгыбыздан шикләнмәсен өчен мин сөйләшүебезне язып та алдым,—диде Талиб һәм биле астыннан диктофон тартып чыгарды.—Теге КГБ егетенең исем-фамилиясен кабатлагыз әле, мин хәзер үк Миланга шылтыратырмын, анда безнең зур гына эшләребез дә бар,—Талиб диктофонын Сенаторның авызы янына ук китерде.

## XXXI

Талибның Милandaгы кешеләре Стрельцовны тиз таптылар. Артур Александрович кунакханә буфетында Стрельцовны күргәндә, аларның икесен дә яшерен генә рәсемгә төшерә иделәр инде. Анда да бер төркем Шубарин белән мәшгуль, икенчесе Стрельцовны төшерә, ә бу төркемнәр бер-берсен белми дә иде. Бу эшне оештырган кеше ничек күзәтергә-эзләргә икәнлеген яхшы белүче булырга тиеш: ике яклап алынган рәсемнәрне чагыштыргач, гаҗәеп кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкин иде.

Ул җәйдә Италиядә көннәр искиткеч матур торды, кунакханәләрдәге яшәү шартларына иң нәзберек затлар да сүз әйтмәслек иде. Кунакханә биш йолдызлы булуы белән генә дан тотмый, биредә еш кына тәхетле-таҗлы гаилә вәкилләре дә туктала. Бик зур футбол уеннары, бигрәк тә немец командалары катнашында булганда, байтак кына күренекле кунакларны җыя икән. АКШның элекке дәүләт секретаре Генри Киссинджер, чыгышы белән Бавария немецы, бигрәк тә еш килеп йөри, имеш.

Әнвәр Абидович та, Шубариннар яшәгән каттагы коридорда кара-каршы ишек аша гына булгач, алар һәрвакыт күрешеп тордылар. Бу юлы ул үзен Мюнхенда очрашкандагыдан күпкә ышанычлырак тота, ирекә дә тиз күнеккән. Ул ничектер сүз арасында гына Италиягә килгәнче бер атнадан артык Мәскәүдә булганлыгын әйтеп куйды. Артур Александрович шулчак генерал Саматов белән булган сөйләшүләрен исенә төшерде, генерал теге телефоннан шылтыратучы башкаладан икәнлеген әйткән иде.

Ничектер ресторанда бер утырып кайткач, алар Шубаринда икәүдән-икәү генә бик озаклап әңгәмә кордылар. Өлкә Комитетының элекке секретаре читләтеп кенә, әлеге акча операциясе уңышлы үтсә, бәлки үзенең дә язмышы үзгәрер дигән өмет белдерде. Чөнки ул үзгәртеп кору елларында утыртылганнарның барысы да диярлек әйләнеп кайтканын яхшы белә иде. Артур Александрович түзмәде, үзенең ул эшкә катнашуы өчен нәкъ менә Әнвәр Абидовичны азат итүне шарт итеп куйганын әйтте. Әнвәр Абидович бик куанды, Шубариннан бу хакта әле үзе сорамакчы булган икән дә, никтер кыенсынган гына икән.

Беренче көннәрендә Әнвәр Абидович эш турында сүз кузгатмады, Шубарин да көтә генә иде. Хәер, ашыгыр урын да булмады. Элекке өлкә комитеты

секретарена тәгаенләнгән бүлмәләргә һәм анын долларларын унга-сулга сибүенә караганда, партия акчалары белән эш итүчеләр аларны кызганмый сарыф иткәннәре күренә иде. Әнвәр Абидович та, ашаган-эчкәндә, Шубариннан бер тиен дә чыгартмый: «Ә мина алар ниемә кирәк? Калсалар—кайтарып бирергә туры киләчәк бит»,—дип кенә сөйләнә. Дүртенче көнендә Артур Александрович түзмәде: «Теге, вәгъдә ителгән эш кешеләре белән очрашу кайчан сон инде?»—дип сорады. Әнвәр Абидович кулын җәеп, җилкәсен генә җыерды:

—Мина: яшә, шатлан, дусларын белән аралаш, кирәк булгач, үзебез хәбәр итәрбез, дип кенә әйттеләр,—диде. Аннары, бераз тынып торгач өстәп куйды:—Мине бирегә алып килүчеләр арасыннан бу кунакханәдә яшәүчеләр күренми. Бәлки, ин төп кешеләр әле килеп җитмәгәндер?—диде.

Артур Александрович, бәлки, бу хакта сораштырмаган да булыр иде, әмма нәкъ шул кичтә, лифт көтеп торганда, ул сигарет кабызган арада әллә каян гына килеп чыккан бер яшь егет анардан инглизчә генә тәмәкесен кабызырга сорады. Шубарин ана, аны-моны уйламыйча гына, кабызгычын сузгач, теге егет тиз генә русча әйтеп куйды: «Сезне ни өчендер гел рәсемгә төшерәләр, сак булыгыз...»—диде. Бу егетнен Стрельцов икәнен Шубарин шундук танып алды.

Артур Александрович үзен шулай күзәтеп өйрәнәләр, шуна күрә очрашу да кичектереләдер дип уйлады. Әлбәттә, ул үзен бөтенләй башка кешеләр, башка сәбәпләр белән рәсемгә төшерәләрдер дип башына да китермәде. Ә Стрельцов белән мизгел арада очрашуларын һәр ике як та эләктереп алган иде инде. Моны Шубаринны да, Стрельцовны да күз унынннан ычкындырмаска кушкан кеше боерыгы буенча эшләделәр.

Италиядәге көннәр шигрин тиресе шикелле бик тиз кыскара бардылар, кайтар юлга билетларга да заказ бирелгән иде инде. Шубарин борчыла калды: әллә сон нәрсәдер барып чыкмадымы яки, нәрсәдәндер шикләнеп, өстәмә мәгълүмат җыялармы? Әмма беркөнне иртән анын янына бик канәгать елмаеп Әнвәр Абидович атылып килеп керде.

—Бүген кичкә сез банк президентынын вилласына чакырулы. Анда бик аз кешеләр генә булачак, котлыйм сезне!—диде ул шатланып. Икәүдән-икәү генә калгач, өстәп куйды:—Безнен бирედә булуыбызнын сәбәбе дә шул: очрашу шунда билгеләнгән. Ә мин инде алар үз ниятләрен үзгәрткәннәрдер дип борчыла да башлаган идем,—диде. Анын талчыкканлыгы сизелә иде.

—Сез үзегез анда буласызмы сон?—дип сорады Шубарин, күнеленнән ул барлык мөмкинлекләрне исәпли иде.

—Әлбәттә, юк. Мин бит арадашчы гына, ә, дөресрәге тотык, төп кеше—сез.

Вилла шәһәрдән шактый ерак икән, аларны алырга өсте ачык машина җибәргәннәр. Якын-тирәдә Стрельцовны инде икенче көн күрмәгән Шубарин, озын гына юлны үткәндә, кирәкле кешеләрнен бүгенге мәҗлестә булмаулары да бик мөмкин икәнлеген уйлады. Анда хәтта Әнвәр Абидовичны да чакырмаганнар, лагерьдан мамык Наполеонын коткаручылар да булмастыр. Уенга, күрәсен, икенче кешеләрне керткәннәрдер, шул исәптән, үзен дә—партия акчаларынын сере нык саклана иде.

Вилла зур гына зәйтүн агачлары әрәмәсендә икән. Шубариннар анда энгер-менгердә генә килеп җиткәндә, биек тимер койма буенда алты-җиде машина тезелеп тора иде инде. Ләкин әле кунакларны көтми иделәр булса кирәк. Бакча сукмакларында утларны яндырдылар, кунаклар ашыкмый гына йөри башладылар. Банк президенты сеньор Сальварани Шубаринга атаклы итальян велосипедчысын хәтерләтә иде, ул хәзер килгән кунакларны үзе каршы ала һәм шунда ук аларны якын-тирәдәге башка кунаклар белән таныштырып тора иде.

Ярты сәгатьтән соң кунакларның барысын да бәйрәмчә балкып торган вилланың мул табыннары янына чакырдылар. Шубариннарны Германиядән килгән ирле-хатынлы банкирлар белән рәттән утырттылар, Артур Александрович алар белән немец телендә берничә сүз дә сөйләшеп алгандай итте. Табында ирле-хатынлы унике пар һәм хатын-кызсыз тагын өч ир-ат бар иде. Күнелле генә гөрләшеп, ашап-эчеп утырганда, Шубарин аларның арасыннан үзе белән сөйләшергә тиешле кешенең кем икәнен чамаларга теләде. Алар арасында берденбер рус кешесе ул үзе генә иде. Бу эштә, әлбәттә, бик канатланмаска да кирәктер, Әнвәр Абидович әйткәнчә, элекке СССРның партия акчалары, кызганыч ки, чит ил кешеләре карамагында бит. Шубаринның чамалавынча, аңа очрашу билгеләгән кешеләр хатын-кызларсыз гына килгән өч ир-ат булырга тиеш. Алар янәшә утыралар, сөйләшү-аралашуларына караганда, бер-берләрен күптән беләләр, юкса, кунакларның күпчелеге үзара беренче тапкыр гына очрашалар иде. Бу хакта үзенең сәламләү нотыгында сеньор Сальварани да әйтеп узды.

Шау-шулы мәҗлес ахырына якынлашып килә иде инде, Шубарин бу юлы да очрашу булмас дигән фикер белән килешкән иде, ике тост арасында тыныбрак торганда, аларны аэропортта каршы алган банк хезмәткәре, Артур Александровичны бер читкәрәк алып китте дә:

—Сезнең белән ялгыз гына сөйләшергә телиләр. Икенче каттагы каминлы залга күтәрелегез әле,—диде.

«Ниһаять!»—дип шатланды Шубарин, хатынын танышып өлгергән, янәшәдә утыручы ирле-хатынлы немецларга калдырып, өскә менеп китте.

Икенче катта ул башта бер ишеккә төртелде, аннары—икенчесенә, бары тик өченче ишек кенә кирәклесе булып чыкты. Биек түшәмле залда идәнгә утыртып куелган фонарьларда гына тонык ут яна иде, ул бүлмә түрендәге бер өстәл янындагы күн кәнәфиләрдә гәпләшеп утырган өч ир-атны тиз генә шәйләмәде дә. Идәнгә җәелгән калын келәмдә аяк тавышлары ишетелми, ишекләр дә тавыш-тынсыз гына ачыла—аның кергәнен сизмәделәр дә шикелле. Шубарин өстәл янына килүгә, тегеләр өчесе дә торып басып аны сәламләделәр.

—Хәерле кич, Артур Александрович, сезне күрүебезгә бик шатбыз,—дип кул бирделәр.

Тәкъдим ителгән урынга утыргач, Шубарин аларны игътибар белән күзәтеп чыкты, әмма берсе дә мәҗлестә булмаган, элек тә үзе күрмәгән кешеләр иде болар. Аннан сораштыра башладылар: килүеннән канәгатьме, кирәкле элемтәләр булдыра алдымы, очрашулар эш буенча файдалы булдымы? Барлык сорауларга да Шубарин унай җавап бирде, Европаның атаклы банкирлары белән турыдан-туры таныштырулары өчен рәхмәт әйтте.

—Бу безнең өчен дә файдалы,—диде чәченә чал керә башлаган кырык биш яшьләрдәге кеше. Аның ачык төстәге костюмы якасында сеньор Сальварани бакчасыннан өзелгән роза чәчәге алсуланып тора иде. Шубаринның чамалавынча, өчлекнең башлыгы шул кеше булырга тиеш кебек.

Аннары Шубаринны аның банкына кагылышлы сораулар белән күмеп ташладылар. Өчесе дә финанс эшләрен яхшы белгән кешеләр икәне сизелә иде. Артур Александрович мондый сөйләшүне көтә иде, барлык сорауларын да диярлек очрашуга әзерләнгәндә үк алдан чамалаган иде. Шулай да көтелмәгән сораулар да булды, әмма ул һәрберсенә төгәл җавап биреп барды. Аннары кинәт кенә шәхси мәсьәләгә кагылышлы сораулар китте: әйтик, берничә тел белгән банкир Көнбатышка күчәргә теләмиме, хәзер Европа белән Америкада аңа электән рәхмәтле бай дуслары да житәрлек бит, диделәр. Гвидо Лежаваны да искә төшерделәр. Шубарин хәтта торгынлык елларында да гаиләсе белән Көнбатышта булгалаганын әйтте. Әмма анда бөтенләйгә калу уе бервакытта да башына кермәде. Германиядә тәҗрибә алып, өйрәнеп

йөргәндә ана бер зур банкта Россия буенча белгеч урыны да тәкъдим итеп карадылар, банкирның да башы әйләнерлек алтын таулары вәгъдә иттеләр, ләкин ул риза булмады. Иң соңгы сораулары шул булды: хәзерге хакимият башындагылар ана ничек карый? Шубарин республиканың күчеш чорына караган үзенең икътисад һәм финанс реформалары проектының әле ике ел элек үк Югары Совет сессиясендә каралганын, банк ачу өчен рөхсәтне дә артык мәшәкатьләнмичә алганын, ана архитектура кыйммәте булган бина—элекке «Рус-Азия банкы» бинасын биргәнлекләрен әйтте.

Әңгәмәгә йомгак ясап, якасына ал роза кадаган кеше:

—Без сезнең хакта ялгышмаганбыз, банкыгыз безне кызыксындыра, хезмәттәшлек итәрбез,—диде.—Ләкин шунысы бар, без хәзер тоткынлыкта булган элекке кулдашыгызны эзләп тапканда, илдә вәзгыять башка иде, безнең сөйләшүебез Үзбәкстан бәйсезлек игълан иткәнче булды. Элекке СССРның барлык төбәкләрендә дә тотрыксызлык булу, безне башка юллар эзләргә, әзер уй-ниятләребезне сүтәргә мәҗбүр итте. Без сезгә киләсе айда ук Италия белән Германиядән җибәрәсе акчаларга бик ышанычлы яна адрес табылды. Һәммәсе дә шушы көннәрдә, шушы атнада гына хәл ителде, шуңа күрә очрашуга да соңга калдык, Миланга бүген генә килеп төштек. Артур Александрович, сездән яшерен серләребез юк: яна адресларыбыз—Куба белән Төньяк Корея. Әүвәле акчаларны без аларга күчерәчәкбез. «Барлык йомыркаларны да бергә, бер кәрҗингә тутырырга ярамый» дигән алтын кагыйдә бар. Без дә шулай эшлибез. Ә сез көч җыегыз, абруй-дәрәҗә казаныгыз, сезнең дә көткән сәгатегез сугар, әйтеп-нитеп тә тормастан, без янадан килеп чыгарбыз, ышанабыз—сез безнең кеше. Ә безгә, партиябезгә булышырга теләгәнегез өчен рәхмәт!—Алар, сөйләшүне тәмамланганга санап, дәррәү урыннарыннан кузгалдылар.

Шубариннар өйләренә дә Германия аша кайттылар—моны яна танышлары, Дюссельдорф банкиры киңәш итте. Аның белән танышулары өчен генә дә Миланга баруны уңышлы дип санарга кирәк иде. Банкир буларак, Шубарин Европаның ун зур банк президентларына турыдан-туры мөрәҗәгать итә алачак иде, ул аларның чакыру-визит кәгазьләрен үзе белән алып та кайтты. Ә немец коллегасы белән ул, кайткач ук үзенең биш хезмәткәрен өйрәнү-тәҗрибә туплау өчен Дюссельдорфка җибәрергә килешеп куйды. Башка банк хуҗалары да аның банкы белән нык кызыксындылар. Шундый сәяхәтне уңышсыз булды дип әйтергә мөмкинме соң?! Әмма Артур Александрович өчен бүген иң мөһиме партия акчалары иде, ул шул ният белән яна башлады, тизрәк нәтиҗәсен күрәсе килә иде аның. Бу эшкә прокурор Камалов белән генерал Саматовны да ул тартты бит. Кайдадыр күңеле төбендә тагын бер өмете бар иде—ничек булса да, Әнвәр Абидовичны тоткынлыктан коткару кирәк. Ташкентта ул аның улларына күз-колак булып торды, Италиягә китәр алдыннан, әтиегез тиздән ирекгә булыр, дип вәгъдә дә бирде. Барып чыкмады бит әле. Миландагы очрашу нәтиҗәләре барыннан да бигрәк Әнвәр Абидовичны борчуга салды.

Дюссельдорфта көтелмәгән тоткарлык килеп чыгу сәбәпле, Шубарин Ташкентка үзе уйлаганнан соңрак кайтып төште. Самолет төнлә бик соңлап кайтса да, ул инде иртән иртүк банкында иде. Ул Италиядән дә эшенә еш шылтыратып торды, андагы хәлләрне белә, үзеннән башка хәл итәлә алмаслыкларыннан да хәбәрдар иде. Өенә кайтып кергәч, иң беренче эш итеп, ул телефонының җаваплар биреп торучы автоматыннан хәбәр тыңлады. Инде менә өч көн рәттән аңа кайту белән очрашырбыз дип сөйләшенгән таныш түгел кеше шылтырата икән. «Димәк, Германиядән килергә тиешле кеше килгән!»—дип елмаеп кулларын угалады Шубарин. Аның бу җинаятьчел дөньяда яткан акчаларны тизрәк коткарып аласы килә иде. Әбәттән соң ул,

Камаловка шылтыратып, очрашу билгеләргә тели иде. Аңа барып кайтуы турында сөйләргә, Талиб кешеләренең Германиядән кайтулары турында да әйтәсе килә иде.

Әбәт алдыннан гына телефон шылтырады. Ул бик очрашырга теләгән кеше үзе шылтырата икән. Таныш түгел кеше аны кайтуы белән котлады, Европадагы кайсы банк вәкилләре тантанада катнашканлыгын белеште. Шулай итеп, үзенең дә банк эшләреннән читтә булмаганын, үзебезнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә финанс дөньясында нинди хәлләр барлыгын белгәнлеген раслады. Аннары ул сиздермичә генә эш мәсьәләсенә күчте, үзенең инде дүртенче көн рәттән шылтыратуын әйтте, Гамбургтан килгән кеше, вакытында килеп тә сезне очратмагач, бик борчыла икән, чөнки ул иртәгә кичекмәстән Гамбургта булырга тиеш икән.

—Ярар,—диде Артур Александрович.—Бүген үк бөтен мәсьәләләрне хәл итәрбез. Ә Гамбургка бездән хәзер һәр көнне самолет оча,—дип тынычландырып та куйды.

—Бик әйбәт,—диде теге кеше.—Хәзер әбәт вакыты. Әгәр дә «Лидо» ресторанында ашап-эчеп алсак, каршы килмәссезме? Ул ресторан сезнең карамакта, диләр бит. Бер унайдан кунакны да куандырырбыз, ул үзбәк ашларын бик яраткан, минем тәкъдим белән, Миланга китеп бармыйча, Ташкентка килүенә дә бик шат. Әгәр сезне очрашу урыны һәм вакыты канәгатьләндерсә, бер сәгатьтән, димәк, «Лидо»да очрашырбыз,—диде теге кеше, кинәт кенә Шубаринның игътибарын йомшартып.

Көтелмәгән бу тәкъдимнән Артур Александрович беразга югалып калды:

—Сез ничәү булырсыз соң?—дип кенә сорады.

—Өчәү. Ә сез үзегез теләгәнчә алып килә аласыз.

—Юк. Мин ялгыз булырмын,—диде Шубарин, аның очрашуны кичектерәсе килми иде, чөнки немец та кайтып китәргә ашыга, Камалов янына да буш кул белән генә бару килешмәс.

Ул очрашуга Коста белән барырга булды, аны үзенә чакырткан иде, ул да урынында түгел икән—аэропортка сыйфатлы бензин эзләп чыгып киткән, «Мазерати» машинасы шундый бензин таләп итә бит. Ишек төбендәге кешеләренә үзенең «Лидо»га киткәнлеген әйткәч, Коста күренүгә үк шунда килсен, дип, Артур Александрович теге таныш түгел кеше белән очрашуга китеп барды.

«Лидо» ресторанында аның булмаганына елдан артык иде инде, соңгы тапкыр Германиягә китәр алдыннан ул анда туган көнен үткәргән иде. Ресторанга киткәнче, ул Нәргиз белән Икрам Мәхмүтовичка үзенең «Лидо»га булган пай өлешен аларга бирергә, абруй-дәрәҗәле бу йортны тулысынча алар файдалансын дигән теләген әйтәсе килгән иде. Ресторан ишегалдында үзгәрешләр дә бар икән—түләүле автомобильләр куярга бик яхшы җиһазландырылган урын җайлаганнар, Ташкенттагы андый урыннарның күпчелеге шикелле, монысын да мафия кулында тотканы билгеле, әлбәттә. Артур Александрович ишегалдына кереп тормады, «Мазерати»ен тукталышта гына калдырды.

Ишек төбендәге швейцар Шубаринга таныш булып чыкмады, баскыч янында ук ягымлы гына каршы алган метрдотель дә таныш түгел иде. Ресторанның эчке җиһазларына, пәрдәләренә кадәр яңа икән, үтеп-сүтеп йөрүчеләр дә аны танымый—«ничек тиз үзгәрә дөнья»—дип уйлап алды Артур Александрович. Ул икенче катка күтәрелгәндә, Талиб аны көтеп тора иде инде. Егет алтынсу дакрон костюмнан, муенында—күбәләк галстук, аягында—ак штиблетлар—койган да куйган эстрада йолдызы инде менә! Ул Артур Александрович белән елмаеп исәнләште, шәрекь гадәтенчә хәл-әхвәлләрен сорашты, аннары куллары белән ишарәләп үзләрен көтеп торган кешеләр ягына—аерым бүлмәгә дәште.

Шубарин, бер биш минуттан килермен, дип, Нәргиз бүлмәсенә юнәлде, шунда Икрам Мәхмүтовичны да очратырга өметләнә иде ул. Алар бит кайчандыр Лас-Вегаста бергә эш башлаган иделәр. Әмма аларның берсен дә тапмады. Кабул итү бүлмәсе алдында Нәргизгә туган көненә үзе бүләк иткән зур «Шарп» телевизоры эшләп утыра иде. Яна секретарь кыз да аны танымады, ул да үзенең кем икәнен әйтеп тормады, күңеленә ни өчендер шигъри юллар гына килде:

Биредә мин беркемгә дә таныш түгел,
Ә белгәннәр күптән мине онытканнар...

Бай табынлы бүлмәдә Артур Александровичны өч ир-ат көтеп утыра иде. Талибны ул танып белә, пеләшләнеп килгән утыз биш яшьләрдәге аксыл чәчле таза гына кешене телефоннан сөйләшкән тавышы буенча шәйләде, ә спортсменнарча таза өченчесе немец булып чыкты бугай. Талиб алар белән таныштырды: телефоннан сөйләшүчесе Станислав икән, немец дигәне үзен Юра дип атады һәм сигез ел элек Актүбәдән күчеп кайтканын аңлатты. Баш бармагы белән имән бармагы арасындагы билгеләргә караганда, аның яшьлегендә хулиганлык өчен утырып чыкканлыгы да күренеп тора иде. Бокалларга шампан шәрабе салып, танышлык һәм алдагы эшлекле хезмәттәшлек өчен эчеп куйдылар. Капкалап алгач, алдагы эш турында сүз кузгаттылар. Артур Александровичка, Миландагы шикелле үк, сорау арты сорау ява башлады, сорауларны нигездә пеләшләнеп килгән аксыл Станислав биреп утырды. Ара-тирә Юра да сорау биргәләде, аның да эш белән таныш икәнлеге күренә иде, ләкин ни өчендер ул өстенлекне теге юанга бирә килде. Бары тик Талиб кына сүзсез утыра иде. Шубарин әле Мюнхендагы стадионда беренче очрашканда ук аның йомышчы гына булганлыгын аңлаган иде. Чеп-чи җинаятьчел дөнья кешесе инде!

Әмма Талибны бөтенләй башка нәрсә борчый иде. Немец Юра тагын бер шампан шешәсен ачты. Шул чакта бүлмәгә тавыш-тынсыз гына официант килеп керде, ул газлы су сифоны куелган поднос күтәргән иде. Талибның җилкәсе артына басып, сифонны аның стаканына якын китерде, газлы суны салырга ниятләгәндәй кыланды, шунда нервларны параличлый торган су агымы Артур Александровичның йөзенә китереп бәрде, ул Талиб каршысында утыра иде, хәтта кычкыра да алмыйча, урындыгыннан йомшак келәмгә шуып кына төште. Кайдандыр зур җәймә тартып чыгардылар, банкирны шуна тиз генә төреп, альпинист баулары белән бәйләп тә куйдылар, бу бауны прокурор Камаловка һөҗүм вакытында файдаланган иделәр инде. Аннары төрелгән Шубаринны ачык тәрәзә аша япон машинасы «Нисса патруль»нең биек түбәсенә төшерделәр, анда көтеп торучылар аны машина эченә керттеләр. Машина Луначарский шоссесына таба элдертте, шоссены шушы көннәрдә генә Тамерлан урамы дип үзгәрткән иделәр.

## XXXII

Соңгы вакытларда Канзафар Рөстәмов үзенең республика прокуратурасындагы эшеннән тәмам туйды: еш булып торган командировкалар, төрмәләрдән качулар һәм бунтлар, зонага һәр барып кайту куркынычка әйләнде. «Почтальон»ның арадашчылыгы да мул табыш китерми хәзер, зонага эте-бете дә кереп-чыгып йөри ала, кем сиңа хәзер менәр сумны төртсен, мең сумнарның да кадере бетте инч. Элек, үзгәртеп коруларга кадәр прокуратурадагы хезмәт хакы да ярыйсы гына иде, ә хәзер хәтта завод-фабрикалар белән чагыштырганда да эшсезлек өчен түләнә торган ярдәм акчалары кадәр генә. Ә Камалов килгәч, таләпләр бик нык артты, ул үзе дә

тәүлекләр буе эшли, башкалардан да шуны таләп итә. Канзафар, Сенатор белән Миршаб берәр бәлагә китереп терәгәнче, яки кем дә булса прокуратурадагы хыянәтләрен фаш иткәнче, эшеннән китәргә булды. Ә «сиам игезәкләре»нен йомышларын үтәүдән баш тарту һич мөмкин түгел, ул алар кармагында бик нык утыра иде, юкса тегеләр дә аның кулында, ул аларның шундый гөнаһларын белә, шундый гөнаһларын! Әмма аларны үз кулы белән тоттырырга аның кыюлыгы җитмәячәк—әнә бит Парсегянны да КГБ подвалында үтерттеләр! Бу көннәрдә аның башына тагын да куркынычрак уйлар килә башлады, Сенатор белән Миршаб турында бик күп белгәч, «сиам игезәкләре» аның берәр этлеген белеп алсалар, яки шундый хәтәр хәл булудан өрексәләр, аны юк итәчәкләр—бетте-китте. Камалов белән көрәш тәмамланмаган, ана Канзафар кебек шаһитны, әлбәттә бирмәячәкләр. Шушы уй-фикерләреннән коты очкан Рөстәмов тизрәк прокуратурадан таярга кирәк дигән карарга килде. Хәзер ул бит әле үзе өчен тагын бер хәтәр серне белде—Сенатор белән Миршаб Шубаринны Талиб кулы белән үтерергә телиләр. Әйе, прокуратурада эшләгәндә аның дошманнары арта гына барачак. Аның юридик тәҗрибәсе зур, элемтәләре дә җитәрлек, ул рәхәтләнеп берәр хосусый фирмага эшкә урнаша ала, андыйлар хәзер Ташкентта буа буарлык, Сенатор да аны тыныч калдырыр, эш хакы да берничә мәртәбә артыр.

Эш сәгате бетеп килә иде, Канзафарга бик күңелсез булып китте, аның каядыр барып утырасы, бераз эчеп, прокуратурадагы куркыныч эшеннән китәргә карар кылуын билгеләп үтәргә кирәк иде. Жылы як халкына хас Канзафар да хисчән~түземсез иде, күп уйланып тормыйча, ул Татьяна Шиловага шылтыратып, аны эштән соң ресторанга барырга чакырды.

—«Лидо»гамы?—дип шатланып сорады Шилова. Бүген иртән Камалов аңа җаваплы көннәр җиткәнен әйтте. Канзафар белән якыннанрак аралашырга киңәш бирде.

—Минем дә «Лидо»да күптән булганым юк. Анда бүдәнәләр эченә яна суелган сарык бавыры тутырып, шундый итеп пешерәләр—телеңне йотарсың!—дип Рөстәмов та кабынып китте.—Хәл иттек алайса, «Лидо»га барабыз. Мин хәзер үк Икрам Мәхмүтовичка шылтыратып безгә өстәл калдыруын үтенермен, анда алдан язылып куймасаң, кич белән үтүе бик кыен, бүдәнәләр турында да сөйләшермен.

Телефон трубкасын куйгач, ул сәгатенә күз төшереп алды. Эш бетәргә әле тагын бер сәгать бар иде. Ул язу өстәле тартмаларында һәм шкафта казына башлады, бер унбиш минуттан үзенең кәгазьләр сайлавыннан, әйтерсең, ничә еллар эшләгән прокуратурадан иртәгә үк китеп барырга җыенганын абайлап алды. Аның кәефе күтәрелеп китте, сайлап алган кәгазьләренең ягылырга тиешлеләрен бер почмакка ташлый барды. Ул шундый мавыкты, хәтта вакытны да онытты. Аны эшеннән көтмәгәндә телефон шылтыравы гына аерды, Талиб шылтырата икән, элек ул беркайчан да прокуратурага шылтыратмый иде.

—Синең эштә булуың бик әйбәт әле,—диде Талиб.—Безнең хәл-вакыйгалар яңа юнәлеш алды. Японец хәзер минем кулда. Синең дусларыңның шикләнүләре нигезле булып чыкты. Әмма без бөтен җаваплылыкны үз өстебезгә алырга теләмибез, Японец артында бик җитди кешеләр тора, безгә бергәләп көрәшергә кирәк. Сенатор белән Миршабны тап та әйт: караңгы төшкәч, алар минем янга килсеннәр, тик эшчеләр шәһәрчегенә түгел, ә Келескә, мин анда йорт төзедем. Адресны язып ал: Көнчыгыш урамы, 13 йорт. Буталып-адашып йөрсәләр, чәйханәгә керсеннәр, ул төн уртасына кадәр эшли, анда Талиб йортына ничек барырга кирәклеген өйрәтеп җибәрерләр. Вакытны анык кына билгеләмим, ләкин син аларны, йоклаган булсалар да, торгыз, миңа алып кил.

—Ни өчен мин китерергә тиеш әле?!—дип кычкырып җибәрде Канзафар, ул бик куркып калган иде.

—Тынычлан, мин ялгыш әйттем, син минем сүземне генә тапшыр, алар үзләре йөгереп килеп җитәрләр. Бу алар өчен дә кирәк,—сүз шунда өзелде.

«Әгәр дә телефонны тыңлап торган булсалар?»—дип куркынып уйланды Канзафар. Сейфыннан сөйләшүләрне тыңлый торган япон аппараты «Сони»ны алды, аны алып кайтып китәргә кирәк иде—ул бит хәзер прокуратурада эшләми, беркемне дә яшерен тыңлап торырга да җыенмый. «Сиам игезәкләре» белән аны соңгы жеп булып Талибның Келескә килергә чакыруы гына бәйләп тора. Инде торып, аска төшәргә, машинасын кабызырга кирәк иде, әмма ул ашыкмады, аның Келескә барасы килми иде. Сенаторга шылтыратты—анысы өйдә юк икән, Миршабның номерын җыйды—ул Юстиция министрлыгына киткән булып чыкты, бүген кайтмас та, диделәр.

«Ярар, «Лидо»дан шылтыратырмын әле»,—диде Канзафар, Келеснең адресы язылган кәгазьне алып, аска йөгереп төште. Татьяна аны машина янында көтеп тора иде инде.

Ярты сәгатьтән «Лидо»га барып җиткәч, Икрам Мәхмүтович кисәтеп куйган метрдотель аларны залның аргы башындагы ике кешелек өстәлгә үткәрде—бүген кабиналарның зурысы да, кечкенәсе дә, хәтта банкетныкы да буш түгел икән. «Ни өчен алай?»—дип уйлады Канзафар, үзе үк җавабын да тапты: «җомга бит, зур шәһәрләрдә ин типтерә торган көн».

Көн уртасындагы кәефсезлеге һаман борчып тора иде, шуңа күрә тост арты тост әйтеп, эчеп кенә утырды. Татьяна аны тыймады, Рөстәмовны нәрсәдер борчыганын сизенде, ләкин әле аек чагында сорашырга базмады. Озак көттереп кенә бүдәнәләрне китергәч, Канзафар тост урынына кинәт кенә әйтеп куйды:

—Татьяна, мин прокуратурадан китәргә булдым.

—Ни өчен?—дип сорады Шилова, артык кызыксынмыйча гына.

—Арыдым. Буталып беттем. Алдашып яшәүдән туйдым. Аннары, ул хәзер эшмени инде! Син бит республика прокуратурасында эшләүнең ни-нәрсә икәнлеген белмисең!—диде кабынып Канзафар, кулын өметсез генә селкеп куйды да, авызына тулы рюмка коньякны каплады.

—Син әйбәтләбрәк уйла әле, бәлки бер рәте чыгар,—диде Татьяна, хатын-кызларча аның хәленә кереп.—Мондый эшләр кайнар баштан эшләнмиләр...

Шунда алар янына официант килеп, өстәлгә ике шешә француз шампаны утыртты.

—Нигә соң син боларны башта ук китермәдең?—дип ачулы гына әйтеп куйды Рөстәмов.

—Бу сезгә бүләк. Дусларыгыз китерергә кушты, алар бер сәгать элегрәк килеп кергән иделәр, бик каты типтерәләр. Алар, биредәге мәйдан аша гына булган валюта кибетенә шылтыраттылар, шуннан өч тартма шампан китерделәр.

—Мин залда ни өчендер танышларымны күрмәдем,—дип гаҗәпләнде Канзафар.

—Алар зур банкет залында утыралар, ә Сухроб Әхмәтович шылтыратырга дип чыккан иде, сезне күрде. Бу шампаннар анардан сезгә бүләк.

—Ул кем белән шулай типтерә, кем шулай валюталарын уңга-сулга сибә?

—Хан Акмал үзенең эшкә кайтуын бәйрәм итә. Анда аның өчен түләргә килүчеләр күп, сез аларны беләсез инде, ә Сухроб Әхмәтович белән Сәлим Хәсәнович, минемчә, кунак итеп чакырылганнар.

—Ул да биредәмени?—дип көлеп җибәрде исергән Канзафар.—Ә мина аны Минюстта киңәшмәдә, дигәннәр иде. Сухробка рәхмәт әйт, минем белән очрашмыйча китеп бармасын, сөйләшәсе җитди эш бар. Юкса, ул инглизләрчә

сиздермичә генә чыгып сызарга оста, бигрәк тә түләргә кирәк булганда.

Залда музыка уйнап җибәрде, түземсезрәкләр, урыннарыннан кузгалып, биергә ашыкты. Ресторан кызып китте—өлкән метрдотель Икрам Мәхмүтович шулай әйтергә ярата, ул халыкның кәефен яхшы аңлый.

Канзафар икенче шешәне ачарга җыенды, әмма Татьяна, аны туктатып, әйдә, биеп киләбез, диде. Ул Рөстәмовның тиз исерә барганын күрде, аннары аның хан Акмалның төрмәдән кайтуын кем шулай бәйрәм төсендә юмарт оештырганын да күрәсе килә, зур банкет залы нәкъ эстрада сәхнәсе янында иде. Оркестр туктап тормыйча диярлек уйнап тора, рәттән өч биюгә чыгып, Татьяна банкет залына кереп-чыгып йөргән кайбер абруй-дәрәҗәле затларны күрергә дә өлгерде. Алар арасында Югары судтан, Юстиция министрлыгыннан, республиканың Министрлар Советыннан да шактый кеше бар иде. Алар турында прокурор Камаловка житкерергә кирәк, хан Акмал хәзерге хакимият әһелләреннән кемнәргә таяна икәнен прокурор белергә тиеш, әлбәттә.

Шилова легендар хан Акмал турында күп ишеткән иде, аны якыннан күрү дә кызык тоелды: хан бит мактаулы КГБны да, акыллы тикшерүчеләре булган көчле СССР прокуратурасын да ярык тагаракка утыртып калдырган, ниндидер кибет мөдирләреннән миллионнарны каерып алганда да казнага бер сум да кайтармаган! Ләкин кызның эше уңмады, хан Акмал биюләр белән дә, биючеләр белән дә кызыксынмады, үзенең мактаулы-дәрәҗәле урыныннан кич буе кузгалмады, бай табын янында үзе турында, кыюлыгы-акыллылыгы турында тост арты тост әйтеп торучыларны тыңлап утыру татлы-рәхәт иде аңа. Нинди тукталып тору ди ул, аны бит гади кешеләр генә данламый иде.

Биюдән туктап, яшьләр өстәл янына килделәр һәм француз шампанын ачтылар. Татьяна бик тә биисе килгән кыланды, аның хан Акмал кунакларын күбрәк күзәтәсе дә килде. Беренче шешәне бушатып бетергәндә, Татьяна артында ягымлы гына тавыш ишетелде:

—Йә, шампан әйбәтме?

—Рәхмәт, Сухроб Әхмәтович, бик әйбәт!—дип кабаланып, күз алдында айный төшеп җавап бирде сикереп торган Канзафар.

—Сезгә комачауларга теләмим, шулай да матур кичә хөрмәтенә берәр бокал шампан эчәрмен,—диде Сенатор, официант үзенә этәргән урындыкка утыра-утыра.

Сухроб Әхмәтович, хуҗаларча ышанычлы итеп, өстәлдәге икенче шешәне кулына алды. Ул шешә бөкесенең сынып төшкән тимерчыбыгын пычак белән алып азапланганда, Татьяна, өстәл астына иелеп, биегәндә җыерылган оегын төзәтеп маташты, Канзафар Сенаторга акрын гына үзбәкчәләп әйтте:

—Сухроб әкә, минем мөһим хәбәрем бар. Талиб шылтыраткан иде, Японец аның кулында икән, сезнең ниндидер шикләнүләрегез расланган. Ул сезнең төнлә үзенә килүен үтенә, менә адресы...—ул үзендәге язуны ашыгыч кына Сенаторның кесәсенә тыкты.

—Ялгыз калгач та әйткән булыр идең,—диде, шулай ук үзбәкчәләп, ризасыз гына Сухроб Әхмәтович, шунда ук шатланып русча өстәде:

—Бирегез әле бокалларыгызны!

Аларның сөйләшүен тыңлап торган Татьяна «гафу итегез» диде дә, Сенаторга яраклашып, куаныч белән:

—Чын шампан шәрабен эчү нинди рәхәт!—диде.

Сенатор китүгә, Татьяна сүзне Сухроб Әхмәтович турында сөйләшүгә күчерергә тырышты:

—Нинди ягымлы, акыллы кеше бу Сухроб Әкрәмхуҗаев! Без үзгәртеп кору елларында институтта аның атаклы мәкаләләрен мавыгып укый идек. Мин сезнең шундый дусларыгыз булуга бик шат, ул бит теләсә кемгә шундый

бүләкләр бирмидер.—Бераз тынып торгач, Татьяна өстәп куйды:
—Ә бәлки, прокуратурадан китү-китмәвегез турында аның белән киңәшү кирәктер?
Ләкин Канзафар кинәт кистереп әйтте:
—Әйе, һәркемгә бүләкләр бирмидер, мин бит аны күптәннән беләм, ләкин аның белән киңәшеп тормам, безнең юлларыбыз төрле,—диде.
—Ни өчен төрле? Ул—юрист, син дә—юрист,—дип кыз Канзафарны янадан сүзгә тартырга теләде.
Ләкин Канзафар кинәт кенә аекларча елмаеп:
—Әйдә биибез, син сораган идең бит. Ә житди сөйләшүне башка вакытка калдырып торыйк. Ә Сенатор, белеп тор, бик еракка карап эш йөртә. Без аның өчен гади пешкалар гына, коммунистлар теле белән әйтсәк—винтиклар...
Банкет залы алдындагы бию мәйданчыгында мәхшәр иде, чынлап та халык «пешеп житкән», котырынып-котырынып бии. Хан Акмал бәйрәм итә торган залның биек ишеге гел ачылып-ябылып торса да, Татьяна биючеләр аша бернәрсә дә күрә алмады һәм биюнең дә кызыгын тапмады. Үз урынына барып утыргач, аны бая ишеткән сөйләшү өтеп алгандай булды: «Бүген төнлә килегез, Талиб сезнең Японецтан шикләнүегез дөрес булып чыкты, ди.»—диделәр бит. Урамда жәйге төн куерып килә иде, үзе ишеткән сүзләрне иртәгәгә калдырмыйча бүген үк прокурор Камаловка житкерергә кирәк иде.
Ул урыныннан торды да, уңайсызланып кына Канзафарга:
—Миңа тиз генә чыгып керергә кирәк...—диде.
—Кая?—дип кырыс кына сорады Рөстәмов. Татьяна ягымлы елмаеп әйтте:
—Мин бүген шампанны күбрәк эчкәнмен...
Канзафар, ниһаять, аңлап алды, көлемсерәп кенә кул селтәде: янәсе, бар инде.
Эштән китәр алдыннан Таня өенә шылтыратты, әнисенә соңга калып кайтачагын әйтмәкче иде, әнисе өйдә юк булып чыкты. Кыз ана рестораннан гына шылтыратырга булды. Шуңа күрә ресторанның икенче катына Канзафар белән күтәрелгәндә күзләре белән телефон-автоматны эзләде, әмма бер кайда да күрмәде.
Хәзер телефоннар тоту кыйммәткә төшә, шунлыктан күп кенә жирләрдә артык чыгымнардан котылырга тырышалар. Ләкин «Лидо» кебек ресторанда телефон булырга тиеш иде. Беренче каттан подносына коктейльләр тезгән официант күтәрелеп килә иде, Татьяна анардан сорады.
Официант сүзчән кеше икән:
—Элек ике телефон аста, икесе бирелдә тора иде, хәзер берне генә калдырдылар, аны еш килеп йөрүчеләр генә белә. Теге башка барыгыз да, колонналар артында директорның кабул итү бүлмәсен күрерсез, шуннан өч метрлар арырак стенага имән такта белән тышланган телефон кабинасы булыр, шуңа күрә ул күренми дә,—дип тәфсилләп аңлатты.
Официантка рәхмәт әйтеп, Татьяна ул күрсәткән якка атлады, кешесез коридорның паркет идәнендә аның туфли үкчәләре яңгырап ишетелде.
Директорның кабул итү бүлмәсендә бу вакытта Сенатор бар иде. Ул, рәсми телефоннан өенә шылтыратып: «Бүген кичке ашка көтмәгез, соң гына кайтырмын»,—дип, бүлмәдән чыгарга жыенганда, шык-шык атлап килгән туфли тавышларын ишетте, кемдер бик ашыга иде булса кирәк. Сенатор, әллә Нәргиз килгәнме, дип, ишекне ачып карады. Колонналар артыннан Канзафар чамалап йөргән кыз күренде, кызның йөзе борчулы, ул нәкъ Сенатор ягына таба атлый, телефонга ашыгуы сизелеп тора иде. Канзафар Рөстәмов күренмәде.
Сенаторның кызыксынуы көчле иде: кемгә шылтырата кызыкай? Ни өчен шылтырата? Ул, ишекне әкрен генә ябып, кабул итү бүлмәсенең бер почма-

гындагы киемнәр шкафы артына ашыкты. Шуннан телефонда сөйләшүчеләрне дә тыңлап торып була, аны ресторанның баш администраторы Икрам Мәхмүтович, сөяркәләренең нәрсә сөйләшкәннәрен тыңлар өчен куйдырткан икән. Әле ярты гына сәгать үзе белән шампан эчеп утырган кыз тиз-тиз генә телефоннан шылтыратырга тотынды, телефон трубкасында ирләр тавышы ишетелде:

—Тыңлыйм сезне.

—Мин оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлегендә эшләүче Татьяна Шилова,—диде кыз.—Мине Хөршид Азизович белән тоташтырыгыз әле, зинһар.

—Булдыра алмыйм. Аңарда хәзер КГБ генералы Саматов утыра.

—Барыбер әйтегез, ашыгыч хәбәрем бар, сүз Японец турында бара. Иртәгә соң булуы мөмкин.

—Ярар, барып карыйм әле,—диде прокуратура кешесе, аның трубканы куеп, чыгып киткәне ишетелде.

Сенатор кызның нәрсә хәбәр итәргә җыенганын аңлап алды, Камалов: «Тыңлыйм сезне»,—диюгә, телефонның нечкә чыбыкларын аерып та куйды.

Татьяна юкка гына әле тагын бер биш минут чамасы прокуратурага шылтыратып торды, элемтә өзелгән иде инде...

## XXXIII

Прокурор Камалов, трубканы куйгач, ниндидер хәвеф барын сизенеп, ярдәмчесеннән сорады:

—Ул ни өчен шылтыратканын әйтмәдеме?

—Ниндидер Японец турында, диде. Хәзер үк сезнең белән тоташтыруны сорады, иртәгә соң булуы бар, диде...

Әле прокурор бүлмәсендә утырган генерал Саматов сүзгә кушылды:

—Бәлки, тегеләр берәр нәрсә белгәннәрдер? Стрельцов ниндидер кешеләрнең Шубаринны яшерен камера белән төшереп торулары турында әйткән иде.—Бераз тынып торгач, зарланып өстәде:—И безнең бу ярлылык... Техник артта калуыбыз... Прокуратурадагы барлык телефоннарның да җайланмалары булса, без хәзер үк Шиловагызның Японец турында кайдан шылтыратканын белер идек.

Аннары, уйланып алды да, махсус элемтә «вертушка»сы аша эшенә—Ленинградская урамына шылтыратты.

Тегендә трубканы алуга, ул:

—Якындагы кырык сигез сәгатькә прокурор Камаловның барлык телефоннарын тыңлап торыгыз: эшендә, машинасында, өендә. Кайсы номердан шылтыратуларын гына белеп калмагыз, адресларын да ачыклагыз,—дип боерды.

Һәммәсен дә үзенә хәбәр итеп торуны үтенеп, генерал китеп барды. Камалов әле тагын берәр сәгать утырды, Татьяна каян булса да шылтыратмасмы әле, дип өметләнде, ләкин телефон шылтырамады. Камалов, үз телефонына ярдәмчесен күз-колакка калдырып, күрше бүлмәдән Шубаринның эшенә шылтыратты, аннары машинасына—җавап бирүче булмады. Өенә дә әбәттән соң шылтыратмаган икән.

Аңа Шубаринның гына түгел, Татьянаның да югалуы көн кебек ачык иде. Әгәр каян булса да шылтыратсалар, үзенә шунда ук хәбәр итәргә кушып, прокурор өенә кайтып китте. Дарханга килеп җитәрәк ул шоферына әйтте:

—Нортухта, сизенәм: төнебез йокысыз узар, машинаңны ишек төбенә үк куй, мөмкин булса, бергәләп тамак ялгап алырбыз. Артур Александровичмы, Татьянамы, Костамы шылтыратмый калмас—көтәрбез. Бәлки, Саматов кеше-

ләре шылтыратыр. Ул инде барлык хезмәткәрләрен дә аякка бастыргандыр,— диде.

Алар ашарга әзерләп тә өлгермәделәр, телефон шылтырады. Камалов янып торган газ плитәсе яныннан тәрәзә төбендәге телефонга ташланды. Трубкада кемнеңдер авыр сулаганы, сүзләре аңлашылмаслык тавыш ишетелде. Прокурор башта, берәр исерек номерын буташтыргандыр, дип уйлап, трубканы куймакчы булды, аннары аның зиһене яктырып китте, ул кычкырып җибәрде:

—Артур, сөйлә, сөйлә, мин сине ишетәм...

Ана трубкадан зәгыйфь тавыш кына җавап бирде: «мин... мин...»

Прокурор сиземләп кенә Артурның исемен әйткән иде, хәзер исә Шубарин тавышын бераз абайлап та алды. Күрәсең, Шубаринның сөйләшерлек хәле юк яки аңа сөйләргә бирмиләр иде. Бары тик авыр сулышы гына ишетелә.

Камалов янадан кычкырып:

—Артур, түз, егерме минутлардан килеп җитәрмен, трубканы ташлама, аңладым... аңладым...,—диде.

Үзен ишеттеләр кебек тоелды, трубка тынып калды, ниндидер тавыш ишетелгәндәй булды, шылтыратучы егылды булса кирәк.

Прокурор икенче бүлмәгә ташланды, андагы телефоннан Ленинград урамына шылтыратты, ул сораганчы ук кизү офицер тезә башлады:

—Иптәш Камалов, бу теге телефон-автоматлы ташландык йорт Луначарский шоссесындагы йорт, аннан Шубаринга берничә мәртәбә шылтыраткан иделәр...

Ләкин Камалов трубканы куеп өлгергән иде инде.

—Тиз генә—түбәнгә! Машинаңны кабыз!—дип боерды ул Нортухтага, аннары сервантыннан ашыгып пистолетын алды, киемнәр шкафыннан автомат тартып чыгарды, автомат аңа Коканд-Ленинабад юлында һөҗүм ясалган көннән калган иде. Ул тиз генә Нортухта артыннан йөгерде.

Милиция сиренасын бар көченә куеп, «Волга» Кибрай ягына юнәлде. Бер егерме минуттан, сиренасын һәм утларын сүндергән машина полковник Жураев күптән күзәтү оештырган йорт янына килеп туктады. Шубарин Италиягә китеп баргач, бирегә беркем дә килеп йөрмәгән, яшерен телефоннан да беркем дә файдаланмаган. Бүген, күрәсең, Жураев сизгерлегән җуя төшкәндер, йортны күзәтүен дә туктаткан. Ишегалдын караганнан соң, йорт янына килделәр. Тып-тын. Ишек бик таза карагай такталарыннан икән, асылма йозагы да бар. Житмәсә, ишек тышка ачыла торган, аны тавышланып озак ватасы булыр иде. Кулына автомат тоткан Нортухта күзе белән генә тәрәзәгә ымлады, шуны бәреп төшерергә булдылар. Жылы якларда тәрәзәләр бер генә катлы, приклад белән бер сугуда ул килеп тә төште. Камалов белән Нортухта эчкә чумдылар. Беренче булып килеп кергән шофер утны кабызды. Чүп-чар тулы иркен генә бүлмәнең җыештырылмаган өстәле өстендә буш шешәләр утыра, беркем дә юк, күрше бүлмәдән ыңгырашкан тавыш ишетелгәч, шунда ташландылар.

Илленче еллардагы унбиш тиенлекләрне хәтерли торган иске телефон-автомат кыршылып беткән язу өстәле янына беркетелгән, утырып сөйләшергә һәм язып барырга җайлы булсын диптер инде. Шунда ук канга баткан, ялангач диярлек Шубарин ята иде. Җәзалаулар аны танымаслык иткән. Камалов бер ыргылуда аның янына килде, канга буялуына да игътибар итмәстән, Шубаринның башын тезләренә салды, аны аңына китерергә тырышты.

—Артур, мин биредә... Артур, ач күзеңне, мин синең янында. Камалов...

Нортухта ватык тәрәзә аша тышка атылды һәм автомобиль аптечкасыннан нашатырь спирты алып керде. Камалов трубкасы асылынып торган телефонга ишарәләде:

—Тиз генә ашыгыч ярдәм машинасын чакыр, реанимациянекен дә.

Саматовка шылтырат—КГБ госпиталендә палата әзерләсеннәр, консилиум җыйсыннар, ярты сәгатьтән шунда булырбыз,—диде.

Күрәсең, нашатырь спирты ярдәм иткәндер, аларның сөйләшүен ишетепме, Шубарин кан савып шешенгән күзләрен ачып пышылдады:

—Рәхмәт, сез һәрвакыт килеп өлгерәсез...

Камалов Шубарин аңында чагында нәрсәләрнедер белеп калырга, эшне кызу тотарга кирәклеген аңлый иде, ул нашатырьлы мамыкны яңадан тоткынның йөзенә якын китерде:

—Без кайда сынаттык? Ни өчен?—дип сорады.

—Сынатмадыгыз. Сенатор аэропортта Стрельцовны күргән,—дип, авырлык белән генә Шубарин бәреп сындырылган тешләрен төкерде.

—Алар нәрсә белергә тели иде соң?

—Ни өчен Стрельцов минем арттан ияргән? Мине сезнең белән һәм Саматов белән нәрсәләр бәйли? Тагын Әнвәр Абидович ни өчен Италиягә барып чыккан?

—Белделәрме соң?

—Юк, күрәсез бит,—дип авыр сулыш алды Шубарин.—Мин, бәлки, КГБ мине күзәтәдер, ә Стрельцов дигән кешене белмим, дидем. Әнвәр Абидовичны үз акчасына Миланга ялга җибәрдем, дидем. Сез аны тиз генә берәр җиргә күчерегез, алар аны эләктерсәләр, ул җәзалауларга түзә алмас... Ә партия акчалары белән эшне әйләндерербез әле...

Үлем белән тартышып ятканда да ул үзенең яклаучысы һәм бурычы турында уйлый бит әле. Дулкынланудан Камаловның күзенә яшьләр килде.

—Нинди акчалар, Артур, тынычлан. Ә Тилләхуҗаевка без бүген үк тотынырбыз, вәгъдәм—иман. Түз, хәзер «ашыгыч ярдәм» килеп җитәр...

Шубарин янадан аңын җуеп барганда нәрсәдер әйтергә тели иде, ахрысы. Камалов нашатырьлы мамыкны аңа янә иснәтте. Шубарин сискәнеп китте, сынган кулы белән аргы почмакка таба изәгәндәй итте.

—Анда берәр сәгать элек бер кызны китерделәр, аны керткән чакта мин аңыма килдем, баш очымдагы телефонны күрдем.

Прокурор Артур Александровичның баш астына сак кына пинжәген кыстырды да әкрен генә ул ишарәләгән почмакка юнәлде. Кызның кем икәнлеген чамалаган иде инде ул. Пычрак җәймәне ачып ташлагач, чалкан яткан Таня Шилованы күрде. Кыз үле иде. Шубарин турында да онытып, Камалов кызның чибәр яшь йөзенә текәлде. Таня: «ни өчен?»—дигән сыман катып калган иде. Кинәт йодрыкларын төйнәп, прокурор илереп кычкырып җибәрде:

—Кабәхәтләр, каһәр суккан убырлар, мин сезне үзем хөкем итәчәкмен!

## XXXIV

Реанимация машинасы белән КГБ госпиталенең «ашыгыч ярдәм» машинасы бер үк вакытта диярлек килеп җиттеләр. Нортухта кечкенә лом белән ишектәге йозакны каерып алды, Камалов башта табиблар белән бергәләп Шубаринны алып чыкты, аннары үзе генә Татьянаны күтәреп чыкты. Машиналар кузгалып китүгә, Нортухта катып басып торган прокурордан сорады:

—Хөршид әкә, сезне хәзер кая илтим? Саматов, кереп чыксын яки шылтыратсын, дигән иде. Әллә башта госпитальгә барып, Артур Александровичны тәгаен генә урнаштырыйкмы?

—Татьяна алдында ант биргәнемне ишетмәдеңмени?—дип аңлаешсызрак әйтеп куйды Камалов, аннары:—Минем күршемә алып бар,—диде.

—Нинди күршең?—дип шикләнебрәк сорады Нортухта.

Камалов аның ни өчен шикләнгәнлеген аңлады, ачыклап әйтте:

—Канзафарга. Ул миннән бер йорт аша гына яши. Ул кабәхәт Артурны ничек алдап каптырганнарын, бәлки, беләдер. Татьяна турында да нәрсәдер әйтергә мөмкин, кыз бит үлеменә бер сәгать кала гына миңа ашыгыч рәвештә нәрсәдер хәбәр итәргә теләгән.

Матур гына итеп салынган кооператив йорт янына килеп житкәч, Нортухта күтәрелеп икенче кат тәрәзәләренә карады да: «Өйдә»,—диде. Ул Канзафарны эшеннән алып кайткалап йөргән иде. Бергә күтәрелеп, ишек кыңгыравына бастылар. Эчтән: «Кем?» дип сорауга Нортухта ваемсыз гына: «Без әле»,—дип жавап бирде. Ишек ачылып китте. Шоферы артыннан прокурорның да кереп килгәнен күргәч, Канзафар бүлмәсенә атылмакчы булды. Ләкин Нортухта бер сикерүдә аны бәреп екты.

Камалов ярсып, Рөстәмовны якасыннан эләктереп алды, ачуын баса алмыйча:

—Кабәхәт! Синең хыянәтең аркасында бүген кеше үтерделәр. Мин синең кебек убырларны үзем хөкем итәм дип ант бирдем. Әмма әүвәл син берничә соравыма жавап бирерсең. Шубаринны кем урлады?—дип сорады.

—Талиб,—диде Канзафар, ике дә уйлап тормыйча.

—Ә Шилованы кем үтерде?

—Ничек «үтерде»?—Канзафар куркуыннан агарып каткан иде.—Без бит «Лидо» ресторанында бергә ашаган идек, мин аның белән күптән түгел генә саубуллаштым.—Рөстәмов куырылып калды, прокурор кызны үтерүдә бу юньсезнең катнашы юклыгын аңлады.

—«Лидо»да дисеңме? Анда тагын кемнәр бар иде?—дип кистереп сорады Камалов.

—Сенатор. Миршаб.

—Алар әле дә шундамы?

—Юктыр. Хәзер алар Талибтадыр дип уйлыйм. Аның шәһәрдән читтәге йортында төнлә зур сөйләшү булачак, Японецны нишләтергә икәнен хәл кылачаклар.

—Адресы?

—Хәтерләмим. Адресны мин ресторанда Сенаторга бирдем, әмма Келестә булачагын төгәл беләм. Талиб миңа телефоннан әйтте: әгәр минем йортымны таба алмасалар, чәйханәгә кереп сорасыннар, анда теләсә кем әйтеп бирер, диде.

Камалов шоферы белән карашып алды да, йорт хужасына боерды:

—Син безнең белән барырсың.

—Юк, Келескә генә булмасын!—дип ялварды Канзафар.

—Ә без сине анда алып барырга жыенмыйбыз да,—дип аны тупас кына кисеп куйды Камалов.

Ул ишеккә юнәлде, Нортухта аның артыннан Рөстәмовны төрткәләп алып китте. Машина янына килеп житкәч, Камалов:

—Моны Саматовка илт, ул бит бездән хәбәр көтә, ә мин кайтып китәм, бүгенгә житәрдер. Иртәгә Талибын да, Сенаторын да, Миршабын да алырга тырышырбыз,—диде. Нортухтага кул биреп, озак кына аның кулын ычкындырмыйча торды, нәрсәдер әйтергә теләде шикелле, әмма кинәт кенә аны кочаклап:

—Хуш, әйбәт егет син, Нортухта...—диде.

Машина кабинасыннан автоматын алып, яшеренми-нитми генә, караңгы ишегалды аша кайтып китте...

Күңеле нечкәргән шофер аның артыннан озак карап торды, аннары гына машинасын кузгатты, арткы утыргычта бөкшәеп Канзафар утыра иде.

...Кайткач, прокурор душта коенып чыкты, озын көннең пычрагын юып төшергәндәй булды, кырынды, чиста күлмәк белән спорт костюмын киде.

Тиз генә 062 номерын җыеп, такси чакыртты: «хәзер үк» дип адресын әйтте. Киемнәр шкафыннан Фирганә вакыйгаларыннан калган бронежилетын, автоматына өстәмә патроннар алды. Барысын да Вашингтоннан кайтканнан бирле тотып та карамаган зур теннис сумкасына тутырды. Пистолетын бил каешына кыстырып, курткасының «молния»сен күтәрде. Утны сүндереп, аска төште. Машина ишек төбендә көтеп тора иде инде. Таксистка ул үзбәкләрнең биш меңлек акчасын сузды да:

—Келескә, чәйханә янына,—дип адрес әйтте. Әмир Тимур урамына чыккач:—Мөмкин булса, куа төш әле...—диде.

Чәйханә янына килеп җиткәч, Камалов шоферга үзен көтеп торырга кушып машинадан төште. Якты залда өч ир-ат нард уены уйнап утыра иде, аларның берсе, урыныннан күтәрелде дә, соңлаган кунакны каршы алырга ашыкты. Камалов аны урамда көтеп алды һәм Талиб йортына ничек барырга кирәклеген сорады...

Чәйханәче кунакның рэкитерларның гадәти киеме булган куе зәңгәр «Адидас» костюмын күздән кичергәч, канәгать кенә елмайды:

—Нишләп соңладыгыз? Мин инде бер сәгать элек Талиб йортына зур бер казан пылау илттем,—диде.—Аның бүген кунаклары күп, гел ирләр генә, мөгаен, зур уен булачактыр,—дип, караңгыланып торган иңкүлеккә таба кул изәде. Тау өстендәге кәттә генә ялгыз йортның утлары якты яна иде.

—Әйе, сез хаклы, зур уен. Миңа уныш теләгез...—дип, прокурор чәйханәчегә меңлек акча тоттырды: соңгы шикләнүләре юкка чыксын.

Барып җитәргә бер йөз метрлар чамасы калгач, Камалов машинаны туктатты, шоферга рәхмәт әйтеп, аны җибәрде. «Волга» караңгыга кереп югалгач, тирә-ягына каранды. Бу тирә яңа төзелешләр ягы икән, төзелеп бетмәгән йортларның пыяласыз тәрәзәләре ыржаеп тора, бары тик аңа кирәкле йортта гына утлар яна иде. «Әйе, төзелеш материалларына хәзерге бәяләр белән мондый йортны караклар белән ришвәтчеләр генә төзи ала»,—дип усал уйлап куйды Камалов. Якынрак килгәч, ул Талибның күршеләреннән тирән чокыр белән бүленеп яшәгәнен аңлады, аста су челтери иде. Ул йорт янына сиздермичә генә бару өчен чокырга төште. Шунда сумкасыннан бронежилетын алып, курткасы астыннан киде, автоматын тикшергәч, балкып торган тәрәзәләр ягына таба атлады.

Беренче катның тәрәзәләре караңгы, ә икенче кат гөлт итеп тора, аннан кычкырып сөйләшкән-көлешкән тавышлар ишетелә, күрәсең, әле пылауны ашап бетермәгәннәрдер. Чокырдан прокурор чак кына күтәрелде, этләрне кузгатудан курыкты, бәхетенә, этләр күренмәде. Ул йортны ике мәртәбә әйләнеп карап чыкты, икенче катка кайдан бәреп керергә уңайлырак икәнен чамалады, гранатасы булмаганга үкенде, ул булсамы! Дулкынланудан куллары тирләп чыкты, бераз читкәрәк китеп сигарет кабызды, бәлки, гомерендә соңгы сигаретыдыр, кем белә... Тартып бетергән төпчеген ташлыйм, дигәндә генә йомшак кына фонарь уты арттан аны башыннан аягына кадәр яктыртып алды.

«Хатыным, улым, Татьяна белән Артур Александрович өчен үч алырга тырышып та карамыйча, шулай мәгънәсез үләрменме икәнни?»—дип күңелсез генә уйлап алды прокурор. Артта якынаеп килүче аяк тавышлары ишетелде, әмма, ни гаҗәп, курку хисе юк иде аның. Ул, үзен «безнекедер» дип уйлауларына өмет итеп, билендәге пистолетын капшады. Якынайса, теге бәндәгә терәп атарга мөмкин булыр иде. Сак кына атлаган аяк тавышлары якынайганнан-якыная бара, инде бер өч метрлар гына калгандыр шикелле. Кинәт аның җилкәсенә авыр кул ятты, икенче кул аның уң беләгеннән каты кысып алды, бер хәрәкәт тә ясарга да мөмкинлек калмады. Таныш тавышның пышылдаганы ишетелде:

—Үзең генә булдыра алмассың, прокурор.

—Син биредә нишләп йөрисең?—дип кырыс кына сорады Камалов, карангыда елмаеп торган Нортухтаны танып алып. Үзе маңгаена бәреп чыккан салкын тирләрен сөртте.

—Сез ниятләгән эш белән йөрим,—диде Нортухта һәм аяк астындагы ПТУРСка күрсәтте. ПТУРС—ягъни «противотанковый управляемый реактивный снаряд» (танкка каршы атканда идарә ителүче реактив снаряд) дигән сүз.—Мондый коралны мин Әфганстаннан беләм,—диде шофер тыныч кына.

—Син аны каян алдың?—дип гаҗәпләнде прокурор.

—Чирчиктәге хәрбиләрдән ике әрҗә аракыга алмашып алган идем, болай тиз кирәге чыгар дип уйламадым да.

—Әйе, бу нәмәрсәдән бер ату да җитәрдер. Бир әле мина!—дип боерды Камалов.

Әмма Нортухта коралны җилкәсенә күтәргән иде инде, аңлатып:

—Бу әйбер тәҗрибә һәм осталыкны сорый. Ләкин тегеләргә бер снаряд кына җитмәс, миндә икәү. Берсен турыга төбәп атармын, икенчесен—яннан. Безне Әфганда шулай өйрәткән иделәр,—диде. Ташкентның барлык убырлары бүген Талибка кунакка килгәнгә охшый, ишегалды тулы чит ил маркалы машиналар—үтеп-сүтеп йөрерлек тә түгел...

Нортухтаның атып җибәрергә җыенуын күргәч, Камалов үкенеч беләнрәк:

—Кызганыч, алар моның минем үчем, минем хөкемем икәнен белми дә калачаклар—диде.

—Соң, үзегезгә бу куанычны булдырыгыз, прокурор, берничә «ягымлы» сүз әйтегез аларга. Анда нәрсә дә булса эшләргә өлгермәячәкләр дә. Бүген өстенлек безнең якта, алар оттырдылар.

Камалов, йортка таба бер адым атлап, каты гына кычкырды:

—Әй, Талиб!

Якты тәрәзә уемында фырт мыеклы кеше күренде.

—Сенаторны чакыр!—диде прокурор.—Бер-ике сүз әйтергә телим.

—Минем кунакларыма боерырга, син кем ул чаклы?—дип усалланып караңгылыкка кычкырды Талиб.

Агач күләгәсе астында торган кеше тыныч кына:

—Республика прокуроры Камалов мин,—диде.

Шул чагында йорт хуҗасы белән янәшә Сенаторның таныш гәүдәсе шәйләнде.

—Мин сиңа һәм дусларыңа үлемегез алдыннан ярты минут вакыт бирәм, Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылыгыз,—диде прокурор.

Сенатор, җилкәсенә реактив снаряд җайланмасы терәгән икенче берәүнең күләгәдән чыкканын күргәч, кабаланып сөйли башлады:

—Тукта, прокурор, ашыкма әле. Без сөйләшеп килешә алырбыз. Бирелә ярлы халык җыелмаган...

—Юк, мин сезнең барыгызны да иң югары хөкемгә тартам, аһ-зарларыгызны, шикаятьләрегезне кабул итмим...

—Синең хакың юк!—Бу—законсызлык, бу—самосуд!—дип илерде Талиб.

—Сезнең өчен мин үзем закон, җәза бирүче кул, сез кәпрәеп аны онытқан идегез, һәр нәрсә сатып алына, сатыла дип яшәдегез...

Шунда күрше тәрәзәдән ике тапкыр аткан тавыш ишетелде, пуляләр колак төбеннән сызгырып үттеләр. Прокурор шоферына боерды:

—Тондыр, Нортухта!

—Лә иллаһы иллаллаһы,—дип, Нортухта тәтегә басты.

Шуннан соң йортның аргы почмагына икенче снарядны юллады. Мәһабәт йорт сикереп куйгандай булды, аннары җимерелеп төште, янгын утлары биешә башлады.

—Йөгердек!—диде Нортухта, прокурорны кулыннан алып, аста торган машинага ташланды.

Шәһәргә якынлашып килгәндә яктыра башлаган иде инде. Камалов Салар елгасы ягына борылырга кушты, Нортухта машинасын шәһәр янындагы шәраб эшләүче совхоз җирләре аша агып ятучы елгага таба борды. Иртәнге елга үзенен көчсез су агымын шәһәр ягына куа, ул тирә-юньдәге бар нәрсә кебек әле черем итә шикелле иде. Елга, бәлки, кайчандыр тулы сулы, балыклы булганын, иртәдән кичкә кадәр тирәсендә балалар чыр-чуын, шатлыклы көлү тавышларын матур төшендә күрәдер. Хәзер инде пестицид-гербицидлар белән агуланган, төбе чүплеккә әйләнгән суда бер егерме еллап коенучы юк иде.

Нортухта машинасын зур ябалдашлы тирәк янына китереп туктатуга, Камалов, тирә-яктагы тынлыкны бозарга курыккан кебек, сак кына кабинадан төште. Яр буена килеп, бер зур таш өстендә башын куллары белән тотып, озак, бик озак утырды. Аннары кинәт сикереп торды, машинадан автоматы белән ПТУРСны алып, яр буендагы куе куаклыкка кереп китте. Бераздан Нортухта сунын авыр гына чупылдаганын ишетте.

* * *

...Иртән нәкъ сәгать тугызда Камалов эшенә килде, өстәл өстендәге биш телефон берьюлы шылтырый иде. Ул хөкүмәт телефоны трубкасын күтәрде, Юстиция министры шылтырата икән.

—Сез бүген Келестә нәрсә булганын беләсезме?—дип дулкынланып сөйли башлады министр.—Бандитлар атаклы бизнесмен, берничә эре фирма иясләреннән берсе булган Талиб Солтанов йортын шартлатканнар. Анарда кунакта бик күп абруйлы кешеләр булган: шәһәрнең адвокатлар коллегиясе рәисе Горский, республика Югары судынын рәис урынбасары Сәлим Хәсәнович Хашимов, партия Үзәк Комитетының элекке бүлек мөдире Әкрәмхуҗаев, атаклы юрист...

Министр Талибтагы бик күп атаклы кунакларның фамилияләрен әле бик озак санады, әмма прокурор аны тынламый иде инде. Трубканы читкәрәк этеп, хисчән министрның сөйләп бетергәнен көтте. Ниһаять, бер мизгелгә тынлык урнашкач, прокурор:

—Мәгълүматыгыз өчен рәхмәт,—диде.—Мин сүзләрегезне диктофонга язып алдым. Тикшерү эшләрен башлап җибәрербез...—ул телефон трубкасын аппарат өстенә куйды, элемтә өзелде.

Шылтыратулар туктаусыз дәвам итә иде. Камалов, ярдәмчесен чакыртып, кырт кисте:

—Зинһар, өзегез әле ... телефоннарны...

*Күктубә—Переделкино*

*1992 ел*

**Марс Шабаев** *тәрҗемәсе*



Илдус Гыйләҗев

# МӘҢГЕЛЕК ҖИРСҮ

* * *

Юлда барам. «Авыр сулап»
Тимер атлар йөри кырда.
Урын җәйгән кәләш кебек,
Җир кабартып уза тырма.
Җирсегәнмен. Китәрмен күк
Тырмаларны тагып, сөйрәп.
Кияү егетенеке кебек,
Каударланып тибә йөрәк...

* * *

Мин утыз ел көткән яңгыр ява,
Көн-сәгатен туры китереп.
Уҗым каплап алган кыр-басулар,
Чүпрә кебек, китте күпереп.
Бу кадәрле туры килер икән:
Хәлиткеч чор—майның азагы.
Безнең гомер үтте күккә карап,
Шифалы дым сорап, казганып.
Сиңа кирәк чакта күренми ул,
Үртәп йөри печән чапканда.
Гарык итә еккан игеннәрең
Теземнәрдә череп ятканда.
Бүгенгесен—бик вакытлы чагын—
Гомер буе көтеп яшәдем...
Килде дә бит... мин алгарак киттем,
Утыз елга ничек яшәрим?

## Элек күрешкәнбездер

Берәүләрнең таныш йөз чалымы,
Кемнәрнеңдер таныш күзләре.
Ә тулаем әйтеп бирә алмыйм,
Кайда гына бар соң күргәнем?

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946)—*шагыйрь; «Җир китабы», «Серле мәгарә», «Хак сүз» һ. б. китаплар авторы. Һади Такташ исемендәге премия лауреаты. Азнакай районында яши.*

Хәтер сандыгының һәр почмагын
Кабат-кабат чыгам тикшереп:
Кай урында, ничек очрашканны
Булмый гына искә төшереп.
Бу гомердә, бәлки, түгелдер дә...
Кабатлану охшаш иткәнме?—
Җан бит җиргә кат-кат килә, имеш,
Шул сүзләре дөрес микәнни?

## Бар ул!

«Чын мәхәббәт бармы соң ул җирдә?»—диеп
Очратканым булды сораучыларны.
Ул кешеләр әллә дәртле сөю хисен
Бөтенләй дә юкка санаучылармы?

Кырык елдан артык инде, хыялларым
Барып куна бер кыз тәрәзәсенә.
...И, Ходаем, төшерә лә күрмә берүк
Ахмак сорау бирү дәрәҗәсенә...

## Төп шарт

Ана сөте белән керсә генә
Була аны уятып:
Милли хисләр—хасил булмый ахры
Үгетләп вә оялтып...

## Тәмам азындылар

Сөлек салдык. Әрсезләнеп
Кан юлларын тишәләр.
Шунсы яхшы: эчеп туйгач,
Тәгәрәшеп төшәләр.
Комсызлыкта кайберәүләр
Шул канәчкеч кебекләр...—
Ник китмиләр ил тәненнән
Олигархлар—сөлекләр?!

## Тарихи наданлык

Әгәр сезгә шулай ошый икән,
Ярар, сөйләнеп тик утырыгыз.
«Татар белән монгол бер үк яу,»—дип,
Дәреслекләр язып тутырыгыз.
Әгәр сезгә шулай кирәк икән,
Әйдә, еллар буе кабатлагыз...
Ай, гарьләнеп яшим сезнең өчен:
Ялган белән йөзне каралтмагыз!

## Барыбер яхшырак

Авыл бит ул—авыл инде,
Ни генә сөйләсәң дә:
Каешлансаң, яшәп була—
Сөйсәң дә, сөймәсәң дә...

Урлаганы урлый бирә —
Күрсәң дә, күрмәсәң дә.
Кешегә бит ярап булмый—
Бирсәң дә, бирмәсәң дә.

Сәрхушләре эчә һаман—
Тотсаң да, тотмасаң да.
Яшьләр чыгып китеп бара—
Тыйсаң да, тыймасаң да.
Әжере юк, уртак эшкә
Йөрсәң дә, йөрмәсәң дә.
Басуларны билчән баса —
Сөрсәң дә, сөрмәсәң дә...

Ит-сөт артмый, сыерларны
Көтсәң дә, көтмәсәң дә.
Кадерең юк, алтмыш яшькә
Житсәң дә, житмәсәң дә.
...Төне тыныч, һавасы саф,
Чиста су...—саныйсың да:
«Монда әйбәт әле»,—дисең,
Шәһәргә карыйсың да...

## Тыныч гаскәри

*Моңда—мин маршал...*
Сажидә Сөләйманова

Маршалдырмы,түгелдерме,
Дәрәжәм бик югары:
Зур гаскәри ясап куйды
Мине гомер юллары.
Миллионнан артык «солдат»,
Һәркемнең үз тахтасы.
Тезелешкән агач өйләр,
Гүя шахмат тактасы.
Хезмәттәшләр шундый уңган,
Таңнан эшкә чабалар.

Чит кешеләр уза алмый,
Якын килсәң—чагалар.
Алар җыйган татлы байлык
Минем данны күтәрә.
Погон тагып йөрмәсәк тә,
Устав төгәл үтәлә.
«Бигрәкләр зур чирүе»,—дип,
Алынмасын котлары.
Яуга чыгар исәбем юк:
Гаскәрем—бал кортлары...

## Соңга калганчы

Йолдызларны күзәтебез,
Галәмне капшый фикер.
Аның чиксез икәнлеген
Аңладык, белдек, шөкер.
Кешеләрне өйрәнергә
Кайчан соң житәр чират?
Безнең бит бар белгәнебез—
Туу, яшәү вә зират...
Кешелекнең чиге бармы?
Кемнән сорарга барып?
Шуны эзлик—телескопны
Кешегә, жиргә борып!

## Ышанмас жиреңнән ышанырсың

Әллә чынлап? Безнен аңыбызга
Мәгълүм түгел көчләр эшеме?—
Нигә диптер якын күреп булмый,
Үз италмыйм кайбер кешене.
Бер зыяны гәрчә тигәне юк,
Өзешкән юк, телгә килешеп.
Якын дуслар кебек,чөкердәшеп
Яшисе бит гөрләп, көлешеп.
Булмый гына. Авыр тәэсиреннән
Читкә киткәч кенә бушанам.
«Кара көч бар жирдә»,—дигән сүзнең
Хаклыгына кайчак ышанам.

*Хикәяләр конкурсына*



Камил
КӘРИМОВ

## СУНАР ВАКЫТЫ

Килә...

Күзгә күренеп яз килә!

Язнын үз тизлеге бар. Фасыл манзарасында көн саен бер яналык. Әле кайчан гына шәһәр урамнарындагы карның дегетен чыгарырлык җылы көннәр башланган иде... Инде Жирнең кыштан калган чокыр-чакырлы шадраларын тигез үлән каплады... Каен сулары кипте... Аяк асты такыр... Үтә күренмәле җилләр нигез тузанында ауный да күзгә күренеп-күренеп ала. Авылдан адашып килеп кергән бал кортларын әлсерәтеп тал песиләре бәргәләнә. Майның унбишләрен дә көтмичә, алмагач чәчәкләренә гыйшык кергән. Тирәк очындагы тирән ояларда, якты дөньяга чыгачак чебиләренең тавышын ишетеп, каргалар саташа... Бер ай эчендә, карлы-бозлы искергән кыш сары чәчәкле яна җәйгә әверелеп бара...

Эшем кешесенең кайтыр сукмагына киртә булып чат саен корылган каеш чатырларнын берсе тәки ымсындырды Рифатны. Тәки, дип әйтү бик үк дөрес тә булмас, кулга җинел акча керсә, яз кояшыннан ышыкланып утырган яшьләр арасында бер кәеф-сафа кыласы килгән иде анын. Сыный карагач кына сизде ул—урам ягындагы уенчык өсталләрдә шешәгә тотынып утырган яшьләр уку елын төгәлләп килүче студентларга охшаган, кызык табардай затлырак халык эчтә булса кирәк.

Ике баланы тәмам өлгерткәнче укытып, аерым тормыш корырдай яшькә житкергән арада, Рифат белән Тәлига гаиләсенә «беренче сентябрь», «сонгы звонок», «имтихан» дигән котылгысыз вакыйгалар алып килгән тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр һаман саен ерагая бара. Чыгарылыш кичәләренә чакыручы юк, «укырга кая барырга?» дигән фәлсәфи сораулар борчымый инде аларны. Быел исә, киресенчә, бөтенләй чит кешеләр мәшәкате һич көтмәгән, өмет итмәгән жирдән яшерен сөенеч алып килде әле.

Рифатнын түш кесәсендә яшел катыргысы таушалып, төпләм жепләре өзгәләнеп беткән блокноты бар. Әнә шул куен дәфтәрендәге адресларны, телефоннарны, эш урыннарына карап, теркәлгән кирәкле кешеләрне санасан—элемтәчеләр чыгарган букча калынлыгы сары белешмәләрен бер читтә торсын! Егерме биш ел буе төзелештә эшләп үзеннән-үзе жыелды ул исемнәр. Байлар күбәеп, сыйнфый көрәшләр көчәйгән саен, фатир ремонтлау, өй алмаштыру,

---

Камил КӘРИМОВ (1950) — *прозаик; «Кулагәдә төлке бар», «Үзеңне бел», «Ком сәгате» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

җиһаз янарту кебек мөлкәт ярышлары кискенләшә. Кайбер хуҗаларга Рифат инде икешәр, хәтта өчәр кат хезмәт иткән. Күпләр аны урамда танып эндәшә, йомышың төшсә ярдәм итәргә дә әзер үзләре.

Дусларны көз саныйлар, дигәндәй, ике бүлмәле «хрущевка»ның балконына тәрәзә куйган чакта, хуҗабикә күңелендәге зарын әйтеп салды. Моның бердәнбер кызы унберенче сыйныфка кергән, укып бетергәненә—аттестат алганын көтмичә, бүгеннән үк, ярдәм итәрдәй кешене эзләргә кирәгеме белә, тол хатын хәләл көчен кызганмыйча эшләп ришвәтлек мәхәрен дә туплаган, тик кем кулына илтеп бирәсен генә белми. Ә куен дәфтәрендә нәкъ шундый кирәкле кеше бар, җәйге каникулга чыккан саен, ул Рифатны дәштереп, Салмачыдагы таш пулатына берәр янарыш кертә.

Уку елы дәвамында телефоннан шылтыраткалап хуҗабикә белән кафедра мөдире арасында урталыкта торды Рифат. Кызның белгеләре әйбәт иде, гимназияне медальгә бетерә алмаса да, имтиханнарда югары балл җыярга тора. Алдан килешенгәнчә, Май бәйрәме үтүгә, хуҗабикәдән тиешле суманы алып, Рифат үз куллары белән мөдиргә илтеп бирде. Мөдир, озын конвертны күз алдында ертып, унөч озын меңлекне Рифатка сузды: «налогын сина түлим, киләчәктә шундый клиентларны күбрәк тап!»—дип, аркасыннан сөйде, кире борырлык итмәде, язылмаган законы шулаерак куша икән.

Акчалар озынайган саен почта конвертларының да озынаерга тиешлеген аңлады Рифат.

Абзагыз төзелештә җигелеп үткән гомеркәйләрен үртәп, озын меңлекләрне кызганмыйча, язгы кызлар күз салырлык итеп, текә егетләргә тиң һаваланып, яшьләрчә ял итәргә әзер бүген. Унбиш ел буе дөнья базарында яшәп тә аның әле гел искечә көн күргән мәле. Ә бит хәзер җаның ни тели—шул бар. Бәктың исә, чынбарлыкның муллыгы телевизорларга сыймый: бу базарда сүзлекләргә кергән исем-җисемнәр, фигыль-шөгыльләр, тән вә тәм—бөтенесе дә товар; татулыкны, чибәрлекне, мәхәббәтне, рәхәтне, хәтта яшьлекнен үзен дә сатып алып була.

Хатын-кыз ирләрне кызыктырыр өчен яшәрергә теләсә фитнес клубларга, бассейннарга йөри, ясалма кояшлы ванналарга кереп ята, косметологларга иялләшә. Ә ир кешегә яшәрер өчен... йөз грамм арыш мае житә, дисәләр, ышанмагыз... Рифат акча алган көннәрдә яшәрә. Касса тәрәзәсеннән өенә чаклы араны ул яшьлек хыялларына күмелеп, аккош канатларында талпынып кайта. Хәләл эше китергән кәгазь сөенечләрне хатынының халат кесәсенә салгач, Рифат тагын гадәти хәленә килә... Тик бүгенге меңлекләрнен хәләл кесәгә керергә хакы юк, хәрәм мал—әрәм мал... Әгәр ул хатын кулына бер эләксә—Рифат өчен кәсепкә әвереләчәк.

Әлеге чатыр колачлап алган бер катлы биек йортны вак-вак соры кирпечләрдән күтәргәннәр. Бу тирәдән көн саен диярлек үткәләп йөрсә дә әллә-ни игътибар итмәгән иде Рифат—салым җыючы, ризык сыйфатын тикшерүче оешмалар алдында берәр хәйлә корганнармы—олы ишекләренең урам ягына вак хәрефләр белән генә «Клуб» сүзе язылган икән. Клуб дигәч өрлегеннән купкан ярык идәннәргә тимер урындыклар тезелгән авыл клубы күз алдына килгән иде. Ә монда туй үткәрерлек ресторан залы, челән аяклы күн банкетклар каршысында бар-буфет, чаршаулы бүлмәләр, бильярд залы. Түшәмнән төшкән миләүшә нурлар баганасы клуб эчендәге энгер-меңгерне куерта сыман.

Акчалы халык кояш баеганны көтәме—кичке ыгы-зыгы башланмаган әле. Ике өстәлдән гайрәсе буш. Кеше әз булгач сыйлаучылар да кабаланмый. Альяпкыч итәкле официант меню өләшеп чыкты да кунакларны онытты.

Түрдәрәк ике агайне бизнес-план корып маташадыр ахрысы. Утырган килеш тә буй аермалары күзгә ташлана: озынрак чандыры сорау билгесе кебек бөгелгән—уч төбендәге микрокалькуляторга авторучка төбе белән төртеп санап тора; базык

гәүдәлесе өстәлгә җәелгән кәгазьләрдән сайлаштырып тегенә саннар эзли... Алардан ике өстәлгә читтәрәк өч кыз төпләнгән: өчесе дә урам сәүдәсендә чыныккан, самимилеген югалткан, яшь чактагы портретларын шактый үзгәрткәнгә охшый. Берсе, кесә телефонын иңбашы белән колагына кысып, ике куллап тәмәке кабызды. Тәмәкесен имеп бетергәнче биш-алты тарафка шылтыратып өлгерде. Ул арада иптәш кызлары гел аңа йотлыгып карап утырдылар... Кемнедер, нәрсәнедер эзлиләр бугай болар...

Рифат та эзли, романтик маҗара көтә. Гүя, серле бер чибәркәй белән яңа танышып, күрешергә сүз куешканнар, ә ул һаман килми дә килми. Залда, кунаклары әкрен җыелган мәҗлестәгечә бушлык урнашты. Эшмәкәрләр кеше игътибарын җәлеп итмәстәй соры фонга әверелде. «Тагын бер җаен табып чумара эшләргә дә, Тәлига белән керергә кирәк икән монда»,—дип, нәүмиз күңелен юатырдай чара эзләп, киң чырайлы тәрәзәләрне каплап торган авыр калын пәрдәләр ярыгыннан урам яктылыгына текәлде Рифат. Фонтанны кабызганнар, су чәпердәве тәрәзә аша да күңелне сөендерә. Каргаларның аласы, күгәрченнәрнең агы быелгы чыпчыкларны түгәрәккә кертеп тал песие, бөре сүрүе белән тулган таш чынаяктан ахшам чәе эчәләр. Урман-күлләрдә язгы ау чоры бара, ә боларның сунарчыларга кирәге юк. Меңьяшәр каланың гөрелтесе, асфальт ватучы чүкеч тыкылдаулары, биек коймалар артында җир тетрәтеп субай дөпелдәүләре бу кошлар өчен иң тыныч урын.

Ниһаять, Рифат каршындагы өстәлгә дә кеше килде. Ике кыз—икесендә дә ботның иң юан җирен генә капларлык джинсы итәк, чөй үкчәле кызыл туфлиләре таш идәндә тыпырдап тора, бала чактан бирле тузмый калган кыска сары футболкаларын кигәннәрме—кендекләре анадан-тума килеш. Пардан киенсәләр дә кызларда шактый ук аерма бар: тукылган житендәй толымын баш чүмеченә төенләп куйганын, малайларча кыска китәртелгән җирән чәчлесе этеп-төртеп йөрткәндәй көйли: урын тәкъдим итте, иңбашына эленгән яфрак рәвешле кызыл сумкасыннан дымлы салфетка чыгарып утырасы урыннарны сөртеп алды, өстәл өстен дә сыпыргалады.

Җирән чәчле кызның, кинәт торып, ишек төбендәге банкеткадан бер гәҗит алып килүен Рифат та кабатларга мәҗбүр булды. Курьерлар, хат ташучылар бушлай таратып йөри торган реклама өеме иде бу. Рифат әйләнеп килгәндә тегеләрнең калын гәҗите житен чәчле кыз кулына күчкән иде, ул егерменче битнең аскы өлешенә текәлгән дә рәттән игълан укый. Рифат та шул битне ачты. Бик шәп белә ул бу гәҗитне, бигрәкләр дә «Вакансия» дип язылган төшен... Алай икән, житенчәч эш эзли, димәк. Студент буларак җәйге каникул өченме, әллә төшемлерәк урын сайлавымы? Ашык кызый, ашык! Җәй уртасы житкәч эшсезләр армиясенә конкурслардан үтмәгән абитуриентлар килеп кушылачак.

Нәкъ шушы мизгелдә Рифатка килгән ялган бәйрәм белән житен чәчле кызның күңелсезлеге ике арага күзгә күренмәс күпер корып куйды. Һәм бу күпердән икенче ярга әвәл Рифат чыгарга тиеш.

—Кызлар, исәнмесез?! Ә менә бу игъланны мин бирдем,—диде ул, килә-килешкә үк, туп-туры житенчәчкә текәлеп.

—...Идән җәям, ишекләр уям...—Кызый игъланны кычкырып укый башлаган иде, пышылдауга күчте.—Сез дә эшсезме?

—Бу бер хәйлә генә. Бригадабыз бер объектны бетергәнче, яңасын эзли торабыз. Плотник эшләрен эзләп минем телефонны бирәбез, тимер-томырлар буенча икенчебез. Кирпеч-бетон буенча өченче кешебез җаваплы, кафель җәю, су кертү эшләрен калганнарыбыз эзли. Ә эшне бергәләп башкарабыз.

—Эштән соң «аулга» чыгасызмы?! Фирмачларның акчасы кычыта инде аларның,—дип, усаллашып сүзгә кушылды җирәнчәч тә.

—Юк. Бүген минем сөенечем бар. Бер танышымның кызын институтка кертергә булыштым.

Житен чәчлесе сискәнеп куйгандай итте. Бер иптәшенә, бер Рифатка карап алды:

—Сез утырыгыз, утырыгыз безнен янга!—Һәм ул Рифатны ялган өстендә тотарга теләгәндәй, муенына эленгән телефонын ачып гәжиттәге номерны җыйды.

Рифатның яшел чалбарына кыстырылган кыска җиңле җете ак тенниска кесәсендә «Әпипә» көе яңгырады. Алар, өстәл аркылы күзгә-күз карашып, телефоннан сөйләшә башладылар.

—Але, кем әле бу?

—Минме? Мин—Лилия, дус кызым—Римма. Ә сез кем?

—Аллу, мин ни, Рифат исемле…

Танышу вакыйгасы, күп дигәндә, ике-өч минутка сузылгандыр. Ул арада инде официант кыз да чыгып җитте, сорау алуны эшмәкәрләрдән башлады:

«Ни телисез, әфәнделәр?!»

Рифат бил каешына таянган булып кына, бармак очларын уйнатып чалбар кесәсен капшады—акча урынында! Күңелдә гармун уйный… Күптән, бик күптән чорманда тузан җыеп яткан гармунның каптырмалы путасы шартлап өзелә дә күреге бар кодрәтенә тартыла… Авыл көе яңгырый. Ул, өшегән җанның ин түренә үтеп кереп, йоклаган теләкләрне уята, онытылган әкиятләрне янарта. Гармун сулышында мәҗлес исе: токмачлы аш, өчпочмак, бастырма, казылык, бәлеш … лагман, шаурма, лангет, жульен…

—Безгә өч жульен!

—Тагын?—Кәгазь белән каләм тотып килгән шагыйрәнә официант сабыр кыланды, кабаланмады.—Тагын нинди закуска аласыз? Эчәргә ни китерим?

—Кызлар, җаныгыз ни тели, сорагыз! Бүген минем көн!

—Алайса, җиләк-җимеш салаты, лангет… тозланган форель, әйбәтрәк вино…

—Ике… юк, безгә өч шешә инвестиция!—дип өстәде Рифат.

Бер шешә бушаганчы, Рифат, Лилия, Римма дигән исемнәр кыскарып, Риф, Лиль, Римм булып үзгәрде, «сез»ләр «син» белән алышынды.

Һәр табигать почмагы, һәр мохитнең үзенә генә хас җан асраучы иярләре була, урам ягындагы чатыр тирәсендә «җирле халык»ка әверелгән шешә эзләүчеләр, чүпрәк бала күтәреп килгән кара тутлы, озын, чуар күлмәкле хәер эстәүче түткәйләр, өйдәге бурзайларына сөяк-санак җыючы агайлар залга үтеп керә алмый, ишек төбендә сугышчан киемле әзмәвер тора, ул хөрмәтле вә кыйммәтле кунакларның иминлеген саклый. Риф бүген ышанычлы кулларда, уйнасын гармунын, сайра кызлар алдында, ял итә торган җирдә эшләп утырасыңмы, эш урынында ял итәсеңме—монда сина кемнең дә исе китми.

—Риф, синең тирәдә минем кебекләргә эш бармы?

—Икегезгә дәме?

—Юк. Римм әйбәт урын тапты, ул…—дип дәвам итәргә ирек бирмәде, Римм дустының касыгына терсәген терәде: серне ачма, янәсе. Ләкин Лиль башлаган җөмләсен өзеп өлгерә алмады.—Ул фатирлар белән алыш-биреш фирмасында риэлтор.

—Бик әйбәт. Дуслыгыбыз бәрәкәтле булыр. Без ремонтлаган фатирларның күбесе сату өчен әзерләнә.

Римм, Рифнең соңгы сүзләрен егетләрчә килешүгә авыштырып, кулындагы шәраблы бокалны чәкәштерер өчен өскә күтәрде. Моңарчы Риф белән Лиль арасындагы туры сөйләмне өнәмичә утырган җирән чәчле кыз ачылып китте.

—Сатарга дип әзерләнгән фатирның алучысы да алдан ук билгеледер. Бизнеска исе китмәгән гамьсезләрне табарга кирәк… Әйтик, минә синең фатир ничә бүлмәле?

—Дүрт!—диде Риф, мактануын яшермичә.

—Ә пропискада кемнәр?

Риф, көтелмәгән сораудан каушап, ялган җавап эзләгән малай-шалай эше як-ягына каранды, тел очына килгән җаваптан, әйтелмәгән килеш, оялды. Хатын белән, дисәң, әлеге кызларны бик тиз югалтыр төсле тоелды. Риэлтор моны бик тиз сизеп алды, соравын шундук үзгәртте.

—Ничә кеше дип әйтүем.

—Ә… ә!—Риф сөенеченнән җиңел сулап куйды, елмаеп та өлгерде хәтта.—Икәү.

—Дүрт бүлмәле фатирда ике кеше?! Бу бит—үз-үзеңне талау! Уйлап кына кара: кешегә фатир ни өчен кирәк? Кайтып ашыйсың, телевизор карыйсың и … ятып йоклыйсың… Димәк, кухнясы, ваннасы белән бер бүлмә бик житкән. Калган өч бүлмәне акчага әйләндерәсе…

—Миңа андый акча нәрсәгә?! Шөкер, эшләп торам.

Карале син бу дивана мужикны, дигәндәй, Римм житен чәчлегә мыскыллы караш сирпеп алды.

—Акчаның андые-мондые юк. Машина алырсың.

—Бар ул минем.

—Классикамы?! Синдәй беркатлылар «Жигули»га ябыша. Ә солидный күренәсең килсә «Мерседес», «БМВ», «Ауди»лар бар: көзгедәй елтыр кузовлы, чем кара тәрәзәле, кондиционеры, телевизоры, суыткычы…

—Караватлы!—дип үртәмәкче иде Риф, кыз ирек бирмәде.

—Әйе, алгы урындыкларын җәясең дә диван итәсең. Ул чагында бер бүлмәле фатирың да кирәкми!

—Аны да сатып җибәрәсеңме?

—Сатмыйсың. Метро төзүчеләр гаиләсенә арендага бирәсең.

Соңгы чирек гасыр эчендә ниһаять бер көйгә салынган гаилә тормышында ул кадәр үк кискен борылышлар ясарга әзер түгел иде әле Риф. Шуңа күрәдерме, җирән чәчле кызның табышлы тәкъдимнәренә ризасызлык күрсәтеп, шәрабы эчелеп бетмәгән бокалны үзеннән читкәрәк этеп куйды. Житен чәчлесе моны шундук сизеп алды:

—Вау! Безнең инвесторның кәефе кителде. Риммга исең китмәсен, ул сүз унаена гына иярде. Син бүген миңа кызыктың, әйе бит?!—Һәм ул, Рифнең «әйе!»сен дә көтмичә, үзенекен җөпләде.—Вәт, сөйләш минем белән.

Лиль, шәрабның тәэсиреннән, яңа танышына тәмам ияләшеп җиткән иде, үҗәт сорауларына җавапны күз карашларын төбәп таләп итеп торды. Мондый чакта аның күз зәңгәрлеге бер сыегая, бер куера кебек иде.

—Син миңа репетитор эзләргә булышасыңмы? Юк, репетитор гына түгел—доцент, профессор, йә проректор булсын. Миңа югары белем кирәк. Болай да бер ел вакытымны әрәм иттем, ниндидер аферист арадашчы аркасында. Үз көче белән кергән балаларны минем ярдәм белән керделәр, дип, мактанган. Ә минем ише «проходной балл» жыя алмаганнарның акчасын кире кайтарды, быел педагогларның үз туганнары күп җыелды дигән була.

—Әле дә рәхмәт, акчаңны кире биргән. Бик үк әшәке аферист булмаган икән.

—Акчанымы?! Мин аның кесәсен ерттырып ала идем.

Һәм житен чәчле кыз, үзенең артык кызып киткәнен сизеп, чак кына тынып торды. Шушы тынлыкта сыек зәңгәр күзләре куерды, ачулы йөзе юмагай елмаюга алышынды.

—Әйт, син миңа ярдәм итәрсеңме? Юкмы?!

Яшьлеге, чибәрлеге, ялгызлыгы белән синнән күпкә өстен тәвәккәл һәм көчлерәк житен чәчле бер өмет күзгә карап туры җавап көткәндә: «Әйе!»—дип котылуы жиңелрәк. Көчлеләргә каршы төшеп: «Юк!»—дип әйтә алыр өчен зур көч кирәк. Риф баш иzде.

—Син шигырен өйрәнмәгән мәктәп баласы шикелле ым кагып утырма, әйенне өзеп әйт!

—Әйе.

—Килештек. Бир бишне!—Житен чәч бокалдан бушаган кулын Рифкә сузды.

Кызның кичә генә чәчәк аткан шомырт чугына тин кулын эш бияләедәй учына алгач Риф бер мәлгә өнсез калды. Аннары сизгер жанына күптән онытылган наз, яшьлегеннән бирле тынгы бирмәгән яшерен сусау, мәрткә киткән күбәләкне дә уятырлык жылылык күчә барганын тойды. Бу нәни бармакларның әле үз гомерендә йодрык күрсәткәне юктыр.

—Римм, өз әйдә бәхәсне! Ул мина укырга керергә ярдәм итә. Ә мин бәрхет сезонда ана ияреп дингез буена барам!

—Тагын бер шешә китерсеннәрме?—Рифнең бу соравы саубуллашуга сәбәп булды.

—Бүгенгә житәр. Син безне такси белән кайтарып куясыңдыр ич?

—Ник, сез шушы тирәдән генә түгел мени?—Ул көтелмәгән яналыктан теге реклама гәжитен бөтәрли башлады.

—Оя янында кем шаяра инде?..

Такси чакырту, йә кул күтәреп юл читенә чыгуның кирәге юк, мондый хезмәт күптән көйгә салынган, чатыр читендәге фонтанлы мәйданчыкка жыелган музыкалы машиналарның көндәлек эше икән ул.

Шунысы хак, кызлар Риф белән төн уртасында качышлы уены уйнарга жыенмыйлар, таксины олы юл читендә калдырып жәяүләп кенә озатырга куштылар. Арча кырыннан сөенә-сөенә килгән житен йомгактай айны түбәсенә алган күпкатлы йорт янына житкәч туктадылар. Римм «чау! чау!»лап саубуллашты да керә торды. Лиль, башта бер сүз дә дәшмичә, юри киткән булды. Кире килде.

—Әнә, жиденче катта, иң кырый тәрәзәдә ут янганны күт. Кул болгармын.

—Римм сездә кунамы?

—Юк. Без бер катта яшибез. Тәрәзәләре теге якта.

Кыз аның ияк очыннан «пәп» итеп үбеп алды да йөгерде. Баягы шәрабләр Рифне әле генә исертте: уйлары кыюланды, фикерләре жетеләнде, өе онытылды... Бүген кызлар белән нәкъ кинодагыча чүкердәште, туйдагыча күнеле иләсләнде, юбилейдагыча шәраб эчелде, өч-дүрт сәгатькә генә яшьлеге дә әйләнеп кайткан иде кебек... Ә күнеле һаман нәүмиз калды. Туздырырга дучар ителгән хәрәм акча хисабына кабынган өмет тынгы бирми, ниндидер иң мөһим теләк гамәлгә ашмый калды. Риф кайтып китәргә ашыкмады. Ул кызның телефонына язма хәбәр жибәрде:

«Китәсем килми. Әйдә, түбәдә таң аттырабыз. Чакыр мине.»

Әпипә көенә: «Юк. Ярамый.»—дигән жавап килде.

Риф үртәлде, кулындагы гәжит уклавы белән тезләрен кыйнады, ачуы чыкты хәтта... Юк имеш... «Юк!» дип әйтүләре жинел ул кызларга, син менә үжәтлегеңне жинеп «Әйе!» дип әйтеп кара. Ярамый имеш... алайса, нәрсәгә әле ымсындырасың? Сиңа бәлкем ярамыйдыр да, ә мина ярый!..

Абзагызның тел очында «әйе!» белән «юк!» бәрелешкә керде.

«Әйе, сине бүген иягеңнән үбеп качтылар. Шуның өчен күпме вакытың, акчаң әрәм китте».

«Юк. Мин бит чатырга сыра эчәр өчен генә киллем».

«Әйе. Башка көннәрдә син ул сыраны өенә алып кайтып эчә идең. Акча коткысына бирелдең. Бу житен чәчле чибәркәй бик күп ирләрнең чәчен агартыр әле.»

«Юк. Хатынымның чәчен житен төсенә буяттырам.»

«Әйе. Кайткач кендеген дә кара син Талиганның...»

* * *

Такси хуҗасы Рифнең юмартлыгыннан кәнәгать иде бугай, кайтыр юлда бик куаламады. Күрер күзгә артык гади, риясыз юлчының кәефен күтәрер өчен нинди дә изгелек эшләргә дә әзер иде хәтта.

Нәкъ шулвакытта, фара нурлары абайларлык ераклыкта гына, җәяүлеләр сукмагыннан олы юл читенә бер кыз сикереп төште: караңгы төн төсендәге колготкие елкылдап тора, түшенә сыланган кызыл күн курткасы таң алсулыгы белән балкый, биле нечкә, аяклары төз, йөзе төзек, күзләрендә тулган ай нуры, кулында, хәрбиләр плащыннан тегелгән, колак мендәре чаклы брезент сумка. Бу кадәр сөйкемлелеге белән төн уртасы таңга авышыр чакта берүзе ничекләр итеп курыкмыйча йөри ала икән ул?..

Кызны күрү белән, машина үзе дә, йөртүчесенә буйсынмыйча, тизлеген киметте.

—Җину проспекты! Озын аяклар эшкә бара, алабызмы?

—Алабыз, әгәр иярсә.

—Иярә дә, ияртә дә, саклана белмәсәң... Шуткы!—дип, акцентларын кавказлаштырып шаяртып куйды йөртүчебез.

Төнге күбәләк тукталган машинага ялт кына очып кермәде, ачык ишектән үрелеп салондагы ирләрне җентекләде.

—Малайлар! Минем шампанский эчәсем килә...

Мажаралы юлчы буларак, кыз белән Риф сөйләшер дип көткән идеме, аның каушавын күреп шофер үзе җавап бирде.

—Юл унае икән, нәкъ кибеткә бара идек. Кунак янына утыр!

Юл унаена алынган «Алтын шампан» кыз кулына күчте. Әгәр ачсаң газлы шәраб утыргычларны күбеккә батырыр дипме, ул аны брезент сумкасына шудырды.

Риф урталыкта калды, кайсы якка аварга да белмәде, сулга борылсаң хатын-кызны өнәмәгән әкәү кебегрәк килеп чыгар, уңга борылсаң... Ул инде кызның билен дә, күкрәкләрен, йөзен, хәтта чәчен дә күрмәс булды. Күз алдында кара колготкиның ялтыравык күзәнәкләреннән балкып торган бот та бот кына. Соңгы елларда кичләрен икәүдән-икәү генә калгачмы, ял көннәрендә дисенме, бергәләшеп айлык отпускага чыксаң да шул ук—хатынының сары фланель халатыннан гайре матурлык күрмәгән ир өчен никах антына кул селтәрлек, тәүбәләрдән ваз кичәрлек, юлдан яздырырлык, хыянәткә мәдхия җырларлык алгысыткыч халәт иде бу. Рифнең сабыр йөрәге кинәт тибешен кызулатып бөтен кан әйләнешен бил тирәсенә куалый башлады, уяулыгы йөгәнсез, аңы хуҗасыз калды. Рифнең, машинада барган көйгә, чалбар балакларын сызганып кына булса да, ялангач аягын шушы ботларга тидереп карыйсы килде. Кыз сизгер идеме, шулай тиешлеген беләме—туфлиен салып шома тәпие белән абзагызның балак очына тыгылып маташа... Салондагы чит ил музыкасын җиңмәслек итеп кенә пышылдый үзе.

—Хатының бардыр инде... Тартынма. Өйләнгән ирләргә күбрәк ышанабыз без... Гайрәтле ирләрне бала табып алҗыган хатыннары тоткынлыкта асрый... Гаилә наркотик кына ул—ташласаң ломка башлана... Хәзер яратышып уйнарбыз... Монарчы төшеңә дә кермәгән ләззәт алырсың... Нибарысы өч меңгә...

—Шушындамы? Кеше алдындамы?

—Яратышыр өчен машинадан да җайлырак урын юк... Диваны йомшак, җылы, түбәбез ышанычлы, үзе тибрәтә... Тәрәзәләре ни өчен каралтылган дисең—безне беркем күрми...

—Юынмаган килешме?

—Ә менә бу нәрсә—сәфәр комганы гел үзем белән.

Ышандырыр өченме, кызый сумканы ачып, газлы суы яртылаш бушаган пластик шешәгә ымлады.

Йә, Хода! Ниндиләрне генә күрмәгәндер инде бу комган?!. Гомеренә баллонын күтәреп газлы су эчүдән ваз кичәрсен!..

Светофор төбендә кинәтрәк туктагач кына анына килде Риф—сихерле пышылдауларга каршы торырга теләгәндәй, баягы реклама гәжитен уклау итеп чытырдатып кыскан икән ул. Баганадан төшкән ут яктысында кызый шул кәгазьне сыйпап ыңгырашып куйды:

—Ух ты, какой!..

Риф өчен шушылар житә калды: кичтән эчелгән шәрабның көче бетте; икенче сменадан әллә кайчан кайтып житкән Тәлигасы күз алдына килде; иртүк эшкә барасы исенә төште.

—Кызый, минем акчам юк.

—Әйеме?! Әнә, безгә бер «девятка» тагылганмы? «Әни» анда өч «әти» белән. Өенә хәтлек ияреп барачаклар. Өч менне биш итеп хатыныңнан сорап алырлар.

—Лутчы хәзер үк түләргә инде,—дип жөпләде шофер да.

Акчаны күкрәк арасына кыстыргач «төнге күбәләк» гүя очып кына чыкты. Чыкты да күз ачып йомган арада сумкасыннан шампан шешәсен алып бот арасына кыстырды. Бөке шартлап ачылуга пыяла гаурәттән күбек ургылды. Кузгалып киткәндә машина көзгесеннән карап барасыларын белә иде ул, шуна күрә шешәне болгап-болгап торды…

• • •

Хатынының тәрәзәгә ябырылып көтеп ала торган гадәтен белә Рифат. Шуна күрә ул таксины өй янына якын китермәде.

Йокымсыраган шәһәр өстенә офык ярыгыннан язгы тан кереп килә. Кояш чыгышына өелгән көяз болытлар иннеккә баткан. Күпер төбендәге әрәмәлектә ялгыз былбыл өзгәләнә. Табигать кочагында сәер бер үзенчәлектер—бары тик ата кошлар гына сайрый белә. Ана кошлар ояда утырганда әтәч кошлар япа-ялгыз кала. Шушы ятимлек аларны сайрарга мәжбүр итә. Моңлылары сайрый, сайрый белмәгәне сөйли. Тутый кошның ялгызлыктан интеккән әтәче хәтта кеше телендә сөйләшә ала. Ана үрдәкләр бәпкә көтеп ояда утырганда ата үрдәкләрне атарга рөхсәт ителә. Комарлы сунарчылар көтеп алган өч атналык язгы ауда үрсәләнеп, сабырсызланып, эзләнеп очкан ата үрдәкләрне ядрә чүпли. Камышлыктан чыкмыйча, оясы янында гына йөзеп йөргәннәре исән кала. Бактың исә, кеше дә табигатьнең шушы кочагында яши икән…

Рифат төнге базардан кайтып килә. Күнелендәге теге гармунны путасына бикләп янә чормага ыргытты ул. Шәһәр урамында жырлап йөрергә ярамый. Тутый кош әтәче кебек үзалдына сөйләнеп барсаң гына инде… Туздырылган каләрлесен өстәп бу озын меңлекләрне кире илтеп бирергәдер. Тәлигамның кара колготкие бар микән? Ялангач тәненә күн куртка кидереп, шул колготкидан ишекле-түрле йөртеп карыйсы булыр әле үзен… Кеше өендә чит мендәрләрдә йоклый алмаслык яшькә житкәч төнге базарга чыгалармы?!.

Рифатның тамагы чатнады. Сөйләнеп бара торган сүзләре кипте. Юл читендә тәүлекләп эшли торган калай кибет бар. Тик абзагыз бу минутта сыра да, шәраб та, хәтта газлы су шешәсен дә күрергә теләми. Аның Тәлигасы тирән эчле касәгә куе итеп ясаган сөтле чәй эчәсе килә…

Шулчак, язгы тынлыкны сискәндереп, Казансуның Дәрвишләр бистәсе ягында ике көпшәле мылтык аткан тавыш ишетелде.

Рифатның колак төбеннән генә ядрә сызгырып үткәндәй булды…



Рафис
Корбан

## КУЯН ЭЗ ЮГАЛТА...

### Тукран

Бөтен кошның үз көе бар,
Үзенчә сайрый бар да.
Сандугачны әйткән дә юк,
Чыркылдый чыпчыклар да.

Ә тукран гел тукылдый,
Ничек авыртмый башы?
Ахры, кошлар оркестрында
Тукран ул—барабанчы.

### Карбыз

Авызыңда эреп китә,
Әйтерсең лә кар инде.
Әллә шуңа карбыз дигән
Исем кушканнар инде?

Кар да шушы карбыз кебек
Тәмле булсын иде лә.

Кар ашаган идем кышын,
Тамагыма тиде лә.

Карбызны да өреп кабам,
Салкыны бар аның да—
Карбыз гүя яткандыр күк
Кар белән боз янында.

### Тузганак

Тузгыганмы
Тузганак?—
Бөтен дөнья
Булган ак.

Юк, кыш җиткән
Ләбаса!
Дөньяны ак
Кар баса.

### Куян

Куян ак карда
Эз салып үткән.
Шулкадәр күп эз,
Буталып беткән.

Төлкене шулай
Алдаган куян!—
Эзләрнең очын
Чуалткан, җуйган.

Рафис КОРБАН (1957) — *шагыйрь; балалар өчен шигырь китаплары, пьесалар, шулай ук популяр җырлар авторы. Казанда яши.*

Төлке, иснәнеп,
Йөри әз буйлап,
Мескен куянны
Тотарга уйлап.

Ә куян кырдан
Урманга киткән,
Чыршы астында
Ял итә күптән.

## Суык көндә

Суык дисәң дә суык!
Урамнан кертә куып.
Бүрәнә чатный өйдә.
Бүрекләр йоклый чөйдә.

Җылы өйгә керергә
Тели тыштан һава да.

Ишек ачылмасмы, дип,
Утыра бусагада.

Йөнтәс мәче мыраулап
Утыра мич каршында.
Киез итекләр—энә
Җылына мич башында.

## Тегүчеләр

Кыш болынга юрган сырган.
Туңмасын, дип калын иткән.
Ә куяннар юрган читен
Тигез итеп тегеп киткән.

## Кыш бабайның шуклыгы

Шук та инде Кыш бабай—
Ап-ак карлар яудыра.
Минем чаңгыларымны
Кар астында калдыра.

Ишек алдын көрәргә
Туры килә аннары.

Кар көрәгәч, киңәеп
Китә ишек аллары.

Кыш бабайның шуклыгы
Шуна күрәдер әле—
Күрә син дип, чаңгымны
Юри күмәдер әле.

## Тигәнәк

Тигәнәкне күр инде син!
Эт-көчектән ким түгел.
Яныннан һич тыныч кына
Үтәргә мөмкин түгел.

Көтеп кенә торадыр күк
Берәр малай узганын,
Ябышырга гына тора
Балагына ул аның.

## Тавык

Кетәклектә бер тавык
Чак алмады котымны.
Тыныч яткан җиреннән
Кытакларга тотынды.

Ни булган икән, дисәм,
Йомырка салган икән!

Күпме шау-шу! Ә үзе
Бер бәләкәй кош кына...
Гүя алтын йомырка
Салган кебек кычкыра.

## Кабак

Түтәлдә ята кабак,
Кояшка кырын карап.
Кабарам да тулам ди,
Мин дә кояш булам ди.

*Бу санда журнал укучыларыбыз игътибарына шигырьләре тәкъдим ителә торган яшь каләм ияләренең өчесе дә—әдәбиятка күп шагыйрьләр, әдипләр биргән Балык Бистәсе районыннан. Алинә—инде университетның татар теле һәм әдәбияты факультеты студенты; ә Ләйсән белән Сиринә—икесе дә 10нчы сыйныфта укыйлар. Балалар иҗат үзәге каршында оештырылган (җитәкчеләре—шагыйрьләр Рәсимә Гарифуллина һәм Вазыйх Фатыйхов) «Алтын каләм» әдәби түгәрәге әгъзасы алар. Һәм... барысы да—якташлары, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин премиясе лауреатлары (шагыйрь махсус рәвештә туган ягына кайтып, үзе тапшыра бу бүләкне!). Ә Алинә—Саҗидә Сөләйманова исемендәге стипендиягә лаек булды.*

*Сәләтле яшьләребезгә хәерле юл телик!*

# Алинә Бикмуллина

## Күзләр байлык белән томаланган...

**Күзләр байлык белән томаланган...—**
**Түбәннәрне алар күрмиләр.**
**Ятимнәрне, мескеннәрне түгел,**
**Кан-кардәшләрен дә белмиләр.**

**Күзләр байлык белән томаланган...**
**Дөнья иркен, дөнья түгәрәк.**
**Кайберәүләр, очын-очка ялгап,**
**Яшәп ята бу көн үзгәрәк...**

**Күзләр байлык белән томаланган...**
**Заманадан калмый йөгерә.**
**Аерым йортлар сала ... шаккатырлык!**
**Җиңел машинада җилдерә.**

**Күзләр байлык белән томаланган...**
**Башка берни җирдә кирәкми.**
**Алтыннарга багып яшәүчеләр**
**Бу дөньяда әллә сирәкме?..**

**Күзләр байлык белән томаланган...**
**Иксез-чиксез күпме байлыклар.**
**Ә берәүләр хаста хәлләрендә**
**Сорап ята... азрак саулыклар.**

**Күзләр байлык белән томаланган...—**
**Алар өчен байлык—чын шатлык...**
**Якыныңның андый булуыннан**
**Булмаганы җирдә мең артык.**

**Күзләр байлык белән томаланган...**

* * *

Тамчылар тамган чак—
Урамга чык кына,
Сине яз кочачак.

* * *

Күпме китап укыганым булды,
Күпме шигырь генә ятладым.
Ләкин «Туган тел» күк шигырьләрне
Эзләсәм дә әлегә тапмадым!

* * *

Инде шатлыкның да, борчуның да
Һәр кешедә булуын беләмен:
Күңелдәге барлык тойгыларны
Шигъри юллар итеп үрәмен.

### Акрошигырь

**Г**амьсез дөнья кинәт яктырды күк,
**А**йсыз төнгә йолдыз сибелде.
**Ш**ыксыз өйгә ямь өстәлеп китте—
**Ы**шанмыйча торды күңелем.
**Й**олдызларның арасыннан берсе
**К**арап куйган кебек сизелде.

**Б**ерсе генә, бары шунсы гына
**У**йландырды минем күңелне.
**Л**әкин мине нигә әсир итте
**Д**өнья йолдызының тик берсе?..
**Ы**шандым мин: сөю ул—могҗиза,
**М**әҗнүн карашларың исертте...

## Сиринә Мөхәммәтҗанова

### Мин—хыялый җир кызы

Мин—җир кызы, ләкин хыялым
Гел күкләргә таба ашкына:
Күңел һаман нидер өмет итә,
Уйларым да тоташ ташкын ла.

Кайчакларда онытылып китеп,
Әллә нинди уйлар уйлыйм мин:
Киләчәгем—чиксезлеккә чумам,
Һич тә хыялланып туймыйм мин...

Сөясем дә килә... сөеләсем,
Бәхет диңгезендә йөзәсем—
Сандугачлар җырын ишетәсем,
«Җәннәт чәчәкләр»ен өзәсем...

Гади дә мин һәм бик катлаулы да,
Бераз сәерлек тә бар җанда.
Күккә баккан хыялларым—үсте,
Гөлдәй, туфрагымда—ватанда!

## Туган як

Йөрәк белән сөям бу тормышны,
Бөтен җаным белән табынам...
Туган якка кайтсам, илһамланам—
Якты йолдыз кебек кабынам.

Чишмәләргә төшеп сулар эчәм,
Күктә йөзгән айны күзәтәм,
Яшәү сынауларын уза-уза
Булган ялгышларны төзәтәм.

Болыннарга чыгып чәчәк җыям,
Җылы яңгырларда коенам.
Күбәләктәй очып-очып йөрим:
Саф һавасы белән туенам.

Каеннарга барып серем сөйлим,
Табигатьне күзлим сак кына...
...Башка җирдә шигырь күреп булмас,
Иң гүзәл як—туган як кына.

## Мин китәм

Мин китәм, ә Сөю кала...
Күздә моң-сагыш:
Безнең сөю—бу җиһанда
Мәңгелек ялгыш...

Мин китәм, (яраткан килеш!)
Ярымнан китәм.
Ә синең яраңны инде
Төзәтсен бүтән.

Минем ярага дәва—җыр,
Шигъри моң гына:
Бер кайтып ирешер, бәлки,
Сиңа—соң гына...

* * *

Ышанычны минем югалтма син,
Йөрәгемне яула, мин әзер!
Соңга калсаң мин гаепле түгел,
Сөя алсаң, әйдә сөй хәзер.

## Ләйсән Фәтхетдинова

### Бәхет...

Бәхет ни ул? Уйладым:
Мин бәхетле...
Бәхет ни ул? Уйландың.
Син бәхетле.
Бәхет ни ул? Уйладык:
Без бәхетле!
Бәхет ни ул? Тәхетме ул?
Кем бәхетле?

Син яшисең бу дөньяда—
Син бәхетле!
Авыр тормыш—үзе сынау,
Мин бәхетле!
Аңлый белү үзе бәхет
Шул бәхетне.
Бәхет алыштыра ала
Бай тәхетне!

Табигатьне аңлый белсәң—
Син бәхетле.
Кояшка карап елмайсам,
Мин бәхетле.
Байлык кына арттыра алмый
Бу бәхетне.
Кешеләрне хөкем итү—
Ул бәхетме?
Тәңрем миңа ярдәм итсә—
Мин бәхетле!

Кулларымда каләм белән
Мин тәхетле!
Сынауларны уза алсам,
Үпкәләрне суга салсам,
Каралыкта чиста калсам,
Изге эшләр эшләп талсам—
Мин бәхетле!

Ничек аңлатырга тагын
Бу бәхетне?
...Шуны белмәү үзе әллә
Бер бәхетме?!

* * *

Татарлык ул яши синең белән,
Татарлык ул яши минем белән.
Татарлык ул яши татар белән,—
Суларда да: «Мин татар!» дип батар белән...

* * *

Татар каны йөрәктә,
Татар җаны үзәктә.
Татар язмышы—җанда.
Үткән тарих—һәр таңда.

## Елмаегыз!

Елмаегыз, иртә белән уянгач та,
Бәхет килеп, шатлыктан куангач та,
Гаделлек барын белеп, юангач та,
Берьялгызың, үзең генә калгач та.

Елмаегыз, авырлыклар килгәндә дә,
Елмаегыз, елаган—сүрелгәндә дә,
Өметегезне кисәкләргә бүлгәндә дә,
Туганда да, яшәгәндә, үлгәндә дә...

* * *

Азатлык—бәхетең,
Хәтерең—тәхетең.
Җитезлек—өметең,
Син шунда—бербөтен.

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

*Белгәне кол булды,*
*Әйләгәне мал булды;*
*Җәеп салса көмешен –*
*Җәйрәп яткан күл булды;*
*Өеп салса алтынын –*
*Әлдермештәй тау булды.*
*Ашаган казы—ял булды,*
*Эчкәне сары бал булды".*
"Идегәй" дастаны

## "Изү"

В.В.Каргалов "Урда изүенең азагы" дигән китабында (1980) шуны дәлилләгән: "изү" сүзен беренче тапкыр король Стефан Баторийнең статс-секретаре Рейнгольд Гейденштейн "Мәскәү сугышы турында язмалар"да кулланган, аннан бу төшенчәне күренекле француз тарихчысы де Ту эләктереп алган, шуннан соң әлеге төшенчә мәшһүрләшеп киткән. Рус кенәзләре исә үзләренең "изү" астында булганнарын белми дә, сизми дә калганнар. Шул рәвешчә, бу термин XVI гасырда гына барлыкка килгән һәм аңа идеологик вазыйфа йөкләнгән. Ул бүген дә әнә шул акыллы немец уйлап чыгарган вазыйфаны башкара.

Татар-монгол "изүе" турындагы стереотиплар шулкадәр дә көчле ки, ул тарихи чор турында теләсә нинди уйдырмалар сөйләргә мөмкин, һәм кешеләр моңа ышаначаклар, әмма "изү"нең булмаганлыгын бик азлар гына кабул итәчәк—ничек инде булмасын, булган ләбаса! Гадәти мантыйк әнә шундый.

Чынлыкта исә "изү"—гаять зур әкият ул һәм аны Россия дәүләте бар куәткә хуплый. Хәер, болай дип әйтүләре дә бар: ябырылу булган, басып алу булган, димәк, изү дә булган!

Татар-монголлар барлыкка килгәнче Русь бер-береннән читләшә барып, үз эчләрендә таркала торган күп кенә кенәзлекләрдән гыйбарәт булган. 1097 елда Любечта кенәзлекләр корылтае узган, анда "һәркем үз җирен тота" дип карар кылынган. Кенәзләр яңа принципны какшамас тәстә үтәргә ант иткәннәр, шуны дәлилләп тәре дә үпкәннәр. Шул рәвешчә Русь яңа сәяси оешмага—бәйсез дәүләтләр конфедерациясенә әверелгән. Тора-бара Төньяк-Көнчыгыш Русь һәм көньяк-көнбатыш җирләр (Волынь, Киевщина һәм Галиция), Чернигов кенәзлеге аерымланган, Смоленск, Туров-Пин җире аерылып чыкканнар, Новгород тулы бәйсезлек алган. Ни дәүләттә, ни чиркәүдә бердәмлек булмаган, һәркайда үзара сугыш барган. 1216 елда Ростов-Суздаль җирендә "уллар—аталарына, аталар—улларына, туган—туганына, коллар—хуҗаларына, хуҗалар—колларына каршы чыкты",—дип яза елъязмачы.[1] Төньяк

[1] С.М.Соловьев. Сочинения. Кн.1.—М., 1988, с. 592.

*Ахыры. Башы журналның 2006 елгы 7–12 саннарында.*

җирләрдән Владимир Мономах вакытында ук аерылып чыккан Муром-Рязань җирләре үз чиратларында үзләре үк төрле кенәзлекләргә таркалганнар. Нәтиҗәдә, XIII гасыр башында Чернигов-төньяк җирләрендә Козельск, Курск, Трубчевск, Сновск, Рыльск, Лопасна, Вщиж, Новгород-төньяк, Путивль, Стародуб, Дебрянск, Караваев һәм башка кенәзләрнең уделлары мыжлап торган. Алар бер-берсенә каршы сугышканнар.

Шул рәвешчә, татар-монголларга кадәр йөз ел элек аерым кенәзлекләр бер-берсен юкка чыгару белән шөгыльләнгәннәр, өстәвенә бу гамәлнең максатлары да аңлашылмый. "Кыргыйлык һәм бер туганның икенче туганга каршы явызлануы рус хакимнәре,— бертуганнар яки туганнан туганнар, абыйлар, энеләр тирәлегендә артык еш булган. Моның коточкычлыгын Александр Невский образы гына бераз каплап торган,—дип яза В. О. Ключевский.—Әгәр үзләре теләгәнчә генә яшәсәләр, алар бөтен Русьны бер-берсенә бәйләнмәгән, үзара мәңге дошман булган корамаларга өзгәләп бетерерләр иде... Хан нәфрәте сугыш чукмарларын тыеп торган, ханның рәхимлеге, ягъни аның ихтыяры белән бөлдергеч үзара сугыш күп тапкырлар кисәтелгән яки туктатылган. Хан хакимияте Всеволод III нәселенең ил эшләрен бутап, бик белеп төйнәгән төеннәрен кисеп атучы тупас татар пычагы булган. Рус елъязмачылары "поганый агарян"-нарны Ходайның гөнаһлыларны аңга китереп тәүбә юлына бастыручы җәза таягы (батог) дип юкка гына атамаганнар".[2] Дәреслекләр берәзлексез яза торган "Рус җиренең һәлакәте" татар-монгол явы нәтиҗәсе була алмаган, чөнки ул Батый хан туудан күп элегрәк тарихи факт булган инде.

"Ябырылу" башта Русьны басып алуны күздә тотмаган. Болгарны тар-мар иткәннән соң  татар-монгол гаскәрләре Иделне кичкәннәр дә ике канатка бүленгәннәр. Берсе—Мүнкә җитәкчелегендә—кыпчакларны куа киткән, кыпчакларны исә Венгрия короле үз канаты астына алган. Икенчесе, Батый хан җитәкчелегендә, кыпчакларны рус җирләре ягыннан камап алган. Батый хан үз гаскәрен рус кенәзлекләре җирләре аша үткәрүне, азык-төлек һәм атлар бирүне таләп иткән. Әмма кенәзләрнең күпчелеге баш тарткан. Рязань кенәзләре, мәсәлән, болай дип җавап биргәннәр: "Безне үтерсәгез, бар да сезнеке булыр". Нәтиҗәдә Батый хан Рязаньны,Владимирны, төньяк-көнчыгыштагы Торжокны, Козельскины, Көньяк Переяславльне, Черниговны, Киевны, көньяктагы Колодяжин һәм Каменецны, көньяк—көнчыгыштагы Галичны һәм Владимир-на-Волыни шәһәрләрен басып алган. Татарлар яулап алган дип белдерелгән калган унбер шәһәргә килгәндә исә, аларның татарлардан зыян күрүенә дәлилләр юк. Н. Н. Воронин  Ярославль, Ростов, Углич, Кострома, Төньяк Переяславль, Тверь һәм "башка шәһәрләр" сугышмыйча гына бирелгәннәр һәм татарлар тарафыннан җимерелмәгәннәр дип саный.[3] Бөек Владимир кенәзлегенең төньяк өлеше исә вакытында уздырылган сөйләшүләр һәм һөҗүм итүче татар-монгол армиясенә азык-төлек һәм атлар биреп капитуляция ясау аркасында исән-имин калган.  Ул заманда барысы өч йөзгә якын рус шәһәре булган.

Киев җирендә Киев яулап алынганнан соң биш ел узгач сәяхәт иткән Плано Карпини болай ди: Киевтан "бернәрсә дә калмаган диярлек, хәзерге вакытта (1245 елда) анда нибары 200 йорт исәпләнә, ә халкын тулысынча коллыкта яшәтәләр". Плано Карпининың шушы сүзләрен һәрдаим өземтә итеп китерәләр. Киевны алуны ачык тасвирлаучы Ипатьев елъязмасында нинди дә булса биналарны җимерү, хәтта халыкны кыйнау турында да бернинди мәгълүмат юк. Киевны яулау турындагы Лаврентьев елъязмасы бу хакта өстән-өстән генә язган, ә Новгород елъязмасында бөтенләй бернәрсә дә юк. Бу гаҗәп түгел, чөнки Киевны татарларга кадәр  руслар үзләре үк өч тапкыр җимергәннәр.  С. Ф. Платонов сүзләре буенча, "татарларның килүе аңа ахыргы һөҗүм булган".[4] Ул инде болай да харәбә хәлендә яшәгән. "Батыйга кадәр, төгәлрәге, 1169 елда, Киевны Андрей Боголюбский бөлдергән, ул үз сугышчыларына Русь башкаласын өч көн таларга ирек биргән, гадәттә, моңа бары тик чит шәһәрләр генә дучар ителгәннәр. 1203 елда кенәз Рюрик Ростиславич Смоленский да Киевта шулай ук кыланган, аңа "Игорь полкы турында сүз"

---

[2] В.О.Ключевский. Сочинения. Т.II.—М., 1957, с. 43.

[3] Н.Н. Воронин. Зодчество Северо-Восточной Руси. Т.2.—М., 1962, с. 130.

[4] С.Ф.Платонов. Полный курс лекций по русской истории.—М., 2004, с. 117.

нең мәгълүм герое—кенәз Игорь Святославич булышкан. Шулай итеп, Батыйга Киевтан өллә нәрсә калмаган да...".[5] Батый хан Киев янына килеп җиткәч, кенәз качкан, чөнки шәһәрне яклап сугышырлык кеше калмаган. Бу шәһәрдә татарлар яулап алырлык һәм җимерерлек бер нәрсә дә булмаган инде.

Киев Русе XII гасырның икенче яртысыннан какшый башлаган, ул чакта "варяглардан грекларга" сәүдә юлы шведлар, немецлар, литвалар ягыннан төре походлары нәтиҗәсендә үз әһәмиятен җуйган. Татар ябырылуы Русьның бетүгә йөз тотуына һәм артка калганлыгына сәбәп була алмаган. Петр Савицкий раславынча, "XIII гасыр башындагы Русьта бөтенләй беткәнлек күренеше хөкем сөрә: Көнбатыш белән чагыштырганда, масштаблар аермасы—ун кат, йөз кат. Һәм бу татар изүе нәтиҗәсе түгел, татар изүенә кадәр ук чып-чын "артталык"!"[6]

Новгород республикасына, Полоцк, Смоленск һәм Туров-Пинск кенәзлекләренә татарлар кагылмаганнар. Рязань зур зыян күргән, ләкин татарлардан бигрәк Суздаль кешеләреннән. Татар-монголлар үзләреннән соң гарнизоннар калдырмаганнар, шуңа күрә алар киткәч тормыш гадәти эзенә төшкән. Зыян күргән шәһәрләр бик тиз яңадан төзелгәннәр, тормыш элеккечә дәвам иткән. "Рязаньның бөлүе турында хикәят" ябырылу нәтиҗәләрен болай тасвирлый: "Игелекле бөек кенәз Ингварь Ингваревич... үз атасы урынына утырды... һәм Рязань җирен яңартты, чиркәүләр төзеде, монастырьлар корды, килгәннәрне урнаштырды, кешеләрне җыйды. Христианнарга шатлык килде, Ходай аларны ... явыз Батый патшадан коткарды."[7] Археологик казынулар Рязаньның тиз торгызылуы турындагы әлеге сүзне исбатлыйлар.

Плано Карпини, Рәшидетдин һәм Ибне әл-Әсири раславынча, татарлар тәҗрибәле һөнәрчеләрне һәм осталарны үзләре белән алып киткәннәр, бу өлешчә хак нәрсә. Әмма өлешчә генә, чөнки рус кенәзлекләрендә тулаем алганда, һөнәрчелекнең бөлгенлеккә төшүе күзәтелмәгән. Авыл хуҗалыгына килгәндә, Б. А. Рыбаков күрсәткәнчә, татарлар крестьяннарга карата сак эш иткәннәр, Ипатьев елъязмасы сүзләре белән әйткәндә, "бодай һәм тары үстерерләр"[8] дип аларга кагылмаганнар. Батый һөҗүменнән соң рус кенәзлекләрендә беркем дә ясак түләмәгән, чөнки татар гаскәрләре рус җирләре аша узып кына киткәннәр. Ясакны 20 елдан соң гына түли башлаганнар.

Тарихи әдәбиятта татарлар рәхимсезлегенең ачык һәм бәхәссез бер үрнәге һәрвакыт очрап тора—нигезенә кадәр җимерелгән Козельск шәһәре. Кайбер авторлар тасвирлавынча, имеш, ул татар-монгол явына каршылыкның үзәгенә әверелгән диярлек. Бу—аерым бер очрак, чөнки ул "явыз шәһәрләр"-дән исәпләнгән, ягъни анда илчеләрне үтергәннәр, бу исә Чыңгыз хан "Яса"сы буенча иң зур гөнаһ һәм моның белән килешергә була, мөгаен. Татар-монголлар мондый гамәл өчен хакимнәр генә түгел, бөтен шәһәр җаваплы дип исәпләгәннәр. Димәк, ул юкка чыгарылырга тиеш һәм алар моны башкарганнар да. Козельскины камалышта тотканда, бер генә рус кенәзе дә ярдәмгә килмәгән, гәрчә нәкъ менә шушы вакытта Ярослав Всеволодович Литвага һөҗүм итеп уңышка ирешкән.

Ябырылу тарихи язмаларда тасвирланганча ук коточкыч булмаган. "Татарлар ябырылуының турыдан-туры нәтиҗәләре нинди?",—дип сорый Д. Феннел.— Рус тарихының башлангыч чорына хас булганча, язма чыганакларда татарлар китергән сәяси, мәдәни яки икътисадый зыян турында нигезле нәтиҗә ясарлык мәгълүмат бик-бик аз. Дружиначылар яки гражданнар арасында югалтулар саны күрсәтелми, без күпме кеше әсирлеккә алынганын да белмибез. Ул замандагы елъязмачылар, сәяхәтчеләр һәм тарихчылар хәтта арттырылган саннар күрсәтүдән дә катгый рәвештә баш тарталар: йә алар, Киев очрагындагы кебек, бер сүз дә язмыйлар, йә укучыларны пешмәгән гиперболалар белән куркыталар... Физик яктан юк итү һәм мәдәни кысрыклау турында археологик мәгълүматлар шулкадәр аз ки, алар нигезендә һөҗүмнән соң рус шәһәрләре һәм авыллары торышы турында реаль картина булдыру мөмкин түгел".[9]

[5] Лев Гумилев. Черная легенда..., с. 269.

[6] П.Н.Савицкий. Степь и оседлость.— Россия между Европой и Азией: Евразийский соблазн. М., 1993, сс. 123-124.

[7] Воинские повести Древней Руси.—М.-Л., 1949, сс. 18-19.

[8] Рыбаков Б.А. Ремесло Древней Руси.—М., 1948, с. 525.

[9] Д.Феннел. Кризис средневековой Руси. 1200-1304.—М., 1980, сс. 127-130.

Авыр "татар ясагы" турындагы сүзләр дә бик күпкә арттырылган. В. В. Кожинов болай дип яза: "П. Н. Павловның "Алтын Урдага рус ясагы мәсьләсенә" карата дигән бик тә әһәмиятле, ләкин табуы ифрат кыен булган бер язмасына игътибар иттем. Ул "Красноярск педагогия институтының фәнни язмалары"-нда 1958 елда басылган. Бу әлеге мәсьәлә җитди һәм төгәл куелган бердәнбер хезмәттер, мөгаен. Һәм язмадан шул ачыклана: уртача еллык ясак, хәзерге заман исәбенә күчергәндә, җан башына бары тик 1-2 сум гына булган икән бит. Ягъни ул, ясак җыючы рус кенәзләренең казнасына шактый сукса да, халык өчен авыр булмаган. Ә менә хәтта шул ук вакытта Иван Калита улы Симеон Гордый ясак түләгән кадәр үк сумманы, ярдәм йөзеннән, Константинополь патриархиясенә үзе теләп бирел барган".[10] Алай гына да түгел, татарлар ябырылуы вакытында руслар арасында кенәзләр, боярлар, урядниклар изүеннән, бетмәс-төкәнмәс үзара сугышлардан, кенәз гаскәрләре җәбереннән һәм талавыннан, түләнмәгән әҗәтләрдән һәм эшләп түләүләрдән котылуга омтылыш яшәгән. Мондый кешеләр бөтен общиналары белән татарлар ягына чыкканнар, бу аларга тыныч тормыш һәм куркынычсызлык тәэмин иткән, салымнарны да азрак түләгәннәр. Аларда халык хакимияте оешкан, аксакаллар идарә иткән. Аларны "татар кешеләре"[11] дип атаганнар. "Салымнар түләү һәм хуҗалык итү ягыннан аларга үз кенәзләре һәм боярлары астында яшәүгә караганда татарлар белән яшәве җиңелрәк булгандыр, мөгаен",—дип яза Михайло Грушевский. Ә татарларның рус җирләренә һөҗүмнәре күбесенчә кенәзләрнең үзара сугышларын туктату өчен ясалган. Һәрхәлдә, инде күп "чәйнәлгән" "изү" вакытында Русьның халкы ике тапкыр арткан.[12] Чагыштыру өчен: Явыз Иван Казанны алгач, киресенчә килеп чыккан—халыкның өчтән бер өлеше юкка чыгарылган, бу инде демографик катастрофа дигән сүз.

Тарихта яулап алуга шатлану очрагы юк. Мәсәлән, Явыз Иванның Казанны алган көнен—1552 елның 2 октябрен бәйрәм итсәләр бик гаҗәп булыр иде. Киресенчә, бу—кайгы көне. Рус җире өчен дә шулай. Әмма объективлык йөзеннән тулаем вәзгыять турында сөйләргә кирәк, ул исә татар белән рус арасындагы каршылыктан гына түгел, башка көчләр нисбәтеннән дә гыйбарәт.

XIII гасырда Русь ике ут арасында кала: татар-монголлар килгән Көнчыгыш һәм тәре йөртүчеләр килгән Көнбатыш арасында. Ягъни тегеләй дә, болай да чит ил "изүе" көткән. Берсен сайлап алырга кирәк булган. "Татар дәрәҗәсе явызлардан явыз: Рус җиренә, Киевка, Володимирга, Галичка ия булган элеккеге бөек кенәз Данила Романович... хәзер тезләнде һәм холоп дип атала... Татар дәрәҗәсе явыз—аның әтисе Рус җирендә патша иде, Кыпчак җирен буйсындырган һәм башка барлык илләргә яу чапкан иде",—дип яза рус елъязмасы.

Даниил Галицкий Көнбатышны сайлап алган һәм аның ярдәме белән Көнчыгышка каршы көрәш алып барырга, мөстәкыйль Галич-Волынь кенәзлеге төзергә һәм король таҗын алырга маташкан. Ул Папа Иннокентий IV белән чиркәү униясе турында сөйләшүләр алып барган һәм аны рус руханиларына ташламалар ясалыр дип ышандырганнар. Даниил король титулы алса да, Пападан ярдәм булмаган, әмма татарларга каршы тәре походы игълан ителгән.

Ләкин Папа схизматикларга—грекларга һәм русларга каршы да тәре походы игълан иткән, ә Русьның католик Европага каршы торырлык көче булмаган. 1237 елда Тевтон һәм Кылыч йөртүчеләр орденнарының рыцарь-монахлары Балтыйк буен яулап алу һәм Руська басып керү, католиклыкны көчләп тагу максатында бик куәтле Ливон орденына берләшкәннәр. Бу чын-чынлап куркыныч нәрсә Новгород җирләре чигендә үк барлыкка килгән, өстәвенә, кайбер урыннарда руслар арасында Тевтон яклы партияләр дә булган.

Александр Невский исә башкача эш иткән. 1248 елда Папа булласында Александр Невскийга, Рим тәхетен таныган очракта, татарларга каршы Ливон рыцарьлары ярдәме вәгъдә ителгән. Икенче яктан, Александрга Батый хәбәр җибәргән: "Рус хакимнәре арасында данлы Александр, сезгә мәгълүм, Ходай миңа күп мәҗүси (халыкларны) буйсындырды һәм барысы да минем олыска буйсына. Шулар арасыннан берүзең минем көчкә буйсынмаска уйлыйсыңмы?

[10] В.В.Кожин. Поиски будущего. // "Наш современник", 1991, №3, с. 128.
[11] Михайло Грушевский. Иллюстрированная история Украины.—Киев-Львов, 1913.
[12] Э.С.Кульпин. Золотая Орда.—М., 1998, с. 66.

Исеңдә калдыр: үз җиреңне бөтен килеш сакларга уйласаң, һич кичектермичә миңа кил һәм минем патшалыгымның даным һәм абруен күрерсең, үзеңә һәм җиреңә файда табарсың". Александр Невский Көнчыгышны сайлаган.

Латинчылык сугышчан дин булган, ул православиене мөртәтлек дип санаган, ә "Яса" барлык диннәрне дә тигез күргән һәм дини кануннар түгел, сәясигражданлык законнары керткән. Татарлар, иң актык чиктә—тәнне кол иткәннәр, әмма җанны түгел, дип яза Г. В. Вернадский,—"латинчылыкта исә җанның үзен бозу куркынычы янаган".[13] Александр Урдага бертуганы Андрей белән барган һәм Батый ханның улы Сартак белән дуслашкан. Аннан алар Каракорымга, Гуйук хан янына барганнар. Бу эшкә ике ел вакыт киткән. Һәм Андрейга—Владимирны, Александрга Новгородны һәм Киевны биргәннәр. Тверьда өченче бертуганнары—Ярослав кенәзлек иткән.

Андрей шведлар, ливонлылар һәм поляклар белән берлек яклы булган, ул татарлардан котылырга теләгән. Александр, өлкән абый буларак, энеләреннән буйсынуны таләп иткән. Буйсынмаганнарын күргәч, ул татарлардан файдаланган. 1252 елда нойон Невруйның татар отряды Андрейны Владимирдан куып чыгарган һәм бөек кенәз тәхете Александрга бирелгән. 1256 елда ул Ярославны да куып җибәргән, аннан соң ясак түләргә теләмәгән Новгород кешеләрен җәзага тарткан.

Рус православиесе традицияләре буенча Александр Невский изгеләр арасына кертелгән. "Татарлар белән Русь арасындагы фаҗигале халәте Изге Александрны газап чигүче итә,—дип яза Н. А. Клепинин.—Ул Рус чиркәвенә дә, рус тарихына да, халык аңына да әнә шул газап чигүче таҗын киеп керә."[14] Газаплы уйлар кемне күбрәк җәфалагандыр: Александр Невскийнымы, Даниил Галицкийнымы—әйтүе кыен, әмма бу вәзгыятьнең фаҗигасе ике явызлыктан берсен сайлау мәҗбүрилегеннән гыйбарәт.

Даниил Галицкий немецлар, ә Александр татарлар яклы булган. Ә кем руслар яклы булган соң? Бер якны да кабул итмәүчеләр дә очраган. Полоцк, Туров-Пин кенәзлекләре татарларга да, немецларга да буйсынмаганнар, ләкин тарихта да эз калдырмаганнар. Татарлар тимәгән Новгород җире тышкы дошманга, ягъни рыцарьларга каршы торырга тулысынча сәләтсез икәнлеген күрсәткән. Новгородка янәсе "татарлар тарафыннан суелган" Владимир кенәзлеге ярдәм иткән. Ә татарлар кагылмаган җирләр, ягъни Полоцк, Смоленск, Туров-Пин кенәзлекләре ни Новгородка, ни Псковка тевтонлылар һөҗүмен кире кайтарырга берничек тә булышмаганнар. Новгород белән "орден немецлары" арасында солыхка 1269 елда Урда отряды җибәрелү аркасында ирешелә: "Новгород җирендәге немецлар, татарларның исеменнән үк котлары алынып, тынып калдылар". Тевтонлыларны куып җибәрү өчен 500 татар җайдагы да җитә калган. Псков һәм Новгород нәкъ менә шул рәвешчә коткарылганнар. Көнбатыш рус шәһәрләреннән иң озак карышканы—Смоленск, әмма ул да 1274 елда Алтын Урдага үзе теләп кушылуны Тевтон оккупациясеннән өстенрәк күргән. Ә бит татарлар Смоленскига хәтта якын да бармаганнар.

Рус кенәзлекләрендә рус җирен берләштерүче берминди әхлакый башлангыч та, кыйммәтләр дә булмаган, хәтта православие дә ул заманда вак акча сыйфатында йөргән, аны, җае чыкса, җиңел генә католиклыкка алмаштыра алганнар. Православиене саклап калырга әзер булганнар исә татарлар ягына чыкканнар, Александр Невский изгеләр рәтенә нәкъ менә шуның өчен кертелгән дә инде.

Үз чиратында татар-монголларның да ике көчле дошманы булган: Багдад хәлифе һәм Папа. Батый хан рус кенәзләре белән дуслашырга теләгән, чөнки Папа татарларга каршы да, православиегә каршы да тәре походы игълан иткән. Европага походы вакытында Батый хан туганнан туган абыйларыннан ярдәм күргән, әмма ул ярдәмнең дә чиге булган. Тарихчылар бәяләвенчә, походтагы гаскәрләрнең саны 30-40 мең җайдактан артмаган. Ә инде 1238 елда Үгәдәй улы Гуйук һәм Чыгытай улы Бори белән ачуланышканнан соң, шаһзадәләр дружиналары белән бергә Монголиягә чакырылып алыналар. Чыңгыз хан бүлеп биргән нибары 4000 монгол гаиләсенә баш хәлдә, Батый иксез-чиксез илнең

[13] Г.В.Вернадский. О составе Великой Ясы Чингиз хана..., с. 499.

[14] Н.А.Клепинин. Святой и благоверный князь Александр Невский. – Париж, 1927, с. 86.

хакимена әйләнгән. Рәшидетдиннең раславынча, "Телгә алынган шушы дүрт әмирне Чыңгыз хан дүрт меңлек гаскәр белән Җучи ханга бирде. Хәзерге вакытта Туктай һәм Баян гаскәрләренең зур өлеше—шушы дүрт меңнең нәселе, ә соңгы вакытта өстәлгәннәр—рус, чиркәс, кыпчак, мажар һәм башкаларның гаскәрләреннән килеп кушылганнар".[15] Үгәдәй үлгәннән соң бөек хан булып Гуйук калган, ә Батый, аның белән ачуланышу сәбәпле, аның ярдәменә исәп тота алмаган. Ул, көнбатыш походын туктатып, көннән-көн мөстәкыйльләшә барган Алтын Урданы ныгыта башлаган. Венгр походыннан кайтышлый, 1242 елда ул Бөек Болгарда тукталган, рус кенәзләре аның янына кенәзлек итү ярлыклары сорап килгәннәр һәм ул "һәрберсен үз җиренә" кайтарган. Ә бөек кенәз Ярославны "Рус телендәге барлык кенәзләрнең өлкәне бул" дигән сүзләр белән кайтарып җибәргән. Шушы датаны Алтын Урданың мөстәкыйль дәүләт сыйфатында Монгол империясеннән аерыла башлау елы дип санарга мөмкин. Шуннан башлап Батый бары тик үз көченә генә таянган. Аның Александр Невский белән дуслык Урданы көнбатыш яктан ышанычлы саклый дигән исәбе дөрес булган. Шундый көчләргә ия һәм ярдәмгә мохтаҗ Батый хан нигездә деспотлык режимы, башкача әйткәндә "изү" урнаштыра алмаган. Шуңа күрә Алтын Урда үзенә бер төрле конфедерация булган: ул бер яктан—төрле халыкларның һәм конфессияләрнең үзара мәнфәгатьләренә, икенче яктан—хәрби осталык җәһәтеннән көндәшләре булмаган татарлар һөҗүменнән куркуга таянган.

Мондый "берлек"тән руслар да, татарлар да отканнар, католиклык исә—оттырган. Моннан ары православие ышанычлы сакланган. Монголларга кадәр дәвердә славян дөньясының кырыйлары мәҗүси булып кала биргән. "Бары тик "татар-монгол изүе" вакытында гына,—дип яза Ю. Кобищанов,—иркенләп монастырьлар төзү, авыл кешеләрен чукындыру, "аю почмакларын" (Бөек Ростовның мәҗүси җире шулай аталган) Изге Руська әйләндерү башланган".[16] Александр Невскийның өметләре акланган. Нәкъ менә "изү" православие культурасының чәчәк атуына ярдәм иткән. Салымнардан азат ителгән православие монастырьлары рус халкының куәтле рухи көченә әверелгәннәр. Русларның XIV гасырдагы икона язмалары Россиянең генә түгел, дөньяның рәсем сәнгате тарихында югары нокта булып санала һәм бу очраклы хәл түгел. Татарлар керткән өстен хокуклар исә Явыз Иван вакытында, 1584 елгы земский соборда юкка чыгарылганнар: "анда барлык тарханнарны яки хөкемнән һәм салым түләүдән монастырь вотчиналары файдалана торган ташламаларны бетерү, монастырь җирләреннән дә башка җирләрдән түләнгән кебек салым түләү билгеләнде".[17]

Татарлар Александр Невский ярдәменнән башка Алтын Урдада тыныч кына хакимлек итә алмаслар иде, әмма руслар Алтын Урдадан башка православиене югалтырлар иде, димәк Россия җире бүген без аңлаганча Россия булмас иде, башкача әйткәндә, без Речь Посполитая яки Бөек Литва дәүләтендә яшәр идек. Яхшымы бу, начармы—башка мәсьәлә, ләкин бу факт.

Александр Невский һәм Даниил Галицкий рус тарихындагы борынгы ике культура тибын чагылдыралар: "көнчыгышчы" тип һәм "көнбатышчы" тип, әлеге нигездә соңрак рус фикеренең ике агымы барлыкка килгән, алар "славянофиллар" һәм "көнбатышчылар" дип аталганнар, болар дәүләтнең нигезләренә үк кагылганнар һәм хәзергә кадәр иҗтимагый фикергә тәэсир итеп торалар.

*Ахыры киләсе санда.*

---

[15] Золотая Орда в источниках..., с. 405.

[16] Ю.Кобищанов. Исламская цивилизация и северная Евразия. // "Независимая газета". 9 апреля 1996, с. 5.

[17] И.Д.Беляев. Земские Соборы на Руси.—М., 1902, с. 25.

Нурфия
Юсупова

# ТЫЛСЫМЛЫ СҮЗ ОСТАСЫ

Узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче еллары милли сүз сәнгатендә үзенчәлекле чорларның берсен тәшкил итә. Гомумкешелек мәсьәләләренә игътибар арту, дөньяны фәлсәфи иңләргә омтылыш көчәю, рухи тормышның активлашуы, фикер хөрлеге һ. б. сыйфатлар хас бу елларга. Лирика исә иҗтимагый-әдәби барыштагы мондый үзгәрешләрне тиз тоеп ала һәм аны лирик геройның хис-кичереше, символ-метафоралар аша укучыга җиткерергә омтыла.

Зөлфәтнең лирик герое да иҗатының буеннан-буена хакыйкатьне эзли. 1970 нче елда язылган «Дүрт җыр» шигырендә Зөлфәт үзе дә дүрт «җырын» атап, шигъриятенең тематикасын ачыклый. Аның шигърияте халыкның үткән традицияләрен яңартырга омтылу, фәнни-техник алгарыштан, «европалашудан» табигый яшәешкә борылырга чакыру мотивлары белән сугарыла, легенда, мифлардан килгән образларны үзәккә ала; эчтәлеге, фәлсәфи фикере, аны җиткерү формалары, әдәби-эстетик хасияте, тема-проблемалар яктыртылышы ягыннан да, сүз-сурәт үзенчәлеге җәһәтеннән дә аерым урын тота. Зөлфәт иҗатының тагын бер үзенчәлеге, һичшиксез, хәзерге татар поэзиясендә символларга аеруча еш мөрәҗәгать итүе, аларны төрле мәгънә төсмерләренә баетуы белән бәйләнә. Заманга бәяне, үз фикер-кичерешләрен шагыйрь символ-метафораларга төреп бирергә ярата, әдипнең иҗатын әнә шул символларны «чишеп» укыганда гына бөтен тулылыгында аңларга була. Бу яктан аны гасыр башындагы символист шагыйрьләрнең иҗади мирасы белән янәшә куярга да мөмкин. Әлбәттә, бер мәкалә чикләрендә генә шагыйрь иҗатын бөтен нечкәлекләре белән тулаем күзаллап бетерү, бигрәк тә тәфсилле бәя бирү—шактый авыр эш. Без исә бу язмабызда төп игътибарны бер якка—аның лирик шигырьләрендә, романтик рухлы поэма-балладаларында символлар бирелешен күздән кичерүгә юнәлтәбез, легенда, риваять сюжетлары, җил, йолдыз, ай, кояш кебек космогоник һәм мифологик образларның мәгънәви төрлелеген ачыклау аша Зөлфәт шигъриятенең фикер һәм шәкел байлыгын, фәлсәфи һәм мәгънәви киңлеген бәяләү-билгеләү белән чикләнәбез.

Әдәбият белемендә символларның ике яссылыкта кулланылуы билгеле: бер яктан символизм иҗат агымына мөнәсәбәтле әсәрләрдә төп терәк төшенчә ролен башкарса, романтик һәм реалистик әсәрләрдә аерым мәгънәне җиткерүгә хезмәт итә. Мәсәлән, XX йөз башында символизм агымы аерым сүз-образларны гына түгел, Сөембикә, Чыңгыз хан, Идегәй, Чура батыр кебек билгеле тарихи шәхесләрне, табигать бирелешен, мифик сюжетларны да символик югарылыкка күтәрә (Д. Заһидуллина). Язучылар, үз фикерләрен укучыга җиткерү ниятеннән, әзер мифик сюжетлардан гына файдаланып калмыйча, яңа «миф»лар да иҗат итә. Алар традицион мифны «уйнату»дан бигрәк, «сүтеп коралар», аның аша билгеле бер мәгънә, бәя үткәрергә омтылалар. Әлеге символлар романтик әдипләр тарафыннан да яратып кулланыла. Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» (1980) поэмасында да шундый символларның берсе белән очрашабыз. Шагыйрь үзе дә бу турыда искәртеп, болай дип яза: «Киресен түгел, киредән уйларга өйрән!»

Поэмада әкият символы—Алты бархан ыруы турындагы легенда—халык

язмышын, бүгенге һәм киләчәк турындагы уйлануларны житкерүче булып тәгәлләшә, вакыйгалар бәйләме еш кына лирик кичерешләр, уйланулар белән аралаша. Мифик сюжет аркылы автор яңа яшәеш моделен төзи; шартлы алым—үткән һәм бүгенгене кушу аша—мифологик һәм бүгенге чынбарлыкны бер ноктага жыя, фәлсәфи күзаллау аша яшәешкә бәя-мөнәсәбәт белдерергә омтыла.

Әсәрдә, хакыйкать темасы белән янәшә, шәхеснең үз-үзен һәм яшәешне танып-белү фәлсәфәсе үткәрелә. Гомумән, Зөлфәт ижаты хакыйкать, хаклыкны табигатьтә, матурлыкта таба. Шуның белән бәйләнештә әдип ижатына табигать һәм цивилизация, кеше яшәеше һәм табигать каршылыгы үтеп керә. Илаһи табигать белән цивилизация каршылыгы лирик герой күңелендәге конфликтны ачуга да таяныч хезмәтен үти.



Сулдан—Р. Гаташ, Роб. Әхмәтжан, Х. Мөдәррисова, М. Әгъләм, Зөлфәт.

Поэмада шагыйрь күрергә теләгән яшәеш сыйфатларын бергә туплаучы идеал итеп әкият күтәрелә, андагы аерым сыйфатларны автор кеше тормышына үрнәк буларак куя, чынбарлык исә хәзерге вакытта кешелек тырышлыгы белән барлыкка килгән ЭВМнар, машиналар, кеше катнашында барган сугыш кебек вакыйгалардан төзелә. Әсәр чынбарлыгы исә әнә шул реаль чынбарлык белән әкиятне берләштерә. Зөлфәтнең идеал-үрнәк рәвешендә әкияткә мөрәжәгать итүе дә очраклы түгел. Гадәттә, әкиятләрдә халыкның яхшы тормыш турындагы гасырлар буена барган, ләкин тормышка ашмаган якты хыяллары чагылыш таба. Ягъни әкиятнең максаты, тормыш чынбарлыктан бигрәк, халык хыялын чагылдырудан гыйбарәт. Билгеле булганча, борынгы Шәрык, һинд, иран, грек, рим халыкларының мифологиясендә кешелекнең алтын гасыры—Аллалар тормышын хәтерләткән Жир кешеләренең яшәеше турында мифлар сакланып калган. Зөлфәтнең әкиятендәге яшәештә әнә шундый күзаллаулар да төсмерләнә.

Поэманың һәр бүлеге лирик геройның хис-кичереш күчешенә бәйләп, әкиятнең бер сыйфатын аерып чыгара. Кереш өлеше үк аерым хасиятләрне укучыга житкерә, аның Шәрык әдәбиятыннан килгән әкияти элементлар (әфсен-төфсен, сим-сим һ. б.) белән баетылуы әсәргә романтик төсмер бирә. Әкиятнең сыйфатлары төсендә миһербанлык, эчкерсезлек, игелек, рухи, камил әхлак, буыннар бәйләнеше, тарихи хәтер, мәхәббәт, бердәмлек, Жир һәм Күк гармониясе, Намус, Вөждан аерып чыгарыла; аңа «Джанни Родари варианты» бүлегендә балачакка хас самимилек, сафлык, «Тукай догасы» бүлегендә халык бәхете, аның өчен көрәш сыйфатлары үрелә; әкият кызы белән бәйле төстә тагын бер хасият билгеләнә. Кыз символы символик һәм романтик әдәбиятта, гадәттә, матурлык билгесе булып йөри. Шуңа мөнәсәбәттә субъектив эчтәлектә әкиятнең янә бер сыйфаты Матурлык булып аңлашыла.

Әнә шул рәвешле әкият үз эченә бик күп сыйфат-хасиятләрне туплый, Зөлфәт алардан «жыелган» яшәешне үрнәк итеп күтәрә. Әкият кызының кешеләр тарафыннан учакка салып яндырылуы аша әдип укучыны бәхетле яшәеш хыялын кешелек үзе үк юкка чыгара дигән фикергә китерә. Учак бирелә явыз көч символы булып аңлашыла. Поэманың хис катламында чагылыш тапкан лирик геройның борчылу хисе әнә шул сәбәпкә тоташа. Әсәрнең буеннан-буена:

*Үкенечтән сыкрап куяр җаннар*
*Һәм кысылып куяр һәрбер йөрәк:*
*Бөтен килеш саклыйк дисәк Җирне,*
*Әкиятне саклап калу кирәк...*

юлларының даими кабатланып килүе, авторның идея-теләге белән янәшә, хис-кичереш сызыгында хиснең дәрәҗәсен дә көчәйтә. Зөлфәт чынбарлыкның ямьсезлеге белән Матурлык, Бөеклек, Намус, Мәхәббәт, Тигезлек символы булган әкиятнең сихрилеген каршылыкта бирә.

Лирик геройның әрнү төсмере белән эретелгән борчылу хисенә икенче сәбәп булып әкиятнең үткән буыннар яшәешендә калуы тәгәлләшә. «Дәшегез!» бүлегендә әкиятнең «карурманда—ботак тишегендә, ишек-тәрәзәләре такта белән кадакланган йортта, экипажы күптән һәлак булган космик корабларда, кара савытларында, Җидегәннең көмеш чүмечендә..» генә яшәве бүгенге тормыштан бөтенләй читтә торуын искәртә. Кешелек алга барган саен, үзенең табигый сизгерлегеннән, табигый сыйфатларыннан аерыла барган, ахыр чиктә бөтенләй җуйган. Шуның аша автор акылга сыймас «цивилизация»не кире кага, кешелекнең бүген «космик йокы»да булуын искәртә.

Ләкин поэманың соңгы строфасы юану төсендә киләчәк буыннарга өмет булып яңгырый. Канатлы ат метафорасы әнә шул өмет чаткысын беркетә:

*...Канатлы ат чаба җир буйлатып—*
*Азат җан ул—Хыял һәм Өмет!*
*Йөрәгендә—үлмәс дастан—Бәхет!*
*Ул булырга тиеш мәңгелек...*

Кешелекнең табигый башлангычына кайту теләге белән бәйләнештә Зөлфәтнең «Яшәгән идем» шигыренә дә кабиләләр яшәеше килеп керә. Лирик герой мәңгелектән уянып, үз яшәешенең башлангычына—кабиләләр чорына әйләнеп кайта. Автор шигырь чынбарлыгында үткәнне һәм бүгенгене бергә үреп бирә. Вакытларның кушылуы шагыйрьгә мәсьәләне гомумкешелек югарылыгына күтәрергә ярдәм итә. Кабиләләр чоры шигырь тукымасында лирик герой күңелендәге сафлыкка, матурлыкка омтылыш булып тәгәлләшә. Лирик геройны борчуга салган сөйгән ярның җирәнеп, аны ташлавы, кабиләнең яуга күтәрелүе исә сафлыкка, матурлыкка каршы көрәшне гәүдәләндерә.

«Тыным бетте...» (1976) шигырендә дә Зөлфәт халык телендә сакланып калган легенда-риваять сюжетыннан файдалана. Шуның ярдәмендә әсәр матурлыктан аерылуның яшәешне караңгылыкка китерүе турындагы идея белән баетыла. Әсәрнең сюжеты Түбән Новгород Кремленең Көянтә манарасы нигезенә тере килеш бер кыз бикләп калдырылуы турындагы риваятьне колачлый. Шушы кыз, аның язмышы бүгенге яшәешкә үзенчәлекле бәя бирүгә юнәлтелә. Югарыда искәртелгәнчә, кыз образы әдәбиятта, гадәттә, матурлык билгесе булып йөри. Чибәр кызның бикләп калдырылуы ярдәмендә әдип хәзерге көндә матурлыкның «бикләп калдырылуы» турында сөйли, матурлыкның цивилизация колы булуы хакында фикер үткәрә. Шул рәвешле лирик геройның әрнү, борчылу хисе кешелекнең көч-куәт, матди байлык артыннан куу нәтиҗәсендә чын, нәфис матурлыктан аерылуына бәйләнә. Табигый, илаһи сафлык кешеләр тормышыннан ерак, матди яшәеш аны каплап киткән. Шигырьдә чынбарлык белән хыял каршылыгы лирик герой күңелендәге каршылыкны да гәүдәләндерә. «Сездә кайсы гасыр?» дигән риторик сорау, даими кабатланып, композицион яктан шигырьне туплап тору белән бергә, төп фәлсәфи фикерне—матурлыкның югалуы белән чын яшәешнең туктап калуы турындагы идеяне гәүдәләндерә.

Зөлфәт иҗатында төп мотивларның берсе булган заман мәхшәренең гүзәл табигать дөньясына китергән зыяны өчен борчылу «Казан шәһәренең 39 нчы кварталы янындагы сазлыкның төнге бәхилләшүе» шигырендә дә үстерелә, табигый башлангычтан аерылуның рухи яшәешне юкка чыгаруы хакында фикер раслана.

Кешенең табигатьне, үзен чолгап алган тирә-юнь мохитне җимереп, киләчәккә юл яруы сәбәпле туган әрнү хисе фаҗигале язмышка дучар сазлыкның «үлем»е белән иң югары ноктага күтәрелә. Сазлык үзенә сердәшче итеп төнне, ә кеше исә көнне юлдаш иткән. Төннең романтик әдәбиятта серлелекне аңлатуын исәпкә алганда, әсәр тукымасында ул, бердән, сазлыкның авыр кичерешләрен, язмышының караңгылыгын күрсәтергә ярдәм итсә, икенчедән, кеше затының төн серләренә төшенә алмавы аның табигатькә дошманлыгыннан килә, дигән фикерне үткәрә. Зөлфәтнең теләге—кешене табигатькә якынайту.

Шагыйрь тарихи легенда сюжетларына да мөрәҗәгать итә, аларда, кагыйдә буларак, күренекле шәхесләр үзәккә алына, алар билгеле бер мәгънә төсмере белән сугарыла. Шундый шигырьләрнең берсе булып «Сөембикәнең хушлашу догасы» (1978) тора. Әсәрнең нигезенә Сөембикәнең Казаннан китүе турындагы риваять салынган. Шагыйрь бирелә борынгы мифологик легендаларның эчтәлеген тулысынча диярлек үзгәртә һәм Казанның азатлыгын саклап калу өчен барган канлы сугыш күренешләренә бәйли. Соңгы өметләрнең дә сүнүе, шәһәр нигезенә эт күмелүе белән бәйле төстә үстерелә барган хәсрәт ахырда иң югары ноктасына күтәрелә. Лирик геройның борчылуына, хәсрәтенә икенче сәбәп булып еллар узганнан соң да халыкның акылына килмәве, сугышларның өзлексез дәвам итүе тора. Сөембикәнең китүе турындагы легенда-риваять сюжеты татар халкының бүгенгесенә бәя бирүгә юнәлтелә, Сөембикә образы үзе милли азатлык билгесе буларак аңлашыла.

Зөлфәт иҗатында еш кулланылган образларның тагын бер төркемен космогоник символлар тәшкил итә. Шундый символларның берсе—йолдыз—шагыйрь өчен илһам чыганагы булып тора. Традицион кулланылышта ул—моңлы тавышлы бер кош та, бәхет, мәхәббәт, сафлык, сөйгән яр символы да. Ә Зөлфәт аны еш кына мәхәббәт, сагыну, мәңгелек, язмыш, соңгы чорда язылган шигырьләрендә ялгызлык, гомер агышы кебек мәгънә төсмерләре белән баета. Күпчелек әсәрләрдә йолдыз—мәхәббәт янәшәлеге тудырыла. Мәсәлән, «Күк тирәге йолдызланган чак...» шигырендә йолдыз символы мәхәббәтнең матурлыгын да, яктылыгын да, бөеклеген дә искәртә. Мәхәббәт кебек изге һәм мәңгелек хисне илаһи Күктәге йолдыз белән чагыштыру, гомумиләштерү аша шагыйрь мәхәббәт фәлсәфәсен үткәрә һәм Мәхәббәтне Җирне генә түгел, Галәмне гармониядә тотучы көч югарылыгына күтәрә. «Төнге гөлләр» шигырендә мәхәббәтнең җылысын, кайнарлыгын бирүче йолдыз капма-каршы—Галәмнең салкынлыгын ачуга юнәлтелә. Шуның аша автор Кеше йөрәгенең җылысы белән Галәм җанының салкынлыгы контрастлыгын тудыра һәм Кешенең бөеклеге, Мәхәббәтнең таулар күчерердәй чиксез көче турындагы фәлсәфәгә килә. Сөю, сөйгән ярны сагыну мотивлары үзәккә алынган «Бар килеш...», мәхәббәтнең көчен йолдыз нурының яктысы аша чагылдырган «Бул гына!», шигырьләрендә дә йолдыз -мәхәббәт янәшәлеге күзәтелә.

Йолдызның кеше тормышында юнәлеш билгеләүче изге нокта булуына бәйләп, икенче мәгънәсе дә үстерелә: йолдыз—язмыш, йолдыз—гомер агышы. Мондый концепция белән без «Шулай икән...» фәлсәфи шигырендә дә очрашабыз. Әсәр тукымасында автор мәңгелек һәм фани дөнья каршылыгын тудыра, аның аша мәхәббәтнең узуы белән гомернең үтүе турындагы фәлсәфи уйланулар үткәрә. «Татар теленең каргышы» шигырендә йолдыз символы—өмет чаткылары, ышаныч билгесе буларак яңгырый. Яшь буынны караңгылык, наданлык биләп алуы, аларның иманы, әхлагы, намусы юклыгы лирик герой күңелендә сызлану тудыра.

Зөлфәтнең кайбер шигырьләрендә йолдыз—фаҗига янәшәлеген күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, «Ялгыз сандугач» шигырендә кара йолдыз афәт, фаҗига, икенчедән, илнең караңгы язмышы, өченчедән, өметсезлек, чарасызлык билгесе булып чагыла. Йолдызның кара төстә бирелүе дә фаҗиганең, ил өстенә килгән афәтнең көчен, дәрәҗәсен билгели.

Зөлфәт иҗатында җил образына да еш мөрәҗәгать ителә. Шагыйрьнең күп кенә шигырьләрендә җил—фаҗига янәшәлеге тудырыла. Мәсәлән, Тукайга багышлаган «Ялгызлык» шигырендә беренче строфа ук шигырьгә «ил өстендә айкалган җил, тәрәзәләргә каткан боз» тудырган борчылу хисен алып килә. Шагыйрьнең бөтен

яшәешен томалап торучы илдәге сәяси вәзгыятьне—цензура хөкемен, милләтне кысу, изү сәясәтен—символлаштырган җил, боз образлары чорны күз алдына бастыра. Алдагы строфалардагы шәм уты, яшен уты, шәүлә кебек образлар да фаҗигане көчәйтә. Икенче строфада әлеге хискә Тукайның гомерен, тормыш барышын, язмышын берләштергән юлның билгесезлегенә, шагыйрь кичергән көннәрнең ямьсезлегенә бәйле рәнҗү төсмере дә кушыла. Шигырьнең өченче строфасында ана шом өстәлә. Каршылык тудырган риторик сорау белән риторик җавап хисне тагын да үстерә, шәмнең утын сүндерергә омтылуның көчәя баруына ишарәли. Идеологик кануннарны таныРга ярдәм итүче мистик кара шәүлә образы кешелекне җимерүче көчләрне символлаштыра. Әнә шулай мистикага сәяси фикер үрелеп китә, шәм өстендә басып торучы көч ачыла. Суфичылык традицияләрен янартып, шәм шагыйрь шәхесен символлаштырып та килә. Ут исә аның яшәеше, гомер агышы белән бәйләнешне тудыра. Салкын җил белән җылы каршылыгы яшәү һәм үлем, ак һәм кара, мәхәббәт һәм рәнҗү кебек капма-каршы төшенчәләр белән бәйләнешкә керә. Салкын җил—Тукайсыз калган татар халкының мәңге «җылы» таба алмаячагына ишарә. «Караңгы җил», «Ялта тыкрыгында», «Игенче», «Эт тоту көне», «Тамыр көлләре» һ. б. шигырьләрендә дә җил символы сәясәт тудырган фаҗигане ачуга юнәлтелеп, чорга бәя бирүгә хезмәт итә.

Зөлфәтнең «Кайчан, кайда», «Сөйләшик бер гомер синең белән» кебек шигырьләрендә җил-язмыш, гомер агышы концепциясен дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, соңгысында җил әсәргә гомернең, яшьлекнең үтүе белән бәйле сызлану фәлсәфәсен алып килә. Гомумән, җилнең моңсулык, күңелсезлек төсмеренә баеп килүе халык җырлары традицияләрен янарта.

«Буранның бураны» шигырендә җил битарафлык символы төсен ала. Лирик геройның үпкә хисе дә җилнең битарафлыгы белән үрелә. Җилнең дәшмәве, гамьсезлеге исә юанычның була алмавын искәртә.

Шагыйрьнең аерым шигырьләрендә җил-шатлык янәшәлеге тудырыла. «Җилләр чиртә сары камылларга» шигырендә ул табигать, яшәү матурлыгыннан туган шатлыкны гәүдәләндерсә, «Баш очында...» шигырендә лирик геройның Мәңгелек серенә төшенүдән туган шатлыгына үрелә. «Син уемда...» шигырендә җил мәхәббәтнең матурлыгын да, сөйгән ярдан аерылуның сагышын да, сагыну сагышын да гәүдәләндерүче күпмәгънәле образга әверелә, җил—сагыш—мәхәббәт комплексын барлыкка китерә.

«Илем» шигырендә җил үткән чорлар, бүгенге көннәр, киләчәк заманны вакыт кысасында берләштерүче образ буларак тәгаелләшә. Илнең авыр, яралы язмышы, өметләрнең акланмавы, чарасызлык лирик геройның күңелен биләп алган борчылу катыш әрнү хисен тудыра. Хисенең шушы сәбәпләрен җил образы бер бәйләмгә туплый.

Зөлфәт космогоник символлардан булган ай образын да төрле мәгънә төсмерләренә баета: ул табигатьнең матурлыгын, мәхәббәтнең сафлыгын, көчен белдереп кенә калмый, афәт, фаҗига булачагын хәбәр итүче күпмәгънәле символ буларак та чагылыш таба. Мәсәлән, «Сүтелгән дә айның толымнары», «Ай һаман дәү» кебек шигырьләрендә табигатьнең матурлыгын, аның сихри мизгелләрен чагылдырган ай образы «Кара күбәләк», «Изге ялвару» һ. б. әсәрләрендә фаҗигалелекне хәбәр итүче билгегә әйләнә. «Аулак сукмак», «Ике гашыйк», «Синең алда», «Әйтәсем килә» кебек шигырьләрдә исә капма-каршы яссылыкта—Мәхәббәтнең изгелеген, сафлыгын, мәңгелеген белдерүче буларак чыгыш ясый.

Зөлфәт шигырьләрендә киң кулланылган символик образларның тагын берсе—кояш образы да—төрле мәгънә төсмерләренә төрелеп тәкъдим ителә. Халык иҗатында кояш—бәхетле тормыш, якты киләчәк, тирән мәхәббәт, сөйгәннең гүзәллеге һәм башка бик күп якты күренешләрнең символы. Ә Зөлфәт шигырьләрендә ул бәхетле тормыш, шатлык, хакыйкатьне белдерү белән беррәттән, бәхетсезлек, начарлык, тирән фаҗига ролен дә үти. Мәсәлән, «Күз тимәсен берүк», «И яраткан еллар...» әсәрләрендә яктылык, матур киләчәк кояш символы аша чагылыш таба; «Җилләр чиртә сары камылларга» шигырендә әлеге символ туган як матурлыгын, аның гүзәллеген белдерергә ярдәм итә; «Яулар илем», «Сандугач

оясы» шигырьләрендә кояш—шатлык буларак чишелә һәм лирик геройның табигать, яшәү матурлыгыннан туган шатлыгы белән бәйләнә; «Ялта тыкрыгында» шигырендә һәм «Җирдән кайтышлый» поэмасында кояш символы хакыйкатьне ачуга юнәлтелә. Зөлфәт әсәрләрендә яхшы, бәхетле, Имин, шатлыклы тормыш символы булган Кояш образына кайчак капма-каршы вазифа да йөкләнә: шагыйрьнең хис тойгылары, тирән кичерешләре, җиһандагы язмышы белән бәйле төстә кара кояш образы үтеп керә. Мәсәлән, «Илем» шигырендә мондый күренеш белән очрашабыз:

*Ниләр көтә сине, бичара ил?*
*Күз яшедәй һәр чык—таңнарда...*
*Кара кояш бата офыгында,*
*Гел карадан таңың уяна.*

Зөлфәтнең күп кенә шигырьләрендә болыт образы да гомер, яшьлек агышы, ышаныч, намус, ап-ак хыяллар белән бергә илнең караңгы язмышын, авыр, аянычлы тормышын да белдерүче мәгънәләргә ия. «Шундый чагы әле җанымның» шигырендә ул намус, ышаныч, өмет, дәрәҗәсенә җиткерелә; гомернең, яшьлекнең агышы белән бәйле сагыш фәлсәфәсе «Мәңгелек» шигырендә болыт символы аша чагыла; «Тезлән дә бер», «Адашкан болыт», «Соңгы томан» шигырьләрендә ул илнең авыр язмышын, сагыштан туган авыр уйларны белдерүгә юнәлтелә.

Чиксез киңлек, мәңгелек, биеклек билгесе булып йөргән күк образын да Зөлфәт яна төсмерләр белән баета. Күк мәхәббәтнең көчен, бөеклеген дә, шул ук вакытта фаҗига, афәтне дә белдереп килә. Мисал өчен «Ай һаман дәү» шигырендә ул табигатьнең матурлыгын ачарга ярдәм итә; күкнең бөеклеге, биеклеге «Күк тамчысы», «Көтелмәгән тәэссорат» шигырендә чагылыш таба; «Нигә кирәк», «Кайнар кәлтә юлы», «Гозер» шигырьләрендә күк—мәхәббәтнең көчен, бөеклеген ачып бирүче символга әйләнә.

Шул рәвешле, Зөлфәт иҗатында чагылыш тапкан символик образлар, төрле мәгънә төсмерләре белән баеп, хәтта бер әсәр чикләрендә дә язмыш фаҗигасен, сәясәт китергән хәсрәт-кайгыны, чарасызлыктан туган сызлану тойгысын чагылдырудан алып, битарафлыкны һәм сагыш аша шатлыкны, Мәхәббәтнең бөеклеген ачуга кадәр үстерелә. Зөлфәт иҗаты хәзерге татар поэзиясендә бер яктан традицияләрнең көчәюен раслый һәм милли сүз сәнгатен яңа сәнгати чаралар, фәлсәфи фикерләр белән баета.

Ркаил
Зәйдулла

# ДУЛКЫН БИЕКЛЕГЕ

*Монда давыл*
*Дулкын биеклеге белән үлчәнә.*
Разил Вәлиев.

Разил Вәлиев тыштан салмак, сабыр күренә. Салкын кырыслык чалымнары да бар сыман йөзендә. Түрәлек иткән кешегә—ә ул күп еллардан бирле халык депутаты, хәзер Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе,—шундый кыяфәт килешәдер дә бәлки. Хәер, ул читтән караганда гына шундый. Якыннан белүчеләргә билгеле—Разил Вәлиев уенчак күңелле, үткен телле, җор кеше. Аның теленнән төшкән канатлы сүзләрне, мәзәкләрне каләм әһелләреннән кем генә белми икән? Мондый чәчәнлек, импровизатор сәләте тагын мәрхүм Илдар абый Юзидә генә булса булгандыр.

...Без, университетка кереп тулай торакка урнашу белән, китап кибетеннән яшь шагыйрьләрнең берсеннән-берсе юка шигырь җыентыкларын җыеп кайттык. Кайберләре авылдан ук ияреп килгән иде. Разил Вәлиевнең «Зәңгәр кабырчыклар» китабы да шулар арасында. Кич буе алмаш-тилмәш кычкырып шигырьләр укыйбыз. Чагыштырабыз, бәялибез. Кайсыбер китаплар кыздырылган бәрәңгеле таба астына куела.

Шундый уен да бар иде: берәү кычкырып шигырь укый, калганнар аның авторын әйтергә тиеш. Янәсе, үзенчәлеклеме, шагыйрьнең үз стиле бармы?

«Зәңгәр кабырчыклар»да төрле шигырьләр бар, бүгенге күзлектән караганда, әлбәттә, кайберләре өйрәнчектәр дә... Әмма авторның холкы, үзгәлеге аларда да ачык сиземләнә иде.

*Бүген минем нәрсәләрем юктыр—*
*белмим...*
*Өметем бар ләкин,*
*түм-түгәрәк өметем—*
*күгем.*

Түм-түгәрәк күк—Тәңре! Һәр шагыйрь шуңа якынаерга омтылмыймыни?!

Шекспир әйткәнчә, һәр кеше актер булса, сәясәтче исә икеләтә актер. Ул һәрдаим битлек киеп йөрергә, вәзгыятькә карап аларны алмаштыра да белергә тиеш. Белмим, бәлки Разил Вәлиевнең дә түрә-кара алдында үз битлекләре бардыр, миңа алар кызык түгел. Кемнең кемлеген («Ху ис ху» хәзер модада, эте дә, бете дә «ху ис ху»!) белергә теләсәң, аның шигырьләрен укы, шагыйрь шигырендә алдаша алмый. Җаны чистаның сәтырларыннан нурлар чәчри, ә инде күңелендә кер булса... әйе, әйе...

Дөньяны, йә үзен үзгәртү турында Разил Вәлиевнең каләмдәшләренә мәгълүм бер шигыре бар. Әдәбият сөючеләр белән очрашуларда ул аны сөйләми калмый. Җәлил дигәндә «Җырларым» искә төшкән кебек, Разил Вәлиев дигәндә дә шул шигырь хәтердә янара. Бу табигый да—һәр шагыйрьнең шундый мәсләки шигыре була... булырга тиеш...

*Чәчәкләргә үз исемем бирәм,*
*Минем терелүм көнгә, минем үләм.*
*...Үлем белән якалашканда да*
*Акны кара диеп сөйләмәм.*

Менә ул—шагыйрьнең холык-фигыле. Һәм ул гомере, эш-гамәлләре белән үзенең шигыренә тугъры калды, киләчәктә дә шуңа хыянәт итәргә язмасын. Чөнки, әдәбият тарихыннан белүебезчә, шигырь хыянәтне кичерми.

Яшьлегендә сайлаган мәсләген—ә бу, әлбәттә, Разил Вәлиев өчен милләт яшәеше, ил гаме, халык мәнфәгате,—җуймаса да, гомер юлларында шагыйрь үзгәрми калмый, әлбәттә. Ә менә дөньяны да—татар дөньясын!—бераз яхшы якка үзгәртү бәхете һәркемгә дә тәтеми.

Артка борылсаң—игелекле эшләр...

Шулай да Разил Вәлиевне һич тә аксакал буларак кабул итә алмыйм. Сакалын кырып йөргәнгә генә түгел... Мин бит аның чем кара чәчле, шундый ук сакал-мыеклы чакларын да хәтерлим. Әле кичә генә кебек...

Ә бүген яшел чирәмгә салмак кына кар катыш кызгылт сары яфраклар төшә. Йөзгә тожымнар орына.

Шул арада утыз ел да үткән.

Ундүрт яшемдә мин беренче мәртәбә Казандагы гәҗит-журнал редакцияләренең ишеген кактым. Ул заманнарда матбугат йортына юлны бүлеп милиция утырмый иде әле.

Ишекләр ябык, бикле.

Шундый ишекләргә төртелеп йөри торгач, «Ялкын» журналы редакциясе урнашкан тугызынчы катка менеп җиттем.

Ниһаять, анда бер ачык ишек күренде. Түрдәге өстәлдә калын кысалы күзлек кигән сакал-мыеклы бер абый, дөньясын онытып, язып утыра.

Бусагада озак кына күзәтеп торуымны ул сизмәде.

Күпмедер шулай басып торганнан соң, кыяр-кыймас кына тамак кырып куйдым. Оялчан идем әле ул вакытта... Максатым бик мөһим булса да—шигырьләремне бер шагыйрьдән укыттырып бәясен ишетү!—кешене эшеннән бүлеп йөрүнең килешмәгәнен аңлаганмын, күрәсең.

Күзлекле абый сискәнеп башын күтәрде.

Тавышымны көр чыгарырга тырыштым:

—Шигырьләр алып килгән идем...

—Бүген ял көне ич,—диде ул гаҗәпләнеп.—Эшкә килүемне кайдан белдең?

—Мин язучыларның ял көне юктыр, дип уйлаган идем.

Ул кычкырып көлде...

Разил Вәлиев белән шулай таныштык.

Әлбәттә, язучыларның ял көне юк. Әмма ул чакта Разил Вәлиев эш бүлмәсенә мәҗбүри килеп утыргандыр инде. Онытылып язар өчен өстәлең белән бергә-бер калу кирәк бит.

Кабинет—язучының эш урыны. Шул урынга үлгәнче тиенмәгән язучылар да бар.

Хәер, Разил Вәлиевне хәзер дә кайбер ял көннәрендә эшкә килә, диләр. Юкса, киң фатиры да, шәһәр читендә авыл өе дә, китаплар белән шыплап тутырылган кабинеты да бар. Ул—эш аты шул. Күрәсең, аңа язар өчен күнегелгән даирә, эш иясенең почмактан карап торуы кирәктер. Балачагымда өлгермәгән шигырьләр тотып кергән төсле, вакытлы-вакытсыз «эшем изләре» генә борчып йөрмәсен.

Борчымыйлар сина! Аның эштәге кабинетында берничә тапкыр булганым бар. Берөзлексез телефон чылтырый, сәркәтип кыз кемнендер килгәнен хәбәр итә, әрсезрәкләр, ишекне ачып, башларын да тыгып карыйлар. Ул баш турында үзләре югары фикердә булгач, бүтәннәрнең дә аны зарыгып күрәсе килә, дип уйлыйлар, билгеле. Разил Вәлиевнең һәркемгә вакыты җитә, барысына да игътибарлы булырга тырыша. Башка чиновникларның хозурындагы шикелле рухны, җанны изеп торган албасты сизелми биредә.

Разил Вәлиев—унай кеше.

Уңышлы әдип.

Унган ир-ат.

Шагыйрьләр арасында теләсә нинди эшне умырып башкара торган эшлекле кешеләр сирәк очрый. Арабызда калак та кага белмәүчеләр бар. Разил Вәлиевнең исә һәр эшкә кулы ятып тора, шуңа күрәдер дә ул бернинди авырлык алдында да югалып калмый. Университетка укырга кергәч, аңа тулай торактан урын бирмиләр. Шәһәрдә таянычы булмаган үсмер егет фатир эзли башлый. Шунда ул Казан елгасы тирәсендәге урамда яшәүче Вәли бабай белән таныша. Бер иптәше белән шуның җимерек сараен «арендага» алып, алар аны идән-түшәмле итәләр, мич чыгаралар. Идәнгә хәтта әрҗә такталарын ышкылап «паркет» тезәләр. Җимерек алачык чын сарайга! әверелә. Шагыйрьләр, шәкертләр сараена!

Затлылыкка омтылу яшьтән үк хас булган Разил Вәлиевкә...

Күрәсең, бу сыйфат та нәселдән килә торгандыр.

Каты холыклы, үҗәт, аягында нык басып торучы кеше була аның бабасы да... Колхозлашу елларында картның бар малын тартып алалар. Ярый әле сөрмиләр, чөнки авылда тегермәннең рәтен белүче булмый. Ул үз тегермәненә, ялланып, хезмәт хакы алып эшли башлый. Әмма колхозга керми. Гомерен ялгызак игенче, тегермәнче, тимерче, балта остасы булып үткәрә.

Бабасының язмышы әдәбиятта тирән гомумиләштерүләргә этәрә язучыны. «Мирас» романындагы Зыятдин картның прототибы нәкъ менә шул бабасы инде. «Ә бабай... бөтенләй башка. Нигә алай икән? Бер карасаң, аның уйлары да, максаты да зурдан түгел сыман... Җирдәге һәр кеше үз өендә, үз ишегалдында, үз бакчасында тәртип урнаштырырга тиеш, ди ул. Җирдәге һәр кеше бәхетле булса, ил дә бәхетле була.»



*Разил Вәлиев Төркиядә яшәүче милләттәшебез Надир Дәүләт белән.*

Шушы фәлсәфә Разил Вәлиевкә гомере дәвамында юлдаш.

Максатчанлык, үз сүзен бирмәү Разилгә бабасыннан күчкәндер. Алай дисәң, әтисе Исмәгыйль абзый да булдыклылыкка аңардан калышмаган. Ул икенче ярда —колхоз рәисе! 1956 елда уныш алу буенча Татарстанда беренче урынны алган өчен Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә. «Әтисе, киресенчә, иң элек ил кайгысын кайгырта, бөтен илдә берьюлы тәртип урнаштырмакчы була».

Аңлашыладыр, атаның да, бабаның да максаты, теләге бер, тик шуны гамәлгә ашырганда тактик аерымлыклар гына бар. Хикмәт тә нәкъ шунда шул! Ниндидер конкрет бер кешегә ярдәм итүгә караганда, абстракт халык өчен тырышуы җиңелрәк. Зөлфәт әйтмешли: «Майданнарда шигырь сөйләдем мин, керфекләрен синең яшьле чакта».

Хәер, колхоз рәисе өчен халык абстракт була алмый. Әнә берсе ат сорап килә, икенчесенә печән кирәк... Бәйсезлеген югалткан игенче күндәм була. Безнең илдә күндәмлек—бәхет билгесе.

Әдәбиятка мәхәббәте Разил Вәлиевне Түбән Кама, Чаллы әдәбият берләшмәләренә китерә. Язу-сызуның үтә дә четерекле эш икәнен бик иртә аңлый ул. Җиденче

сыйныфта укыганда микән, элек әчеп-тузып, хәзер тәкъва булып йөргән бер абзый турында район гәҗитендә мәкалә бастыра Разил. Икенче көнне үк әлеге абзыйның малайлары «яшь язучыны» тотып дөмбәслиләр.

Беренче каләм хакы—истә калырлык!

Дөньяга чыгу юлларының шома түгеллегенә ул шулай иртә төшенә. «Алдан ук кисәтеп куйганнары» өчен теге малайларга рәхмәт укыйсылары алда була әле. Һи, ул малайлар якты хатирә генә—ачыктан-ачык кыйнарга чыккан ич алар! Мыштым гына арттан килеп тешләүче әнчекләр куркыныч...

...1986 елда ул җиде ай Казан, Мәскәү хастаханәләрендә аунады.

Мәскәүдә вакытта мин дә, Марсель Галиевкә ияреп, аның хәлен белергә кергән идем. Сырхау шагыйрь чыра кебек кенә калган... «Тукай егерме җидедә үк үлгән әле»,—дип әллә үзен, әллә безне юатты ул.

Чыра түгел, чыраг!

Чирләрне дә, гайбәтләрне дә егып, Разил Вәлиев яңадан аякка басты. Үзеннең дөя түгеллегенне расларга тырышу да кешегә (бигрәк тә совет кешесенә) зур гайрәт бирә бит.

Димәк, өмет әле һаман түм-түгәрәк килеш. Тәңренең ымлавын күрдеме ул анда?

Илдә үзгәрешләр башланган чор... Рәсәй дәүләте кризиска тарган чорларда безнең татарга җилкәсен язарга бераз җай чыга гадәттә. Бу юлы да чабата бавына басып абынмаска иде бит. Нидер эшли торган вакыт. Андый чакта ничек үләсең?!

Яшьтән үк җәмәгать эшләренә чос Разил Вәлиев сәясәткә кереп чумды. Үзгәрешләр башлануга түрә-караның каушап калуы, яңа сәяси көчләрнең булмавы иҗтимагый мәйданда бушлык хасил иткән иде.

Өстәгеләрнең «ә» дигәненә «җә» дип, астагыларның башына тибеп яшәгән чиновниклар, капкачын бәреп пары атылган казан янында берара мингерәеп, аптырап, каушап калдылар шикелле. Бераздан аңга килделәр килүен. Янә идарә дилбегәсен кулга алуга ук үзләренә хас өлгерлек белән үрчи башладылар. Гади кеше янә араталар артына куып кертелде.

Ә үзгәртеп кору елларында нинди өметләр уянган иде бит! Ниһаять, бездә дә демократия булачак, имеш... гадел мөнәсәбәтләр урнаштырабыз... фәлән-төгән... Мәскәүнең озын кулыннан котылып та булмасмы әле... Азатлык—татлы сүз. Тик аңа ирешер өчен чиксез фидакярлек кирәклеген генә онытканбыз. Шулай да, тарихны белмәгәндәй, без дә бер канатланып алдык. Югыйсә, системасына карамастан, дәүләт үзе нинди дә булса диктатура коралы бит! Хәер, кысыр, әмма гүзәл омтылышлар белән яшәп алу үзе үк кешене соры яшәештән өскә күтәреп куя, пакьли төсле. Болганчык суда балыкны мулрак тотып калырга тырышучы кемсәләрнең яңәшәдә мәш килүен дә искәрмисең... Хәят диңгезе дулкынланганда, күбек пәйда булуы да табигый.

Ул елларда каләм ияләренең дә шактые сәясәт белән ярәшеп алды. Милли-азатлык хәрәкәте юлбашчылары арасында язучылар аз түгел иде. Украина «Рух»ының яртысын диярлек әдипләр тәшкил итте.

Мисал өчен Балтыйк буе язучыларын да искә төшерергә мөмкин. Гамсахурдиа, Ардзинба, Илчебәй, Тер-Петросян, Ландсбергис кебек гуманитарлар исә хәтта ил башына ук менә алдылар. Тик кайда алар хәзер?

Казаннан пар чыгып беткәч, бу романтикларга сәясәттә урын бетә. Яңа каһарманнар йә прагматикка әверелеп сәясәттә калырга, йә язу өстәле янына кире кайтырга мәҗбүр булдылар.

Татарстанда, әлбәттә, сәясәт белән азмы-күпме шөгыльләнергә тиеш кеше хакимияткә турыдан-туры каршы төшә алмый. Хәтта ул көндәш көч булмаса да, ярым мөстәкыйль фикерләре белән туйдыра башласа, төрле юллар белән аны киртәгә кертү җаен табалар.

Бүген Рәсәй янә торгынлык, авызлык заманында яши. Рәсәй парламентының җитәкчесе: «Парламент—бәхәсләшү урыны түгел»,—дигәч, күпләр башын кашыды. Кремль кушканны гына кәгазьгә теркәүче орган булса, аның нигә кирәге бар? Кануннар гомер-гомергә төрле фикерләрнең чәкәләшүеннән пәйда булган ләбаса!

Сиксәненче еллар ахырындагы чагыштырмача гадел сайлауларда җиңеп чыккан

депутатлар корпусын искә төшерегез. Милләтебезнен талантлы, сөрсемәгән уллары барлыгына шунда янә ышандык түгелме соң?

Гадел сайлауларда җиңүе җиңел түгел. Разил Вәлиев Казан шәһәренең Вахитов сайлау округында, альтернатив сайланып, халык депутаты булды. Урыс-улак тулы шәһәрнең үзәгендә авыл малае, татар язучысы җиңеп чыкты! (Соңрак та ул Түбән Кама, Зеленодольски кебек шәһәрләрдә партия исемлеге буенча түгел, ә бер мандатлы округларда сайланды.)

Шул сайлаулар алдыннан, 1988 елның октябрь урталарында, бер газета өчен аның белән әңгәмә корган идем. Җәмгыятьнең өске катламнарына ыргылган 41 яшьлек ир-атның, язучының ул вакытта сөйләгән сүзләре хәзер дә гыйбрәтле. Ул чакта Разил Вәлиев—бераздан аның тырышлыгы белән «Милли» исемен алачак!—Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсендә директор булып эшли иде.

*«Тормышта һәрнәрсә дә бер-берсе белән бәйле. Яшүсмерләр арасындагы җинаятьчелек—җәмгыятьтәге рухи ярлылыкның, әхлаксызлыкның нәтиҗәсе ул. Элек китапны һәр өйдә кадерләп саклыйлар иде, басма сүзгә ышаныч зур иде. Бүген миллионлаган томнар подвалларда череп ята, янгыннарда юкка чыга (Разил Вәлиев, депутат булгач, китапханәгә яңа биналар алырга иреште—Р. З.). Ә без тыныч кына мәрмәр рестораннар төзибез, «җирнең тыйнак кешесе»н данлап зур сарайлар торгызабыз (боларга хәзер казинолар, фитнес-үзәкләр, офислар, сәүдә нокталары, ипподромнар, бозлы сарайлар... дип тә өстисе килә—Р. З.). «Барысы да—балаларга!» дибез, ә алар иң ярлы, иң бетәшкән курчак театрына йөриләр. (Ул урнашкан иске чиркәүне поплар үзләренә сорап интектергәнгәме, күптән түгел курчак театрына дигән яңа бинаның проектын расладылар бугай. Балаларга озак көтәсе калмады. Тик алар үсә-үсә бала булудан туктыйлар шул—Р. З.). Без халыклар дуслыгын сакларга ант эчәбез, ә күпме халыкларның үз телендә укырга мөмкинлеге юк, алар милли традицияләрен җуялар.*

*Экология турында сөйләсәк тә, минемчә, мәдәни экологиягә игътибар җитенкерәми. Аны сангa сукмау кешеләрне әхлакый яктан үтерә. Шуна күрә мин Казандагы һәм республикадагы барлык мәчетләрне, чиркәүләрне һәм башка гыйбадәтханәләрне, архитектура һәйкәлләрен яңадан торгызырга кирәк, дип саныйм. Печән базары мәчетен реставрацияләү турындагы проект бүген өстәлемдә ята (Әлеге мәчетнең манарасы Р. Вәлиев тырышлыгы аркасында да калкып чыкты—Р. З.). Шулай ук болгар-татар язма әдәбиятының чишмә башында торучы Кол Галинең һәйкәлен салу да көн тәртибендә тора. (Казанның мең еллыгын үткәргән көннәрдә һәйкәлне күрү бәхетенә ирештек—Р. З.). Үз шәһәремнең патриоты буларак, минс Сөембикә манарасының язмышы да борчый. Казанның символы булган бу манара безнең гамьсезлегебезнең, маңкортлыгыбызның символына әверелә бара бугай (Хәзер реставрацияләнгән манара өстендә ай балкый—Р. З.).»*

Әлеге әңгәмәне искә төшерүем юкка түгел. Әлбәттә, әлеге гамәлләр Разил Вәлиевнең эшчәнлегенә күрә генә башкарылган, дип әйтүдән ерак торам. Әмма ул милләтпәрвәрләрне борчыган мәсьәләләрне ил күләмендә күтәрә белгән, шул юнәлештә көчен дә, вакытын да кызганмыйча казганган. Моны беркем дә инкяр итә алмас.

Депутат булып сайлануга ук биргән вәгъдәләрен онытткан кешеләр югыйсә бихисап бездә...

Милли мәнфәгатьләр Разил Вәлиев тормышының төп мәгънәсен тәшкил итә.

Кешедә милли рух ничек уяна?

«Түбән Камада мәктәптә укыганда шәһәрдәге урыс телле татар малайларының безне—авылдан күчкән малайларны, «татарва» дип мыскыллап, кыйнарга килүләрен күргәч, үз милләтем өчен ачыну хисе уянды»,—ди шагыйрь. Күрәсең, милли язмыш турында гамьләнә башлау өчен нинди дер этәргеч кирәктер. Югыйсә, совет халыклары арасында сез бертигез, татар—бөек халык, дип колакка тәкърарлап торганга безнең иммун системасы бөтенләй сафтан чыга язгандыр да...

Тик барыбызныкы да түгел.

1968 елда, язучыларның чираттагы корылтаенда, Разил, иптәшләре белән, Г. Камал исемендәге Академия театрының балконыннан яшьләр өчен журнал

чыгаруны таләп иткән листовкалар ташлый. Ул вакытларда бу «крамоланың» Казанда нинди шау-шу кузгатуын күз алдына китерүе кыен түгел.

1979 елда ул үз авылының мәчетенә манара куйдыра. Бу мәчетне салуда аның алда телгә алынган бабасы башлап йөргән була. Ә бәреп төшерелгән айны әнисе үземе, әллә энеләренә әйтепме, абзарларына алып кайтып, иске-москы астына күмеп куялар. Шунда ул ярты гасырга якын саклана. «Яшен тамыры» китабының каләм хакын алгач, Разил, Казаннан ике реставратор ияртеп, авылына кайтып төшә. Энесе Рәмзил лапас корырга дигән такталарын бирә. Шунысы кызыклы: авыл-район түрәләре әлеге гамәлне күрсәләр дә күрмәмешкә салышалар. Бу бит дәһрилек гөрләп чәчәк аткан еллар!

Әлбәттә, Казанга «жалу» язучылар була. Янәсе «мәчет төзүче коммунистның КПСС сафларында торырга хакы бармы?»

Ләкин Аллаһ юлындагы кешегә андый дошманнар куркыныч түгел.

*Дошманыма карап юлга салам,*
*Үзгәртәм мин тормыш агышын.*
*Ул булмаса, кайдан белер идем:*
*Кайсы дөрес, кайсы ялгышым.*

Иблис жанлы кешеләр таш атканда, яхшы кешене фәрештә канаты белән каплый, диләр. Ул биртелгән фәрештәнең исеме Шигырь түгел микән? Бураннарда адашканда Шигырьгә, Гаделлеккә булган ышаныч безне саклап калмыймыни, шул—Тимер Казык йолдызы булып күктә пәйда булмыймыни...

Шагыйрь гомере—шигырь юлларында. Яшьлегендә Разил Вәлиев кысаларны да җимереп ташлый, вәзен-кафияләрне санламыйча алга ыргыла. Иректе! Тик өлкәнәя төшкәч кенә шигырь кысалары эчендәге иреклнең тәмен-ләззәтен тулысынча тоеп буладыр, мөгаен. Хикмәт чәчелми, йөрәк кадәр генә булып күкрәк куышлыгына укмаша.

Разил Вәлиевнең шигырьләрендә көчле холыклы кешенең кулы сизелә. Жылы шигырьләр. Көчле холыклы кешеләр генә шәфкатьле була ала. Үз-үзен яклый алмаган бәндәдән бүтәннәргә нинди шәфкать көтәсең... Ләкин шигырьләрдәге өмет-ышаныч, теләкләр сагыш төсенә өртелгән. Шагыйрь заманга да, хәтта табигатькә дә ярашып яши алмый. Шигырьләр шул үзгәлектән туа да инде...

*Кабул булмый нигә бар теләгем?—*
*Бу дөньяда мин дә кеше бит.*
*Янып яшим дөнья суык чакта,*
*Дөнья җылы чакта—күшегеп.*

Кабул булмаган теләкләрнең, тормышка ашмаган өметләрнең көленнән ярала шигърият...

Разил Вәлиев беренче әсәрләре белән үк әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итә. Мәйданда киң колачлы, тирән акыллы, йөрәгендә хисләр давылы уйнаган язучының пәйда булуына беркем дә шикләнми. «Акыллы хис» шигырьгә генә сыя алмый, Мәскәүдә укыганда ук ул «Эт кояшы» дигән бәян яза. Шунысын да әйтергә кирәк, үз заманы өчен шактый кызыклы алымнар белән язылган әлеге әсәр мөхәррирләр арасында шактый бәхәсләр уята һәм нәшер ителгәндә кыскартыла. Беренче карашка анда бер мәхәббәт тарихы гына тасвирлана кебек, әмма тел астында бөтенләй бүтән сүз, бүтән мәүзуг. Системаның самими, үзенчәлекле кешене читкә тибәрүе... Барыбыз да «айт-два»га бер колоннада коммунизм тарафына барырга тиеш заманда... Ә яшь автор һәркемнең үз дөньясы барлыгын, үз йөрәге кушканча яшәргә хакы булуын искәртә.

«Яшисе килә», «Иске сәгать дөрес йөри», «Мирас» бәяннары. Бер-бер артлы шигырь китаплары чыга. Аның сүзләренә дистәләрчә көй языла. Бездә шулкадәр җыр текстлары язган шагыйрьләр берничә генә. Пьесалары сәхнәгә менә. Тәрҗемәләр... «Ялкын» журналында саннан-санга Разил абыйлары тәрҗемә иткән

төрле халык әкиятләрен укып балалар һәмишә сөенә. Әсәрләрнең барысы да бер кимәлдә түгел, билгеле, әмма: «Начар кешедән яхшы шагыйрь, яхшы язучы чыга алмый торгандыр. Разилнең шигырьләрен тыңлаганда, проза әсәрләрен укыганда, мин шул турыда уйладым. Аның һәр әсәре халкыбыз язмышы өчен борчылып язылган, алар халкыбыз бәгыреннән өзелеп төшкән сыман»,— дип яза шагыйрьнең дусты Илһам Шакиров.

Республика китапханәсенә директор булырга ризалашуын ул болай аңлатты:

—Язучылар мохитеннән арынып, укучылар даирәсенә якынаерга уйладым.

Гасырлар дәвамында басылган миллионнан артык китапның иләннән түшәмгә кадәр эскертләп өелгән килеш ятуын, республикабызда бердәнбер нөсхәдә генә булган иң кадерле тупланмаларның кадерсезлеген күргәч исә... Китапханә директоры асылда хуҗалык эшләрен башкаручы кеше икән ич! Анда бәрелә, монда сугыла яна хуҗа. Тик түрәләрнең берсендә дә китап кайгысы юк икән...

Депутат булырга омтылуның төбендә иң беренче нәүбәттә, китапханәләрнең дәрәҗәсен күтәрү сәбәбе дә яткандыр, мөгаен.

Күп еллар депутат, өстәвенә комитет рәисе дә булу дәверендә хөкүмәт кимәлендә китапханәгә мөнәсәбәтне үзгәртте бугай ул. Аның бихисап чыгышларыннан соң аю да, тыңлап торса, укырга өйрәнергә тиеш иде. Әмма... әнә соңгы вакытта авыл китапханәләрен ябу турында сүз кузгалды.

—Соңгы елларда мәдәният өчен нинди дә булса эш башкару тагын кыенлашты,— ди ул.—Күреп торасыңдыр, депутатлар да туксанынчы елларга караганда бөтенләй бүтән бит хәзер. Югыйсә яртысы диярлек шул ук кешеләр. Ул чакта милләт өчен янып йөрүчеләр дә хәзер битарафка әйләнде.

Пар чыгып беттеме? Әллә Мәскәүнең күз карашындагы дәһшәтле чаткылар үзгәрттеме безне? Тукай әйтмешли, күпләребез «яфрак астында»...

Разил Вәлиев түрәләр өчен җайлы кеше түгел. Аларга үз мәнфәгате өчен генә яшәүче депутатлар уңайрак. Ә Разил Вәлиев исә мәдәниятебез ихтыяҗы хакына теләсә кемнең ишеген кага, үзе инанган мәсьәләне югары җиеннарда ярсып яклый. Кайберәүләргә ул җил тегермәне белән көрәшүче Дон Кихотны да хәтерләтәдер. Хәер, Туфан Миңнуллин белән икесен күргәч, кайсы Дон Кихот, кайсы Санчо Панса икәнен тиз генә аныклап та булмый...

Ләкин өстә аның дәрәҗәсе бар. Кайберәүләр, әйтергә җөрьәт итмичә күңелләрендә йөрткән фикерләрнең Р.Вәлиев авызыннан мөнбәрләрдә яңгыравын ишетеп, эчтән куаналар да бугай...

Язучыларның да түрәлектәге каләмдәшләренә карата мөнәсәбәтен гел уңай, дип булмый.

Мәрхүм Нурихан Фәттах бер әңгәмә вакытында галәттәгечә кискен итеп болай дигән иде: «Язучы өчен иң зур бәхет, иң зур мәртәбә—язучы булу. Әгәр дә мәгәр язучы дигән кеше, үзенең язучылыгыннан гына канәгать булмыйча, нинди дер житәкчелеккә омтыла икән, димәк, ул безнең арага ялгыш кына килеп кергән. Җитәкче буласың килә икән, бул син, әйдә. Татар түрәләре арасында да татарча укый-яза белүчеләр булырга тиештер ләбаса!»

Әмма Разил Вәлиев без күзаллаган рәвештәге түрәме соң? Уйлап баксаң, ул әдәбият-сәнгать ихтыяҗларын түрәләргә җиткерергә алынган илчебез түгелме? Һәм нинди дер нәтиҗәгә ирешер өчен анардан чырышлык, дипломат таланты таләп ителә. Хәер, кайбер туң йөрәкле түрәләргә әлеге сыйфатларның да тәэсире булмавын еш кына күреп торабыз.

Бу җәһәттән бирелә яраткан язучым Виктор Астафьев сүзләрен дә искә аласым килә: «Язучыны мин җәмгыятьтәге вазифасы өчен түгел, ә бары тик талантына карап кына бәяләдем һәм бәялим,—дип язган иде ул.—Әмма еллар үтү белән шундый фикергә килдем: әгәр дә кешедә җитәкче һәм язучы таланты аерылгысыз, ул һәркайсында бербөтен икән, бу әдәбият өчен зыянга түгел, ә файдага гына».

Хәер, түрә язучыларга тискәре карашта торган Нурихан Фәттахның да тәгаен Разил Вәлиевкә карата мөнәсәбәте үзгә иде: «Минемчә, Разил Вәлиев татарның бүгенге иң күренекле, иң данлы һәм атаклы шәхесләренең берсе. Һәркем белә, Разил Вәлиев язучы гына түгел, сәяси эшлекле дә, ул армый-талмый татарның

бәйсезлеге өчен көрәш алып бара. Моның өчен без аңа һәрвакыт рәхмәт әйтергә тиешбез».

Бер көнбатыш кешесе, Иранда министрларның ил язмышын хәл иткәндә үзара шигырь сөйләп гәпләшүләрен күргәч, чиксез гаҗәпләнә. Шәрекъ үзгә... хисләре гарипләнгән Гареп түгел.

Ил тоткан иләмән шагыйрьләр Шәрекътә бихисап. Олуг вәзир вазифасын башкарган бөек төрк шагыйре Галишир Нәваине генә искә төшерү дә җитә. Ул үз дәүләтендә мәчетләр, мәдрәсәләр салдыра, мохтаҗлар өчен хәйрия вакыфлары оештыра. Үз вакытында аны Шаһ-и гарибан дип атаганнар, ягъни гарипләр, моңлылар шаһы...

Хәер, Рәсәйдә дә, Көнбатышта да андыйлар булмаган түгел. Рәсәйнең беренче юстиция министры булган, шактый вакыт губернатор вазифаларын башкарган Державинның шагыйрьлеген кем генә шик астына алыр икән? Веймар кенәзлегенең чәчәк аткан дәвере дә баш министр Гете исеме белән бәйле. Бүген аларның иҗтимагый вазифаларын кем хәтерли? Кешелек тарихына алар олуг шагыйрьләр булып теркәлгән.

Шагыйрьлекне бер бизмән белән үлчәп булмый.

Тик һәрберсенең йөрәгендә иярләнгән ат ята.

Яшьлегендә Разил Вәлиев Франсуа Вийон, Гарсия Лорка, Александр Чак, Уолт Уитмен иҗатлары белән мавыккан кеше. Ул күбебез кебек көнбатыш шигъриятенең тәэсирендә үскән.

Дәүләт советындагы бер җыенда татар халкының дәүләтчелеге турындагы чыгышын ул шигырь белән сөйләде.

Әлбәттә, хакимияттә аның ят каннан яратылганын беләләр.

Шагыйрь күңелендәге иярләнгән атның, борын канатларын дерелдәтеп, каядыр билгесезлеккә ыргыласы киләдер.

Җанын кая куярга белмәгәндә ул юлга чыгып китә. Авылына кайта, урмандагы йортына юнәлә. Ялгызын калдырыгыз! Канда Вийонның зимагурлыгы, Лорканың чегән аһәннәре уянган вакыт.

Күпме илләр күрелгән, тик туган җирдә генә өмет кебек һаман түм-түгәрәк калган күк йөзеннән сирпелүче карлар керфекләргә үз итеп куна... эреп язга күчәсе моңга әверелә.

Ил-көн турындагы уйлар, сәяхәтләр хатирәсе ак кәгазьгә күчә. Шул шатлыкны, шул сагышны, гамьне тиздән без дә шагыйрь кебек үк кичерербез.

Давыл яшеренгән дулкыннар шавын йөрәгебез ишетер.

Роберт
Миңнуллин

# ДӨРЕС ЯШИСЕҢ, РАФИС КОРБАН!

Рафис Корбан турындагы мәкаләмне башлый алмый интегеп беттем. Нидән тотынырга белмичә шактый гына аптырап йөрдем. Шагыйрьгә 50 яшь тула икән бит. Димәк, юбилей мәкаләсе язарга кирәк. Димәк, ул мәкаләне шәп иттереп, үзен күкләргә күтәреп мактап, иҗатына җентекле анализ ясап, аның татар әдәбиятында тоткан урынын күрсәтеп язу сорала. Тик мена нидән башларга? Иҗатының кайсы ягыннан тотынырга?..

Бездә бит шулай гадәткә кергән: шагыйрьгә, язучыга бер исем, бер тамга сугылса, аннан тиз генә котылырмын димә. Бу бигрәк тә балалар әдәбиятында күзгә бәрелеп тора. Әйтик, сиңа «балалар шагыйре» дигән исемне чәпәп куялар да—шуның белән вәссәлам! Нигә әллә нинди «гениальный» лирик шигырьләр, проза әсәрләре, драма әсәрләре язмыйсын, син барыбер «балалар язучысы» булып каласың. Шәүкәт Галиев белән шулай булды, Ләбибә Ихсанова, Җәүдәт Дәрзаман белән дә шундый ук хәл. Рафис Корбан белән дә. Әмма шунысы кызык: әлеге мөхтәрәм язучыларыбыз «балалар шагыйре», «балалар язучысы» диюдән бервакытта да кимсенмиләр. Киресенчә, алар әлеге югары исемне үзләре өчен зур дәрәҗә дип саныйлар, аны зур горурлык хисләре белән йөртәләр. «Балалар язучысы» булудан качарга тырышучылар да житәрлек, әлбәттә. Анысы инде, гафу итәсез, аларның үз эшләре.

Әле күптән түгел генә Язучылар берлегенең идарә утырышында балалар әдәбияты турында сүз чыкты. Дөресрәге, балалар әдәбияты буенча остаханә җитәкчесе Рафис Корбан республикада балалар әдәбияты атналыгы уздыру турында тәкъдим белән чыгыш ясаган иде. Шунда кемдер: «Язучыларны балаларныкына, олыларныкына аерып карарга ярамый. Син дә бит олылар өчен күбрәк язасың» дигәнрәк сүз ычкындыргач, Рафисыбыз кырт кисеп куйды. «Юк, мин—балалар язучысы! Минем бөтен язганнарым да балалар өчен! Ә күп язучылар алар «мин дә яза алам» дияр өчен генә, китап чыгарыр өчен генә язалар»,—дип җавап кайтарды. Шунда мин Рафис Корбанның балалар әдәбиятына ихластан хезмәт итүен, татар балалар әдәбиятының патриоты булуын ныклап аңладым. Балалар әдәбиятына каләмдәшләр тарафыннан ниндидер бер кимсетүле мөнәсәбәтне тойган халдә, «балалар өчен өлкәннәргә язалмаганнар гына яза» дигән караш яшәгән бер мәлдә, үзенне «мин—балалар язучысы» дип йөртү өчен, дөресен генә әйткәндә, зур батырлык кирәк бит! Рафис Корбан исә нәкъ әнә шундый батыр рухлы, балалар әдәбиятынын фидакарь шагыйре. Чыннан да, балаларга атап шигырь язу белән генә түгел бит әле ул, балалар әдәбияты өчен җан атып яшәргә дә, аны пропагандаларга да, аның абруен күтәрү өчен армый-талмый эшләргә дә кирәк. Югыйсә, бай тарихлы, зур-зур әдипләре булган балалар әдәбиятыбызны күрмәмешкә салышучылар болай да җитәрлек...

Әдәби тәнкыйть тә, әдәбият гыйлеме дә әдипләрне буыннарга, төркемнәргә, дулкыннарга бүлгәләп карарга ярата. Шул ук вакытта бер төркемгә дә кертеп булмый торган язучы-шагыйрьләребез дә очрый. Әйтик, Роберт Әхмәтҗанов бер төркемгә дә сыймас шагыйрь булып калды. Рәшит Әхмәтҗановны, киресенчә, буыннан-буынга күчереп йөртә торгач, безнең буын шагыйрьләренә үк төшереп калдырдылар. Ә безнең буыннан соң килгәннәр, үзләренең яшьләре белән дә, иҗатлары белән дә, бөтенләй үзара аралашып, буталышып беттеләр шикелле. Мена әле Рафисны да кайсы төркемгә кертим икән дип утырам. Бер караганда, ул илле яшьлек Вахит Имамов, Нәбирә Гыйматдинова, Галимҗан Гыйльман, Факил Сафиннар белән чордаш: яшь ягыннан алар буынына керергә тиеш. Икенче яктан, ул үзеннән яшьрәкләр белән күбрәк аралаша. Мин биредә Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләбиб Лерон,



*Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре. Сулдан (алгы рәттә): Р. Әмирханов, Д. Шакиров, Х. Әюп; икенче рәттә: Б. Хәмидуллин, Р. Шәмсетдинов, Р. Рахмани һәм Р. Корбан. 2000 ел.*

Зиннур Хөсният, Ләис Зөлкарнәйләр буынын күз алдында тотам. Әдәбиятка килеп керүе дә шулар белән бергәрәк туры килде. Мина калса, Рафис менә шушы ике буынны бергә кушып, тоташтырып тора шикелле.

Баштарак ул шул ике арада адашыбрак, югалыбрак та калган кебек булган иде. Матбугат битләрендә дә яшьтәшләренә караганда сирәгрәк күренде. Шунлыктандыр, ахры, исемен дә сирәк кенә телгә алгаладылар. Башта иҗат эшенә үзе дә бик үк житди карамады бугай. Укуы белән дә шулайрак килеп чыкты. Әйбәт кенә укып йөргән жиреннән, университетның журналистика факультетын ташлап китте. Үзе тынгысыз, дуамалрак табигатьле булуы аркасында тормыш дулкыннары Рафисны шактый гына каккалады да, суккалады да. Бер урында гына утыра алмый торган күчмә холыклы булгангадыр инде, эшләмәгән жире, тотып карамаган эше калмады. Башта ул «Татарстан яшьләре» гәзитендә эшләп алды, аннары Буа районына барып чыкты. Анда район гәзите редакциясендә зур тормыш мәктәбе узып йөрде.

Шигырь җене кагылган егет Казансыз яши аламы соң инде? Юк, әлбәттә. Ул яңадан да Казанына әйләнеп кайтты. Билгеле инде, аны биредә беркем дә кочагын җәеп каршы алып тормагандыр. Әмма үҗәт егет югалып калмады: кайсыдыр бер оешмага рәссам булып урнашты. Ике елдан ул Татарстан радиосына эшкә килде. Шуннан соң гына үзенең урынын тапты дияргә мөмкин. Радионың көндәлек тормышы, андагы тынгысыз иҗади мохит аның күңеленә хуш килде, радио журналисты буларак ул тапшырулар әзерләде, эфирда исеме яңгырый башлады. Җиде ел дәвамында Рафис радионың кайсы гына бүлегендә эшләп карамады: музыкаль редакция, балалар өчен тапшырулар редакциясе, ниһаять, әдәби тапшырулар редакциясе... Әмма кайсы гына редакциягә күчмәсен, ул үз вазыйфасына күңелен биреп, ихластан тотына, һәр эшен жиренә җиткереп башкара. Музыкаль редакциядә Татарстанның халык артисты, күренекле җырчыбыз Рафаэль Ильясов кул астында эшләү, анда республиканың күренекле сәнгать әһелләре белән, җырчылар, композиторлар белән аралашу, музыкаль тапшырулар әзерләү, ул тапшыруларны радио тыңлаучыларга эфир аша җиткереп бару, әлбәттә, эзсез югалмый. Яңа язылган җырларны ул чакларда, билгеле инде, иң элек радиога алып киләләр, һәр авторның, талантлымы ултalantсызмы, үз җырын радио аша яңгыратасы килә. Радиодан яңгырау популярлыкка юл ача дигән сүз. Әмма аларның барысы да музыкаль редакциядә эшләүчеләрнең, художество советының «иләге» аша узарга тиеш. Рафис та шул җырлар белән мәш килә. Җыр сәнгатенең асылын, аның нечкәлекләрен акрынлап аңлый башла-

ган егет үзе дә җырлар иҗат итәргә тотына.

Бүгенге көндә җыр җанрында эшләүче аз санлы шагыйрьләребез арасында Рафис Корбан күренекле урын алып тора дисәк тә дөреслеккә хыйлафлык булмастыр. Ул җыр өчен шигырьләр генә язып калмый, ә бүгенге җыр җанрының, эстрада җырларының камиллеге өчен тырышып, җан атып та яши: төрледән-төрле түгәрәк өстәл сөйләшүләрендә, радио-телевидение уздырган дискуссияләрдә катнаша, матбугатта усал-усал фикерләр белән чыгышлар ясый. Кайчакларда кызыбрак та китә, артыгырак та җибәрә, аның белән риза булмаучылар да, аның белән бәхәскә керүчеләр дә табыла. Нишлисен, башкача булдыра алмый ул: ни уйлый, шуны әйтә, ничек дөрес дип таба, шулай яза. Халтураны күреп борчылганга, татар эстрадасын зәвыксыз сүзләр тезмәсе басып киткән өчен җаны әрнегәнгә яза.

Быелның язында Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында Рафис Корбанның иҗат кичәсе узды. Әйтер идем, бик җитди әзерләнгән, профессиональ яктан тел-теш тидермәслек зәвыклы концерт булды ул. Татарстанның халык артистлары Рафаэль Ильясов, Айдар Фәйзрахманов, Фердинанд Сәлахов, шулай ук танылган җырчыларыбыз Газинур Фарукшин, Лилия Муллагалиева, Рәбига Сибгатуллина, Фәридә-Алсу дуэты катнашлыгында узган әлеге концерт Рафисның инде өлгергән, профессиональ яктан җитлеккән, искиткеч матур җырлар иҗат иткән җырчы-шагыйрь булуын күрсәтте. Рөстәм Яхин, Рим Хәсәнов, Рәшит Кәлимуллин, Луиза Батыр-Болгари, Илгиз Закиров, Мәсгут Имашев, Шамил Тимербулатов, Фәрит Хатыйпов, Фирзәр Мортазин, Илһам Байтирәк кебек билгеле композиторларыбыз белән берлектә иҗат ителгән кырыклап җырны тамашачы алкышлап каршылады, яратып кабул итте. Кичәдә мәшһүр Илһам Шакиров кына катнаша алмады. Әгәр дә ул шагыйрьнең халык көенә җырлана торган «Уян, татар!» җырын да яңгыратса, тагын да шәп буласы иде. Беренче тапкыр туксанынчы елда ук Илһам ага башкарган әлеге җыр республикабызның мөстәкыйльлеген яулаган көннәрдә милләтпәрвәрләребезнең милли гимнына әйләнде бит.

Рафисның балалар өчен иҗат ителгән җырлары да бик күп булуын билгеләп үтәргә кирәк. Алар арасында «Тургай», «Нәүрүз моңнары» фестивальләрендә җиңгәннәре дә бар.

Рафис Корбанның иҗат белән ныклап шөгыльләнә башлавы да нәкъ менә радиода эшләгән елларына туры килә. Ул анда балалар өчен беренче шигырьләрен язды, Татарстан китап нәшриятында балаларга атап «Буран кайда йоклый?» (1987), «Җиде төстә кунакта» (1989) исемле китапларын бастырып чыгарды. Балалар әдәбиятының уртасында кайный башлады. Без аның белән Татарстан Язучылар берлегенең балалар әдәбияты секциясендә дә (мин—рәис, ул—сәркатип сыйфатында) бергә эшләдек. Балалар әдәбиятының актуаль проблемаларына, әдипләребезнең иҗатларына багышланган семинарлар, сөйләшүләр уздыру, яшь язучыларның беренче кульъязмаларын тикшерүләр, яңа чыккан китапларга күзәтүләр, әдәби ел йомгакларында чыгыш ясаулар Рафис өчен үзе бер мәктәп булды.

1989 елда мин, Рафис Корбанны Язучылар берлегенә тәкъдим итеп, мондыйрак сүзләр әйткән идем: «Рафис Корбановны мин беренче шигырьләреннән беләм. Шуннан бирле аның инде балалар өчен язылган ике китабы басылып чыкты. Өченчесе нәшриятта чират көтеп ята. Дүртенчесен дә тәмамлап килә. Егет яза, күп эшли, балалар әдәбияты өчен янып яши. Тырышлык, билгеле, бушка китми. Кыска гына вакыт эчендә, үзенең булганлыгы, унганлыгы, сәләте нәтиҗәсендә, ярыйсы гына танылып та өлгерде ул. Аны татар мәктәпләрендә, балалар бакчаларында да беләләр, көтеп алалар.

Шөкер, балалар әдәбиятына да, сирәк булса да, яшь көчләр килә тора. Әгәр дә игътибар ныграк булса, алар тагын да күбрәк булырлар иде. Югыйсә, «чиста» балалар шагыйре генә булу әлегә «престижлы» түгел, аларны кочак җәеп каршы алырга тормыйлар. Шуңа да карамастан, Рафис Корбанов фәкать балалар өчен генә яза һәм дөрес эшли. Бер жанрда бөтен көченне куеп эшләгәндә генә зур уңышларга ирешергә буладыр дип уйлыйм. Рафис моны аңлый кебек.

Ул балалар дөньясын яхшы төшенә, нәниләр күңелен аңлый, алар өчен яза белә. Язганнары—традицион. Б. Рәхмәт, Ә. Фәйзи, Ш. Галиев кебек олы шагыйрьләрнең матур традицияләрен лаеклы рәвештә дәвам итә. Ә традицияләрне дәвам итүнең үз авырлыклары бар. Булган традицияләрне иҗади дәвам иткәндә генә, заман таләпләренә туры китереп үстергәндә генә аклый ул үзен. Рафис шулай эшли дә:

таныш ритмика, мәгълүм темалар, чордан-чорга, шагыйрьдән-шагыйрьгә күчкән шигъри алымнар яңача яңгырый башлый, заман төсмерләре белән балкып китә, үзенчә шигъри образлар белән тулылана. Нәтиҗәдә, шагыйрьнең үз дөньясы, балалар бакчаларына аваздаш үз шигъри бакчасы үсеп чыга.

Рафис Корбанов балалар поэзиясендә җитди эшли, туктаусыз эзләнә, таба да. Шулар өстенә шагыйрьнең мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укытуның торышы турындагы үткен радиотапшыруларын һәм мәкаләләрен дә, балалар әдәбиятына багышланган мәкалә, рецензияләрен дә, 35 нче мәктәптә әдәбият түгәрәге алып баруын да, балалар әдәбияты секциясе бюросында актив эшләвен дә искә алырга кирәк. Болары—яшь шагыйрьнең иҗтимагый йөзен күрсәтеп торучы дәлилләр. Ул эштән йөз чөерми, иренми, вакытын да, көчен дә җәлләми, әдәбиятка файдалы булырга тырыша. Язучыга әлеге сыйфатлар да, һичшиксез, кирәктер дип беләм.

Кыскасы, Рафис Корбанов балалар әдәбиятына кунакка дип түгел, эшләргә, тир түгәргә дип килә. Әйбәт китаплары да, гражданлык позициясе дә шул хакта сөйли».

Күренә ки, моннан күп еллар элек яшь шагыйрь Рафис Корбановка биргән бәяләрем бүгенге танылган шагыйрь Рафис Корбанга бик тә килеп тора. Бер генә фикерен дә, бер генә хәрефен дә үзгәртәсе юк. Ул күпкырлы иҗатын да, тынгысызлык, тырышлык, энергия сорый торган иҗтимагый эшчәнлеген дә бүгенге көнгә кадәр дәвам итә: хәзер инде үзе Язучылар оешмасында балалар әдәбияты остаханәсен җитәкли. Балалар әдәбияты өчен, балаларга язучы әдипләребезне бергә туплау өчен, аларның иҗатын җанландыру өчен армый-талмый янып йөри. Ул инде—танылган балалар әдибе. Шәйхи Маннур исемендәге, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Аның кече яшьтәге балалар өчен чыгарылган «Сөзгәк болыт», «Капкорсак», «Мин бәйрәмнәр ятатам», «Сөйләшергә өйрәтәм», «Капкорсак һәм Бавырсак», «Болыт суны болгаткан», «Алмалы төн», «Бәхет телим», «Тапкырга табышмак» исемле китаплары бүгенге балалар шигъриятенең йөзен билгели торган басмалар... Әлеге китапларның дүртесе «Ел китабы» конкурсларында җиңеп тә чыкты.

Рафис—кайда гына эшләсә дә, үзенең иҗатына җим таба белә торган шагыйрь. Радиода эшләү дәверендә без аның балалар шигырьләре һәм җырлар иҗат итә башлавын белдек инде. Ул әле бервакыт Казан дәүләт курчак театрында әдәби бүлек мөдире булып та эшләп ала. Һәм, нәтиҗәдә, танылган балалар драматургы булып китә. Бернинди арттырусыз әйтәм, чөнки бу чыннан да шулай. Моның шулай икәненә ышану өчен аның театрларда куелган пьесаларын санап чыгу да җитәр иде. Казан курчак театры аның «Куркуын җиңгән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1995), «Ак күлмәктә кара елан» (1996) дигән пьесаларын тамашачыларга күрсәтте. «Керпе малае дуслар эзли» дигәнен 1995 елда Татар дәүләт яшьләр театры сәхнәләштерде. Чаллы курчак театрында «Куркуын җиңгән Куян», Уфадагы «Нур» театрында, Чаллы татар драма театрында «Патша кызы һәм җырчы» исемле пьесалары уйналды. Түбән Кама һәм Әстерхан театрларында да Рафисның балалар өчен язылган пьесалары уйналганы бар. Ә менә курчак театрларының Канны шәһәрендә уздырылган халыкара фестивалендә Рафисның пьесасы буенча куелган «Бардым күлгә, салдым кармак» спектакле лауреат була. «Знай наших!» дияр иде бу урында «Эфир»дан һава торышы турында сөйләүче Куранов иптәш...

Рафис Корбан, әйткәнемчә, бер урында гына утыра алмый торган тынгысыз җан. Кайларда гына эшләп карамады ул?! Татарстан китап нәшриятында китап тарату бүлеген дә җитәкләде, «Мәгариф» нәшриятында мөхәррир дә булды, «Салават күпере», «Идел» журналларында һәм «Заман», «Шәһри Казан» газитләрендә эшләп алды. Ул елларда эшмәкәрлек модага кереп киткән иде, кем газит-журнал чыгара, кем китап дигәндәй... Рафис та, каян башына килгәндер, «Әдәби җомга» исемле газит чыгара башлады. Гамәлгә куючылары—Язучылар берлеге белән Мәдәният министрлыгы булырга тиеш иде. Әмма, сәяси сизгерлеге житенкерәмәгәнлектәнме, газитнең беренче санында ук Мәдәният министрына каты-каты гына әйтелгән мәкалә басылып чыкты. Нәтиҗәсе билгеле инде—4 саны чыкты да шуның белән тукталды. Аннары Рафис «Балачак» исемле нәшрият ачып җибәрде. Бернечә китап чыгару белән анысы да көрчеккә барып терәлде. Берара ул Татарстан Язучылар берлегенә әдәби фонд житәкчесе итеп тәгаенләнде. Әйбәт кенә эшли башлады: язучыларның юбилейларын уздырды, утыз язучыга ярты бәясеннән генә дубленка туннар өләште... Безнең үзебезгә ул тун эләкмәде, билгеле. Шулай да карап йөрим: өлкән яшьтәге хөрмәтле язучыларыбыз әле һаман да шул туннан. Ничауа, килешеп тора үзләренә!

Шул кыска гына вакыт аралыгында да Рафис шактый гына игелекле гамәлләр кылып өлгерде. Әмма, әлеге дә баягы шул холкы аркасында, союз житәкчеләре белән уртак тел таба алмыйча, аннан да китәргә мәжбүр булды. Хәзер инде үзе дә олыгая бара, холкы да басынкылана torгандыр: менә ничә еллар инде Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият һәм балалар әдәбияты редакцияләре мөдире булып, басылып кына эшләп йөри. Яратып, бөтен күңелен биреп эшли дияр идем. Эше - күп, мәшәкатьләре, ыгы-зыгылары тагын да күбрәк. Ни дисән дә, китап чыгарасы килгәннәр ин элек анын ишек төбен таптый. Кульязмалар ин элек анын кулы аша уза. Һәммәсен дә укып чыгарга кирәк: анализ ясарга, бәя бирергә, барырлыкларын алып калырга, булмастайларын кире борырга... Кире борудан да авыр әйбер юк, алып калганнарын китап итеп чыгару тагын да авыррак. Әгәр дә соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты китап чыгару эшен жайга салып жибәргән икән, язучышагыйрьләребезнең тирән эчтәлекле, полиграфик яктан әйбәт сыйфатлы китаплары чыгып тора икән, биредә, һичшиксез, бүлек мөдире Рафис Харис улы Корбановның да хезмәте зур.

Инде килеп, шагыйрьнең лирикасы турында да берничә сүз әйтмәсәм, дөрес булмас. Ни өчен дисәң, берничә ел элек бер дә уйламаганда гына анын «Яра» исемле шактый гына саллы шигырьләр, жырлар, тәржемәләр китабы дөнья күрде. Биредә Рафисның нечкә лирик, гражданлык хисләре белән сугарылган ялкынлы публицист икәнлеге дә, популяр жырлар авторы, оста тәржемәче булуы да ачык күренә. Шагыйрьнең укучыларына әйтер сүзе бар. Ул шигъри сүз халык язмышы, республика язмышы турында, яшьлек һәм мәхәббәт турында, гомер һәм яшәү турында. Ул ихлас шигырьләр, шигъри образлар жанны иркәли. «Йолдызларның жиргә төшкән мәле, Ә без күктә идек ул чагында» яисә «Ә күктә йолдыз сүнәргә Оныткан иде» шикелле юллар хисләрне янартып жибәрә. Әлеге китап Рафисның балалар шагыйре генә түгеллеген тагын бер кат раслый.

Рафис Корбан үзенең бер шигырендә: «Дөрес яшимме мин?» дип үз-үзенә сорау бирә, әмма жавабын әйтми калдыра. Ә минем бу сорауга жавабым әзер:

—Дөрес яшисең, Рафис Корбан! Моннан соң да шулай дәвам ит! Үзенчә яшә! Ижат итеп кал, яшәргә, яратып калырга ашык! Үзең дә «яшәүләр юк жирдә янадан» дип язасың бит!

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан ижтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәжәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-ижтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр кишттәшкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТИРЕС***—"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" "тирес" сүзенең "кире, сул; арт", "тискәре, каршы", "төньяк" мәгънәләрен дә теркәгән. Аның бу мәгънәләре күп кенә төрки телләрдә дә бар, борынгы төрки телгә дә хас. Р.Әхмәтьянов бу мәгънәләрне фарсы теленнән кергән дип саный (фарсыча *тәрса*—дошман як). *Үҗәт* мәгънәсенә дә тарта шикелле. Татар телендә *тирес бакасы* дигән төшенчә дә бар. Сүзлек аны *баз бакасы* белән тәңгәлләштерә. Ихтимал, "тирес бакасы" дигән атама "төн", "караңгылык" мәгънәсенә ишарәле торгандыр. // *Бәхетсез милләт! Ник синең бер дә бәхетең булмады?! Ник сиңа һәммә эш тирес килеп торды?* Г.Исхакый. *Тискәре тирес ягы белән туа.* Мәкаль. *Тирестән искән җил*—төньяк җиле. *Тирес чабата* (Сергач сөйләшеннән). *Тирес-мирес*—киреле-мырлы. Гаяз Исхакыйда: "*Коръәннән, хәдистән тирес-морыс мәгънәләр чыгарып, әлләниләр кылындырып бетерәләр иде.*"

***ТИРЕС АЯК***—Сүгенү сүзе. Электә җен-пәриләрнең аягы, йөзе, күзе кирегә караган була дип ышанганнар. Ошатмаган кешегә җен, шайтан дип әйтү урынына *тирес аяк* (кирегә караган аяк), *тирес бит* дигәннәр ("кирегә беткән нәмәстә").

***ТИРЕС БИТ***—Бу сүз намуссыз һәм вөҗдансыз кешегә карата әйтелә. "Тирес күз" дә диләр. Кара: *Тирес аяк.*

***ТИСГЫЙН*** *г.*—Туксан. Бу санның гарәпчә һәм татарча әйтелешендәге охшашлык күзгә ташлана. Ләкин тел белемендә (мәс., Л.Җәләй) татарча "туксан сүзе" "тугыз+ун" кушма сүзеннән килеп чыккан дип карала ("сиксән"—"сигез+ун"; ә сиксән саны гарәпчә—"сәманин", "сәманүн").

***ТИЯБИРСЕН ИТҮ, ТӘБЕРСЕН ИТҮ***—Керәшеннәрдә ашарга утырыр алдыннан вафатларны да табынга чакыру һәм аларга ахирәттә һәртөрле рәхәтлекләр теләү догасы, ул күңелдән генә укыла. Бу вакытта якын кардәшләрнең исемнәрен искә алудан (зикер кылудан) тыш, барлык ата-бабаларның гомумиләштерелгән символы да атала (М.Глухов буенча). Православиедә үлгәннәрне чиркәүдә литургия вакытында искә алуны да тәберсен итү диләр. Нугайбәкләр сөйләшендә бу сүз авыз итү мәгънәсенә дә ия. *Гүр тәберсене*—нугайбәк керәшеннәрендә үлгән кешене аның кабере өстенә ашау әйберләре алып барып искә алу.
Русча—*поминовение.*

***ТИЯК*** *тар.*—Билге өчен утыртылган таш; ташбилге. Ыруның корбан чала һәм әйләнеп кайта торган урыны.

***ТОЕК*** *иск.*—Каламбур, сүз уйнату. Сүзнең икенче, серле мәгънәсен тою (Нәкый Исәнбәт, төрекчә сүз кулланып, "*гизле* мәгънәсен сиздерү" һәм "тоек" сүзе шигъри алым буларак әдәбиятыбызда искедән кулланылып килгән" дип яза, аннары моңа Кандалыйдан мисал китерә.

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

**ТОЖЫМ** – 1.Пәрәвез жебе. Курган өлкәсе Эчкен сөйләшендә – *мизан*. Сергач сөйләшендә *шайтан дилбегәсе* диләр. 2.Гөслә кыллары (нугайбәк керәшеннәре сөйләшендә). Телефон-телеграф чыбыкларын белдерә торган *чожым / чыжым* сүзе дә "тожым" белән уртак нигезле. 3.Бозыла башлаган ризык өстендә хасил булган аксыл кунык (Казан арты керәшеннәре сөйләшендә).

**ТОЗ САЛЫМЫ** *тар.* – Патша заманнарында һәр өйләнгән кеше казнага тоз салымы түләргә тиеш булган, йә аны тоз ташырга мәҗбүр иткәннәр.

**ТОМАГА** *к.* – Сунар шонкарының башына кидерелә торган күн башлык.

**ТОМАК** *тар.* – Кырыйлары җилкәгә, аркага төшеп торган башкорт бүреге. Чаг.: **ТОМАГА.**

**ТОТКАВЫЛ** *тар.* – Киртәләүче отряд, тоткарлаучы туплан (заградительный отряд). Шәһәр капкаларын караучы, тышкы сакчыларны да тоткавыл дип атаганнар. Р.Әхмәтьянов "тоткавыл – качак солдатларны тотучы" дип тә аңлата.

**ТОТСАК** *тар.* – 1.Әсир төшкән кеше, тотык, тоткын. Чыганакларда туснак / тоснак варианты да теркәлгән. 2.Бурыч түләү хисабына бирелгән нәрсә. // *Атымның арпасы булмаса, йә ийәремнең киезе тотсак булса, солтан колларына алтын белән саранлык кылса, җан белән аңа юмартлык итсә булмас.* Сәйф Сараи.

**ТОХЫМ, ТӨХЕМ** *ф.* – 1.Токым, орлык. // *Ул нәдеркем, зәррә-зәррә кян (җәүһәр коесы) ирер, зәррә төхме миwәсе чәндан (бик күп) ирер; Авызы бер, теле ике, җаны юк, Аны белми күп кеше хәйран ирер* (табышмакның җавабы – кара савыты). 2.Йомырка, күкәй.

**ТӨМӘН** I – Көнбатыш Себердә Тура елгасы буендагы шәһәр, хәзер өлкә үзәге. Риваятьләргә караганда, каланы татар кенәзе *Тайбуга* нигезләгән һәм ул вакытта шәһәр *Чимге-тура* дип аталган. 1585 елда бирегә ныгытылган рус кальгасы торгызыла.

**ТӨМӘН** II – Борынгы төрки телдә ун мең мәгънәсендәге сүз; ун мең кешелек гаскәр. Меңнәргә, йөзләргә һәм уннарга бүленгән. Чыңгызилар дәүләтендә ун мең кешелек гаскәр төзеп бирә ала торган хәрби-административ берәмлек та төмән дип аталган. // *Тылыг кәлүрти, сабы антаг: Йарыс языда он түмән сү тәрилти, дир* – "Тел" тотып китерделәр: сүзе мондый: Ярыш даласында йөз мең (ун түмән) гаскәр җыелды, дип әйтә. (Тонйокук ядкәре.)
*Төмән / түмән* сүзе "бик күп" мәгънәсендә дә кулланылган.

**ТӨМӘН АГАСЫ** *тар.* – Чыңгыз хан гаскәрендә ун мең сугышчыга баш кеше.

**ТӨМӘН БАШЫ** *тар.* – Кара: **ТӨМӘН АГАСЫ.** Русча чыганакларда: *темник*. Ясак һәм пошлина җыю кебек эшләр дә төмән башының вазыйфасы булган. Бу дәрәҗәле урын нәселдән күчә килгән.

**ТӨНКАТАР** *тар.* – Ханның урдасын саклаучы гаскәрнең төнлә торучылары, тургаул. Чаг.: **КӘБТӘУЛ.**

**"ТӨННЕК БӘЙРӘМЕ"** – Электә Казан арты – Лаеш, Казан арты – Әтнә якларында уразага керер алдыннан башкарыла торган "шаян йола". Кеше йокламасын өчен аның төннек тишегенә тыккан чүпрәген урлап йөргәннәр, капкаларын, арбаларын алып китеп суга салганнар, морҗаларын сүткәннәр һ.б.

**ТӨП ХАЛЫКЛАШТЫРУ** *иск., тар.* – Русчасы – "коренизация". XX гасырның 30-елларында совет милли сәясәтендә тәкъдим ителгән термин.

**ТӨРБӘ** *г.* – 1.Туфрак. 2.Кабер (зиннәтле кабер). Төркестанда суфи изгеләренең

мавзолейлары *төрбәт* дип атала. / / *Төрбәи шәриф* — пәйгамбәр төрбәсе. Ләкин шулай да кабер өстенә төрбә кору һәм һәйкәлләр торгызу Исламга хас йола түгел. Ул миләди X гасырда гына тарала башлаган. Беренче булып үзенә һәйкәлне әл-Моктәдирнең әнисе (грек кызы), аннары әр-Ради хәлифә (вафаты 940 елда) куйдырткан. Төрбәләр Шәһри Болгар территориясендә дә бар.

"Идел буенда элекке төрбә бинасының җимерелү уңае белән 1528 елда куелган ташка түбәндәге юллар язылган булган:

...Ходаның рәхмәте улсын анларга,
Анлар лаек иде дога кылырга.
Йикерме алтыда улды фәнасы,-
Йыкылды ташының бер хуп бинасы;
Мөзәййән батыйны, ләгыль-җәваһир,
Йабылмыш ләә-ләә мәрҗанлә заһир."
("Татар әдәбияты тарихы", I том, 1984.)

"Төрмә" сүзе дә шушы "төрбә" сүзенә бәйле дип караучылар бар. Электә кабер өстенә төзелгән өсте ябулы корылмага тоткыннарны да япканнар икән.

***ТӨРЕК СИСТЕМАСЫ (ҺИҖРИ КАЛЕНДАРЬДА ТӨРЕК ЦИКЛЫ)*** — Бу 8 еллык циклда (шәлкемдә) 2, 5 яки 7 нче номерлы еллар кәбисә ел дип исәпләнә. Елның цикл эчендәге номерын табу өчен һиҗри елларны күрсәткән санны 8 гә бүлеп карыйлар. Калдык әлеге номерларга тигез булса, ул ел *кәбисә ел* дип исәпләнә һәм төрек системасында ул елны зөлхиҗҗә ае 30 көннән килә.

***ТӨРКИ ТЕЛЛӘР*** — Төрки телләрдә барлыгы 80 миллион чамасы кеше сөйләшә. Шулардан төрекләр — 35 миллион, үзбәк — 12, әзәрбайҗан — 8, татар — 7, казакъ — 6, уйгыр — 5, төрекмән — 3, кыргыз — 2, чуаш — 1,5, башкорт — 1,2, кашкай, афшар һәм Ирандагы башка төрки кабиләләр — 1, каракалпак — 0,4, якут — 0,3, комык — 0,2, карачай-балкар — 0,15, тува — 0,15, кырым — 0,15, гагауз — 0,15, нугай (0,1), алтай (0,05), хакас — 0,05 миллион кеше.

***ТӨРМӘ*** — Мәхбүсханә, зиндан, хәбесханә, тоткыннар йорты; баструк. Халык телендә "өтөрмә", "өтөрмән" вариантлары күзәтелә. Рус телендә — "*тюрьма*". "Тюрьма" сүзе Е.Н.Шипованың "Словарь тюркизмов в русском языке" сүзлегенә теркәлгән. Бу сүз Мәхмүд Кашгарыйда да очрый ("*түрмә*" — Рясанен буенча Е.Н.Шиповада шулай күрсәтелгән). Борынгы төрки телдә "*тура*" — ныгытылган торак, ныгытма, кирмән ("Котадгу белек"), Себер ханлыгында да ныгытылган шәһәрләр *тура* дип аталган. Ләкин рус галимнәре арасында "тюрьма" сүзенең немец телендәге "turm" (манара, башня) сүзеннән алынган булуы турында фаразлар бар һәм мондый фикер дә игътибарга лаек. Француз телендә "tour" — манара, башня. Шахмат һәвәскәрләре хәтерли булыр, хәзерге рус шахмат терминологиясендә "ладья" дип атала торган һәм түгәрәк манарага охшашлы фигура элегрәк "тура" дип тә йөртелә иде. Чыннан да бу тура-манаралар уен башында шахмат тактасының почмакларында, борынгы кальга-замокларны хәтерләтеп, "сакта" торалар.

Рус теленнән татар теленә кире әйләнеп кайткан "төрмә" сүзенең этимологиясен Р.Әхмәтьянов: "...рус теленә исә иске төрки түрмә, түрбә "төрбә (өсте ябулы кабер, шунда тоткыннарны да япканнар)" сүзеннән алынган дип аңлата. Шушы ук фикер Е.Н.Шиповада да бар. Электә төрмә-зинданнарның җирне казып ясалган базлардан гыйбарәт булганлыгын искә төшерсәк, халык аңында "төрмә" белән "төрбә"нең, зиндан белән кабернең тиңдәшлеге гаҗәпләндермәс. Фарсыларда онытылырга хөкем ителгәннәр төрмәсенең махсус исеме дә булган: *зиндан фәрамушан*.

Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, бу очракта көнчыгыш һәм көнбатыш алынмаларының рус телендә бергә керешеп, кушылып китү ихтималын кире кагып булмый.

***ТӨС*** — Керәшеннәрдә: *икона*. Татар телендәге *йөз, бит, чырай* мәгънәсеннән булырга тиеш. Татар телендәге *төстәш* сүзе "двойник" мәгънәсенә ия.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Салман

Кама аръягында Әлки, Чистай һ.б. районнар җире борынгы тарихи һәйкәлләргә бай булуы белән аерылып тора. Авылларда өлкән буын вәкилләре белән сөйләшсән, авыллары оешу, тирә-як турында легенда-риваятьләр, борынгы бабаларыбыз тормышына мөнәсәбәтле әллә никадәр тарихи вакыйгалар ишетәсен. Бу җәһәттән караганда, Иске Салман авылы берсеннән дә калышмый кебек.

Актай елгасына сул яктан килеп кушылган Салман суы буендагы Иске Салман авылы Әлки районы җирләрендә, район үзәге Әлки авылыннан—17 чакрымда, тимер юл станциясеннән—80, пристаньнән 62 чакрым ераклыкта урнашкан. Су үзенә атаманы авыл исеме Салманнан алган.

Салман атамасы тарихи чыганакларда, фольклор әсәрләрендә еш искә алына. А. Артемьев китабында (1866) күрсәтелгәнчә, Салман суы ярына утырган Иске Салман авылындагы 172 хуҗалыкта 557 ир-ат һәм 562 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет эшләгән. Шул ук су буендагы Абдул Салманы авылында 33 йорт булып, аларда 99 ир-ат, 112 хатын-кыз яшәгән, мәчет берәү булган. Яна Салмандагы (Урта Салман) 171 хуҗалыкта 482 ир-ат һәм 456 хатын-кыз гомер кичергән, авылда бер мәчет эшләгән. Шул ук су буендагы Абдул Салманы авылында 33 йорт булып, аларда 99 ир-ат һәм 112 хатын-кыз яшәгән, мәчет берәү булган. К.П.Берстель хезмәтендә күрсәтелгәнчә (1908) Иске Салман авылында 1659, Яна Салманда—1600, Түбән Салманда—616, Абдул Салманында 255 татар кешесе яшәгән.

Иске Салман авылы оешуы турында түбәндәге легенда-риваять бар.

Мөхәммәт пәйгамбәр исән чагында Мәккә шәһәреннән зур бер галим кеше Идел буена дин өйрәтергә җибәрелгән икән. Бу кеше Сөләйман атлы булып, галим булганга күрә, аны Сөләйман Хуҗа дип йөрткәннәр, ди.

Сөләйман Хуҗа Мәккә шәһәреннән, күп газаплар кичеп, Шәһри Болгарга килгән, ди.

Шәһри Болгарда хан Хуҗаны үзенең сараенда тотып, соңыннан илгә аң-белем таратыр өчен, безнең якка җибәргән. Сөләйман Хуҗа илгә чыгып, зур мәдрәсә ачып, бик зур муллалар чыгарган. Алар, авылларга таралып, илне агартканнар, ди. Сөләйман Хуҗа бик күп телләр белгән. Болгар илен бик яраткан, шуның өчен кире Мәккәгә кайтып китмәгән. Ул безнең бу як халкын яратып сөйли икән. Сөләйман Хуҗа әйтә торган булган: «Шәһри Болгар җире бик бәрәкәтле җир, ислам ул җиргә кылыч көче белән таралмаган. Болгар илендәге халык ислам динен үзе теләп кабул иткән, шуның өчен җомга намазында хөтбәләр агач таяк тотып кына укыла»,—дип.

Менә шушы Сөләйман Хуҗа безнең Иске Салман авылының беренче карты вә изге бабасы. Ул безнең Салман авылын нигезләүче бабабыз булган.

Шул рәвешле Салман бабай исеме белән су Салман суы дип, ә авыл Салман дип аталган. Бу авыл янында башка Салманнар да барлыкка килгәч, монысы Иске Салман исеме алган. Халык сөйләвенә караганда, Сөләйман Хуҗа зираты Иске

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Салман белән Морза Салманы арасына урнашкан. Салман атамасы тарихи чыганакларында, фольклор әсәрләрендә һ.б. еш кулланыла. Тирә-юнендә археологик ядкарьләр шактый табылган.

Археологлар Иске Салман авылы янында болгар—Алтын Урда чорларына мөнәсәбәтле каберлек һәм авыл хәрабәләре, Салман авылы янында борынгы болгар заманнарына караган әйберләр тапканнар.

Хәзерге көндә дә Иске Салман белән Абдул Салманы арасында, су буендагы матур бер урынны «Йортлар өсте», «Салман хужа кабере», «Кичү» дип йөртәләр. Халык Салман бабайны онытмый: кабернен өсте койма белән тотып алынган, ул әледән-әле янартылып тора. Борынгы гореф-гадәт, йола-кануннарны күз карасы кебек сакларга тырышкан олы буын, җәйнен матур көннәрендә тавыклар һәм сарыклар чалып, «Изгеләр өсте», «Салман хужа каберенә», «Кичү»гә килә.

Иске Салман авылыннан 4-5 чакрым көньякка таба соңгы болгар чорларына мөнәсәбәтле зират билгеләнгән. «Кичү» дип атала торган урынның да кызыклы тарихы бар. Элек Болгар шәһәреннән шушы урынга кадәр зур гына су аккан. Бу су буйлап Болгардан сал һәм көймәләр белән килгәннәр. Хәзер бу су бик кечкенә инде, шулай да Кичү дигән исеме сакланып калган. Абдул Салманы дип аталган авылны икенче төрле Салман—Морза дип йөртәләр. Иске Салман—борынгы авыл, төп Салман.

Революциягә кадәр Иске Салман авылында 450 гә якын хужалык булган. Шуларның 110 лабы ярлы, 290 тирәсе урта хәлле, 50 тирәсе хужалык шактый бай исәпләнгән. Авылда 5 жил тегермәне, ике ярма яргыч, 6 кибет эшләгән. Анда 2 мәчет гөрләп торган. Бер мәчетнең мулласы Сибгатулла исемле булган, икенчесе—Әхмәтша мулла булып, нигәдер аны терелә̆й күмеп үтергәннәр. Авылда өченче мәчет салырга җыенганнар, ләкин революция чыгу ана комачаулаган.

Авылда ике мәдрәсә эшләгән. Гайнулла Айтуганов дигән кеше рус-татар мәктәбе ачарга да тырышып йөри. 1912 елда бина булмауга карамастан, бу мәктәп ачыла һәм сабакларны төрле кешеләрнең өйләрендә укыталар.

Революциядән соң авылда совет хакимияте урнашкач авыл советы рәисе итеп Кәлимулла Хәбибуллин сайлана. Анын житәкчелегендә Аграмаковка алпавыты жирләре халыкка бүлеп бирелә.

1918 елда илдә гражданнар сугышы башланганнан соң авыл ир-атларын сугышка ала башлыйлар. 150 дән артык кеше гражданнар сугышында катнаша. 67 кеше сугыш кырында үлеп кала.

1919 елда укытучы Харис Шакиров Спас кантоны жир бүлеге мөдире Кочкариннан Яна Бездна авылы алпавыты Булыгинның өен Иске Салман авылына мәктәп итеп салу өчен рөхсәт ала. Яна Бездна авылының бай катлау вәкилләре өйне сүтүгә каршы чыгалар, ләкин ул куркып калмый, өйне сүтеп алып кайталар. 1919 елның сентябренә мәктәп бинасы өлгереп житә һәм авылда 4 классլы башлангыч мәктәп ачыла. Укулар ана телендә алып барыла.

1921 елда зур ачлык була, авылда 400 кеше ачтан үлә. Күп кеше ачлыктан котылу өчен читкә китә. Мәктәп бинасында ятим балалар өчен приют ачалар.

НЭП елларында авылда Гыйниятов Сәлим, Хәлиуллин Сөләйман, Еврей Сөләйманы, Мәскәү Кәли, мулла Арысланов Габдерәүфләр көчле сәүдә итә башлыйлар. 1925 елда Гыйниятов Сәлим кибете бинасында авылда беренче кооператив магазины ачыла.

1926 елда ярлы кешеләрнең җирләрен эшкәртү өчен «Машинное товарищество» оеша. Бу ширкәтнең сабаннары, тимер тырмалары, уру, ашлык сугу машиналары була.

1927 елда авылда уку өе һәм клуб ачыла. Уку өендә авыл яшьләре пьесалар, концертлар куя башлыйлар. Шушы елда ук комсомол оешмасы төзелә, клубта стена газетасы чыгарыла. 1929 елда авылда беренче радиоалгыч сөйли башлый. Халык радиога ышанмый, ана «сихер» дип карый. Шуннан соң, авыл алдынгыларының берсе—Гатауллин Кадыйр Казанга килеп радио аша авылдашларына мөрәҗәгать итә.

Ватан сугышы елларында авылдан 184 кеше фронтка алына, 98 кеше сугышта

башларын салалар. Бу елларда колхозның экономикасы бик нык какшый. 1944 елда авылда колхоз икегә бүленә: «Кызыл Байрак» һәм «Ворошилов» исемендәге колхозлар. Чәчү жирләренең бары 30-35 проценты гына эшкәртелә. Фермалардагы терлекләр саны кими. 1945 елда жиңү килә, солдатлар авылга кайта башлый. Сугышта булганнарның 39 кешесе орден, 57 се медальләр белән бүләкләнгән.

Сугыштан соң (1950 ел) Иске Салман авылындагы ике колхоз һәм Абдул Салманындагы «Ударник» колхозлары берләшеп, «Ворошилов» исемендәге колхозга әйләндерелә. Колхоз рәисе итеп Яруллин Сибгат сайлана.

1951 елда Чыгыш күле зур итеп буыла. Фермада терлекләр саны арта, бу елны беренче тапкыр колхоз дәүләткә икмәк тапшыру планын үти. Фермаларда сыерлар, сарыклар, дуңгызлар, атлар, тавыклар һәм куяннар асрыйлар. Шул елларда Чыгыш күле янына алмагачлар, чия, карлыган һ.б. агач, куаклар утыртыла. Авыл халкы аны Алма бакчасы дип йөртә. Колхоз монда кыяр, помидор, суган һ. б. яшелчәләр дә үстерә. Көз көннәрендә аларны арзан бәягә генә колхозчыларга саталар.

1965 елның декабрендә Иске Салман, Иске Тахтала, Яңа Тахтала, Яңа Баллыкүл һәм Иске Нохрат авыллары берләшеп, «Спутник» совхозы оештырыла. Бу совхозның үзәге Иске Салманда урнаштырыла. Совхоз директоры Шакиров Фаиз Вагыйз улы була.

Авыл 1967 елда тулысынча электрлаштырыла. 1974 елда директор итеп Әхмәтжанов Рәшит сайлана. 1981 елда совхоз директоры итеп Вафин Рөстәм Мингәрәй улы куела. Ул 1991 елга кадәр эшли. Шушы ук елда Иске Салман авылы үзе генә «Спутник» совхозында кала, башка авыллар аерылып чыгалар. 1991 елдан совхозга директор Харисов Гаваз Габбас улы билгеләнә.

1990 елда совхозда фермер хужалыклары төзергә тырышып карыйлар. Вафин Сиренад Мәсгут улы житәкчелегендә Әхмәтшин Рәшит, Нурмөхәммәтов Рәшит, Сәхаветдинов Ринат совхоздан арендага жир, ферма, трактор алганнар. Язгы чәчүне үзләре чәчеп, жәй буе карап һәм саклап үстергәннәр. Нурмөхәммәтов Рәшитнең фажигале үлеме һәм калганнарының да гомерләре энә очында калуы фермерлык эшен туктата. Аларның жирләрен совхоз кире үзенә ала.

Хәзер авылда яшьләр күбәя, авыл жанлана бара. Халыкка 4 кибет хезмәт күрсәтә. Шуларның берсе—Зыятдинов Равилнең шәхси кибете.

Авылда мәдәният йорты, медпункт, китапханә, балалар бакчасы һәм мәчет эшли.

Бүгенге көндә авылның табигате, елга-күлләре кеше ярдәменә мохтаж. Чыгыш күле көннән-көн пычрана, суы кими бара, ә аның янындагы Алма бакчасында көтү йөри. Язын һәм көзен авыл урамнары бик пычрак.

1912 елда авылга Казаннан Гайнулла Айтуганов кайта. Ул үзенең революцион карашлары өчен сөрелеп жибәрелгән була. Ул авылга кайткач, инде югарыда әйтелгәнчә, русча-татарча укыта торган мәктәп ачу өчен тырыша. Беренче мәхәлләнең алдынгы карашлы мулласы Габдерәүф Арысланов үзенең иске өен мәктәп итеп бирә. 1912 елда русча-татарча мәктәп үзенең эшчәнлеген башлап жибәрә. Башта укырга 31 бала килә. Ләкин 10-15 көннән 14 бала мәктәпкә йөрми башлый, мәктәптә бары 17 укучы кала. Мәктәптә ана теле, рус теле, математика, биология һәм география фәннәре өйрәтелгән. Укыту дүрт еллык була. 1917 елда Айтуганов янадан Казанга күчеп китә (1961 елда 82 яшендә Казанда вафат булган).

1917 елда Г.Айтугановка алмашка Спастан курслар бетереп Зарипов Һади кайта. 1919 елда ул Базарлы Матак волостенә күчерелә, аның урынын Шакиров Харис ала.

1919 елда Шакиров Харис, югарыда әйтелгәнчә, Яңа Бездна авылы алпавыты Булыгинның өен авылга мәктәп бинасы итеп күчерергә рөхсәт сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә һәм бу елны уку яңа мәктәп бинасында башлана.

1921 ачлык елында мәктәп бинасында ашханә ачыла, ятим балалар өчен приют оештырыла. 1921-22 елларда укулар булмый, бары 1923 елдан гына башланып китә.

1919—1926 елларда мәктәп мөдире булып Шакиров Харис эшли. Шушы елларда мәктәптә Алишева Закирә апа (Абдулла Алишнең бертуган апасы) Иске Салман авылының беренче коммунисты Яруллин Галимуллага кияүгә чыга, ә кызлары Сөнкишева Илсөяр әдәбият укытучысы булып эшләгән.

1934-35 уку елыннан мәктәп мөдире булып Мирхуҗин Кадыйр эшли. Ул мәктәп тирәсен рәшәткә белән әйләндереп алдыра, агачлар утырттыра, мәктәп өчен яңа парталар, өстәлләр һ.б. кирәк-яраклар кайтарта. Кадыйр Мирхуҗин репрессиягә эләгеп, 1938 елда Спас-Куйбышев төрмәсендә һәлак була.

1938 елда иске мәчет бинасы мәктәп өчен бирелә. Мәктәп мөдире булып Яруллин Абдулла эшли башлый. Укучылар саны 200 дән арта, ике сменалы укуга күчәләр.

1941 елда Иске Салман мәктәбе башлангыч мәктәп булып кала, мөдир итеп Заһидуллин Кәли билгеләнә. Ул фронтка киткәч, мәктәп мөдире булып

Сания Яруллина кала. 1942 елда укучылар житмәгәнгә күрә Иске Салман мәктәбе ябыла.

1943 елда авылда тулы булмаган урта мәктәп ачыла. Директоры Сания Шакирова була.

Сугыш беткәннән соң, авылдагы тулы булмаган урта мәктәпне ябып, башлангыч мәктәп итеп кенә калдыралар. Мәктәп мөдире булып Гәрәев Салих эшли.

1945 елда иске мәчет бинасын мәктәптән алалар һәм аны амбар ясап ашлык салалар.

1945-46 уку елында мәктәп 4 класс-комплект булып кала.

1946 елда мәктәп мөдире булып Шакиров Мансур Харис улы куела.

1949 елның сентябреннән башлап авылдагы башлангыч мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә. Директоры Шакиров Мансур була.

1950 елда иске мәчет бинасындагы ашлыкны бушаталар һәм ул бина кире мәктәпкә бирелә. Мәктәп өчен тагын бер бина салалар. Бу бина 1951 елның сентябренә салынып бетә. Мәктәпнең өч бинасы авылның төрле якларында урнашкан була. Укытучылар тәнәфестә бинадан бинага йөрергә тиеш булалар. Болай йөрү бик унайсыз була. 1954 елда өч бинаны бергә авыл уртасындагы калкулык өстенә урнаштыралар. 1954 елдан барлык укучылар да бер сменада укыйлар.

1956 елда мәктәп тирәсе рәшәткә белән тотып алына, агачлар утыртыла.

1966 елда мәктәпкә электр кертелә, телевизор, магнитофон алына, мәктәп телефонлаштырыла. 1968 елда укучылар саны 300 дән арта, тагын ике сменада укыта башлыйлар.

1979-80 елларда укучылар саны азая, янадан бер сменага күчәләр. Хәзерге вакытта бу иске мәктәп биналары сүтелгән һәм алар урынында таштан мәчет салынган.

1987 елда таштан ике катлы яна мәктәп бинасы төзиләр. Иске Салман сигезьеллык мәктәбе урта мәктәп итеп үзгәртелә. Яна мәктәпкә 78 бала укырга килә. Мәктәпнең якты һәм киң спортзалы, спорт мәйданы бар, ашханә эшли, дисплей бүлмәсе бар.

Авылда халык таза, нык һәм матур тормышта яши. Авыл өлкәннәренә ихтирам зур.

Зиратны халык тәртиптә тота.

Иске Салманнан 3 чакрым ераклыкта Яңа Салман авылы урнашкан. Исеменнән үк күренеп торганча, Яңа Салман авылы сонрак төзелгән. Яңа Салман авылында совхоз идарәсе, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, унъеллык мәктәп бар.

Авылда мәчет эшли. Зиратны халык карап һәм чистартып тора. Яна Салманнан 1-2 чакрым ераклыкта Рус Салманы башлана. Түбән Салман түбәнлек жиргә утырган.

Салман авыллары тирә-юнендә табигать матур. Авыллар янында урман-сулар да житәрлек. Ләкин сулар саега, ярлар ишелә. Минем күзәтүемчә, су-инеш, чишмә-чыганакларны карауга игътибар житеп бетми әле. Әйләнә-тирә мохитне, табигатьне саклау мәсьәләсен көн тәртибенә кую кирәк.

Авыллар янындагы географик берәмлекләр бу авылларның борынгылыгына ишарә ясыйлар. Кол атавы дигән топонимны аксакаллар болай аңлата. Борынгы заманнарда бу атауга Тау ягы төбәгеннән Колмөхәммәт исемле бабай килеп урнашкан. Шуңа авылның ул очы Кол атавы дип йөртелә башлаган. Бу бабай югарыда сүз алып барылган Сөләйман Хужа нәселеннән булган, имеш.

Зиратларда мәетләр өстенә куелган ташларны телгә китерү халык һәм авыл

тарихын ачыклау өчен өстәмә мәгълүматлар бирә. Иске Салман авылындагы Иске зират дип атала торган каберлектә 3 таш булган. Анын икесен 1974 елгы эпиграфик һәм археологик экспедиция вакытында Г.Ибраһимов исемендәге институтнын баш гыйльми хезмәткәре Марсель Әхмәтжанов күргән. Берсенен язмаларын укыган да. Бу ташта ул 1317 ел датасын күрә. Икенчесенен өске өлеше генә җирдән күренеп торган, язулары сакланмаган. Өченче таш инде бөтенләй юкка чыккан. Шушы авылда яши торган Зариф бабай сөйләвенә караганда, мондый ташлар бу зиратта 7-8 булган әле. Ләкин вакытлар үтү белән алар югалганнар.

Аксакаллар Салман бабайнын балалары Морзалар авылына чыгып утырганнар дип сөйлиләр. Андагы иске зиратлар аларныкы икән. Абдул Салманы (Морза Салманы) янында Салман суы Морзалар буе яисә Су буе дип йөртелә. Халык сөйләвенә караганда, Су буе кешене тота икән, кешене тотмасын өчен, анын янында үрдәк чалалар, ягъни суга корбан бирү гадәте сакланган. Урыслар да, чуашлар да бу йоланы үтиләр икән. Бу авылда да Иске зират бар. Авыл картлары бу зиратта 3-4 таш барлыгын сөйләгәннәр, ләкин Марсель Әхмәтжанов 1974 елны ул ташларны күрмәгән, ә зират канау белән әйләндереп алынган булган. Борынгылар каены исә—икенче иске зират исеме. Элек анда бик күп кабер ташлары булган. Ләкин аларны, халык сөйләвенә караганда, трактор белән ваттырганнар. Авылдагы тагын бер борынгы каберлек Кызыл бура дип атала. Имеш, бу урында Болгардан Буләргә укырга барганда өч кызнын берсе үлеп калган, аны күмгән җиргә шундый исем биргәннәр.

Иске Салман авылы халкынын килеп чыгышы мәсьәләләренә Колмәмәт шәҗәрәсе беркадәр ачыклык кертә. Ул ун буынны һәм хронологик яктан XVII—XX йөзләрне үз эченә ала. Шәҗәрә чылбыры түбәндәге буыннардан гыйбарәт. Колмәмәт (ул Әлки районы Иске Салман авылына Кама Тамагынын Әмәкәй авылыннан күчеп утырган)—> анын улы Мәсгут—> Давыт—> Әдһәм—> Динмөхәммәт—> Мөхәммәтжан—> Мөхәммәтша—> анын кызы Минсылу (1977 елны туган)—> Галимулла—> анын кызы Лалә.

Шәҗәрә XVII йөзнен икенче яртысында татар халкынын күчеп утыру юнәлешен күрсәтү өчен әһәмиятле.

Иске Салман халкынын бер-берсен атый торган кушаматлары үзенчәлекле: чәлтерләр, шамран, озын, пиры, куян, солы, пәриләр, компот, әнкә, майор, маймыл, әплиләр, макарлар, әнижан, тәпәчләр, зачемнар, чапай, әрсез, шимаме, кайнар, кырын, бүре, пәртүк, чумка.

Югарыда искә алып кителгәнчә, авылда күренекле педагог, халык мәгарифе отличнигы Илсөяр Гали кызы Сөнкишева туган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# «ИНДЕ ҮЛСӘМ ДӘ БУЛА...»

## МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ. КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕ

**1978 ел 5 май** көнне өлкә комитетына чакырып минем монографиягә суд ясадылар, шунын белән анын язмышы хәл ителде. Цензор Д. Ш. бөтен галимнәрне сүгеп чыгыш ясады. Судта минем монография эчендә ни барын да белмәгән кешеләр утыра иде, минем һәм И. Нуруллин (фәнни редактор) адресына күп гаеп ташладылар...

...Без матбугат көнен әнә шулай билгеләп үттек.

Фәннең, әдәбиятның Д.Ш. кебек надан, шакшы зат кулына калуы бик кызганыч, әлбәттә.

**17 май, 1981 ел.**

Мин бала вакыт. Кышкы кич якынлаша. Әни бүлмәгә чыгып чирек белән керосин алып керә. Лампаларга сала. Аннан бик зур пөхтәлек белән лампа пыялаларын сөртә, өрә, парландыра. Чырага чүпрәк чорнап пыялаfamның нәзек жирен чистарта. Бозлы тәрәзә яктысына алып килеп чисталыгын тикшерә. Өйгә керосин исе чыга. Шулкадәр тәмле, жылы, якты кич вәгъдә итә. Хәзер керосин исен якыннан сизсәм, әни, кышкы кич, тәрәзә пыяласы искә төшә. Безнең авылда кичләр бик озын була иде. Хәзер шәһәрдә телевизор кергәч, кич дигән бөек поэтик бер мәгънәгә ия булган гомер кисәге бетте...

**1981. 27 май.** Минем каршыда кибет. Хатын-кыз жыелган. Көн эссе. Ярым ялангач таза хатыннар. Кибеткә сөт килгәнне көтәләр. Ә авылда теге сөт савучы? Көтүче? Ферма мөдире? Райком секретаре? Ул сөт шушында килеп житсен өчен күпме энергия түгәләр! Бу хатыннарның берсе дә ул турыда уйлап та карамый.

**...1944 елны...** Гимн чыккач (1.01.1944.—Ред.) Х.Искәндәрев Арча педучилищесында дәрес саен шуны укучылардан хор белән укыта. "Сметём!" дигәнне хор белән әйтелә бер малай текстны укыганда.

Гимнны пропагандалау шул дәрәжәгә житә ки, моны аулак өйләрдә жырлыйлар, буш вакытларда моны шыншыйлар, клубларда моны жырлыйлар, эчү мәжлесләрен монын белән ачалар. Бервакыт Чүриле РК пропагандисты М. килгәч Крәнне мәктәбендә аш мәжлесе уздырылды. Шул мәжлес алдыннан стаканнарга аракы салгач берәү гимн жырларга тәкъдим итте. Бастык. Кулда аракы. Берәү дә текстны юньләп белми. Бутадык. Шунда куркып кына М. әйтте:

—Иптәшләр, белеп тә бетермибез, урыны да бу түгел, әйдәгез, алай эшләмик, диде. Аны ничек утыртмадылар икән икенче көнне?

Авылда дини легенда. Кеше күмгәч, берәү тынларга кала. Күмүчеләр зират коймасыннан 40 адым киткәч, теге кеше кабергә колагын куя да тынлый. Тынлык булса, мәетнең хәле яхшы; дөбер-шатыр килсәләр—начар. Имеш, кешеләр китүгә фәрештәләр килә дә, кәфенне шатырдатып ертып сорау ала башлыйлар.

Бер хатын имеш баласын имезмәгән. Тынларга калган кеше бик яман тавышлар ишеткән. Сүтеп, казып карасалар, ике кара елан теге хатынның күкрәкләренә ябышып суыралар ди.

Тыңлаган кеше боларны сөйләргә тиеш түгел. Сөйләсә—үлә. Анын зираттан

*Ахыры. Башы журналның 2006 елгы 11–12 саннарында.*

кайтканын көтеп торалар, ана сорау бирмиләр, сәдака бирәләр.
Зур серлелек, кеше күмүгә зур эш итеп карау, борынгылык белән бәйләү.

Укытучы бер малайны сүгә, рус теле дәресендә:
—Ну чего ты стоишь, не отвечаешь, стоишь?
—Стойсани... (торсани дигәнне әйтә).

Әтисе малайны каеш белән ярам дип үстерә, яргалый да. Малай бервакыт әтисенә әйтә, урманга барыйк, ди. Әтисе: агач яфрак яргач барырбыз.
—Агачларны да каеш белән яралармы?

—Минем түфлиләрем (русча әйтә) әнинекеннән матурее.

Язарга онытканмын: бала вакытта
1) үз өебездә әдәби кичәләр. Тукай китабы. Тукайның "Көз" шигырен сөйләү, урындыкка басып. Мәктәптә колхоз председателе кергәч кемне мактады. Аннан гомер буе шулай китте.
2) Либавада бер кыз белән танышкач конфет алу. Чит илдән кайткан кыз белән ашханәгә кергәч портвейн, селедка.

**1979, 16. V.** Кафедрага килеп мине телевидениегә төшерделәр. Үземнән башка һәм операторлар белән режиссердан башка моның ни өчен икәнен белмиләр иде. Шунда һәркем ачылды. Бик кызык комедия булды. Бу комедиянең авторы мин идем—көлеп утырдым. Кешеләр акылларыннан шаштылар. Һәркем бер хата җибәрде, ә берәү ике хата. Мин дә ялгыштым бугай әле кеше хатасыннан көлеп утыра торгач.

Әдәби деталь: к/з председателе хатынын санаторийга җибәрә. Хатын кайткач председатель исеменә хат килеп төшә: "Хатының бик ошады, киләсе елга тагын шул срокка җибәр"—аноним. Председатель моны чәченнән урап алып ишек алдына алып чыгып кыйный. Булган хәл.

Минем гомеремдә иң шатлыклы көннәр:
**1. 1945 ел, 9 май.** Сугыш беткәнне ишеткәч.
**2. 1956 ел, яз.** КПССның XX съездында шәхес культын тәнкыйть иткәнне ишеткәч. Нахакка кешеләрне төрмәгә утыртканнар дигәнне партия исеменнән әйткән көннәр.
**3. 1966 ел, 17 ноябрь**—малай туганны ишеткәч. Большая Красная урамында больница ишегенә килгәч.

• • •

**1981, 15 декабрь**: Иртән төш күрдем, башта әнине, аннан әлләничә тапкыр Равияне. (Әтинең бертуган апасы.—Г. Х.). Шул сәгатьтә Равиянең внучкасы дөньяга килгән икән. Аннан бөтен кешене озаткач ятып йокладым, иртәнге 9ларда Пушкинның шигырен төштә күрдем ("К няне"). Шуның бөтен юлларын тикшереп Пушкинның сагышына кушылып елап уяндым. Шигырьне тулысы белән кичердем.

Бер хикәя язарга: әти тектергән "толстовка", аның язмышы, укытучы Х., әти өстеннән донос, Х.-ның кызы ничек итеп мина экзамен бирә. Әти—шигырь уку—толстовка—донос—төн—1937 ел, 19 декабрь.

• • •

*Кайгырмагыз, еламагыз,*
*Сабыр кирәк һәр эштә;*
*Әҗәлләр җитмәгән булса,*
*Канат каплар фәрештә.*

* * *

Әни гомер буе укучылар, укытучылар белән эш иткән кеше булганга "каникул" дигән сүзне бик яратып әйтә иде.

Без кечкенә вакытта "уф алла" арбасына утырып, армиягә китүче егетләр булып урамда җырлап йөри идек. Гомәр Нургалие дигән бер малай гел болай җырлый иде:

*Кайсы йолдыз турысында*
*Сезнең йөргән юлыгыз.*
*Бәлки бергә дә булырбыз,*
*Пока хуш, сау булыгыз.*

Ике кыз кич чыгар алдыннан (күршедән кергәне) әниләренә әйтә:

—И, апа җаным, сина рәхәт, синең кич чыгасың юк,—ди. (Сүз, чыннан да эш турында бара—кияү эзләү).

* * *

Колхоз председателе әйтә:

—Үз хатынының янында әтәчләнеп булмый, чөнки синең бөтен кимчелегеңне белүче кеше бу дөньяда бары ул гына.

* * *

"Торналар"га керми калган: авыл хатынының кич токмач җәюе; катыклы аш ашаган мужикның капка төбенә чыгып утыруы; сыерга үгез ияргән, үгез озата кайткан; мужик сөенә—сыер кысыр калмаячак.

Кышкы кич—керосин лампасын кич утырырга әзерләү шатлыгы, поэтикасы.

* * *

"Торналар"га өстәргә: 1944 ел җәенең мул чирәмле Чөмә Елга ындыр арты. Мин әтинең башына житкән председательнең өенә кермим, яшьтәш кереп катык ашап чыга. Мине кыстап карый—мин ач көе шул чирәмдә ятып торам. Керсәм мине дә ашатырлар иде. Әмма мин ач, горур калдым. Шул вакытта минем ачлыкны теге явыз күрмәде, мин аны җиңдем.

* * *

**1945 елның октябрь иртәсе.** Кояш чыга. Бөтен дөнья бәрәңге сабагы исенә уяна. Бөтен дөнья сары—кофе төсле чия-сары. Кояш жылы. Тын, сагышлы. Тыныч елның беренче көзе. Мин Арчадан болын буйлап, Корайбан—Сәвин тегермәннәре аркылы кайтам. Дөнья бик сагышлы иде шул иртәдә (мин вокзалда кунган идем идәндә, капчыкны ярып сынар чүәкне урлаганнар иде).

Сикертән Г. абзый: хатыны киткән саен барып ала икән. Бервакыт барып алмаган, хатыны үзе кайткан.

—Ник килеп алмадың?—дип дулый.

—Әнә Сөнгатулла шәкерт котыртты,—ди юаш Г. Хатын әти янына керә. Әтинең каникулга кайткан вакыты икән.

—Ник кеше котыртасың син? Менә үзең өйлән әле, аннары белерсең,—дип сүгә.

Шуннан соң хатын бер тапкыр да китми.

Берәү хат яза: фәлән көнне фәлән поезд белән син мине каршы ал, сина кунакка киләм, ди. Тегесе җавап бирә:

—Сине каршы ала алмыйм, үземнең энекәшне җибәрәм, ул сине кулыңдагы каз түшкәсе буенча танып,—ди.

Бәләкәй малай солдаттагы абыйсына хат яза: сыер буаз, ала каз күкәй сала

башлады, абзар түбәсен күрәдек, сыерчыклар килергә тиеш... Ин ахырда: түтәй кияүгә бармыйча гына бала тапты...

6 апрель (1982 ел) көнне иртән сәгать 8:10 минутта кинәт кенә остеохондроз бәреп екты...

...Ә мин төштә әтинең кәкре кара таягына таянып йөрдем. Таяк сыек, яргаланган, таянырлык түгел, шулай да—ышаныч.

Билем бик авырта...

Бүген начар йокладым: төне буе мәчеләр бер-берсе белән мөнәсәбәтләрен ачыклап шауладылар.

**1946 елны** немец фашистларыннан бушап калган госпитальгә килгәч, складта тулып ята иде мундир, пилотка, тагын әллә нәрсәләр. Барысы юа юештә череп ята. Беркем бернәрсә алмады.

“Мне кажется, что со временем вообще перестанут выдумывать художественные произведения... Писатели, если они будут, будут не сочинять, а только рассказывать то значительное или интересное, что им случалось наблюдать в жизни”.

Л. Н. Толстой

Кадереҥ барда—кадерлән, кадерен беткәч каберенә әзерлән.

* * *

Ирдәй ирнең эчендә иярләнгән ат ятыр.

Хатындай хатынның эчендә биләүләгән бала ятыр.

Бүген 2-3 август төнендә (Пицундадан кайткан көнне) бер җырны төштә күрдем. “Алмагачлары” көенә. Бөтен моңы, баслары, сүзләренең мәгънәсе белән. Уйнаучысын ачык хәтерләмим.

*Ай яктылары якты дип*
*Ташка басып су алма;*
*Минем ярым читтә диеп*
*Ятлар белән чуалма.*

Искитәрлек моң иде.

* * *

**1944 елның май ахырында** Сикертән мәктәбен тәмамлаганда мин ниндидер имтиханны бишкә биргәч яланаяк йомшак юлдан авылга торып чаптым. Авылга керер алдыннан гына исемә төште: подвалда бер савыт бәрәнгеле, умачлы аш биреләр иде укучыларга. Ә өйдә—ачлык. Мин кире төшеп тормадым.

Фронттан кайткан берәү сөйли:

—Мин снайпер идем, мине фашистлар әллә каян белә иде. Бер вакыт камышлыкка барып кердем, кычкырып җибәрдем. “Ханди хох... майть”, дип. Тегеләр куркышып калдылар, әйтәләр: Яруллин, ата күрмә...

Шулвакыт хатыны сорый—алар татарча беләмени соң? Ире әйтә: Тик кенә тор, ирләр сүзенә катышма, ди.

Икенче берәү сөйли: мин, ди, бер эшелон немесне бер үзем пленга алдым, 800 кеше иде, шуларга чөгендер чүбе утаттым. Бервакыт маршал Жуков килде, строй алдыннан узганда мине танып елмайды, молодец, Сибагатов, диде. (Хатыны сорый: кием-салымы нинди иде?).

—Нинди булсын, яхшыдан инде. Кара кәчтүм-чалбар. Аягында ялтыравыклы ботинкалар. (Биектау ягы фольклоры).

Большая наука начинается с умения правильно задавать вопросы.

Диплом яклыйлар. Комиссиядә шулкадәр гаделсезлек, берсен-берсе бугазлап үз кешеләренә бишле даулыйлар, минекеләргә өчле, дүртле тезәләр. Бер чыгып бәргергәме?—дип йөри идем, Тукайны укыдым.

*Юк, маташма, и каләм!—Калсынчы—шундый юк белән,*
*Борчак атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән!*
("Сәфилгә каршы")

**1983 ел, 1 сентябрь.** Искәндәр 10 класска китте. Мин 1937 елның бу көнендә дәрестән кайттым. Беренче тапкыр. Кояшлы, жылы көн. Әти белән әни сәкедә чәй эчәләр. Мине түргә утырттылар. Әти сорашты. Ничек булды? Мин жыр дәресен сөйләдем. Әти нәрсә жырлаганымны сорады. Мин кычкырып жырладым.

*Төш чагындагы кояштан*
*Ялкын коела.*
*Җәелде Буденный атлы*
*Гаскәре кырга.*
*Һичкем безнең үткән юлны*
*Тартып алалмас.*
*Буденный атлы гаскәре*
*Әйдә, алга бас.*

Әти "Молодец!" диде.

Шуннан соң әтине хәтерләмим. Бүген 1983 ел, 1 сентябрь. Искәндәр Х классның беренче дәресеннән кайтты. Мин ана кавын алып куйган идем. Гомерләр...

Сугыш вакытында кыш көне врачлар килеп бөтен мәктәп баласына ниндидер бер кызгылт таблетка йоттырдылар. Ике көн буе авыл арасындагы кар өсте кызыл хәрефләр, фамилияләр белән чуарланып торды.

Шахтадагы малайга хат язалар: әтиең каты авырый, кайт, күмешергә кеше кирәк.
—Беләбез без балчык казуның нәрсә икәнен, кайта алмыйм,—дип хат яза...

**1941 ел, июнь ае.** Ш.—авылның иң оста пыялачысы, балта остасы. Ничек аңа повестка килде. Ничек итеп ул балтаны бәрде—балта ничек бүкәнгә кадалды. Нинди оста кеше—иң нечкә мастер—хатыннан уңмады. Юньле ризык ашамады, юньле күлмәк кимәде. Аның осталыгы белән юньле хатын туры килгәндә, яки ул безнең авылда түгел, ә Франциядә, Англиядә булса—аны каретага утыртып йөртерләр иде. Ә ул бәрәңге боламыгы ашаудан да югары күтәрелә алмады...

**1983 ел, 19 декабрь.** Әтине фашистлар алып чыгып киткән кич. Үзебезнең сәвитский фашистлар. Әсәр төзәтеп утырам. "Питрау тәкәсен печән өстендә суялар" дигән жөмлә бар. Печән өсте—июль ае. Тәкә, гадәттә, февраль, мартта туа. Июль аена кадәр бәрән булып йөри. Июль ае кергәндә тәкә бәрәнгә дәрт керә, саулыклар кирәк була башлый. Шул вакытта аның ите тәмсезләнә (организмда башка күзәнәкләр эшли башлый). Шул дәрт кергәнче аларны суялар—итләре тәмле була.
Бөтендөнья сугышының беренчесе, икенчесе нәкъ шулай эшләде: өйләнмәгән егетләрне (1922—1923 елгыларны), "нецелованный"ларны... турады, үтерде, бетерде. Бу сугышны башлаган картлар моннан ниндидер ләззәт алдылар (Гитлер, Сталин). Жинү-жинелү дигән сүзләр булды, әмма нигезендә—өлгергән Питрау тәкәләрен тәмле вакытта казанга салып ашау, "саулык" бәрәннәрне карт тәкәләргә калдыру иде инде ул.

**1981 ел, 27 август.** Коры көн, өйгә форточкадан ком тула, шәһәрнең Казанка арты районнары өермә эчендә. Эсселек 28°.
...Жәй буе корылык, афәт, бөтен дөнья көя, яна. Жәй башында язучыларны жыеп авылга ярдәм итәргә кирәк, дип тараттылар. Газеталарда көн саен язучылар

чыгышы. Урып-сугып алынган икмәктән дә күп. Бик афәтле ел, ниләр булыр? Ниләр?

Бер комбайнер эштән кайтканда гел сумка белән ашлык алып кайта икән, мона тавыклар ияләнгән, гел чорнап алалар икән. Янгыр вакытында буш сумка белән кайткан (ура алмаган), тавыклар чорнап алган, "буш сумкамны әйләндереп күрсәткән идем, олы тавык кычкырып елады", ди. (Актаныш).

Для истории.

**22. VIII. 1984.** Өлкә комитетына чакырып әйттеләр: авыл турында күп яздын, кабатлана башладын. Бу теманы бераз ял иттер. 1986 елда Тукайга 100 ел тула. Шуна роман бир. 1986 елның 1 январена өлгертсән—апрельга басып чыгарабыз. Синен материалга бай икәненне беләбез. Бөтен издательстволарда (Казан, Мәскәү) резерв калдырабыз. Синнән бүтән кеше яза алмый. Н. ышанычны акламады...

Мин риза булдым. Хәзер башымда гел шул гына. Заготовкалар эшләнә башымда, утырып язасы килә. Әлегә мөмкинлек юк. Пицундага барып "Ф.Әмирхан" дигән ике табаклык очерк язарга тиешмен. 25. VIII. 84.

Бүген **1984 елның 15 октябре.** Военком белән сөйләшеп, Искәндәрне... ВМФка җибәрергә теләгән идем, барып чыкмады. Нинди дә булса бер частькә (род) җибәрербез, отправкага әзер булсын, диде. Йөрәгемне кан баса: кая? Афганстангамы? Караком чүлләрендәге радиацияле зоналаргамы?

Без хезмәт иткәндә болар юк иде. Без матур, чиста хезмәткә барган идек.

Әни мине озатканда военкомат юлларында йөрмәде. Анын кайда икәнен дә белмәгән көе үлеп китте. Мин үзем теләп, үзем артыннан йөреп Искәндәрне армиягә озатам. Минем замандашлар, коллегалар бөтенесе малайларын Мәскәү вузларына, чит телләр институтларына һ. б. урнаштырып бетерделәр. Ә мин һаман авылча—армия хезмәте узсын дип йөгереп йөрим.

Кем хаклы? Кем ота?

Ходай белгән. Мин ялгышамдыр? Мин оттырамдыр, ләкин минем теләгем изге.

Мин бу мәсьәләдә күп газап, кайгы күрермендер, ләкин намусым чиста.—Ник калдырмыйсын?—диләр. Мин язмыш каһәреннән куркам. Шуна—калдырасым килми.



*Улы Искәндәр ялга кайткач 1987 ел.*

**15. V. 1985**

...Бер атна инде... рәхәтләнеп эшлим—яна роман язам. "Зәңгәр урманнар артында". Якынча исем, герой исемнәре дә якынча. Кул тала. Күптән мондый канәгатьлек белән эшләгәнем юк иде. Хәерле булсын...

**28 июнь, 1985 ел.** Җомга көн иртә 8 с. 10 минутта Искәндәрне военкомат ишек алдына кертеп җибәрдем.

Үзәкләрем өзелде. Хәерле булсын, хәрби хезмәткә җибәрергә үзем тырыштым. Хәерле юл, улым, йөрәгем кисәге!

**Бүген 1 июль,** кич 18.30 м. Беренче тапкыр ашыйсым килә башлады. Йөрәк һаман өзгәләнә. Үзем әлегә адрессыз гына хатлар язам. Кайда син, Искәндәр? Бу

дөнья сине кыерсытмыймы? Мин үзем ул юлда кыерсыттырмадым. Әмма син бик намуслы бит! Мин дөньяның шактый кабахәтлеген күргәч кенә ул юлга чыккан идем. Минем үзәгем өзелә. Синең өстәлең янына килә алмыйм. Ул бүлмәгә чыга алмыйм.

Улым! Нихәл? Авырмы! Бүген—җомга көн. Син чыгып киткән көн. Бик ерак ташлады бит сине язмыш. Егет кешенең язмышы шул инде аның—җир читенә барып аякны салындырып утыру. Ә миңа бик авыр. Әйтеп бетергесез авыр.

*"Сабыр итеп карыйк, дуслар,*
*Сабыр, диләр, дәвасын".*

Йа Хода, сабыр бир!


**5.VII. 16:00**

Минем тормышымда икенче этап башланды. Мин әле моны аңлап бетерә алмыйм. Ул этап үзе аңлатачак инде аны. Ләкин инде икенче кешегә әйләнеп барам. Элеккеге хыяллар, планнар бик кечкенә булып калды. Йа Хода, нинди кечкенә идеаллар белән яшәгәнмен. Зурларны күрмәгәнмен... Кеше шулай олаядыр инде.

**5.VII. 16:00**

**7.VII. 18:00**

Улым, нихәл? Сиңа авырмы? Нишлим соң инде? Мин сиңа хатлар язам—адрессыз хатлар. Сиңа дөньяны күрергә кирәк иде, син бик тә, бик тә китап кешесе илең. Инде мин бер генә нәрсә телим: син хыялыңда йорткән матур дөнья белән чынбарлык арасындагы котчыккыч аерма синең дөньяга карашыңа зыян китермәсен иде. Мин ул этапны әйбәт уздым, авыр булды, ләкин сәламәт көе уздым. Мин сине мона әзерләдем. Нык бул, улым! Нык бул! Миңа бик авыр! Синсез авыр. Бүген синең Кемьнән төшергән хатың килде. Мин шатландым да, борчылдым да. Сиңа адрессыз хат яздым.



*М. Мәһдиев, Р. Ишморатова, Ә. Еники, А. Гыйләҗев. Пицунда. 1985 ел, сентябрь.*

**1 сентябрь, 1985 ел.**

Мин—Пицундада. 309 нчы бүлмәдә. Ике бүлмәм, ике өстәлем, ике кузлегем бар. Әле берсенә, әле икенчесенә күчеп утырып эшлим. Мине каршымда Кавказ таулары, тәрәзә тулы тау күренеше. Рица күле артындагы легендалы тау сыртлары. Мин ялгыз, ялгыз. Тау араларында болыт гөлдери. И күнелле, рәхәт була иде: минем янда балалар, дингездән кергәннәр, мин язып утырып арган, эре янгырлы болыт килә, тәнгә кояштан, дингездән куәт тулган. Өстәлдә яшелчә, жимешләр, итләр, эчемлек. Без ужинга әзерләнәбез, ашханәгә төшкәнче өйдә утырып алабыз. Капризлар, ачулану, жинелчә талаш, үпкәләү, янаулар—и күнелле заманнар булган икән.

Менә мин инде берүзем, өстәлем дә буш, тик язу өстәлләре генә тулы. Балаларым да юк янымда, эчемлек тә юк, берни дә юк. Теге гөрелдәү дә инде кызык түгел—берни юк.

Шундый күнел бушлыгын мин 1953 елның көзендә хәрби хезмәттә кичергән

идем. Ул 5-6 айга кадәр сузылган иде. Хәерле булсын...

Бүген **(10. X. 85)** уйлап куйдым: хулиганнар сугышканда хәзерге заманда үтерер өчен кыйныйлар: ботинка белән башына тибәләр, бавырына, бөеренә, ике аяк арасына. Котчыккыч!

Ләкин интеллигенция дә шулай икән бит. Фән дөньясында, сәнгатьтә, әдәбият кешеләре арасында да нәкъ шулай. Үлсен, бетсен өчен эшләнә. Кызгану юк.

* * *

Тормышының иң авыр, тупикка кергән вакытларында әти кычкырып җырлап ала иде. Бер җыры болай:

*Алма диләр, алма ашыйлар,*
*Нидер алма туклыгы?*
*Бәхетлеләр рәхәт яши,*
*Читен бәхет юклыгы.*

Мондый критический хәлдән аны мөдһиш Сталин "коткарды". 1937 елның 19 декабрь төнендә.

**1977.** Язып утырам. Шушы көннәрдә генә чираттагы китабымны планнан төшереп калдырулары, берничә кешенең минем белән хыянәтчел мөнәсәбәттә булуын белдем.

Искәндәр мина комачау итә. Мина комачаулама, эшем күп дим. Работай—не работай, барыбер толк чыкмый, ди. Кем сүзе дим. Нәрсә әйткәнен аңлый башлады булса кирәк.—Извини, диде.

Ә бит устами младенца глаголет истина.

**1985.** Искәндәр, кадерле улым! Мин сине бик сагынам бит. Нишлим соң? Нинди дәвалар бар мона?

*"Ничә сәхраларга чыксам,*
*Ничә төрле агач күрсәм,*
*Бән һәм катларына барсам,*
*Диеп сорыйм ки анлардин:*
*—Әя, агач, яшең күпме?*
*Түгелгән яфрагың күкме?*
*Минем күк хәсрәтең күпме?—*
*Диеп сорыйм агачлардин".*

Укыдым: 1937—1941 елларда Арча районы Гөберчәк башлангыч мәктәбендә; 1941—1944—Сикертән җидееллык мәктәбендә; 1944—1947 Арча педучилищесында (1944—1946—Үрнәк совхозында, 1946 ноябрь—1947 июнь—Арчада);

октябрь аеннан Сеже мәктәбендә пионервожатый булып эшли башладым.

**1948 елда** (пединститутта заочно укый башладым. 1948 ел көз Крәнне мәктәбендә тарих, география, конституция укыта башладым.

**1950 ел, 3 октябрь.** Хәрби хезмәткә киттем. 1954 елнын 14 октябренда—демобилизация.

**1954 елның ноябрь-декабрь, 1955—январь, февраль**—Сикертән мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыттым.

**1955—март-апрель.** Яна Мичән мәктәбендә тарих, татар әдәбияты, теле укыттым.

**1955—1960 елларда** Казанбаш мәктәбендә тарих укыттым, соңгы ике елында завуч булдым.

**1959 елда** бик яхшы отзывлар белән пединститутны тәмамладым.

**1960—1963 елларда** университетнын татар әдәбияты кафедрасында аспирантура уздым.

* * *

Туган көнем, аем билгеле түгел. Бу мәсьәләдә мин бик күп җәфа күрдем.

Лексикон прописных истин
(минем күзәтүләрем)

1. Хатын-кыз никадәр ямьсез булса, шулкадәр киенә белми.
2. Тукай поэзиясен иң примитив аңлаучы кеше, һичшиксез, тукайчы була.
3. Уңган хатын ирсез кала. Күп очракта.
4. Татар әдәбиятын иң примитив аңлаган кеше, һичшиксез, тәнкыйтьче була.
5. Татар теленең нечкәлеген аңламаган, тоймаган кеше химиягә, физикага, математикага китми: ул—тел галиме була.
6. Кешенең тормыш коруы—космоска чыгу. Старт дөрес алынса—программа үтәлә; старт начар алынса бернинди центр корректировка ясый алмый.
7. Бер рәхәтнең бер михнәте була, диләр. Дөрес түгел: михнәте биш тапкырга артыграк була.
8. Әгәр кеше надан булса, аннан котыла алмый: надан профессор, надан академикка хәтле күтәрелеп була, әмма наданлык кала.
9. Бер борчу килердәй булса—көт, ул килә.

* * *

Үз хатыны белән танцыга чыккан кеше кебек тонык, кәефсез.

* * *

Үз хатының белән ресторанга барып танцевать итеп йөрү кебек мәгънәсез эш.

* * *

Ягып жылыт, ачып суыт (исрафчыл кеше турында).

* * *

Агач көрәк белән карандаш очлап булмый.

* * *

Йа Хода! Түбәннән күтәрелгән түрәнең ачуыннан үзең сакла!

**1987 ел, 29—30 апрель төне.** Мин Түбән Камада, чыгыш ясадым... Төнге икедә Казаннан телефон: Искәндәр кайткан. Йа Алла! Юлда бөтен курыкканым авария булды. Аңарчы инфарктттан курыктым. Күрешә алмабыз, дип уйладым.

Инде Алланың биргәненә шөкер, күрештек, 2 май көнне ярты көн кочаклашып яттык, флотский анекдотлар сөйләдек, мин үзем язганны укыдым, аннан ике диванга таралышып йокладык, көне буе дип әйтерлек.

Инде язмышка бер үтенечем дә юк. Инде үлсәм дә ярый. Мин бәхетле, ә бәхетле кеше вакытында үлә...

**5.V.87**

Кешенең иң зур бәхете—балалары белән горурлану хисе. Мин әле моны аңлап бетермим. Әмма ялга кайткан улым белән шәһәрнең Бауман, Ленин урамнарыннан узганда мин моны тойдым. Ул тойгыны сендерергә организм әзер түгел иде.

**18.III.1995.** Бүген көндез сәгать 11дә кызым Гәүһәрия роддомда өч кило авырлыгында кыз бала тапты. Шатлыгымнан тәгәрәп еладым. Үлем көтеп больницада ятам, увольнениегә кайткан идем. Ярабби, бәхете белән туган булсын иде, мин күргән авыруның ни икәнен дә белмәсә иде.

**1994 ел, 30 май.** Президент Минтимер Шәймиев үзенең резиденциясендә миңа һәм тагын өч иптәшкә "Халык язучысы" исемле дипломнар һәм медальләр тапшырды.

Әзһәр
Шакиров

# ЯЗМЫШ һӘМ УЗМЫШ

(АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ)

М. Сәлимжановка мин рәхмәтлемен дә әле: ул мине теге-бу спектакльнең алмаш төркеменә куеп, чын-чынлап эшләргә өйрәтте.

Гадәттә, репетицияләр беренче состав белән үткәрелә; алар сәхнәгә чыгып, премьера уйный. Мин айлар буена иптәшләремнең күнегүләрен карап утырырга тиеш. Ә үзем исә бер-ике мәртәбә узып, чыгам да уйныйм, шуңа күрә бәйдәге эт кебек ашкынып торам.

Нишлисең инде, язмышның шул: мин һәрвакыт репетициягә әзер булырга тиешмен. Аеруча Шәүкәт абый Биктимеров артыннан җәфаланырга туры килә иде. Марсель Сәлимжанов аны гел куркытып тора:

—Әзер булмасаң, әнә—Шәкә утыра, хәзер чыга да уйный,—ди. Мин дә кеше бит, җаныма тия: нишләп мин гел кул астындагы «запасной вариант» булырга тиеш. Шуңа күрә хәзер инде минем Марсель белән бик эшлисем дә килми иде инде. Ул моны үзе дә сизә, белә. Минем бәхетемә, театрда Ришат Хажиәхмәтов бар. Ул үзенең һәрбер спектаклендә миңа баш рольләрне бирә. Аның белән эшләү миңа гаять тә җиңел, чөнки ул күбрәк артистка ышана, минем уйнавымны чын күңелдән кабул итә. Ә бу исә артист өчен бик кыйммәт, кадерле, иң кирәкле сыйфатларның берсе. Рольне үзең эшләргә өйрәнәсең, режиссердан көтеп, нишләргә белмичә аптырап тормыйсың.

Мин Ришат Хажиәхмәтовны Марсель Сәлимжанов белән һич тә тиңләргә теләмим. Чөнки бу нәрсә гадел булмас иде. Әмма Ришатның спектакльләренә дә тамашачы һәрвакыт яратып йөрде. Шуңа күрә мин:

—Миңа бөек режиссер кирәкми, зур рольләр кирәк,—дип әйтә торган идем.

Шундыйларга карата «башы бар, акылы юк» дип әйтәләр бит инде. Бу очракта миңа үтә дә туры килә инде. Ул әлләни әйбәт режиссер түгел иде, дип, Ришатны сүк тә сүк, театрда әйбәт кенә эшлисең килсә. Минем холык-табигатем һич тә андый түгел шул. Син үз-үзеңне юкка чыгармасаң, сине һичкем юкка чыгара алмый—дустың да, дошманың да, хәтта Иблис тә.

Миңа да бераз кояш елмайды. Әзәрбайҗан классигы Җаббар-Җаббарлының «Айдын» пьесасы буенча Ага киши Кәязимов үзенең диплом спектаклен бездә куясы иткән. Шул әсәрдәге Айдын образы минем өчен иң бәхетле рольләрнең берсе булды. Беренчедән, Әзәрбайҗан әсәре үзе үк безнең өчен яңалык; икенчедән, Айдын—чын мәгънәсендәге классик роль. Әгәр дә артист талант иясе икән, аңа монда үз-үзен, фаҗигале язмышны күрсәтергә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Ул миңа бик тә туры килә, үзем нәкъ шул Айдын хәлендә идем. Үз-үземә урын таба алмыйча, бик интегеп йөргән чагым: теләкләрем зурдан, тик эшләгән эшләрем генә юк!

Бу рольдә тамашачы мине җылы кабул итте. Яшь режиссер Ага киши Кәязимов, минем уйнавымны бик мактагач, күңелләрем күтәрелеп, эшкә дәрт-дәрманым бермәбер артып китте. Ләкин бер ягы бар: ул Айдынны әзәрбайҗан артистлары уйнаганча күрә иде. Шунлыктан мин әлеге образны бераз күтәренкерәк, илһамлырак рухта бирергә тырыштым. Монда мантыйк бар: чөнки Айдын үзен Наполеон Бонапарт, Чыңгызхан кебек сизәргә тиеш. Бераз «китапчарак» уйнарга туры килсә дә, ул минем эчке рухи бер халәтемә якын, ятышлы иде. Безнең театрыбыз гадилекне, «җирләштерүне» ярата, романтик рухка әлләни исе китмичә, моны бигүк кабул итеп

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2006 ел, 11-12 саннарында.*

тә бетерми. Хезмәттәшләрем миңа гадирәк уйнарга киңәш итәләр, ә режиссер исә, киресенчә, романтик биеклеккә күтәрелергә кирәклеген әйтә.

Бу яшь режиссерның диплом эшен татар тамашачысы яратып карады, чөнки әлеге әсәр безнең халкыбыз рухына якын тора. Ошбу спектакльне сәхнәгә куяр өчен академия театры һәммә мөмкинлеген, көчен бирде дип әйтмим инде. Күмәк күренешләрдә, әсәрнең иң көчле, мәгънәви урыннарында театр училищесы студентлары парик киеп, сакал-мыек ябыштырып, ир-ат эшчеләрен сурәтләп уйнаганда күңелемә: Марсель Сәлимҗанов спектакльләрендә мондый хәлне күз алдына китерү мөмкин түгел, дигән уйлар килде.


*Актерлар Ә. Шакиров (сулда), Н. Дунаев (уңда) Л. Леоновның «Ябырылу» спектаклендә.*

«Айдын» спектакленнән соң, миңа тагын да кызыграк рольләр бирерләр әле дип бик өметләнгән идем дә— өметләрем чынга ашмады шул. Бер дә бер елны безнең театрыбызга зур бәла килде, бөтен өлкән буын артистлар бер-бер артлы тиз арада вафат булды. Болай да Шәүкәт абый Биктимеров кебекләрнең аталарын уйный торган кеше идем, хәзер бөтенләй картларга күчтем: Равил Шәрәфи белән Ринат Таҗетдинов минем «малайларым» булып калды. Югыйсә араларындагы иң яше мин. Минем дә үз яшемдәге образларны гәүдәләндергән рольләрне уйныйсым килә ич.

Бер вакытны репетициядә Марсель Сәлимҗановка:

—Әйдә, Шәүкәт абыйны алыштырып куй. Ул минем «әтине» уйнасын, ә мин— аның улын,—дип «острить» иткән идем.

Ул:

—Не остри, самоучка!—диде дә, сүзен әрәм итеп тормыйча, кулын гына селтәде. Шулай итеп, мин театрда иң карт кешеләрне сурәтләп уйный торган «бабай»га әйләндем дә куйдым.

Көтмәгәндә-нитмәгәндә миңа тагын бәхет елмайды: Дамир Сиражиев Чыңгыз Айтматовның русча язылган «Плаха» романы нигезендә куелган «Ахырзаман» спектаклендә миңа Бостон ролен бирде. Әлеге әсәр турында шуны гына әйтә алам: заманында мондый әсәр язучыдан зур батырлык сорый иде. Әгәр аны Чыңгыз Айтматов язмаса, нәшер итмәсләр иде. Татар әдәбиятында андый тетрәндерерлек әсәрне ул заманда укый алмадык. Чыңгыз Айтматов без яшәгән җәмгыятьнең, шушындый хәлдә барса, киләчәге юк дип, җанында, күңелендә, йөрәге белән социализм системасына ышанган кешеләрнең бөтен хыялларын, идеалларын чәлпәрәмә китерде. Безнең илдә болай яшәп булмый дигән идеяне сәхнәгә менгезү артистлар өчен дә, бигрәк тә режиссер өчен дә гаҗәеп катлаулы гамәл иде. Әсәр драма итеп язылмаган, ягъни пьеса түгел; коллектив бу режиссерның сәхнәләштерүенә ышанып бетми; мондый идеяне, фикерне академия театры сәхнәсеннән бик ишеттерәселәре дә, күрсәтәселәре дә килми иде. Сүз дә юк, Дамир Сиражиев бу спектакльне куеп, үзенең югары дәрәҗәдәге режиссер икәнен күрсәтте. Беренче мәртәбә татар сәхнәсендә рок-музыка алымнары, микрофоннар, бүреләр, үзенә бер төрле кабатланмас сәхнә бизәлеше, гомумән, романны ничек сәхнәгә куярга мөмкин икәнлегенә юл күрсәтте. Мин академия театрында нинди дә романны сәхнәләштереп, шундый зур уңышка ирешкән бүтән режиссерны хәтерләмим. Чыннан да, бу безнең театр өчен яңалык иде. Бостон роле минем театрдагы бөтен эшемне үзгәртте дә куйды. Мин үземдә нинди иҗади зур мөмкинлекләр барлыгын сиздем. Зур рольләр эшләргә Ходай миңа сәләт биргән

икән, дип уйладым; күңелем күтәрелеп китте, бик тырышсам, артист булам икән дип, бераз ычкынып та алдым.

Шуннан соң Дамир Сиражиев У. Шекспирның «Антоний һәм Клеопатра» трагедиясен куярга алынды, тәрҗемә иттерде. Зөлфирә Зарипова белән миңа төп рольләрне бирәм, әзерләнегез дип, безне бәхетле итәргә торганда, билгеле сәбәпләр аркасында театрдан китеп барды. «Антоний һәм Клеопатра»ны куюын-куйдылар, ләкин Зөлфирә белән миңа ул спектакльдә уйнарга насыйп булмады инде. Нишлисең, Ходай Тәгалә шулай язгандыр, күрәсең. Бездә дөнья бер битен күрсәтә, бер артын күрсәтә, диләр бит. Бу нәрсә бик туры килә. «Кара әле, нишләп син шундый акыллы, артистка бер дә килешми бит. Артист бераз «тегендиерәк» булырга тиеш». Шулай да артист буларак рольләргә алынганда мин әз генә булса да гаделлек күрергә теләдем. Чөнки бәхетсезләр дә кешеләрнең яклавына мохтаҗ.

Мин шулай җәфаланып йөргәндә, Фәрит Бикчәнтәев үзенең диплом эше итеп Мансур Гыйләҗевның «Бичура» пьесасын куярга алынды. Ул миңа төп рольләрнең берсен—Аксак ролен бирде. Пьесаны укып чыккач, бөтен күңелемне, җанымны, йөрәгемне татар язмышы, аның киләчәге, бүгенге фаҗигасе тетрәндереп җибәрде. Ничек кенә булса да, минем бу рольне «кеше төсле» итеп уйнап чыгасым килде. Беренчедән, андагы вакыйгалар миңа бик таныш, чөнки безнең авылыбыз да нәкъ әсәрдә сурәтләнгәнчә юкка чыкты. Әтием, әнием, күршеләрем—барысы да күз алдыма килеп баскан шикелле булды. Татарның авылы бетә, авыл белән бергә халкы бетә. Дәвамы шулай барса, татар милләтенең киләчәге юк дип, моннан егерме еллар элек әнә шундый әсәр язылган булган. М. Гыйләҗев, халкыбызның киләчәген, бөтен фаҗигасен ачып бирә. Бу драма бездә күренмәгән яңа алымнарга таянып эшләнгән. Әсәрдә гәүдәләндерелгән каһарманнар безнең театрда һәркөн уйнала торган авыл кешеләре түгел. Әлбәттә, спектакльнең уңышында Фәрит Бикчәнтәевнең эшен әйтмичә үтү мөмкин түгел. Ул әлеге хезмәте белән үзен оста режиссер итеп күрсәтте. Аңа: «Мондый дәрәҗәдә куелган спектакльдән соң тагын нәрсә эшләргә мөмкин?»—дип әйтәләр иде. Ул үзенең эстетикасы белән театрга килеп керде һәм үз урынын тапты. Ошбу спектакльдә мин җанымны, йөрәгемне борчыган татар язмышы турында сәхнәдән үз сүзләремне җиткерергә тырыштым кебек.

Артистка бәхет бик кирәк, рольләр турында әйтүем инде. «Бичура»дан соң театрда Гафур Каюмовның «Мирас» пьесасын Празат Исәнбәт куярга ниятләде. Миңа шундагы төп рольләрнең берсен—Хәким образын бирде. Пьеса талантлы язылган, авторның беренче эше дип һич уйламассың. Г. Каюмов татар язмышын 20 еллар элек ни көткәнен аңлап, күрәзәчедәй белеп язган. «Мирас» әсәрендә балалары байлык өчен аталарын кыйнап үтерәләр. Мин әле татарларның кем икәнен мондый дәрәҗәдә сәхнә өчен сурәтләүне күргәнем булмады. Үзен кыйнап үтерүче балаларның атасы кем, нинди? Ул фани дөньяда ничек яшәгән? Кайдан җыйган ул байлыкны? Байлык татар кешесенә бәхет китерәме? Бу кешенең фаҗигасе нәрсәдә? Мин менә шундый катлаулы сорауларга җавап бирергә тырышып уйнадым. Бигрәк тә тамашачыны ышандырырлык алымнар эзләдем. Акыллы белән җүләр арасында бер генә аерма бар: акыллы сүз әйткәнче уйлый, җүләр башта сүз әйтә, соңыннан уйлый. Кешенең холык-фигыле—аның язмышы ул. Бу уй-фикер минем маңгаема язып куелган.

*Ахыры киләсе санда.*

Сәйдәш
Гарифуллин

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ...

*Үткәннәргә таш атсак, киләчәкнең
бәллүр савытын ватуыбыз бик ихтимал.*
Билгесез философ

Мин Буа шәһәрендә туып-үстем. Музыка мәктәбенең фортепиано классында укыганда минем сабакташларымның берсе Ирек Галимов иде. Ул тора-бара атаклы баянчыга әверелде, Татарстанның атказанган артисты дигән исемгә лаек булды, 30 елга якын Илһам Шакировның концертмейстры булып эшләде. Кызганыч: 48 яше тулган чактарак бу фани дөньядан бик иртә китеп тә барды. Ирек—минем тормышымда хәлиткеч роль уйнаган кеше. Чөнки, танылган баянист Рифкать Гомәров музыка училищесына китеп бару сәбәпле, аның урынына ул мине И. Шакировның концертмейстры итеп татар дәүләт филармониясенә 1968 елны эшкә чакырды. Мин бу вакытта Казан дәүләт университетын тәмамлап, «Оргсинтез» заводында инглиз полиэтиленын житештерү буенча тәржемәче сыйфатында ике ел эшләп өлгергән идем. (1969 елны тарих-филология факультетының роман-герман бүлеген тәмамлавымны әйтеп китү кирәктер бу очракта.)

Мин инде аккордионда фанатикларча шөгыльләндем, төрлечә ансамбль яисә ресторannarда уйный идем. Ә инде филармониягә, дөресрәге Илһам бригадасына эләгү—минем өчен күктән төшкән бәхет иде! Советлар Союзы киңлекләре буйлап гастрольләргә йөрдек, концерттан соң исә артистларны бик еш кунакка чакыралар иде.

Бервакыт, 1970 елны Алма-Ата шәһәрендә, Илһам Шакиров, Ирек Галимов һәм мине 27 яшьләр тирәсендәге бер казах егете үзенең өенә кунакка чакырды. Һөнәре буенча тау инженеры, әмма поэзия, тарих, филология белән тәмам «женләнеп» беткән шәхес булып чыкты. Исем-фамилиясе—Олжас Сөләйманов. Без таңга кадәр диярлек чәйләр-мәйләр эчеп, сөйләшеп утырдык. Әдәбият, сәнгать, милли сәясәт турында. Илһам белән Олжас әңгәмәбезнең йөзек кашы иделәр, билгеле.

Менә шул чакта Олжасның: «Мексика индеецлары телендә казах сүзләренең барлыгын ничек аңларга?»—дигән фантастик соравы мине таң калдырган иде. Ә инде 1975 елда О. Сөләймановның «АЗ и Я» дигән атаклы китабы дөнья күрде. Аны укыганнан соң мин Олжасның шумер һәм төрки телләр лексикасындагы охшашлыклар белән бик тирәннән кызыксынуын белдем. 1977—1981 елларда Гыйракта тәржемәче булып эшләгәндә (СССРның мелиорация һәм су хужалыгы карамагында) мин Ур, Шумер, Вавилон кебек борынгы өлкәләрдә еш булгаладым. 1985-87 елларда исә мина Сүриянең Латакия дигән порт-шәһәрчегендә яшәргә туры килде. Бу шәһәр Әлифбаның ватаны дип саналган Угарит калдыклары өстендә салынуы белән кызыклы. Ирексездән борынгы Шәрык турында уйланасың.

Һәм менә, ниһаять, Татарстан Академиясенең тел, әдәбият һәм тарих институты (ИЯЛИ) каршында аспирант булып йөргән чагында мина аның баш хезмәткәре, «Протюрки и индейцы Америки» (Москва, «Инсан», 1995 г.) Әбрар ага Кәри-

муллин белән танышырга туры килде. Кайчандыр әкияти-фантастик тоелган күп кенә мәсьәләләргә ачыклык керде. Чыннан да, жирле индеецлар телендә гомумтөрки тамырларның күплеге үзен һәрчак сиздереп тора. Моның сәбәпләрен тарихи яктан шактый жиңел һәм бик нигезле аңлатып була икән ләбаса: әллә ничә меңәр елларга сузылган бөек бозлык чорында диңгез төпләре судан арчылган, Азиядән—бигрәк тә Камчаткадан алып Алеут утраулары аша Америка континентына кадәр «Коры» юл ачылган. Төрле сәбәпләр аркасында халыклар, кыргый мал-туар (бигрәк тә бизоннар) шул якка таба агылган... Алгарак китеп булса да бер дәлил. 2006 елның мартында «Вести» программасы Канада бизоннарының Якутиягә күчүләре хакында репортаж күрсәтте. Феноменаль хәл бу: моннан меңнәрчә ел элек күчеп киткән кыргый үгезләрнең «тарихи ватаны»на кире кайтырга теләүләрен кан чакыруы беләнме, нәрсә белән аңлатырга?

Күченүчеләрнең, нигездә, төрки халыклар булуы берничек тә бәхәс уята алмый. Чөнки Идел белән Тын океан арасында төрки халыкларның элек тә, хәзер дә яшәп ятканлыгы тарихта яхшы мәгълүм. Көнчыгышта кытай, фарсы, византиялеләр юлны каплаган, алар үзләре дә салкын һәм кыргый Камчаткага бер дә ашкынып тормаганнар, билгеле. Дөресен таныргa кирәк—индеецларның борынгы бабалары төрле юллар белән Америка кыйтгасына эләккән Африка, Европа, Кытай кавемнәреннән дә калыплашкан. Ләкин лингвистика өлкәсендә төп агым булып төрки тел сакланып калган. Менә бер кызыклы мисал: Юлиан Семенов дигән язучы Штирлиц һәм Мюллерның сугыштан соң Көньяк Америкадагы мажаралары унаеннан бу кыйтгадагы иң атаклы шарламаның Игуасу икәнлеген әйтеп уза. Жирле халык телендә бу «Зур су» дигәнне аңлата. Төрки телләрдә «Су»ның су икәнлеген аңлатып та торасы юк.



*Сәйдәш Гарифуллинның «Алтын аккордеон» дигән музыкаль язмасы тышлыгы.*

80-нче еллар ахырында мина Ленин исемендәге китапханәдә шактый нык эшләргә туры килде. Менә шул чакта Г. Ершованың (хәзер инде фәннәр докторы, профессор) индеецлар теленә багышланган хезмәтенә тап булдым. Исеме—«Тарихи-этнографик чыганак буларак майя теленең иерогриф текстлары». Шуның азагында майя телендәге кыскача сүзлек рус телендә бирелгән. Мин моны игътибар белән укып чыктым. Боларның билгеле бер өлеше төрки телләргә якын иде һәм алар Әбрар ага Кәримуллинның хезмәтләрендә дә чагылыш тапкан. Ләкин анда керми калган сүзләр дә очрады, мин аларның кайберләрен татар теленә тәржемә рәвешендә тәкъдим итәм:

*как—кыяк (росток),
тул—тулы (вокруг),
туул—тулу (переполняться),
цоц/сос—сач, чәч (волосы),
каам—камаш (челюсть),

суу—су кайнату савыты ( сосуд),
цак—сак, саклау (охранять),
чум—чуми (лиса, нора, женский орган),
ав—авыл (селение),
теп—жеп (веревка),
баак—кабак (тыква).

Мин болар хакында 1997 елны Татарстан фәннәр Академиясенең еллык фәнни конференциясендә чыгыш ясадым һәм ул текстны Әбрар ага Кәримуллинга бирдем. Кызганыч: ул инде фани дөнья белән саубуллашырга җыенган иде.

Үземнең кандидатлык диссертациясендә мин татар теленең бәйлекләрен дә, төрки телләрдәге һәм руник язмалардагы килешләрне дә чагыштырып өйрәндем. Менә шуларны шумер телендәге килешләр белән чагыштырганнан соң аларның бик нык охшашлыгына шаккатып калдым! Галимнәр даирәсенә генә ныграк анлаешлы бу мәсьәләләр белән укучының башын катырасым килми, мин бу эзләнүләремне «Татар теленең лексикологик һәм лексикографик проблемалары» дигән китабымда җентекләп, таблицалар аша күрсәтеп бирдем.


*Олжас Сөләйманов (сулда) һәм Сәйдәш Гарифуллин. 2004 ел.*

Абруйлы тюркологлар Фуат Ганиев (минем фәнни житәкчем), Вахит Хаков (КДУ), Мирфатыйх Зәкиев бу хезмәтемә унай бәя бирделәр, хупладылар. 2004 елны Олжас Сөләйманов Казанга килде. Мин аңа 35 ел элек күрешкәнебезне искә төшердем һәм әлеге китабымны бүләк иттем (фоторәсемдә шул мизгелне күрәсез). Ул барысын да хәтерли икән: Илһам Шакировка сәлам тапшырырга кушты, ә инде шумер һәм төрки телләрдәге грамматик килешләрнең охшашлыгын (тәнгәллеген) табигый бер хәл дип кабул итте, чөнки ярты гасыр диярлек бу телләрне өйрәнү, чагыштыру, анализлау белән шөгыльләнгән бу галим-язучыдан бүтәнчә бәя ишетү мөмкин түгелдер. (Илһамга сәламен житкердем, безнең теге чактагы «тарихи» очрашуны озаклап, сагынып искә алдык).

2006 елны Олжас янадан Казанга килде, аны күрү насыйп булмады, шулай да аңа Кол Шәриф мәчете һәм Пирамида сурәтләре төшерелгән музыкаль дискымны бүләк итә алдым. Сүз унаеннан, безнең бу Пирамида Шумерның (Месопотамия) Ур шәһәрендәге баскычлы пирамидалар үрнәгендә төзелгән. Моңа ышану өчен Сетон Ллойдның «Месопотамия археологиясе» (Москва, «Наука», 1984 г.) китабындагы 271 нче биткә күз салу да житә. Күптән түгел Лас-Вегаста (Казанныкыннан зуррак), Парижда (Казанныкыннан кечерәк) шулай ук пирамидалар төзелде, ләкин алар—барыннан да бигрәк модага ияру һәм архитектура стиле. Казан пирамидасы исә—төрки дөньяда бердәнбер һәм шумер, төрки һәм индеецлар (Америкада яшәүче төп җирле халыклар) цивилизациясендәге тирән тарихи бәйләнешләрне гәүдәләндерә. Лингвистлар гына түгел, тарихчы галим Рафаэль Мөхәммәтдинов та «Звезда Поволжья» газетасының апрель саннарында («Бабаларыбыз рухы кайта») Шумер цивилизациясе белән бәйләнешләрне онытмаска чакыра. Күргәнебезчә, тарих, археология, лингвистика фәнен

өйрәнүчеләр борынгы төрки дөньяның Гыйрактан алып Аргентина чикләренә кадәрге географик киңлектә җәелеп ятканлыгын бердәм рәвештә яклыйлар.

1987 елны Көньяк Уралда атаклы Аркаим шәһәрлеге арчылды. Байкал тирәсендәге борынгы шәһәрлектә әле күптән түгел 3 мең ел элек эшләнгән тимер җайланмалар табылды. Кызыклы хәлләр дә юк түгел. Менә ерактагы аулак бер Себер авылын күрсәтәләр, анда америка экспедициясе монарчы «билгеле» булмаган өр-яңа телгә юлыгалар. Йорт хуҗабикәсе американ галимнәренә ашау әсбабын күрсәтеп, аның «кашук» дип, ә инде табындагы ипи телемнәренә күрсәтеп, ризыкның «икмәк» дип аталуын аңлата. Чыннан да, өр-яңа «тел» ачканнар! Кемдер әйтмешли, урысны тырнасаң—татар чыга, Себер кешесен тырнасаң—төрки кавем чыга. Берничә мең еллар элек Себердә төрки юнәлешле куәтле цивилизация үзәге булганлыгы бәхәссез фактлар белән ныгытыла.

Әмма зур фән әллә өлгерми, әллә инде булган мәгълүматларга күз йомып карый. Мәсәлән, «Лингвистик энциклопедия сүзлеге»ндә (Мәскәү, 1990) «шумер теленең башка телләр белән бәйләнеше расланмый» диелә, аның гаҗәеп грамматикасы безнең көннәргә тикле сакланып килгән бер генә телгә дә охшаш түгел, янәсе, (177, 589 битләр). Кыскасы, тарих фәне төркиләр турында бик аз белә. Чөнки Л. Н. Гумилев язганча, борынгы төркиләр һәм күчмә кабиләләрнең матди культура калдыклары—киез, күн, агач һәм мехлар—ташларга караганда начаррак саклана.

Америка индеецларының борынгы төрки халыклардан килеп чыгу гипотезысына каршы килүчеләр болайрак фикер йөртә: «индеецлар теле моннан 30-40 мең еллар элек Азиядән Беринг бугазы аша күчеш ясаган халыклар теленә керә». Бу вакыт эчендә мигрантлар телендәге сүзләр берничек тә саклана алмый, янәсе. Моның ялгыш караш икәнлеге көн кебек ачык. Һәрбер бозлык чорында яңадан-яңа кавемнәрнең күченүен нигәдер онытып җибәрәләр. Бизоннар, ягъни кыргый үгезләр белән бергә күченүчеләрнең соңгы дулкыны моннан берничә мең еллар элек булганлыгы тарихта мәгълүм. Шунысы да бар—әлеге күчеш кире якка таба да кабатланып торган.

Шумерлар белән тарихи бәйләнешне үзара бүлгәләргә, таркатырга ярамый. Куллардагы бармаклар шикелле, бу—төрки халыкларның, аеруча татар, казах, башкорт, якут, чуваш, уйгур һ. б. кардәшләрнең бердәм тармагы ябалдашы, йолдызлыгы. Мәсьәләгә сак килергә, үзара хөрмәт һәм чама хисен югалтмаска кирәк безгә.

**P.S. (Автордан өстәмә).** Әйткәнебезчә, борынгы төркиләр тарихы ныклап өйрәнелмәгән, фәндә ул чагылмый диярлек. Америка индеецлары әллә каян, урманнар ясисә тау-таш арасыннан гына килеп чыкмаган, алар акрын-акрынлап безнең биниһая киңлекләребездән күченеп килгән. Тарихтагы менә шушы «ак тап»ны бетерү өчен халыкара фәнни конференция үткәрергә кирәк. Нәкъ менә башкалабыз Казанда, Пирамида бинасында. Чит илләрдән дә галимнәрне, белгечләрне чакырып. Аннары андагы яңгыраган чыгышларны татар һәм рус телләрендә бербөтен китап итеп бастыру фарыз. Бу материаллар тарих дәреслекләренә дә кертелергә тиеш. Әлеге конференцияне үткәрү өчен химаячеләр (спонсорлар) табылыр, бу изге чараны үткәрүдә хөкүмәтебез дә ярдәменнән ташламас дигән ышаныч бар. Амин, шулай булсын.

**—Татар рухын, милләтебезне бердәм туплауда Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеге хуплауга лаек. Менә дүрт ел инде татарның дөньякүләм дәрәҗәле оешмасын җитәклисез. Сез үзегезнең эштән канәгатьме? Конгресс эшчәнлегендәге иң актуаль мәсьәләләр нәрсә ул?**



**Ринат ЗАКИРОВ,** ***Бөтендөнья татар конгрессы рәисе:***

—Быел Бөтендөнья татар конгрессы оешуына 15 ел тула. Бу вакыйганы без август аенда узачак БТКның IV Корылтаенда билгеләп үтәргә җыенабыз.

Тарихтан беләбез: дөньяга сибелеп яшәгән татар халкын берләштерү, аның идарә структураларын булдыру омтылышы 1917 елда Милли мәҗлес һәм башка формаларда чагылыш тапкан. Әмма совет чорында болар юк ителә, татар тормышын автономия кысалары белән генә чикләргә тырышалар, ә читтәге татар дөньясы белән аралашу бөтенләй тыела. Татар конгрессының яңа сыйфатта оешуы, аның 90 нчы еллардагы милли күтәрелеш чорына туры килүе очраклы түгел. Бүген конгрессның кирәклеге, аның игелекле гамәлләре милләтебез тарафыннан гына хупланмый, ил җитәкчеләре дәрәҗәсендә дә югары бәяләнә. Моның ачык дәлиле—үткән ел Петербургта булып узган Бөтендөнья Россия ватандашларының конгрессында яңгыраган В. Путин һәм М. Шәймиев чыгышлары.

Соңгы елларда без милләт мәнфәгатьләрен яклауның яңа формаларын һәм юнәлешләрен табарга тырыштык. Әйтик, былтыр җәй аенда татар яшьләренең II Бөтендөнья татар яшьләре форумы уздырылды. Шулай ук дин, мәгариф өлкәсендә, хатын-кызлар, гаилә мәсьәләләре буенча да шактый алга китеш бар. Аларның кайберләрен санап китәм: Бөтенроссия татар укытучылары корылтае, Изге Болгар җыены, Татар гаиләсе фондын һәм Бөтенроссия «Татарча көрәш» федерациясен булдыру һ. б. Милләтебезнең дин әһелләрен бергә туплау, дин өлкәсендә җыелган зур проблемаларны уртага салып сөйләшүне, шәхсән, шулай ук зур казаныш дип саныйм. Халкыбызның яраткан бәйрәме Сабан туе турында да әйтмичә булмый. Бүген алар Россиянең 64 төбәгендә һәм 30лап чит илләрдә даими уздырыла.

Халкыбызның бердәмлеген ныгыту исә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып кала. Сер түгел, татарның төрле оешмалары оешып тора һәм бу беренче карашка начар түгел. Ләкин алар арасында еш кына милләт мәнфәгатьләрен кайгырту икенче планга күчә, ә үзара низаглар, тарткалашулар өскә калкып чыга. Монда мәкальдәге сыман: һәрберсе мулла, әмма «атка печән салучы» табылмый. Безнең төп принцип болай—милләтебез мәнфәгатьләрен яклап кем конкрет гамәлләр башкара һәм төбәктә яшәүче татар халкын берләштерә, шул Бөтендөнья татар конгрессының урындагы таянычы.

Соңгы елларда милли мәгариф мәсьәләләре чит төбәкләрдә генә түгел, Татарстанның үзендә дә шактый борчу тудыра. 16 район үзәгендә татар мәктәпләре юк. Бүген Бөтенроссия күләмендә татар мәктәпләрендә, «оптимизация» яисә кадрлар кытлыгы сылтавы белән, татарча укытуны бетерү киң колач алды. Моның сәбәбе күпкырлы: бер яктан ассимиляциягә, имансызлыкка китергән илдәге сәясәт булса, икенче яктан шул сәясәтнең корбаннары, милли анны җуйган, туган телдән, ишле гаилә корудан читләшкән милләттәшләребез. Татар гаиләсендәге күркәм гореф-гадәтләрне, матур традицияләрне, һичшиксез, янадан торгызырга тиешбез.

Без инде соңгы дәвердә милли анның никадәр мөһим булуын аңладык. Бу эштә мәгълүмат чаралары бик мөһим урын алып торырга тиеш, ләкин аларның мөмкинлекләре төрле сәбәпләр аркасында елдан-ел чикләнә бара. Мин, мәсәлән, «Казан утлары»ның 80-90 мең тираж белән чыккан вакытларын хәтерлим. Матбугатны таратудагы проблемалар күп кенә басмалар өстендә кылыч кебек асылынып тора.

«Без бөтен дөньяга чыгабыз!» дип шапырынган «Татарстан—яңа гасыр» телеканалы хәтта кайбер якын төбәкләргә дә әлегәчә үтеп керә алмый. Өстәвенә, аның эчтәлеге дә милли мәнфәгатьләрне житәрлек чагылдырмый.

Инде ярты гасыр дәверендә татарның гомуммилләт мәгълүмат чарасы булып «Азатлык» радиосы эшләп килә. Гаҗәп бит: татар мәсьәләләрен яктыртучы дөньякүләм берданбер радиостанция АКШ конгрессы акчасына яши. Россиядә сан ягыннан икенче урында булган татар милләте федераль радио һәм телеканаллардан мәхрүм. Шунысын да әйтергә кирәк, бүген Россия чит илләр өчен 40 телдә радиотапшырулар алып бара һәм моңа шактый чыгымнар да сарыф итела. Әмма ил файдасына тырышып эшләүче, бөтен салымнарны түләп баручы татар халкына ил күләмендә тапшырулар оештырырга акча һаман табылмый. Бу инде илдәге милләтләргә булган мөнәсәбәтне, аларның мәнфәгатьләрен санга сукмауны ачык күрсәтеп тора.

Кайбер төбәкләрдә милләттәшләребезнең хокуклары шактый чикләнә. Ниһаять, конгрессның III съездыннан соң Башкарма комитет каршында махсус юридик төркем тупланды. Аның эшчәнлеге кеше хокукларын яклаудан башлап, радиациядән зыян күргән татар авылларының мәнфәгатьләрен кайгыртуны да, дин кардәшләребезне төрле эзәрлекләүләрдән саклауны һ. б. үз эченә ала. Татар үзе-үзен якламаса, аны кем яклар? Дөньяның зур халыклары кебек, без бу дөньяда үз урыныбызны алыр өчен көрәшергә тиеш. Ә моның өчен ныклы бердәмлек кирәк.

Әңгәмәдәш—**Р. НИЗАМИ**

---

# КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

**«Яңа дәвер кешесе»**

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызның мең санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меңнәр белән язылды. Яна меңьеллыкка—яңа дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яңа дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөрриятка, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Яңа хикәяләргә ачык конкурс дәвам итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елның декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**

# В

**ВОДЕВИЛЬ** (франц. vaudeville, Vau de Vire – жанрга исем биргән Нормандиядәге төбәк исеме), комедия жанрының (музыкаль номерлар, такмаклар, романслар һәм биюләр) бер төре. В.га күңелле сюжет, кызыклы интрига, юмор хас. Татар драматургиясендә борынгы халык уеннары нигезендә барлыкка килә. Этнографик характердагы беренче татар В.ләре милли муз.-шигъри әсәрләрдән тора ( мәс., И.Гаспринскийның «Кыз ярәшү» В.). 20 йөз башында татар драматургиясе көнбатыш, шәрекъ һәм рус әдәбиятлары йогынтысында үсә. Татар сәхнәсендә А.П.Чеховның «Кыз сорау», Мольерның «Саран», «Ирексездән табиб» пьесалары һ.б. уйнала. Рев-циядән соңгы татар драматургиясендә социаль-сәяси характердагы яңа В. барлыкка килә. Бу сыйфат бигрәк Г.Камал пьесаларына хас (мәс., «Ахырзаман»). 1930-50 елларда татар драматургиясе В. жанрына бөтенләй мөрәҗәгать итми. 1960 елларда яңадан В. жанрындагы пьесалар языла. Мәс., Г.Насрыйның «Яшел эшләпә», З.Шәһиморатның «Тугыз гашыйк», Х.Вахитның «Күк капусы ачылса», И.Юзеевнең «Бөркетләр кыяга оялый», Т.Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү», Ф.Яруллинның «Әнә килә автомобиль», Ф.Садриевның «Их сез, егетләр!..» пьесалары һ.б.

Әд.: Ханзафаров . Н.Г. Татарская комедия. К., 1996; Мәхмүтев Һ.; Илялова И., Гыйззәт Т. Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988.

*Н.Г.Ханзафаров.*

**ВОЗНЕСЕНСКИЙ** Александр Николаевич (18.7.1888, хәзерге Мордовия Республикасы, Адоратов р-ны Чукалы а. – 16.1.1966, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1943). Варшава ун-тын тәмамлый (1913). 1921-30 елларда Белоруссия ун-тында (1926 дан проф.), 1931-34 тә кинематография, хим.-технология һәм педагогика ин-тларында (Мәскәү) укыта. 1939 дан Казан пед. ин-тында, 1940-61 дә Казан ун-тында, 1943-48 дә тарих-филология ф-тында декан, шул ук вакытта 1946-48 дә рус әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре әдәбият методологиясенең гомум мәсьәләләренә, славян әдәбиятларын чагыштырып өйрәнүгә, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, И.С.Тургенев, Т.Г.Шевченко, Я.Купала, Я.Колас, М.Богданович һ.б. иҗатларына карый. Әдәбият белеменең милли үзенчәлекләре теориясен алга сөрә. А.А.Фукс, Г.П.Каменев, Г.Тукай турында басылмый калган мәкаләләр авторы.

Хезм.: Метод преподавания литературы // Изв. Наркомата просвещения БССР. Минск, 1921; Метод изучения литературы // Тр. Белорус. ун-та. Минск, 1922. N1; Опыт историко-литературного изучения художественных произведений в трудах профессора В.А.Богородицкого // Уч. зап. Казан. ун-та. 1961. Т.119, кн.5.

Әд.: Белорусская ССР: Краткая энцикл. Минск, 1982. Т.5.

**ВТОРОВ** Иван Алексеевич (1.6.1772, Оренбург губ., Бузулук өязе, Ласкарёвка а. – 14.2.1844, Казан), библиофил. 1805-15 елларда Самара шәһәрендә судья булып сайлана, шул ук 1812-14 тә городничий булып тора. 1790 еллар башында шигырьләр яза башлый, ләкин 1800 дән соң матбугатта әсәрләре басылмый. 1835 елда Казанга килеп урнаша. В. истәлекләрендә 19 йөз башы Мәскәү һәм Казан тормышына караган әһәмиятле мәгълүматлар тупланган, атаклы рус әдипләренең тәрҗемәи хәлләрен өйрәнгәндә алар чыганак ролен үтиләр, мәс., аларда А.С.Пушкинның Казанда булуы турында, В.А.Жуковскийның, Н.М.Карамзинның һәм 18 йөзнең күренекле рус «волтерчы»сы В.И.Полянскийның әдәби портретлары бар. В. ның 903 исемдәге 1908 томнан торган китапханәсе аның вафатыннан соң улы тарафыннан Казан шәһәренә тапшырыла, ул Казан шәһәр китапханәсенең (1991 дән ТРның Милли китапханәсе) нигезен тәшкил итә.

Хезм.: Москва и Казань в начале XIX в. // Русская старина. 1891. N4.

Әд.: Бобров Е.А. А.А.Фукс и казанские литераторы в 30-40-х гг. // Русская старина. 1904. N7; Русские писатели. 1800-1917: Биогр. словарь. М., 1989.Т.1.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

## Канәфи Бадыйков



Канәфи Габделбәр улы Бадыйков (әдәби тәхәллүсе—Ханәфи) Татарстанның Арча районы Мөрәле авылында туа.

Сеже урта мәктәбен тәмамлагач, Арча педагогия училищесында белем ала. Хезмәт юлын Сикертән сигезьеллык мәктәбендә математика һәм җыр укытучысы буларак башлап җибәрә, шул ук вакытта Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә.

1964—1967 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Хәрби хезмәттән кайткач, университетны көндезге бүлектә укып тәмамлый.

1970—1974 елларда Кама Тамагы районында Иске Казиле сигезьеллык мәктәбе директоры, Олы Карамалы урта мәктәбендә директор урынбасары вазифасын башкара. Шул елларда очерклары, шигырьләре матбугатта күренә башлый.

1974 елда туган ягы Арчага кайтып, башта «Коммунизмга» газетасында хатлар бүлеге мөдире булып урнаша; 1975—1979 елларда Урта Пошалым урта мәктәбе директоры булып эшли, тел, әдәбият, тарих, җәмгыять белеме укыта; 1978 елда Казан дәүләт университеты каршындагы аспирантурага укырга керә, аны 1981 елда тәмамлый. 1979—1986 елларда КДУ нын татар теле кафедрасында эшли, 1982 елда патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» әсәрләренең тел-стиль үзенчәлеге турында язган кандидатлык диссертациясен яклый.

1986—1994 елларда Казан дәүләт педагогия институтында ассистент, өлкән укытучы, доцент вазифаларын башкара, тел белеменең төрле тармаклары—фонетика, лексика, стилистика, тарихи һәм чагыштырма грамматика, гомуми тел белеме буенча лекцияләр укый. 1994—1996 елларда Татар Милли университетында уку-укыту эшләре буенча проректор булып эшли.

1997-98 елларда «Казан» журналы мөхәррире, 1998—2004 елларда «Мирас» журналында бүлек мөхәррире, баш редактор урынбасары була. Хәзерге вакытта Казан дәүләт консерваториясе доценты, шул ук вакытта әдәби-гыйльми, музыкаль иҗат белән дә шөгыльләнә.

Ул—«Уроки татарского языка. Самоучитель»—1993, «Туган тел китабы»—1993, «Абага чәчәге»—2001 (әдәби тәнкыйть мәкаләләре, фәнни хезмәтләр), «Күңел ялкыны»—2002 (шигырьләр, поэмалар, җырлар) китаплар авторы.

Моннан тыш, аның күпсанлы лирик һәм юмористик шигырьләре, хикәяләре, фәнни-публистик мәкаләләре республикада нәшер ителүче газета-журналларда даими урын алып тора. Үзешчән композитор буларак, ул бер дистәгә якын җырлар авторы да («Арча ягы», «Еракларга китәм, дисең», «Язгы кичләрдә», «Мәктәбем», «Тик син бер генә», «Бик сагындым сине, Туган ил», «Казан капкасы» һ. б.).

2006 елның 8 ноябрендә, Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (Тәкъдимнамә язучылар: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Әхәт Гаффар, Рашат Низами) Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Бадыйков Канәфи Габделбәр улын (Ханәфине) Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.



*Әлмәт язучыларыннан бер төркем. Үткән гасырның 70 нче еллары.*



*Кадыйр Сибгатуллин (уңда) һәм Марсель Гыймазетдинов. 1990 ел.*



*Кырымтатар шагыйре Сәитгомәр Әмин. Үткән гасырның 80 нче еллары.*



*Расул Гамзатов һәм Дания Дәүләтшина (Татарстан Югары Советы президенты секретаре). 1986 ел.*



*Ләбибә Ихсанова һәм Хәсән Сарьян. 1975 ел.*

*Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» спектакленнән күренеш. Г. Камал театры артистлары (сулдан уңга) Ә. Зарипов, И. Баһманов, Г. Фәтхуллин, Ф. Колбарисов. Үткән гасырның 70 нче еллары.*



# ГОМЕРЛЕК СҮЗ

## Зәкия Туфайлованың тууына 100 ел

Матур әдәбиятны ярату кайчан башлана? Билгеле, бишек җырлары, бала чакта ишетеп, укып үскән җыр-шигырь, әкиятләр аша. Кем генә йотлыгып «Су анасы», «Шүрәле»не тыңламаган да, үзе дә әти-әни булгач, белгәнен баласына өйрәтмәгән икән? Бала тәрбияләүдә зур әһәмияткә ия булган ул шигырь-җырлар күбебезнең әле бүген дә хәтерендә саклана булыр. Әни сүзе гомерлек бит ул!

*«Әни» диеп язып куйдым*
*Яңа яуган ак карга.*
*Таптамагыз!*
*Һич ярамый*
*«Әни» сүзен таптарга.*

Озак еллар буе мәктәп, китапханәләрдә эшләгән, балалар дөньясын бөтен күңеле-җаны белән аңлап-тоеп, яратып язган Зәкия Туфайлова шигырьеннән әлеге юллар.

Зәкия Туфайлова 1907 елның 29 январендә Башкортстанның Кушнаренко районы, Илморза авылында мулла гаиләсендә туа. 1930 елда Свердловск шәһәренең педагогика техникумын тәмамлый. Беренче шигырьләре Уфада «Игенчеләр атнасы» дигән газетада басыла. 1954—1977 еллар З. Туфайлова иҗатының иң актив чоры, бу елларда аның унбер китабы басыла («Уйла, тап», «Тапкыр бул!», «Әни сүзе» һ. б.). Зәкия Туфайлова шигъриятенең асылы—бала психологиясен бөтен җанлылыгы, тулылыгы белән ачып бирә алуында, балаларча самими сурәтли белүендә. Шунамы, әлеге шигырьләр инде вафатына күп еллар узган булса да, бүгенге көндә дә үзләренең мәгънәви төсмерләрен җуймаганнар, буыннар алмашынса да тәрбияви әһәмиятен югалтмаганнар, киресенчә, яңа буын балалар шагыйрьләре тууга да зур этәргеч, үрнәк, өлге була алганнар.

Зәкия Туфайлова 1971 елда СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә.

1977 елның 11 гыйнварында Казанда вафат була.

### ФӘННЕҢ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ КИҢӘЯ

Татарстан Фәннәр академиясенең гомуми җыелышы булып узды. Анда сүз житештерүне арттыруда фәнни эшләнмәләр, беренче чиратта, инновацион технологияләр төп таяныч булырга тиешлеге әйтелде.

Галимнәр алдында Президент М. Шәймиев чыгыш ясады. «Без үз икътисадыбызның йөзен нык үзгәртергә һәм аның үсеш тизлеген дә арттырырга телибез»,—диде Президент. Әлеге үсешнең умыртка сөяген нефть химиясе комплексындагы зур мөмкинлекләр тәшкил итәргә тиеш.

Президент М. Шәймиев фән тармагын финанслау турында да әйтеп узды. «Ул, беренче чиратта, без көткән нәтиҗәне бирергә тиеш»,—диде республика җитәкчесе. Әмма гуманитар фәннәргә игътибар кимиячәк, дигән сүз түгел бу. Аларга да бюджеттан тиешле сумма биреләчәк һәм шул ук вакытта аннан кирәкле нәтиҗә дә көтеләчәк, әлбәттә.

Шулай итеп, республика галимнәренә, барыннан да элек, гамәли фәннәр өлкәсенә зур бурычлар йөкләнде. Фәннәр академиясе президиумының вәкаләтләре дә киңәя: ана ведомствоара комиссияләр башкарган күп бурычларны хәл итәргә туры киләчәк. Шул сәбәпле, президиумның составында башкарма хакимият вәкилләре, вуз ректорлары һәм эре сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре дә булачак.

М. Шәймиев мәктәпләрдә православие нигезләрен укытуга карата да үз фикерен ачык итеп әйтте. Күпмилләтле республикада мондый нәрсә булмаячак, диде ул.

Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында Президент аппараты җитәкчесе Ю. Камалтынов, Премьер-министрның беренче урынбасары Р. Моратов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова катнашты.

### ЯШЬЛӘРНЕҢ ОЛЫ ҖЫЕНЫ

«Казан» милли мәдәният үзәгендә Бөтендөнья татар яшьләре форумы үтте. Бирегә, дөньяның төрле төбәкләреннән туып, хәзерге көндә Казан югары уку йортларында белем алучы татар яшьләре җыелган иде. Форумның төп максаты—татар яшьләрен бергә җыеп, аларга ана телләрендә аралашуга мөмкинлек бирү иде.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров әйтүенчә, быел оешманың зур тырышлыгы белән, Россия төбәкләреннән—282, БДБ илләреннән—60, Кытайдан—32 милләттәшебез Казан югары уку йортларына укырга кергән.

Форумда Президент аппараты вәкиле А. Әхтәриев, Россия татарларының федераль милли-мәдәни автономиясе рәисе Р. Вәлиев, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгының төбәкләр белән эшләү бүлеге мөдире А. Марова, язучы Р. Батулла, «Кардәшлек» җәмгыяте рәисе Л. Әхмәтова, Татарстанның халык артисты Гөлзадә һ. б. катнашты.

### ЯҢА ЛАУРЕАТЛАРГА ЮЛ АЧЫК

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе комиссиясе 2007 елгы премияләргә дәгъва кылган эшләр кабул итә башлады.

Комиссиягә, киң җәмәгатьчелеккә танылып, илебез мәдәниятен һәм милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән күренекле әдәбият һәм сәнгать әсәрләре (сынлы сәнгать, музыка, театр, эстрада, цирк, кино, архитектура һәм шәһәр төзелеше), шулай ук әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә күренекле фәнни тикшеренүләр тәкъдим ителә ала. Эшләрне министрлыклар һәм ведомстволар, дәүләт, иҗтимагый һәм иҗат оешмалары, фәнни, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре, югары уку йортлары 2007 елның 15 февраленә кадәр тәкъдим итәргә мөмкин.

Документларны тәкъдим итү һәм тапшыру белән бәйле мәсьәләләр буенча Мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Адресы: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт, 109 һәм 110 нчы бүлмәләр. Телефоннар: 264-73-97, 264-73-98, 264-75-19.

### ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Әүвәл идарә рәисе Илфак Ибраһимов соңгы ай дәвамында башкарылган эшләр турында сөйләп үтте. Аннары утырышта катнашучылар, Президентыбыз Указы нигезендә 2007 елның Татарстан Республикасында Хәйрия елы дип игълан ителүе уңаеннан, Хәйрия елын әзерләүнең һәм уздыруның төп чаралары планына Язучылар берлеге тәкъдимнәрен тикшерделәр. Идарә утырышында шулай ук киләсе елда республика күләмендә үткәреләчәк әдәби-мәдәни чаралар планы да каралды. Идарә утырышының көн тәртибенә 2007 ел өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар күрсәтү

мәсьәләсе дә кертелгән иде. Әлеге югары бүләккә, «Иске сәгать дөрес йөри» (Татарстан китап нәшрияты, 2004), «Ядкарь» («Рухият» нәшрияты, 2005) исемле проза һәм җырлар китаплары өчен күренекле язучы Разил Вәлиев бертавыштан тәкъдим ителде.

Утырышта каләм ияләре Камил Тангалычев (Саранск), Илшат Вәлиулла (Мари Эл, Волжск) һәм Мирсәй Гариф (Башкортстан, Октябрьск) Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды.

### ЯЗУЧЫЛАР МАМАДЫШТА

2006 елның ноябрь ахырында Мамадыш районында татар әдәбияты көннәре булып узды. Әлеге бәйрәмдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендә каләм әһелләре делегациясе катнашты. Аның составында Татарстанның халык язучысы, Дәүләт Советы депутаты Туфан Миннуллин, Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, шагыйрь, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров, язучылар—«Идел» журналының баш мөхәррире Нәбирә Гыйматдинова, «Салават күпере» журналының баш мөхәррире Зиннур Хөснияр, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире Вахит Имамов, «Сүз» нәшриятының мөхәррире Шаһинур Мостафин, шагыйрә, «Ватаным Татарстан» газетасының бүлек мөхәррире Фирүзә Жамалетдинова, әдәбият галиме, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Әлфәт Закиржанов бар иде.

Кунакларны Казан—Мамадыш юлы чигендә муниципаль район башлыгы—район Советы рәисе Рөстәм Кәлимуллин, район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Шамил Хәсәнов һ. б. рәсми кешеләр каршы алды.

Каләм әһелләре иң әүвәл Кече Кирмән урта мәктәбендә оештырылган тантаналы очрашуда катнашты. Әдәбият көннәренең нәкъ менә бирегә башланып китүе шуның белән аңлатыла: бу авылда танылган шагыйрь һәм прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ф. Хөсни исемендәге әдәби бүләк иясе Рафаил Газизов яши, һәм ул күптән түгел «Бүләгем» исемле китабы («Мәгариф» нәшрияты), гомумән, балалар әдәбиятын үстерү өлкәсендәге уңышлары өчен Х. К. Андерсен исемендәге Халыкара дипломга лаек булды. Мәртәбәле бүләк алу уңаеннан аны хөрмәтләү әдәбият бәйрәме программасына махсус рәвештә кертелгән иде. Шуңа күрә Рафаил Газизов иҗаты үзе директорлык иткән мәктәптә дә, район мәдәният йортында да, башка авылларда оештырылган очрашуларда да игътибар үзәгенә алынды.

Мамадыш шәһәре мәдәният йортында үткәрелгән тантаналы кичәдә муниципаль район башлыгы—район Советы рәисе Рөстәм Кәлимуллин һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов сәламләү сүзе белән чыкты. Үз чыгышларында алар Әдәбият һәм сәнгать елы кысаларында уздырыла торган әлеге чараның чын мәгънәсендә мәдәни бәйрәмгә әверелүен, танылган каләмдарларның һәркайда да көтеп алынуын, мондый әдәби-музыкаль очрашуларның һәр ике як өчен дә гаять файдалы булуын искәртеп үттеләр.

Әдәбият көннәре программасы шактый тыгыз төзелгән иде, ике көн эчендә районга килгән язучылар, аерым төркемнәргә бүленеп, Кече Кирмән, Түбән Яке, Урта Кирмән, Кече Сөн, Түбән Ушмы, Тәкәнеш, Җөри, Көек-Ерыкса, Көмешкүл, Шәдчә, Дүсмәт авылларында булырга өлгерделәр. Мәдәният йортларында, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында үткәрелгән очрашулар халык күңелендә онытылмаслык тәэсирләр калдырды.

### «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ»НЫҢ АЛТЫНЧЫ ОЧЫШЫ

17-19 ноябрьдә Биектау районында урнашкан «Байтик» лагеренда «Иделем акчарлагы-2006» яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау өлеше уздырылды.

Быелгы алтынчы бәйге Габдулла Тукай музеена сәяхәт белән башланып китте. Берочтан бәйгенең ачылу тантанасы да шунда узды. Анда бәйгенең жюри рәисе Газинур Морат, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Әлфәт Закиржанов, язучы Галимҗан Гыйльманов, танылган җырчыбыз Мингол Галиев чыгыш ясады. Ә кичен «Байтик» лагеренда яшь язучылар белән очрашырга күренекле шагыйрьләр Равил Фәйзуллин белән Рәдиф Гаташ килде.

Бәйгенең икенче көнендә остаханәләр эше башланды, һәр конкурсантның иҗат җимешен җентекләп тикшергән жюри әгъзалары әсәрләргә анализ ясады. Драма әсәрләре язучылар белән Рәдиф Сәгъди, Әлфәт Закиржанов, шигырь язучылар белән Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Фәйрүзә Мөслимова остаханә уздырды. Чәчмә әсәр язучылар Газинур Морат, Вакыйф Нуриев, Марат Закир, Галимҗан Гыйльманов остаханәсендә «сабак» алды. Аннары язучылар Рифә Рахман, Рашат Низамиев, Әлфәт Закиржанов, Равил Рахмани, Нәҗибә Сафина, Аманулла аерым жанрлар буенча мастер-класслар үткәрде.

Соңыннан бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булды. Шигърият буенча беренче дәрәҗәле диплом—Ландыш Әбүдәровага, икенче дәрәҗәле диплом—Илдар Фазлетдиновка, өченче дәрәҗәле диплом Ләйсән Якупова-Гатауллинага тапшырылды. Чәчмә әсәрләр буенча беренче дәрәҗәле дипломга—Рөстәм Галиуллин, икенче дәрәҗәле дипломга—Таңгөл Харрасова, өченче дәрәҗәле дип-

ломга Айдар Жамалиев лаек дип табылды. Драма әсәрләре буенча Лилия Закирова—беренче, Раилә Мөхсинова икенче дәрәҗәле дипломга ия булды. Болардан тыш Эльвира Һалиева, Ләйсән Фәтхетдинова, Алинә Бикмуллина, Айсылу Имамиева, Александр Долговка кызыксындыру бүләкләре бирелде. Римма Шәехова «Иделем акчарлагы—2006» бәйгесенең махсус бүләгенә лаек булды. Бәйгенең төп бүләге—Гран-прига Рифат Сәлахов (поэзия) һәм Айдар Зәкиев (проза) лаек булды.

### ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

21 ноябрьдә Парламент үзегенең яна бинасында Татарстан Дәүләт Советы тарихы музеен ачу тантанасы булды. Аның экспозициясе Татарстанда XX гасырдан башлап бүгенгә кадәр парламентаризмны үстерүгә багышланган.

Музейны ачу тантанасында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һ. б. рәсми кешеләр катнашты.

Музейда 1906—1917 елларда патша Россиясендә Дәүләт Думасы, аның мөселманнар фракциясе һәм Казан губернасыннан сайланган депутатлар эшчәнлеге, совет хакимиятенең беренче елларында Идел-Урал төбәгенең милли дәүләт төзелеше проектлары, Татарстан АССР төзелү, Дәүләт Советын формалаштыру һәм аның эшчәнлеге турында сөйләүче меңнән артык экспонат бар. Алар Россия һәм Татарстан парламентчылары кабул иткән иң мөһим карарларны хәтердә яңарталар, Татарстанның илдә федерализмны үстерүгә керткән өлешен чагылдыралар.

Фәрит Мөхәммәтшин музей ачу тантанасында ясаган чыгышында, үзләренең тарих музее булган төбәк парламентлары күп түгел, дип билгеләп үтте. Ул экспозицияне оештыруда турыдан-туры катнашкан кешеләргә һәм учреждениеләргә рәхмәт белдерде.

### СӘХНӘДӘ—«ШАГЫЙРЬ МӘХӘББӘТЕ»

18 ноябрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Шагыйрь мәхәббәте» дип исемләнгән операның премьерасы булды. Композитор Резеда Әхиярова белән шагыйрь Ренат Харис тарафыннан иҗат ителгән әсәр халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган.

Тукай партиясен Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Санкт-Петербургның Мария театры солисты Әхмәт Әһади, Зәйтүнәне Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Венера Ганиева башкарды. Фатих партиясендә—Татарстанның халык артисты Мөнир Якупов, Шүрәле партиясендә Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов иде. Операның музыка җитәкчесе һәм дирижеры—Виктор Соболев (Санкт-Петербург), ә спектакльне сәхнәгә Мәскәү Дәүләт Зур театры режиссеры Михаил Панджавидзе куйган.

Татар опералары бездә сирәк куела. Шуна күрә яңа операның тууы мәдәни тормышыбызның күренекле вакыйгасы саналырга хаклы.

***

Премьера көнне опера авторы Резеда Әхиярованы 50 яшьлек юбилее белән Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тәбрикләде.

—Резеда Әхиярова үзенчәлекле, моңлы җырлары, симфонияләре белән Татарстанда, Россия Федерациясендә генә түгел, татар яшәгән һәр төбәктә билгеле шәхес,—диде ул.—Опера иҗат итеп, ул үзенең шәхси бәйрәмен һәммәбез өчен дә зур тантанага, мәртәбәгә әверелдерде. Резеда Әхиярова опера иҗат иткән икән, димәк, аның иҗат мөмкинлекләре әле зур, дип уйларга нигез бар. Резеда ханымнан без Татарстан, Россия һәм, гомумән, дөнья музыка мирасын баетырлык яңа әсәрләр көтеп калабыз...

Президентыбызның Указы нигезендә композитор Резеда Әхияровага һәм «Шагыйрь мәхәббәте» операсында—Тукай, Н. Җиһановның «Алтынчәч» спектаклендә Җикмәргән рольләрен башкарган опера җырчысы Әхмәт Әһадигә «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Резеда Әхиярованы Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин, Татарстан рәссамнары исеменнән рәссам Фәридә Хәсьянова тәбрикләде.

### ЯҢАРТЫЛГАН ТУКАЙ МУЗЕЕ

Габдулла Тукайның әдәби музеенда аның ачылуына 20 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Ул 1986 елда Г. Тукайның 100 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә ачылган иде. Соңгы елларда музей фонды яңа экспонатлар белән баетылды. Ә бу үз чиратында юбилей елында реэкспозиция үткәрергә форсат бирде. Бүгенге көндә эшләп килүче экспозиция дүрт залда бүленеп урнашкан.

Музейның 20 еллыгы уңаеннан уздырылган бәйрәм кичәсендә реэкспозициянең фәнни җитәкчесе, филология фәннәре докторы Н. Хисамов, консультантлары—филология фәннәре докторлары М. Әхмәтҗанов, З. Рәмиев, фән эшлекләре, шагыйрь-язучылар, рәссамнар, музыкантлар катнашты. Алар әдәби музейның беренче директоры Госман Хәбибуллинны җылы хисләр белән искә алды, гомерен мәдәнияткә багышлаган, бик күп музейларны төзүдә башлап

йөргән Мөжип Низамиевны тәбрикләде. Музейның бүгенге көндә житәкләүче шагыйрь Рәмис Аймәткә һәм музейнын күп кенә хезмәткәрләренә Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Милли музее исеменнән Мактау кәгазьләре тапшырылды. Бәйрәмдәр музейны Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең сәнгать житәкчесе, мәшһүр жырчыбыз И. Шакиров, А. Фәйзрахманов житәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле тәбрикләде. Анда шулай ук Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## УРДАЧЫ ГАЛИМ ХӨРМӘТЕНӘ

Тарих фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт университеты профессоры Герман Федоров-Давыдовның исеме илебез һәм дөнья галимнәренә яхшы таныш. Ул—15 монография, 200дән артык гыйльми мәкалә авторы, күпсанлы шәкертләрнең остазы. Галим 40 елдан артык Түбән һәм Урта Идел буйларында археологик тикшеренүләр алып барды, аеруча Алтын Урданы өйрәнүгә үзеннән зур өлеш кертте. Юкка гына аны «Алтын Урда археологиясенең атасы» дип йөртмиләр. Галимнең шәкертләре арасында Әзһәр Мөхәммәдиев, Альберт Борһанов кебек татар археологлары да бар.

Мәскәүдә Россия Фәннәр академиясенең Археология институты, Дәүләт тарих музее һәм Мәскәү дәүләт университеты Г.Федоров-Давыдовның тууына 75 ел тулу уңаеннан, «Евразия зонасында шәһәр һәм дала» дигән темага халыкара фәнни конференция үткәрде. Анда Мәскәү, Санкт-Петербург, Краснодар, Саратав, Төмән, Киев, Будапешт, Баку һәм башка шәһәрләрдән килгән күренекле археологлар белән бергә, Казан галимнәре дә (Р. Фәхретдинов, Ә. Мөхәммәдиев, Е. Казаков, Х. Миннегулов, К. Руденко, А. Борһанов, Д. Вәлиева) катнашты, Алтын Урда, Болгар, рус, чит илләр тарихына, археологиясенә, сәнгатенә кагылышлы 100дән артык доклад тыңланды. Дәүләт тарих музеенда үткән пленар утырышта Казан дәүләт университеты профессоры Хатыйп Миннегулов доклад белән чыкты. Ул Алтын Урда әдәбиятының байлыгы, аның татар сүз сәнгате тарихында гаять мөһим роль уйнавы, бу дәүләтнең төп дәвамчылары, варислары хәзерге татарлар булуы хакында сөйләде.

## КАРТАЙМАС ӘДИП

«Казан» милли мәдәният үзәгендә танылган язучы, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Рафаэль Мостафинга 75 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды. Патриот-шагыйрь Муса Жәлилнең исемен, иҗатын халыкка кайтаруга зур өлеш керткән, аның тормыш һәм көрәш юлын эзлекле өйрәнгән эзтабар-язучы, танылган тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинны дәүләт житәкчеләре, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, ижатташ дуслары чын күңелдән тәбрикләде.

Язучыга тәбрик сүзен, иң элек, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова әйтте һәм Президент М. Шәймиевнең Рәхмәт хатын укыды. «Рафаэль Мостафин—талантлы журналист, педагог, ижади эшчәнлеген М. Жәлилнең тормыш юлын һәм ижатын өйрәнүгә багышлаган кеше,—диелә Рәхмәт хатында.—Аның бүген дә актив тормыш эшчәнлеге алып баруы, матбугаттагы кызыклы язмалары, белемен һәм йөрәк көчен татар халкына бирә алуы шатландыра».

Р. Ратникова юбилярга Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшиннын Рәхмәт хатын да тапшырды. Барлык каләмдәшләре исеменнән әдипне Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов котлады: «Әниегез кебек үк, 100 яшьтән дә артыграк яшәвегезне телим!»—диде ул Р. Мостафинның ижат эшчәнлеген югары бәяләп.

Галимнәр, сәнгать әһелләре исеменнән юбилярны академик М. Госманов, Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры артистлары, танылган жырчылар Р. Маликов, Г. Сафиуллина, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты И. Мөхәммәтгалиев һ. б. сәламләде.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИЖАТ БӘЙРӘМЕ

С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында күренекле шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый исемендәге бүләк иясе Әхмәт Рәшиткә 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

Әлеге кичә шагыйрьнең «Колшәриф» исемле тарихи поэмасы буенча эшләнгән композицион тамаша белән башланып китте. Аннары юбилярның аерым әсәрләре, аның шигырьләренә язылган популяр жырлар башкарылды. Алар Әхмәт Рәшитнең ижатына бирелгән бәяләмәләр һәм тәбрикләүләр белән аралашып барды. Чыгышларда шагыйрьнең һәрвакыт илкөнне борчыган гамь-ваем белән яшәве, шигъри әсәрләрендә дә, публицистикада да тынгысыз әдип булып калуы уртак фикер буларак әйтелде.

Кичәдә Премьер-министр Рөстәм Миннеханов, шулай ук аның урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева котлауларын мәдәният министрының беренче урынбасары Айдар Гайнетдинов ирештерде.

Әдәби-музыкаль кичәдә бәйрәмдарны аның каләмдәшләре—Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Буа якташлык жәмгыяте әгъзалары, шулай ук муниципаль район житәкчесе исеменнән юбилярның авылдашлары тәбрикләде. Шагыйрьнең әсәрләрен күренекле артистлар Ринат Тажетдинов, Да-

ния Нурлы, Иллус Әхмәтжанов, Хәлим Җәләй, Фәнис Җиһанша, Илтәзәр Мөхәммәтвәли, ә җырларны Шамил Әхмәтжанов, Лидия Әхмәтова, Мәсгут Имашев, балалар ансамбле һ. б.лар башкарды. Кичәне Зөһрә Шакирҗан алып барды.

### ЯЗУЧЫ РӨСТӘМ КУТУЙНЫ ОЛЫЛАУ

Күренекле шагыйрь һәм прозаик Рөстәм Кутуйның 70 яшьлегенә багышланган әдәби-музыкаль кичәнең Казан Кремлендәге Бөек Ватан сугышы музеенда үткәрелүе бик табигый килеп чыкты, чөнки биредә аның әтисе—фронтовик язучыбыз Гадел Кутуйга кагылышлы экспонатлар да урын алган, һәм, әлбәттә, тантана барышында, үзен лаеклы дәвам иттерүче улы белән бергә, атаклы «Таптырылмаган хатлар» авторы телгә алынды.

«Мин Казанга килгәч, урамда очраклы рәвештә Рөстәм Кутуйны очраттым,—дип башлады үзенең тәбрикләү сүзен Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева.—Менә шул чакта уйлап куйдым: башкала шуның өчен дә башкала инде ул—монда күренекле каләм әһелләрен күрергә мөмкин!» Юбилярның иҗаты һәм шәхесе турында ихлас бәяләү сүзләрен әйткәннән соң, Зилә Вәлиева Татарстан Президентының бәйрәмдарга юлланган Рәхмәт хатын укыды, әдипнең татар шагыйрьләре әсәрләрен русчага тәрҗемә итүдә зур өлеш кертүен дә искә төшереп, киләчәктә Рөстәм Кутуйның татарча китабын чыгару зарурлыгы хакында да искәртеп үтте.

Бик тә үзенчәлекле рәвештә оештырылган очрашуда Рөстәм Кутуйны каләмдәшләре—Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Әлфәт Закирҗанов, Владимир Корчагин, Нонна Орешина, Зиннур Мансуров, Ольга Левадная, «Казан» журналының баш мөхәррире Юрий Балашов һ. б.лар тәбрикләде.

Әдәби-музыкаль кичәне шагыйрә Лилия Газизова алып барды.

### МИЛЛИ МУЗЕЙДА ӘДӘБИ КИЧӘ

Татарстан Милли музееның әдәби салонында чираттагы мәҗлес булып узды. Ул танылган шагыйрә Салисә Гәрәеваның «Йолдыз янгырлары» исемле яңа шигырьләр җыентыгын тәкъдир итү уңаеннан узды.

Шагыйрәнең тормыш юлы һәм иҗаты хакында музей хезмәткәрләре Флера Дәминова һәм Вакыйф Нуруллин, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире шагыйрь Зиннур Мансуров һәм башкалар сөйләде. Салисә Гәрәева үзенең шигырьләрен укыды. Кичәдә шулай ук танылган җырчылар Георгий Ибушев, Рәшит Сөләйманов, баянчы Кирам Сатиев башкаруында Салисә Гәрәева шигырьләренә язылган җырлар, халык җырлары һәм көйләре яңгырады. Милли музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова мондый кичәләрнең даими үткәреләчәген белдерде. Милли музейда шагыйрәнең тормыш һәм иҗат юлын яктырткан күргәзмә дә оештырылган иде.

### РАФАЭЛЬ СИБАТНЫ ИСКӘ АЛУ

3 ноябрь көнне күренекле каләмдәшебезнең туган җирендә язучыны искә алу кичәсе үткәрелде. Ул Түбән Шөн авылы мәдәният йортында уздырылды. Анда Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Фоат Галимуллин, Рафаэль Газизов, Вахит Имамов, Шаһинур Мостафин һәм Хөсәен Вәлиәхмәтов катнашты. Язучылар һәм Рафаэль Сибатның Алмаз исемле улы, оныклары, туганнары, укытучылары һәм сабакташлары тамашачыларга үзләренең истәлекләрен, хатирәләрен сөйләделәр, язучының каберен зиярәт кылдылар.

### ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

Хәзерге заман әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеше, Татарстан хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан-Казань» журналы бүлек мөхәррире **Кутуев Рөстәм Гаделша улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы манзара.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Илсөяр Иксанова**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде: 26 ноябрьдә, озакка сузылган каты авырудан соң, Татарстанның халык шагыйре **Мөдәррис Әгъләм** вафат булды.

Мөдәррис Зөфәр улы Әгъләметдинов 1946 елның 13 октябрендәТатарстанның Зәй районы, Биш Субаш авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килгән. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән. 1968 елда урта мәктәптә тарих укытучысы булып эшли башлаган, шуннан соң Чаллы халык театрының режиссер ярдәмчесе булган. 1974 елда Казанга күченгәч, әдәби иҗат белән профессиональ төстә шөгыльләнә башлаган.

Мөдәррис Әгъләмнең тәүге шигырьләре 1959 елда «Яшь ленинчы» газетасында басылган. 1970 елда «Кыңгырау» исемле беренче китабы дөнья күргән. Аның шигырьләре һәм поэмалары татар халкының рухи бөеклеген раслый. Туган җиргә, аның тарихына мәхәббәт, киләчәгенә үткен караш, замандашларының эчке дөньясы белән кызыксыну—шагыйрь иҗатында төп урынны әнә шулар алып тора. Татар әдәбияты классиклары Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, күренекле башка шагыйрьләр һәм язучылар Мөдәррис Әгъләмнең иҗатын югары бәяләде. Ул чын мәгънәсендә халык шагыйре булды. Аның шигъри юллары миллионлаган укучылар йөрәгенә үтеп керә алды. Гадилеге, кояш кебек якты таланты аңа халык арасында зур танылу китерде.

М. Әгъләмнең иҗат уңышлары югары бәяләнде: ул «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә, «Мин әйттем» һәм «Киләчәккә кайту» дигән китаплары өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. 2006 елда Мөдәррис Әгъләмгә Татарстан Республикасының халык шагыйре дигән мактаулы һәм дәрәҗәле исем бирелде.

Мөдәррис Әгъләмнең якты истәлеге күңелләребездә озак саклаunion.

**М. Шәймиев, Р. Миңнеханов, Ф. Мөхәммәтшин,**
**Ю. Камалтынов, З. Вәлиева, И. Метшин, Р. Фәрдиев,**
**И. Ибраһимов, Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин.**

***


28 ноябрьдә җәмгыятьчелек Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Мөдәррис Әгъләмне соңгы юлга озатты. Хушлашу җыены С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында узды. Аны Татарстан Премьер-министры урынбасары–мәдәният министры Зилә Вәлиева ачты һәм алып барды.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында шагыйрьнең иҗатына һәм шәхесенә зур бәя бирде.

Шагыйрьнең каләмдәшләре Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов, якташы, Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары Госман Мухамов Мөдәррис Әгъләмнең иҗатына һәм шәхесенә карата ихлас сүзләрен әйттеләр.

Мөдәррис Әгъләмнең җәсәде Казанның Татар зиратында җирләнде.

# Яңа китаплар




**Шәриф Хөсәенов:** Повесть, очерклар, хатирә-истәлекләр, әңгәмәләр, хатлар (төзүче һәм кереш сүз авторы Р. Юсупова)—Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.—407 б. Тиражы—3000 данә.

Үзенчәлекле бу китап мәшһүр драматургның «Мәхәббәт сагышы» исемле повесте белән ачыла. «Ярату һәм соклану» бүлегендә әдип үзе исән чакта аның турында чыккан мәкаләләр (Р. Фәйзуллин, Т. Миннуллин, Б. Камалов), аның белән әңгәмәләр (Р. Юныс, Р. Юсупова) урын алган. «Юксыну» бүлегендә истәлек-хатирәләр тупланган (А. Гыйлаҗев, Ф. Яруллин, И. Юзеев, К. Тимбикова, М. Маликова, Ш. Закиров h. б.). Ш. Хөсәеновның ил житәкчеләренә, газета-журнал редакцияләренә юллаган хат-мөрәҗәгатьләре аерым бер бүлекне тәшкил итә.

Китап Ш. Хөсәеновның шәхси тормышына һәм аның әсәрләре буенча куелган спектакльләргә кагылышлы фоторәсемнәр белән бизәлгән.




**Рифә Рахман.** Айлы күлдәвекләр: Хикәяләр һәм кыйссалар / Рифә Рахман.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.—190 б. Тиражы—2000 данә.

Әдәбият сөючеләргә шагыйрә буларак таныш Рифә Рахманның прозасына да шигърилек, аһәнле яңгыраш, отышлы әдәби детальләр, кызыклы күзәтүләр хас.

Хикәяләр һәм кыйссалар дип ике кисәктән торган бу китапка тупланган әсәрләрнең күпчелеге—үсмерләр, яшь гаиләләр тормышына багышланган хикәяләр, кыйссалар һәм җитмешенче-сиксәненче елларда барган реаль вакыйгаларны авторның иҗади хыялы белән кушып яктырталар, шуңлыктан аларда яшьлек романтикасына, мәхәббәткә урын мул бирелгән.



Илсөяр Иксанова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)